КАЗАН УТЛАРЫ
www.kazanutlary.ru
ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР
Гәрәй РӘХИМ. Мин – мине югалттым... *Шигырьләр*. ....3
Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Гөләйза. *Тарихи роман*. ....8
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Дөньялыкта кылган сәфәрем... *Шигырьләр*. ....84
Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Хисләремдә иркле мин... *(Фәүзия Солтан шигъриятенә күзәтү)*. ....114
Фәүзия СОЛТАН. Тоясы килә яңгыр тамчысын... *Шигырьләр*. ....116
Мәдинә МАЛИКОВА. Татлы гыйшык җимеше. *Хикәя*. ....118
Фарсель ЗЫЯТДИНОВ. Әгәр дә бу кеше вафат булса... *Новелла*. ....135

«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ
Әхтәм ЗАРИПОВ. Күпер. *Повесть*. ....88

ЯҢА ИСЕМНӘР
Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ. Күзләрдән юату эзләмә... *Шигырьләр*. ....131
Райнур ӘГЪЛӘМЕТДИНОВ. Чат. *Хикәя*. ....140
*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....149

ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ
Абдулла АЛИШ. Тоткынлыктан кайткан шигырьләр. ....151

ЮБИЛЕЙЛАР
Фирдәвес ХУҖИН. Гали зат. *(Рүзәл Юсуповка 80 яшь)*. ....155

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ
Зиннур МАНСУРОВ. Җанны көйгә салу. ....162

ТАРИХ
Әхмәдһади Максуди мәкаләләре *(Ленар Гобәйдуллинның кереш сүзе белән)*. ....170
*Безнең календарь:* Вера Минкинаның тууына 100 ел. ....176
*Юмор-сатира:* Илдар Хәйруллин. *Юморескалар*. ....177

АК ҖИЛКӘН
Алинә БИКМУЛЛИНА. *Хикәяләр*. ....179

Уены-чыны бергә. ....188
«Казан утлары» архивыннан. ....160
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).


✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
✆: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.08.2018, график буенча 29.08.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-2243. Тираж 4167.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел



Гәрәй
Рәхим

# МИН – МИНЕ ЮГАЛТТЫМ...

## Минем әткәй

*Әти исән чакта язылган шигырь*

Минем әткәй иртә бөкерәйде,
Чәч-сакалы иртә агарды.
Күп вакытта бушый алмады ул
Кырып йөрергә дә аларны.

Булды вакыт,
        сабан сөрә иде,
Ә чоланда торды мылтыгы.
Булды вакыт,
        урман кисә иде,
Яңа чабата да тукымый.

Шәһәр өчен нигез казыган ул,
Кышкы туңны чокып лом белән.
Вокзалларда вагон бушаткан ул,
Күпме таш кискәндер кул белән.

Татыды ул ачлык-суыкны да,
Күтәрде ул бөтенесен дә.
Узган еллар...
        Авыр, усал еллар –
Әтиемнең бөкересендә.

Гәрәй РӘХИМ (1941) – *Татарстанның халык язучысы; биш томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә чыккан күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Айбагар

*Бу шигырь минем шәхси карашларыма нигезләнеп язылды.*

Мәчет өстендәге айны
Алдан күргән төркиләр.
Айга багуны татарга
Керәшеннәр теркиләр.

«Ай багар...
Татар кешесе
Айга багар», – дигән ул.
Ярымайны олылаудан
Мөселманга туры юл.

Керәшен – сатлыкҗан, димә,
Бу – сүзе күңеле тарның.
Ул саклаган ай багарын,
Ярымаен татарның.

«Кояш» сүзен борынгылар
«Көн» диеп атаганнар.
«Айбагар»ны «көнбагыш» дип
Үзгәрткәннәр татарлар...

...Мәчет өстендә ярымай.
Кагылмасын ла ятлар! –
Айга багучы яисә
Ай багар кеше – татар!..

Менә шуннан керәшенне
Татардан куып кара...
«Керәшен – сатлык», – диген дә
Мәчет башына кара.

Күр, анда бит керәшеннәр
Саклап калган ярымай!
Ай багар – син, айга багар
Карт бабай һәм яшь малай!..

Кем саклаган ярымаен,
Ай багуын татарның?!.
Керәшен ул – сатлык, димә,
Бу – сүзе күңеле тарның...

## Шундый бер халәт

*Метаморфоза яки шагыйрь монологы*

Ә тән инде тәмам тузган… тузган:
Үпкә… бавыр… йөрәк… баш мие…
Әмма күңел әле япь-яшь егет,
Күңел әле һаман шул көе!

Аякларым авыр атласа да,
Рухым чаба һаман атлыгып:
Тояклары җирне дөпелдәтеп
Чабышларга чыккан ат кебек.

Күзләр күрми үзем язганны да,
Укый алмыйм мин үз китабым…
Күз алдымда, ләкин, йолдызлы күк,
Күңел иңли чиксез кыйтганы…

Сизәм… Сизәм…
Тәнем дигән җисми агачымның
Янып бетә торган ялкынын…
Тик чирләми, һаман сау-сәламәт
Шигырь яза торган акылым.

Тән картайды.
Моңа бер чара юк –
Күңел картаялмый интегә.
Карт тәнле бер бабай... әмма ләкин
Япь-яшь рухлы егет мин менә!..

## Мин кая?..

Яшьлегем дә үткән,
Бик еракка киткән.
Син дә юк янымда,
Тәүге сөйгән иркәм!..

Мәктәп елларым да,
Үткән юлларым да
Киткән... Ерак киткән...
Бүген бу дөньяда
Мин – мин түгел икән.

Карыйм зиратларга
(Мин һич үз итмәгән...).
Мин әле анда да
Юк...
        Барып җитмәгән.

Мин – мине югалттым.
Кая соң мин, кая?..
«Син – миндә, ямьсездә», –
Дип картлык елмая...

## Сырхаулар һәм сәламәтләр

*Шагыйрь, каләмдәшем Айдар Хәлимгә*

Айдар Хәлим ята больницада.
Мин дә шулай ятам больниста.
Мондый халәткә бик күнекмәгән,
Шигырь язарга тик без оста.

Гомер буе һәр күрешкән саен,
Гөрләп аралашу хас безгә...
...Кесә телефоны аша гына
Якынаеп була хәзергә.

Чаллы белән Казан арасында
Бара безнең татлы әңгәмә.
Мин шагыйрьгә шундый сүзләр сөйлим,
Әйткән кебек әткәм-әнкәмә.

Ул да мине шулай юата да
Сырхавымны шактый киметә.
Ике чирле шагыйрь әнә шулай
Юатышып кына көн итә.

Ә сәламәт затлар бер-берсенә
Шундый авыр сүзләр әйтәләр.
Талашалар, нидер бүлешәләр,
Берсен-берсе мыскыл итәләр.

Берсен-берсе мөмкин кадәр изеп,
Юкка чыгарырга телиләр.
Алар таза... Әмма бер-берсенә
Күтәралмас авыр теләләр...

...Без сырхаулар...
                Бу дөньяны көн дә
Каһәрләргә тиеш кешеләр
Бер-беребез белән бик мөлаем –
Ана белән бала ишеләр...

...Чаллы белән Казан арасында
Бара безнең татлы әңгәмә.
Айдар Хәлим белән без бит бүген
Охшаганнар угыл-әткәгә.

## Дусларга бер үтенеч

Дуадак каз кебек ялгыз калдым...
Дуслар мине ташлап киттеләр...
Алданган кыз кебек өнсез калдым...
Нигә инде болай иттеләр?!.

И дусларым!
Мин бит сезнең өчен
Җирдән күпме чәчәк эзләдем.
Сезнең өчен күпме куандым мин,
Күргәч күктә йолдыз эзләрен.

Сезнең өчен будым елгаларны,
Сезнең өчен кала төзедем.
Бары сезгә җылы булсын, диеп,
Салкыннарда күпме өшедем.

Шәраб эчсәм – эчтем сезнең өчен,
Сез шат булсын өчен шаярдым.
Кирәк булса, сезгә иңем куйдым,
Кирәк икән, үзем таяндым.

Кулым белән казып чишмәләрнең
Арттырдым мин салкын суларын.
Сезгә чиста һава бирер өчен
Күп вакытта ялкын суладым.

Кирәк булса, мәгез, гәүдәмне дә,
Тик җанымны читкә типмәгез.
Ялгышларым булса, йә, кыйнагыз,
Ләкин
Ялгызымны ташлап китмәгез...

## Үткен Уткин

*Шагыйрь Егор Уткинга*

Уткин идең... Син тормышта
Шигырьдәй үткен идең.
Тик шигырьдә син бары тик
Егор һәм Уткин идең.

Сине Җәгүр, дип, иркәләп
Әйтсәк тә, Үткен, диеп,
Син һаман да кабатладың:
«Мин Егор Уткин!» – диеп.

Егор Уткин булып калдың
Илдә, иҗатта, җырда.
Син бернигә бирешмәдең
Илдә иң авыр чорда.

Бүген инде китапларың
Сине яклап яшиләр.
Үрнәк алсын иде синнән
Улың Игорьдай ирләр.

Без синең белән һаман да
Бөек шигъри дулкында.
Егор Уткин бүген дә бит
Безнең янда, ул – монда!..

## Ятимлек

*2015 елның 9 декабрендә, 74 яшемдә*
*18 яшьлек Кубрат улым дөнья куйды.*

Бабаңнан ятим калу бар,
Әбкәңнән ятим калу,
Атаңнан ятим калу бар,
Әнкәңнән ятим калу...

Бу ятимлекләр һәркемгә
Табигый килә торган,
Гомер итеп китә алар –
Өсләренә ак юрган!..

Безләргә табигый кайгы –
Алардан ятим калу...
...Гайре табигый фаҗига
Балаңнан ятим калу.

...Бу кайгымны кая куйыйм?!.
Юк, хаклык түгел бит бу –
Балаңнан ятим калу...
Улыңнан ятим калу…

## Дөнья шулай кушкан

*Беренче мәхәббәтемә*

Авылымда йөрсәм дә мин,
Йөрсәм синең авылда...
Аяз көнне йөрсәм дә мин,
Йөрсәм дә җил-давылда,

Үз илемдә йөрсәм дә мин,
Йөрсәм дә чит илләрдә...
Кая гына барсам да мин –
Гел син бит күңелләрдә...

...Вакыт безне аералмый,
Аералмый ераклык...
Мәхәббәттә без аймылыш,
Диеп уйлау дураклык!..

Без гел бергә, мәңге бергә –
Җаннарыбыз куш җан бит!..
Тәннәр генә гел аерым, –
Дөнья шулай кушкан бит...

Язмыш шулай кушкан бит...

Фәүзия
Бәйрәмова

# ГӨЛӘЙЗА

ТАРИХИ РОМАН*

**Өченче китап**

## «Гөләйзадан сорау алырга килгәннәр!»

Аллаһның рәхмәте белән, Гөләйзага биш ел буе кагылмадылар – судлар булмады, тикшерүләр сузылды, карар кабул ителмәде. Баштарак, бүген киләләр, иртәгә алып китәләр, дип борчылып көтсәләр дә, үзләре дә бу хәлләрне оныта башладылар, шулай бетәр, дип өметләнделәр. Әмма әлеге вакытлыча гына туктап тору, вакытлыча гына сузылу һәм вакытлыча гына тынычланулар булып чыкты. Халыкның дәррәү килеп чукындыруга һәм урыс авылларына күчерүгә каршы чыгуы, судларның мәкруһлар эше белән тулуы, бу татарларның төрле урыннарга туктаусыз язып торган хат-үтенечләре дә Гөләйза эшен бераз читкә этәреп торгандыр, мөгаен... Чистай морзалары да тик ятмадылар – старовер урыс байлары белән берләшеп (ә алар шәһәрдә күп иде), астан гына үз эшләрен эшләделәр. Кемнәргәдер «төртергә», кемнәрнедер «өркетергә» дә туры килде. Инде картайган, чак өстерәлеп йөргән Биләр побына да бармак янап алдылар, чөнки аны татарлар да, старовер урыслар да бер дәрәҗәдә яратмыйлар, кабул итмиләр иде.

Ишмөхәммәтнең үзенә каршы ачылган эш тә кайдадыр күмелеп калды, ул да үз вакытын көтә иде... Чистай төрмәсендә бергә яткан татарларның кайберләрен озакка сузмыйча, эшне тирәнгә җибәрмичә чыгардылар, Йорткүлдән Вәлиәхмәт һәм Биктимердән Миңнәхмәт авылларына кайтып китте. Ә менә Көекнекеләр белән алай җайлы гына булмады, чөнки алар хакимияткә каршы баш күтәргән булып саналалар һәм җәзасын алырга тиешләр иде. Башта аларны тиз генә моннан Казанга озаттылар, анда исә аяк-кулларына богау салып, суд та ясап тормыйча, Себергә, Турухан якларына сөргәннәр, Ишмөхәммәт моны соңыннан гына белде. Әлбәттә, авылларына барып, гаиләләренә ярдәм иттеләр, хәзер дә ярдәм итеп торалар, аларны урыс арасына күчерүдән дә саклап калдылар. Баш күтәргән татарларны Себердән кире кайтарту артыннан да йөриләр, әмма анысы катлаулырак булып чыкты, кәгазь эшенең очы-кырые күренми...

* Журнал варианты.

*Ахыры. Башы 7-8 нче саннарда.*

Ә тормыш ул барыбер үз юлы белән бара – синең судларыңа да, утларыңа да карамый, яхшыга өмет һәм яшәү дәрте барыбер барысын да җиңә, барысын да оныттыра. Гөләйзалар белән дә шулай булды – бугаздан алган тимер келәшчәләрен аз гына ычкындыруга, алар тагы үзләренчә яши башладылар. Намазын укыдылар, уразасын тоттылар, үсеп килә торган балаларына дин сабагы бирделәр... Кыр тутырып иген чәчтеләр, абзар тутырып мал асрадылар, урманда – умарта, шулар белән салымын түләделәр, тапканнары үзләренә җитеп барды: көзләрен урманнарда капчык-капчык чикләвек, җәйләрен әрәмәләрдән җиләк җыеп, кагыт киптерделәр; балыгын тоттылар, кеше кулына карап тормадылар. Моның өстенә, шыңгырдап торган юан бүрәнәләрдән яңа йорт җиткереп чыктылар, мунча салып куйдылар, теге елларда күргәннәр онытылды, инде кабат кайтмас, дип уйладылар... Шуңа күрә, башкалар кебек коры арбага төялеп, авылдан чыгып качасылары да килмәде, алар өчен Шонталадан башка тормыш юк иде...

Ул арада өченче балалары да туды, аңа авыл мулласы Гыйниятулла дип мөселманча исем кушты, бу хәл 1842 елның 16 августында булды. Тегеләре инде үсеп килә, аларның сабый чаклары бик шомлы, борчулы вакытка эләкте, шуңа күрә бу бала бигрәк тә тансык һәм кадерле иде. Кыр Шонталасыннан Ишмөхәммәт белән Гөлзада да күчтәнәчләрен төяп килеп җитте, үзләренчә, бәби туе ясап алдылар. Мәҗлескә Әхмәт мулла белән азанчы Мөхәммәтша, күршеләре – урыс авылына куылмый калган Миңнегәрәй белән Сәетгәрәй, Хәкимнең абыйсы сотник Әбуталип та килгәннәр иде.

Исем кушу кешечә, җиренә җиткереп башкарылды, бала туугa козгын кебек Биләр побы да килеп җитмәде, ул хәзер бу татар авылларына аяк басарга курка иде. Әмма алар өстеннән язуыннан туктамады, гел тамызып торды, инде татарларга гына түгел, аларны яклый дип шикләнгән урыс староверларына да бәйләнә башлады. Нәтиҗәдә, Чистай земство судьясы Савелий Аркадьечны, яше җитте, дип, этә-төртә, эштән җибәрделәр, ялга чыгардылар.

Ул китү белән, тау-тау өелеп яткан кәгазьләр арасыннан Гөләйзаның эшен табып алалар. Суд эшләре буенча өяз түрәсе Книгин яшерен рәвештә приставка мөрәҗәгать итә, бу хәл 1842 елның 12 августында була. Стряпчий Книгин әлеге эшнең 1838 елдан бирле тәмамланмыйча ятуын искә төшерә, эшне империянең юстиция министрлыгы һәм Казан губерна прокуратурасы күрсәтмәсе буенча тизләтүне сорый. Биләр өлкән рухание Михаил Лавровның шикаять-әләкләре анда да барып җиткән, димәк, Чистай земство судьясын да шул сәбәпле эштән читләштергән булулары мөмкин.

Чистай юлын таптаган Ишмөхәммәт боларның барысын да белмәсә дә, земство судьясының эштән китүеннән соң нидер сизенде. Ул үзе дә шулай ычкындырды – тагы казыналар, диде. Бу хәбәрне ишеткәч, Чистай морзалары да хәрәкәткә килде, үзләренең таныш урыс байлары-староверлар аша Гөләйза эшен кабат кузгатмаска, бастырырга тырыштылар. Ишмөхәммәт боларны Гөләйзага әйтеп тормады, бала бәхетеннән балкыган кызының кояшын сүндерәсе килмәде.

– Теге Биләр козгыны күренмиме, кияү? – дип сорады ул чәй табыны янында.

Хәким сүзнең Биләр побы турында барганын аңлады: «Юк, бабай», дип җавап бирде. Сүзне абыйсы Әбуталип дәвам итте.

– Үзе күренмәсә дә, этләрен җибәреп тора! Палисайлары кырык килеп

әйләнде авылны бу елларда, Гөләйза киленне дә күзәтәләр, теге качак татарларны да эзлиләр булыр...

– Алардан хәбәрләр юкмы?

– Каядыр Ырынбур якларына ук барып чыкканнар, казакъ-кыргыз далаларына киткәннәр икән, дип ишеттек.

– Бик ерак ара шул, кайтыр өчен китмәгәннәр инде алайса... Аллаһ аларга сабырлык бирсен! Сезгә бәйләнмиләрме соң, Миңнегәрәй энем?

– Башта анда-монда чакыртып азапланганнар иде, аннан туктадылар тагы... Әмма күзәтеп торганнары сизелә. Ул урыс авылларына көчләп күчергән татарларны анда да буйсындыра алмыйлар икән, дип ишеттек, бәлки, безгә шуңа кагылмыйлардыр, кая куйсыннар безне?

– Әйе, мин дә Чистайдан ишетеп кайттым – хөкүмәтнең ул эшләре барып чыкмаган, урыс арасына күчергән татарларның бер өлеше кайсы-кая качып беткән, кире үз авылларына кайтып яши башлаганнары да бар ди. Анда калганнары да урыска баш бирми икән, талашып-сугышып үзебезнең динне тотып яталар ди, әлхәмдүлилләһ! Хәзер теге заманнар түгел инде, татарны итек кунычына бөтәрләп тыгып куя алмаслар!

Ирләр, шулай дөнья хәлләрен сөйләшеп, мәҗлесне дәвам иттеләр, Әбуталип үзен борчып торган яңалык турында да әйтте.

– Бу көннәрдә мине дә Чистайга чакыртып, икенче стан приставы Гөләйза килен белән кызыксынды.

Барысы да, капкан ризыкларын йота алмыйча, Әбуталипка текәлделәр, чөнки бу алар өчен өр-яңа хәбәр иде.

– Әллә, Ходаем, тагы казына башладылармы икән? – диде Гөлзада, борчылып.

– Аларда безнең кайгы түгел хәзер, – диде Ишмөхәммәт, аңа җавап итеп. – Чистай судлары хәзер качаклар, баш күтәргән татарлар эше белән тулган...

– Алайса нигә Гөләйзаны сорадылар икән соң?

– Алар тикшереп торырга тиеш инде... Эшкә нокта куелмаган бит әле. Авыл халкыннан, поп-муллалардан сорау алырга тиешләр иде...

– Соң, аңа ничә ел үтте бит инде! Син нәрсә дип әйттең соң, Әбуталип кода?

– Авылда яшәп яталар, дидем, тагы нәрсә дип әйтим? Алар аны, качмаганмы, дип кызыксыналар, ахры... Тагы бер тапкыр кул куйдырдылар, Гөләйза киленне авылдан беркая да җибәрмәскә, дип...

– Ник боларны безгә әйтмәдең соң, эзи?

– Әйтеп ни мәгънә, энем? Мин барысын да күзәтеп торырга тиеш инде, авыл башлыгы бит, шуңа күрә кисәтәләр, дип уйладым...

– Чистай судьясы ни ди соң, бабай? Теге вакытта безнең яклырак булган иде кебек?

– Аны эштән җибәргәннәр инде, кияү, яше җиткән, имеш... Нәрсәдер сизенделәр, ахры, Исмәгыйль морзалар да шулай ди. Алар хәзер анда башкалар белән эш алып бара, борчылмагыз.

Бу хәбәрләрдән табынның бераз яме киткән кебек булса да, аны артык куертмадылар, чөнки инде шактый вакыт үткән, теге вакыттагы хис-тойгылар да сүрелә төшкән иде. Әхмәт мулла да тынычландырырга ашыкты.

– Аллаһ язмаган эш булмас, җәмәгать, алдан борчылып куймагыз! – диде ул, мәҗлес халкын юатырга тырышып. – Аллаһ әмереннән башка агачтан яфрак та өзелеп төшмәс! Бәндәләр белән дә шулай, аларның тәкъдирләре Раббыбызның көрсие астында саклана торган «Ләүхел-мәхфүз» дип аталган

Төп Китапта үзләре туганчы ук язылып куелган инде... Бу хакта Коръәни-Кәримнең «Хәдид» сүрәсендә, егерме икенче аятендә менә болай әйтелә: «Ләүхел-мәхфүз»дә (күк китабында) язылмыйча, ягъни, Аллаһ тәкъдир итмичә, җиргә дә, сезнең күңелләрегезгә дә бернинди бәла-каза, кайгы ирешмәс. Бу бәла-казаның булачагын белү Аллаһ өчен бик җиңелдер». Ягъни, тәкъдирнең яхшысы да, яманы да – Аллаһтан, тәкъдиргә ышану ул иман шартларының берсе булып тора. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһиссәлам әйтә: «Аллаһы Тәгалә күкләрне һәм җирне бар иткәнче 50 мең ел алдан кешеләрнең язмышларын язып куйган», ди. Аллаһ өчен вакыт дигән нәрсә дә, ара ераклыгы да юк, Ул үткәндәге һәм киләчәктәге барлык нәрсәләрне берьюлы күрә... Бәндә үзе дә белмәгәннәрне белә... Ул безнең алдыбызга сайлау мөмкинлеген куя: бер якта – хәләл, икенче якта – хәрам, кеше аны үз ихтыяры белән сайлап ала, Аллаһ безне мәҗбүр итми... Хәләл белән хәрамны, яхшы белән начарны аерып алу өчен, Ул безгә акыл биргән, гыйлем биргән, тумыштан ук иман биргән. Кешеләрнең җаны, рухы – Аллаһтан, әле туганчы ук, алар Аңа тугры булырга ант иткәннәр. Бу хакта Коръәни-Кәримнең «Маидә» сүрәсендә, җиденче аятендә менә ничек әйтелә: «Аллаһуның сезгә биргән нигъмәтләрен хәтерләгез! Һәм дөньяга килмәс борын Аллаһуга биргән гаһедегезне дә хәтерләгез! Аллаһ рухларны халык кылгач: «Әйә! Сезне юктан бар кылып тәрбияләүче мин түгелме?» – дигәч, «Әлбәттә, Син! Сүзеңне ишеттек, үзеңә итагать иттек», дидегез, шуны белегез! Аллаһудан куркыгыз, аңа гасый булудан сакланыгыз! Күкрәкләрдә булган нәрсәләрне Аллаһ, әлбәттә, белүче.» Шулай, җәмәгать, бөтен дөньясы сиңа каршы чыкса да, Аллаһы Тәгалә бу эшне теләми икән, ул эш булмаячак. Шул ук вакытта әллә кайларга качсаң да, тәкъдиреңә шундый язмыш язылган икән, ул эш булмыйча калмаячак... Шуңа күрә мөселман кешесе яхшы чакта шөкерана кыла, авырлык, кайгы килсә – сабыр итә, «Әлхәмдүлилләһи галәә күлли хәл», ди, ягъни, һәрбер хәлдә Аллаһка мактау әйтә... Бу хәлләр безгә Аллаһтан сынау инде, бәлки, үзебезгә һәм нәселебезгә җәннәткә керергә шушы авырлыклар сәбәпче булыр. Шушы авырлыкларга сабыр итеп, барыбер диндә-иманда калу сәбәп булыр, инша Аллаһ!

Барысы да Әхмәт мулланы зур игътибар белән тыңладылар, әйтерсең лә ул аларны нәрсәгәдер хәзерли иде. Моны Гөләйза да аңлады, әмма сиздермәде, йөрәге генә сулкылдап кысылып куйды. Ул түзәр, ул барысына да түзәр, сабыр итәр, әмма аңа бер-бер хәл булса, балалары бигрәк кечкенә бит, алар нишләр? Гөләйзаның да күз карасыдай газиз балаларын аннан елатып аерып алып, урысларга бирерләрме икәнни? Юк, юк, мондый хәл булмас, Аллаһы Тәгалә мондый гаделсезлеккә юл куймас, ничә еллар буе борчымадылар, бәлки, хәзер дә шулай үтеп китәр?

Бишектә яткан нәни Гыйниятулла уянып елый башлады, Гөләйза аны кулларына алып, чаршау артына имезергә кереп китте. Нигәдер, тагы теге еллар исенә төште... Ул чагында Габделҗәббар шулай имчәк баласы иде, хәзер әнә урамда йөгереп йөри... Ә олысы, Габделвахит, инде әтисе белән бергә мәчеткә намазга йөри, Әхмәт мулладан белем ала. Ул бала бик акыллы, тырыш булып чыкты, кечкенәдән бөтен эшне үзе белеп эшли – каз бибиләрен көтү дә, югалган сарык бәрәннәрен эзләп алып кайту да, бозауны эчерү, колынны су коендыру, энесен карау да аның өстендә. Ул урманда җиләк, чикләвек җыюны инде әйтеп тә торасы юк, тиен кебек елгыр, бөркет кебек өлгер, балакай... Элек Кыр Шонталасына әби-бабаларына барырга, Актауда кунак булырга бик ярата иде, хәзер алай йөрергә вакыты юк, өйдә кирәк. Актауда Мәрьям дә матур гына кызчык булып үсеп килә, әнисе белән монда кунакта да булганнары бар,

Габделвахит белән аларны аерып алып булмый. Кем белә, тагы ун елдан, бәлки әле, чәчләре чәчкә дә бәйләнер, барысы да Аллаһ кулында...

...Әйе, барысы да Аллаһ кулында, һәм Ул бу гаиләгә бергә булырга тагы берничә ел вакыт бирде. Әмма Күк Китабында Гөләйзаның язмышы язылган, мөһере сугылган, битләре ябылган иде... Гөләйза соңгы вакытта сәер төшләр күрә башлады – әле урыс авылында кара мунчада төтенгә тончыгып үлгән Гөләйзар әбисе каршына килеп баса, ул ап-актан киенгән, йөзеннән нур чәчеп тора... Әбисе аны нигәдер юата, тынычландыра, курыкмаска куша, сиңа үз янымда урын калдырдым, ди... Һәм ул урынны күрсәтә... Ул урынның матурлыгын әйтеп тә, аңлатып та булмый, ул зөбәрҗәттәй яшькелт нурдан тора, андагыдай матур чәчкәләр җир йөзендә юк, алардан башны әйләндерерлек хуш ис килә... Баш очында кошлар сайрый, күгәрченнәр гөрли, аларга чишмә тавышлары, су агышлары кушыла... Гөләйза, әллә җәннәт шушы буламы икән, дип уйлый, аның монда бөтенләйгә каласы, хәвефле дөньяга яңадан әйләнеп кайтасы килми... Чөнки монда кайгы-хәсрәт тә юк, авыру-сыкранулар да юк, тәне мамык кебек җиңел, җаны сабый баладай тыныч...

Бала, дию белән, аның исенә каядыр еракта, аста, томаннар арасында калган балалары исенә төшә, йөрәген пычак белән телеп җибәргәндәй була. Аның сабыйлары, аның газизләре, күз нурлары! Габделвахиты, Габделҗәббары, Гыйниятулласы! Ул монда калса, аннан башка алар нишләр?! Бик ерактан, кара болытлар баскан кара урманнар арасыннан, сабый баланың өзелеп-өзелеп елаганы ишетелә... Бу бит аның баласы, бу бит аның улы, бу бит аның газизе! Сабые, Гыйниятулласы инде елый-елый карлыгып беткән, ул әнисен мәңгелеккә югалттым, дип курыкты ахры... Курыкма, улым, ана кеше балалары хакына күктәге җәннәттән җирдәге җәһәннәмгә дә әйләнеп кайта икән ул...

Икенчесендә, төшенә Әкълимә әби керде, ул да ап-ак киемнән, йөзеннән нур бөркелеп тора... Кулларында бала... Кая алып бара ул аны ак болытлар арасыннан? Бу Әкълимә әби яшәгән Актау авылы түгелме соң? Анда бит мәчет юк, чиркәү генә! Кая алып бара ул бу баланы?! Кем баласы ул? Үз улы Мөхәммәтме? Әмма бу бала Габделвахит белән Габделҗаббарның кечкенә чагына да охшаган, нәни Гыйниятулланы да хәтерләтә... Кая алып бара аны Әкълимә карчык ак болытлар арасыннан? «Син курыкма, кызым, – ди ул. – Барыбыз да монда булачакбыз... Син үзең дә, нәселең дә яхшы урында булачак, әмма моның өчен сезгә зур сынаулар үтәргә туры киләчәк... Мин өйрәткән догаларны онытма: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Үә биһии нәстәгиину үә биһил хәүлү үәл кууәтү рабби сәһһил үә йәссир гәләйнәә йәә мүйәссира күлли әмрин гәсиир» – «Раббым, авырайтма, җиңеләйт! Көч-куәт бары тик Синдә, ярдәмеңнән ташлама!» Син курыкма, кызым! Алар бездән курыксын, чөнки гаделлек безнең якта, Аллаһ безне яклаячак! Иманыңны сакла, үз исемеңне онытма! Дисбемне югалтма, анда милләтнең хәтере... Үзеңә дә, балаңа да янымда урын алып калам...»

Сискәнеп уянып киткәндә, Гөләйзаның кулында Әкълимә әбинең дисбесе иде... Төймә-төшләре бармак эзләреннән инде ялтырап-шомарып беткән, ничә гасырлар буе милләткә хезмәт иткән һәм аның хәтерен саклаган бисмиллалы дисбе! Поплар тартып өзгәннән соң да яңадан берәмтекләп җыелган, һәр төймә-хатирәсе үз урынына куелган изге дисбе! Милләтнең бәхетле һәм бәхетсез чакларының сүзсез шаһиты, аның зурлыгын да, коллыгын да күргән телсез тарихы... Бу төймәләр телгә килсә, сүзгә килсә, милләтнең иман өчен ничек көрәшүен, нинди газаплар күргәнен, кулларына Коръән тотып, утларда

янганын, шаһәдәт кәлимәсен әйтеп, бозларга ябышып катканын, аяк-куллары богауланган килеш, тәкъбир әйтеп, Себерләргә сөрелгәнен бөтен җиһанга сөйләрләр иде... Бу төймә-хатирәләргә татарның өмет яшьләре тамган, кайгы-сагышлары сеңгән, бөек һәм фаҗигале тарихы уелып калган...

Гөләйза сизенде – төшләре аны нәрсәгәдер әзерли иде... Каралык аша – яктылыкка, авырлык аша – яхшылыкка, газаплар аша – мәңгелек җиңеллеккә... җирдәге вакыты бетә барганын да аңлады, әмма моны беркемгә дә әйтмәде.

Ул арада тагы елдан артык вакыт үтте, инде Гыйниятулла да йөгереп йөри башлады, әмма әле имүен ташламады. Бу вакыт эчендә Чистайдан да, Биләрдән дә әллә ни борчымадылар, шуңа күрә авылдагылар да тынычландылар, тагы үз җайларына яши башладылар. Әмма Чистайда инде дулкын кузгалган, эш хәрәкәткә килгән, ул да үз җае белән соңгы ноктасына якынаеп килә иде. Теге Книгин дигән суд күзәтчесе бер айдан тагы приставның исенә төшерде – Гөләйза эшен урынга барып тикшерүне тәмамларга һәм мәхкәмәгә әзерләргә кушты. Ә аны ничек алай тиз генә тәмамлыйсың – сорау алучыларның әле авылларга чыкканы да юк бит! Әйтерсең лә ничә еллар буе махсус сузалар, оеша алмыйлармы, теләмиләрме – билгесез, әмма эшләренең нәтиҗәсе күренми. Бәлки, Чистай байларының астан гына алып барган эшкәртүләре, кайбер түрәләргә бирелгән мул-мул бүләкләре дә файда иткәндер – Гөләйза эше сузылды да сузылды...

Моңа иң ярсыган, иң кайнаган кеше Биләр атакае булды, чөнки ул бик картайды, гомеренең чигенә килеп җитте, һәм ул бу дөньядан җиңеп китәргә тиеш иде! Ә ул шушы бер татар хатынын да җиңә алмый! Ишетүенчә, хатын басурман ирённән инде өченче баласын тапкан, монысын да чиркәүгә алып килеп чукындырмаганнар. Аларга полициянең дә көче җитми, судлар да берни эшли алмый, ничек теләсәләр – шулай яшәп яталар. Ул үзе дә хәзер бу фетнәче татар авылларына баш тыкмаска тырыша, аны этләр өстереп куалар... Үзе дә курка, теге вакытта атасын асып үтергән кебек, бу басурманнар аны да асып куярга күп сорамаслар! Алар хәзер бик үзгәрде, моннан берничә еллар электәге татарлар түгел, кая кусаң, шунда бармыйлар, сәнәк-казык тотып, ыжгырып өстеңә киләләр. Әмма Биләр побы үзенә сүз бирде – Гөләйзаны һәм аның нәселен чукындырмыйча торып, аның бу дөньядан китәргә хакы юк! Бу аның Ходай каршында изге бурычы. Һәм ул моның өчен барысын да эшләячәк!

Биләр побының котыртуы буенча, Чистай стряпчие Книгин, Гөләйза эшен тикшерүне тизләтүне сорап, приставка үтенеч артыннан үтенеч юллый, 1842 елның 1 октябрендә һәм 1843 елның 22 мартында тагы шундый эчтәлекле хатлар яза. Болар – рәсми документлар, һәм инде аларны җавапсыз калдыру мөмкин булмый. Шушы таләпләр нигезендә, Гөләйзаның туган авылы Кыр Шонталасына һәм хәзер яши торган Чирүле Шонталасына Чистайдан тиз арада комиссия чыгып китәргә тиеш була. Әмма бу «тиз ара» дигәне дә, Аллаһ рәхмәте белән, тагы бер елга сузыла. Бу тикшерүдә полиция һәм суд ягыннан да, чиркәү тарафдарлары да, дөньяви оешма вәкилләре дә катнашырга тиеш була. Бик авырлык белән оешкан төркемгә дәүләт милке округы җитәкчесенең ярдәмчесе, флот лейтенанты Мейснер да кертелә. Комиссия шулай ук урыннарга барып, Кыр Шонталасы, Урманасты Шонталасы, Каравай, Дума авылларындагы мәкруһларның да эшләрен тикшерергә тиеш икән. Суд тикшерүчесе Книгин бу турыда туктаусыз аларның үзләрен кисәтеп тора, һаман исләренә төшерә, пристав исеменә хат артыннан хат яудыра, әмма комиссия һаман эшкә керешми. Бәлки, моңа тикшерү төркеменә алман милләтеннән булган, католик динен

тоткан Генрих Мейснерның да кертелүе сәбәпчедер, бәлки, татар морзалары кулыннан «ашаган» элеккеге приставлар шулай махсус сузгандыр, әмма 1844 елның 24 февраленә кадәр халыктан сорау алулар үткәрелми. Тик шушы вакыт эчендә 2 нче стан приставы үзгәрә – ул урынга үзенең ерткычлыгы белән дан алган, татарларны күралмаган Кызылъяр алпавыты, отставкадагы корнет Александр Шахт билгеләнә. Һәм җиң сызганып үзенең канлы эшенә тотына...

Ә бу бәндә үзенең явызлыгы, кансызлыгы белән инде тирә-юньдә начар дан алган була. Каяндыр чирмеш-мари якларыннан, ниндидер яманлыклары өчен бирегә күчерелгән Александр Шахт монда килгәч тә ерткычлыгын дәвам итә. Ул ислам диненә кайткан керәшен татарларын күралмый торган кеше була. Аның өчен алар – хайваннан да түбән дәрәҗәдә, эт итеп кыйнарга да, хәтта үтерергә дә мөмкин мәхлуклар. Ул алар белән сөйләшеп тә тормый, авызларын ачуга, сугып кына ега, аннан өсләренә менеп сикерә башлый... Кайбер авылларда хәтта сорау алган вакытта исерек баштан мәкруһларны буып үтергән очраклары да булган. Зиратларда да ул мәет козгыны кебек очынып йөргән – яңа кабер күрүгә, аны казытып алган, мәетнең мөселманчамы яки христианчамы күмелүен тикшергән. Мөселманча күмелгән булса, мәетне җир өстенә чыгарып бәргән, бу эшне эшләүчеләрне кыйнап ташлаган, аннан хөкем итеп, Себергә сөрдергән. Шахт аркасында, гомерлек хәрби хезмәткә китеп, шунда юкка чыгучылар да күп булган. Әлбәттә, халык әлеге хәлләргә түзмәгән, аның өстеннән Казан губерна идарәсенә шикаятьләр язган, әмма Казан һәрвакыт бу җәлладны яклаган...

Чистай өязенә шундый кешенең пристав итеп билгеләнүенә иң нык сөенгән кеше дә, Биләр атакае Михаил Лавров булды. Үзе бирегә килгәнче үк аның турында шушы хәбәрләр ирешә, килеп эшли башлагач та, Шахт христиан динен санламаган татарлар белән нишләргә кирәклеген күрсәтте. Әйе, ул адымнар рәхимсез иде, әйе, монда кешелек кануннары да, хөкүмәт законнары да юкка чыга иде, әмма ул кыргый татарлар белән башкача эшләү мөмкин түгел! Инде сиксән яшен узган поп үзе шаһит – татарлар православ диненең дошманы! Аларны башкача денгә кертеп булмый, диндә тотып та булмый... Александр Иванович дигәннәре әллә кайчан бу якларга килсә, бөтен керәшен татарлары күптән, чиркәүләргә йөреп, чын христиан булырлар иде инде!

Биләр атакае шулай хыялланды, канәчкеч Шахтны Ходай үзе монда җибәрде, дип сөенде. Әмма ул әле татарларның ни дәрәҗәдә хәйләкәрлеген, усаллыгын белми, аны кисәтергә кирәк булачак. Ул тегендә чирмеш-чувашларны эт урынына кыйнап, чиркәүгә бәйләп куйган, әмма монда алай ук барып чыкмас, татарлар үзләре аның башына җитүләре мөмкин. Һәм бу Пелагея-Гөләйза эшен дә кичекмәстән үз кулына алсын, югыйсә теге приставтан рәт чыкмады, судьясы да ничә елларга сузды, барысы да шул татар акчасына сатылган! Дин турында уйлаучы юк, чиркәүләр буш, татарлар көтүләре белән үз диннәренә кайта. Юк, алга таба болай баралмый, шуның өченме патшаларыбыз бу басурманнарны яулап алды, шуның өченме аның үз атасы асып үтерелде?! Михаил атакай соңгы сулышына кадәр татарларның үзләренә дә, диннәренә дә каршы эш алып барачак, соңгы татар православ динен кабул иткәнче көрәшәчәк иде...

Яңа пристав Александр Шахт Биләр якларына килеп чыккач та, ул аңа шуларны сөйләде, бу көрәшне аңа әманәт әйткән кебек тапшырды.

– Сине монда Ходай җибәрде, улым! – диде ул, күзләре яшьләнеп. – Менә инде ничә еллар мин берьялгызым көрәшәм бу басурманнарга каршы!

Чәчләрем, сакалым агарды, ә ул кыргыйларны изге динебездә калдыра алмадым! Ходай каршында ни дип җавап бирермен?! Таяныр кешем булмады, Чистай түрәләре татар акчасына сатылган, попларына кадәр күз буяу өчен генә ул керәшеннәрне чиркәү кенәгәләрендә тоталар. Аларга татарның акчасы гына булсын, чиркәү өчен түләнгән салым гына булсын! Йә Хода, кичер безне?!.. Инде, углым, бөтен өмет синдә, каты кулың белән туры юлны күрсәт ул кыргыйларга! Алар башканы аңламый. Әмма сак бул, алар бик хәйләкәр һәм усал, акча белән сатып ала алмасалар, казыкка тотыналар, үлгәнче үз диннәрен һәм бер-берләрен яклыйлар! Алар арасында хәзер укымышлылары да бар, бөтен Казанны һәм Питерны шикаятьләр белән тутырдылар. Син бернәрсәгә карама – бугазларыннан ал динебез хакына! Аларның үзләре кебек бул! Бу минем сиңа васыятем!

Моның шулай икәнен Александр Шахт үзе дә белә иде, мишәр-татарларны бастыру өчен дә аны монда күчерделәр. Югыйсә, иллешәр-кырыгар татар авылы берьюлы баш күтәрә башлаган бит, шуңа барып җиткәннәр – попларны авылларына кертмиләр икән, хәтта полиция белән дә чиркәүгә алып бара алмый башлаганнар. Болар бит чукындырылган татарлар, православ динендә хисапланалар, ә алар өерләре белән үзләренчә яшәп яталар! Алга таба, әлбәттә, болай булмас, бу татарларның тереләренә генә түгел, үлгәннәренә дә көн күрсәтмәбез!

– Борчылма, атакай, динебез хакына мин аларны таптап изәчәкмен! Ник туганнарына үкенерләр, нечистьлар! Шуышып килеп, аягыбызны үбәр! Без аларга ничек дин тотарга кирәклеген күрсәтербез! Динебезне күрәләтә мәсхәрә итәргә ирек бирмәбез! Мин тегендә күп күрдем аларны, бугазларыннан алып, артларына тибеп чиркәүгә кертеп җибәрә идем... Алтарьга барып бәрелеп, маңгайлары ярыла иде, канга батып чукыналар иде... Менә ничек кирәк алар белән!

Аның сүзләреннән Михаил атакай үзе дә сискәнеп китте, таш чырайлы бу кешедән барысын да көтәргә мөмкин иде. Әмма монда барыбер саграк булырга кирәк, бу мишәрләр андагы чирмешләр түгел, үзеңнең башыңны ярырга мөмкиннәр.

– Син мондагылар белән бераз саграк бул, улым! Мондагы татарлар үзләре дә бик усал. Күбесендә корал бар, заманында патшага хезмәт иткән кешеләр... Үзеңә зыян-зәхмәт сала күрмәсеннәр.

– Курыкма, атакай, андыйларны гына күргән! Мин дә хәрби хезмәттә булган, сугышларда катнашкан кеше, хәрби офицер! Хәзер минем өчен яу кыры – шушы басурманнар, аларны яңадан чиркәүгә кайтармыйча, мин бу сугышны туктатмаячакмын! Бу минем урыс чиркәве алдында изге бурычым, атакай!

– Слава Богу! Инде миңа да тынычланып үләргә була икән болай булгач, углым! Юк, тынычлана алмыйм, үзем башлаган бер эшкә нокта куясы бар, ярдәм ит, углым!

– Әйт, атакай, синең сүзең минем өчен әмер!

– Шактыйдан, моннан алты-җиде еллар элек Казаннарга язып, христиан диненнән чыккан һәм басурман белән зина кылып яткан бер татар хатынына каршы эш кузгаткан идем... Әмма бу эшне Чистай суды озак әвәләде, җиренә җиткерә алмады, елларга суздды... Бу азгын хатын һаман шул басурман ире белән яшәп ята, инде зинадан өч бала тапкан, ә берсен дә чиркәүгә алып килеп чукындырмаган! Югыйсә, ул бит үзе керәшен, балалары да чукындырылырга тиеш! Менә шушы эшкә үзең тотын һәм тиз арада нокта куй, углым! Ул

хатынны иреннән аерып, монастырьга җибәрергә һәм бер урыс кешесенә кияүгә бирергә кирәк. Балаларын алардан алып, чиркәүдә чукындырып, урысларга бирү тиешле, алар шунда гына чын христиан тәрбиясе алачак. Ходай ризалыгы өчен, минем хакка син бу эшне башкарып чыгарга тиеш!

– Ул хатынның исеме ничек? Кайдан ул?

– Аның христианча исеме – Пелагея, үзләренчә Гөләйза, диләр, ире белән Чирүле Шонталасында яшәп ята. Әмма ул хатын ислам фанаты, үлсә дә үз диненнән баш тартмаячак, атасы аннан да куркыныч, иманын бирмәс өчен бугазыңны чәйнәр... Менә сиңа шуларны җиңәргә туры киләчәк, улым!

– Аларга башка юл юк, атакай – йә чиркәү, йә кабер! Мин сиңа тәре үбеп ант итәм!

...Чирүле Шонталасында әлеге хәбәр кышкы көндә яшен суккан кебек яңгырады – Гөләйзадан сорау алырга килгәннәр, аны алып китәргә дә мөмкиннәр икән! Халык бу хәлләрне инде үткән, беткән дип йөри иде, юк икән, пар атлар җигеп, төрле чаналарга утырып, Чистай урыслары үзләре авылга килеп җиткәннәр, Гөләйзаның иреннән, Әхмәт мулладан да сорау алачаклар, ди. Халык мәчет тирәсенә җыела башлады, каравыл өе янына барып килүчеләр дә булды. Кайда сорау алырлар, бөтен авылны җыярлармы, берәм-берәм генә берәр җиргә чакырырлармы? Җәйге көн түгел бит, теге вакытта, май аенда, каравыл өе янында урамда сорау алганнар иде, хәзер кыш, болай эшләп булмый. Андый зур түрәләр караңгы каравыл өенә кереп тә вакланмас, бу алар өчен түбәнлек санала. Мәчеткә халык үзе кертмәс. Авыл халкы шулай кайнады, кайнарланды, ирләр мәчет белән каравыл өе арасын таптады.

Бу хакта сорау алырга килүчеләр үзләре дә уйланды һәм авылның урыс очындагы алпавыт утарына тукталырга булдылар. Алар теге юлы килгәндә дә урыс байларының йортында туктап ял иткәннәр иде, бу юлы сорау алуны да шунда оештырырга туры киләчәк. Биредә Михаил, Елена, Евгений Стрелковларның «господский дом» дип аталган утарлары бар, әлеге алпавытлар кышларын анда яшәмиләр, җәйләрен дә үзләренең крепостной крестьяннарын барлап, тикшереп кенә китәләр. Чистайдан килгән хөкүмәт кешеләренең бу йортларда тукталырга килешү-рөхсәтләре бар. Бу юлы да шулай булды, чөнки сорау алынырга тиешле кешеләр күп түгел иде, аларны алпавыт утарына гына чакыртырга булдылар. Яхшы атларда чаптырып, авылның урыс очына килеп туктадылар һәм үз яннарына сотник Әбуталипны чакыртып алдылар, ул биреге Гөләйзаны, аның ире Хәкимне, Әхмәт мулланы алып килергә тиеш иде.

Әбуталип җиккән аты белән килеп туктаганда, Гөләйзаларның да капка төбенә халык җыелган, монда инде ир-атлар гына түгел, хатын-кызлар да күренә иде. Алар Әбуталипны сырып алдылар, сораша башладылар, аяк атларга ирек бирмәделәр.

– Бу козгыннар тагы нәрсә дип килгәннәр? Нигә һаман шул бичара хатынга бәйләнәләр?

– Нинди керәшен булсын ул, безнең кебек үк татар динен тота бит!

– Нигә аның балалары чукынырга тиеш? Алар мөселман атадан ласа!

– Бирмибез Гөләйзаны! Бар, шулай дип барып әйт!

Әбуталип үзе дә аптырап калды. Бер якта – Чистай түрәләре, аларның әмерен үтәмичә булмый, икенче якта – авыл халкы, аларны да тыңлау кирәк. Әмма хәзер бу Чистай түрәләрен кире борып җибәрсәң, теге вакыттагы кебек, авыл өстенә атлы казаклар белән киләчәкләр, ярый ул вакытта Ишук әзи саклап калды зур бәладән! Хәзер монда ул да юк. Халык ярсыган. Гөләйза

да кызганыч, бераз авырып та тора, диделәр. Ул халык белән дөресен әйтеп сөйләшергә булды.

– Үземә дә бик кызганыч Гөләйза килен, балалары кечкенә, үзе дә авырып тора... Әле ярый Гөлзада кодагый килде карашырга. Әмма аларны сорау алырга алып бармыйча да ярамый, тәртибе шундый, җәмәгать! Сорау алу ул әле алып китү дигән сүз түгел бит, алар әле иртәгә Кыр Шонталасына да халыктан сорау алырга баралар икән. Шулар барысы да беткәч кенә, Чистайда яңадан суд буласы, ди, бәлки әле, карар Гөләйза килен файдасына чыгарылыр.

Аның бу сүзләреннән халык тагы бер тапкыр шаулашып алды, ул арада Әбуталип өйгә кереп китте. Өйдәгеләр бу турыда беләләр иде инде, Хәким, мәчет тирәләрен урап кайтып, барысын да ишеткән иде. Соңгы вакытларда Гөләйза бераз авырып тора, үзеннән-үзе хәлсезләнеп китә, йөрәк тибеше начарая, шуңа күрә балаларын карашырга Кыр Шонталасыннан әнисе килде. Бу сорау алу дигәннәре дә бөтенләй вакытсыз килеп чыкты, авыру кешегә анда йөри торганмы?! Әмма бармасаң, мәҗбүри алып китүләре бар, ичмасам, шундый вакытта яннарында Ишмөхәммәт тә юк бит! Киңәш-табыш иткәннән соң, балалар янында күршеләрне калдырып, сорау алуга бергә барып-кайтырга булдылар. Әйе, алар кире әйләнеп кайту нияте белән җыендылар, Әбуталип бу хакта кат-кат әйтте.

– Гөләйзаны андый-мондый Чистайга ук алып китмиләрдер бит, кода? – дип сорады аннан Гөлзада, борчылып.

– Алай дип әйтмәделәр, кодагый, сорау алырга гына, диделәр. Синең үзеңнән иртәгә авылыгызда сорау алырга тиеш булганнар, әмма монда икәнлегеңне белгәч, бүген үк сорау алырлар, әзерләнебрәк тор. Элек нәрсә әйткән булсаң, шуны әйтерсең. Гөләйза килен дә шулай эшләр.

– Соң, шулай булмыйча, кода! Тагы нәрсә әйтик инде?!

Шулай сөйләшә-сөйләшә киенделәр, балалар янында күршеләрне калдырдылар, Әбуталипның ат чанасына төялеп, урыс очына юнәлделәр. Авыл халкы аларны догалар һәм күз яшьләре белән озатып калды... Алпавытның әллә ничә бүлмәдән торган зур, иркен йортында аларны берәм-берәм комиссия каршына чакырттылар, башта түрәләр утырган зур залга Гөләйзаны керттеләр. Гөлзада да аңа ияреп кермәкче иде, әмма тәртибе алай түгел икән, бергә ярамый, диделәр. Гөлзада, Хәким, Әхмәт мулла үз вакытларын көттеләр, Әбуталип ике арада йөреп торды. Сорау алу, дигәч, Гөләйза, Чистай судындагы кебек булыр, дип уйлаган иде, әмма монда кешеләре дә, сөйләшүләре дә бөтенләй башка төрле иде. Бу юлы тәрҗемәче булып Котош авылы побы Николай Казанцев килгән, ул үзе дә керәшен татары. Пристав та бөтенләй башка кеше – явызлыгы белән яман даны таралган Александр Шахт, татарлар аны Әликсәй Шайтан, дип атап йөртә. Алман Мейснер, кая килеп эләктем мин, дигәндәй, калын күзлек пыяласы астыннан барысына да аптырап һәм бераз чирканып карый, бу эшне теләр-теләмәс башкарганы сизелеп тора. Шуңа күрә дә монда барысы белән дә Әликсәй Шайтан идарә итә, Гөләйза бүлмәгә аяк басуга, ул аңа котырган эт кебек ябырылды.

– Басурман белән зина кылып ятучы азгын хатын синмени инде ул?! Христиан башың белән! Юк, сиңа хәтта Пелагея дигән христиан исеме дә әрәм! Христиан түгел син, нечисть, нәҗес! Синдәйләрне, хайван кебек, абзарга ябып куеп, чыбыркылап ярырга кирәк!

Гөләйза, аптырап, як-ягына карады, авызы күбекләнеп чыккан әлеге затның бер сүзен дә аңламады, ни өчен үзенә кычкырганын да белмәде. Милек

палатасы вәкиле Мейснер да мондый хәлгә аптырап калды, аның бу яңа пристав белән халык арасына беренче тапкыр чыгуы иде, юл буе әдәпсез нәрсәләр сөйләп баруыннан да туйды. Җитмәсә, килүгә каяндыр табып, нәрсәдер эчеп тә алган, күзләре бөтенләй калайланган, авызыннан килгән яман ис бөтен бүлмәгә таралган... Котош побы, ашыга-кабалана, приставның сүзләрен Гөләйзага тәрҗемә итә башлады, әмма кайберләрен төшереп калдырырга мәҗбүр булды, теле күтәрелмәде. Болай да авырудан йөрәге яфрак кебек лепердәп торган Гөләйза бу сүзләрне ишеткәч, чайкалып китте, тизрәк өстәл читенә таянды. Эченнән белгән догаларын укыды, бераз тынычлангандай булды, аннан тагы теге судта сөйләгәннәрен кабатлады.

– Әйе, син дөрес әйттең – мин христиан түгел, ә татар динендә – мөселманмын... Минем исемем Гөләйза, Пелагея түгел! Урыс динендә беркайчан булмадым, аны белмим дә, белергә дә теләмим...

– Белерсең! Ничек кенә белерсең әле!!! Тезләнеп гафу сорарсың бу сүзләрең өчен! Башыңны бәрә-бәрә чукынырсың – мәҗбүр итәрбез! Сез вәхшиләргә башка юл юк – йә чиркәү, йә кабер!

– Алексей Иванович, бераз тынычрак мөмкин түгелме? Аңлап та, язып та өлгереп булмый, тәрҗемә турында әйтмим дә инде. Сорау алуның да беркетмә өчен үз тәртибе бар, башта Пелагеяның, дөресен сөйләячәкмен, дип, Библия тотып ант итүе кирәк. Николай атакай, аңлатыгызчы аңа боларны.

Котош побы бу сүзләрне Гөләйзага тәрҗемә итте, аңа Библия китереп бирде, әмма Гөләйза аны кулына алмады.

– Мин – мөселман, Коръән тотып кына ант итә алам, – диде ул.

– Әмма син чиркәү кенәгәсе буенча – христиан, шулай булгач, Библия тотып ант итәргә тиешсең, – диде аңа Мейснер.

– Юк, мин – мөселман, чиркәүдә беркайчан булмадым, чукынмадым, ул китабыгызны күрмәдем, анда нәрсә язылганын белмим... Мин кечкенәдән Коръән укырга өйрәндем, намаз укыдым, ураза тоттым, яшем җиткәч, мине шушы авылның мөселман кешесенә кияүгә бирделәр. Аннан өч бала таптым, төпчек улыбыз Гыйниятуллага бер яшь тә җиде ай... Балаларыбызның барысына да авылыбыз мулласы Әхмәт хәзрәт мөселманча исем кушты, мәчет кенәгәсенә теркәп куйды. Балаларым да, әлхәмдүлиллаһ, татар динендә, чөнки мөселман ата-анадан тудылар, мөселман йоласы буенча колакларына азан әйтеп исем кушылды... Миңа хәзер утыз җиде яшь, балаларым кечкенә, үзем хәзер авыру, биш-алты ел буе шушы борчулар белән яшәү сәламәтлегемне какшатты... Мин бу илгә, бу хөкүмәткә бернинди зыян да эшләмәдем, кечкенә генә татар авылында тын гына яшәп ятучы бер мөселман хатынымын... Чиркәү кешеләре миңа кагылмасыннар иде, оямны туздырмасыннар иде, патша галиҗәнапләреннән шуны гына сорыйм...

Күрше бүлмәдән тагы өстәп кергән пристав Шахт, тәрҗемәче аша Гөләйзаның бу сүзләрен ишетеп, атылып аның янына килде, Библияне йөзенә төртте.

– Син, вәхши татарка, безнең изге китабыбызны тотарга да җирәнәсеңме?! Әйт, җирәнәсеңме?!

Ул кулындагы калын китабы белән Гөләйзаның йөзенә бәрде, Библия идәнгә барып төште, битләре таралып китте. Моны күреп, Котош атакаеның коты чыкты, ул, мүкәләп, аларны җыя башлады. Мейснер инде монда ник килгәненә үкенә башлаган иде, ләкин эшне дәвам итәргә кирәк, хөкүмәт аларны

берегә зур акчалар түләп җибәрде, моны акларга туры киләчәк. Ул тагы исерек приставны тынычландыра башлады, бераз оялтып та алды.

– Без хөкүмәт эшендә, Алексей Иванович! – диде ул. – Һәм аны намус белән башкарып чыгарга тиешбез. Безгә карап, хөкүмәткә бәя бирәләр. Бу халыкны Библия белән кыйнап кына дингә кертеп булмас, ә үзебездән бөтенләй биздерүебез бар... Башка юлларын табарга кирәк.

– Аларга ике генә юл – йә чиркәү, йә кабер! – дип ырылдады Әләксәй Шайтан, көрмәкләнгән теле белән. – Мин тегендә чирмеш-чувашларны шулай бугазларыннан өстерәп керттем православлау диненә! Артларына типкәли-типкәли! Алар башканы аңламый! Болары белән дә шулай булачак, ник туганнарына үкенәчәкләр!

Котырган үгез кебек, Гөләйзага таба китте, кан баскан күзләрен аңа текәде. Ул кыргый дип атаган хатынның йөзеннән нур сирпелеп тора, кара кыйгач кашлары астында зөбәрҗәттәй зур яшькелт күзләр, аларны озын керфекләре урап алган... Гәүдәсенең зифалыгын хәтта озын кышкы киемнәре дә яшерә алмаган... Кыяфәте горур, авырыйм, дисә дә, мескенлек юк, аның сүзләреннән курыкканга да охшамаган, бу хәл приставны тагы да җенләндерде. Гөләйза исә үзеннән нәрсә таләп иткәннәрен, ни өчен бу кешенең аңа ярсып ташлануын аңламый иде. Ул, ярдәм көткәндәй, башкаларга карады. Котош побы белән палата вәкиле дә хәлнең болай ямьсез төс алуын көтмәгәннәр иде, үзләре өчен дә шүрләп калдылар. Бер якта – наганын селкеп йөрүче исерек пристав, икенче якта – урам тулы татарлар, монда берәр нәрсә булса, аларны исән килеш авылдан чыгармаячаклар. Мейснер бу турыда Алексей Шахтның исенә төшерде.

– Урам тулы татар, эшнең нәрсә белән бетүен көтәләр, – диде ул. – Бу хатынга берәр нәрсә булса, безне бетерәчәкләр... Болар сиңа тегендәге чирмеш-чувашлар түгел, Алексей Иванович, болар корал тоткан чирүле татарлар, башбирмәс мөселманнар!

Мейснер шул сүзләрен әйтеп бетермәде, пристав үкереп кычкырып җибәрде.

– Бирерләр! Бирерләр, ничек кенә бирерләр әле! Башларын да бирерләр, иманнарын да бирерләр, кирәк икән, җаннарын да бирерләр! Шулай бит, басурманка?!

Шул сүзләр белән ул тагы Гөләйза өстенә ыргылды, попның муенындагы тәресен йолкып алып, Гөләйзаның битенә төртте.

– Тәре үбеп ант ит – мин христиан, диген! Поганый басурман диненнән баш тартам, диген! Ант ит, сука, югыйсә моннан исән чыкмыйсың!

Гөләйза аның бер сүзен аңламаса да, кул яссуы тимер тәрене күрүгә, куырылып килде, үзен чукындыралар икән, дип уйлап, битләрен каплады. Алексей Шахт аның кулларын каерып алды, ул килеп кагылу белән, Гөләйза елан чаккандай сискәнеп китте, аны читкә этеп җибәрде. Болай да аягында чак басып торган пристав чайкалып куйды, кулындагы тәресе чыңгылдап идәнгә килеп төште, аны тиз генә Котош атакае эләктереп өлгерде. Гөләйзаның ишеккә таба йөгергәнен күреп, пристав айнып киткәндәй булды, аны җилкәсеннән эләктереп алып, бугазыннан өскә күтәрде.

– Нәрсә, сиңа Библия дә, тәре дә, православлау дине дә кирәкмиме, татарва?! Аларны идәнгә салып таптыйсыңмы?! Төрмәдә черетәм, юк, кабергә кертәм мин сине, җир белән тигезлим үзеңне дә, нәселеңне дә...

Гөләйзаның тынсыз калып, сыгылып төшкәнен күреп, ул тимер келәшчәдәй

кулларын аның бугазыннан ычкындырды, үзен селтәп бер читкә атты. Идәнгә шыбырдап нәрсәләрдер коелды, бу Гөләйзаның муенына аскан дисбесе шулай өзелеп, төймәләре идән буйлап тәгәрәп киткән иде... Бүлмәдәге тавышка сотник Әбуталип ашыгып кереп җитте, идәндә аңсыз яткан Гөләйзаны күреп, аның өстенә иелде.

– Килен... Килен! Гөләйза килен! Нәрсә булды? Ник болай ятасың син? Тавышка кердем, ни булды?

Аннан ул, җавап көткәндәй, бер хөкүмәт вәкиленә, бер Котош побына карады, пристав күрше бүлмәгә чыгып киткән иде. Мейснер белән поп бер-берсенә карашып алдылар, әгәр бу татарга дөресен әйтсәң, аларга моннан исән чыгу юк иде. Инде бу хатын үлә-нитә генә күрмәсен, бетерәчәкләр! Котош атакае моны аңлады һәм, татарчалап:

– Пелагея бераз хаста икән, Әбуталип! Менә хәле китеп ауды... Без чыгып торабыз, әнисе белән ире кереп, ярдәм итсеннәр үзенә.

Шулай диде дә, алар Мейснер белән күрше бүлмәгә чыгып киттеләр, алар артыннан ук ашыгып зур залга Гөлзада белән Хәким килеп керде. Гөлзада шунда ук елап кызы өстенә ауды, аның башын тезләренә куеп, сулышы белән җан өрергә тырышты. Хәким дә, нишләргә белмичә, алар янына тезләнде, Гөләйзаның әле хәлсез кулларыннан алды, әле күтәреп торгызырга азапланды, үзе нидер сөйләнде. Аларның тавышы бик ерактан, куе томан арасыннан ишетелгән кебек иде, әмма Гөләйза ишетте – әнисе дога кыла, ире елый иде... Гөләйза авырлык белән генә күзләрен ачты – бүлмәдә теге урыслар юк, янында әнисе белән ире иде... Хәким аны күтәреп торгызды һәм бер читтәге йомшак кәнәфигә алып барып утыртты. Гөләйза хәлсез куллары белән өс-башларын рәткә китерде, уңайсызланып, якыннарына карады.

– Нәрсә булды, кызым, әллә бер-бер нәрсә эшләделәрме бу явызлар? – дип сорады Гөлзада, аның янына утырып.

– Әйт, Гөләйза, әллә сиңа кул күтәрделәрме? – дип, Хәким дә сүзгә кушылды. – Әйт, шулай булса, хәзер бөтен авылны күтәрәбез!

– Килен, монда бик тавышландылар, теге приставның акырганына керсәм, син идәндә егылып ятасың... Нәрсә булды, кыйнадымы әллә ул исерек сине?

Гөләйза нәрсә булганын исенә төшерде. Әйе, ул аңа акырды-бакырды, тәре белән битенә төртте, бугазыннан алып болгады... Әйе, Гөләйза боларны яхшы хәтерли һәм мәңге онытмас та... Әмма хәзер бу хакта иренә, авыл халкына әйтсәң, монда кара тавыш чыгачак, сугышуга барып җитүләре дә бар. Аннан барысын да җыеп алып китәчәкләр...

– Башым әйләнеп китте, авырып тора идем бит... – диде ул, артыгын сөйлисе килмичә. – Дисбем чәчелде, әни...

Әле генә игътибар иттеләр – идәндә, чыннан да, дисбе төймәләре тәгәрәп ята иде. Тартып өзмәсәң, аның җебе өзелә торган түгел бит, нәрсә булды икән соң монда? Гөлзада тиз-тиз генә төймәләрне җыеп алды, дисбене кесәсенә яшерде. Ул арада күрше бүлмәдән Мейснер белән Котош побы чыкты, приставны шунда яткырып калдырганнар иде. Мейснер эшне үзе генә дәвам итәргә булды, чөнки ул котырган Шахттан зыяннан башка файда юк иде. Ул Әбуталипны Әхмәт мулла артыннан җибәрде, үзе Гөлзададан сорау ала башлады. Гөлзада исә теге вакытта Чистай судында сөйләгәннәрен кабатлады – үзе дә, балалары да мөселман, чукынмаганнар, чиркәүгә йөрмәгәннәр, киресенчә, намаз укыганнар, ислам динен тотканнар. Кызы Гөләйза үсеп буй җиткәч, аны шушы Чирүле Шонталасы авылы кешесе Хәким Камаевка кияүгә

биргән. Алай да, кияүгә бирер алдыннан Кызылъяр побы белән киңәшкән, ул Гөләйзаны чиркәү кенәгәсендә юк, дигән, мөселманга кияүгә бирергә рөхсәт иткән.

Аннан соң Гөләйзаның ире Хәкимнән сорау алу башлады, Әхмәт мулла аны Коръән тотып ант иттерде. Хәким дә ничек бар – шулай сөйләп бирде, бары тик бер урында гына яшерде – никах укылганны әйтмәде. Бу хакта әйтсә, керәшен кызына мөселман ире белән никах укыгансың, дип, Әхмәт мулланың үзен Себергә сөргән булырлар иде.

– Минем исемем – Хәким Камаев, 37 яшьтә, мөселман динендә, хөкемгә һәм штрафка тартылганым юк, – дип башлап китте ул. – Үзем шушы Чирүле Шонталасы авылының дәүләт крестьяны... Моннан тугыз еллар элек Кыр Шонталасыннан Гөлзада – Фекла Тимофееваның кызы Гөләйзаны хатынлыкка алдым. Аның белән никахыбыз булмады...

– Син аның чукындырылган икәнен белдеңме?

– Юк, каян белим ди? Ул бит миңа килгәндә үк мөселман иде – намазын укый, уразасын тота... Безне чиркәүдән килеп борчучы да булмады. Өч балабыз туды – Габделвахит, Габделҗәббар һәм Гыйниятулла, олысына – 8, уртанчысына – 5, төпчегенә бер яшь тә җиде ай...

– Балаларыгызга исемне кем кушты – чиркәүдә попмы, мәчеттә мулламы?

– Балаларга мөселманча исемне, минем чакыруым буенча, өебезгә килеп авылыбыз мулласы Әхмәт хәзрәт Әхмәров кушты.

– Ул хатыныңның керәшен икәнен белә идеме?

– Исем кушканда, ул хатынымның нәсел чыгышы турында миннән сорамады, белмәвем сәбәпле, мин дә әйтмәдем. Өстәп шунысын да әйтәм: балаларым беркем тарафыннан да чукындырылмаган. Безнең мөселман тәртибе буенча, баланың кемлеге этисе буенча билгеләнә, ягъни, мин татар-мөселман булгач, алар да татар-мөселманнар... Алар да, безнең кебек, чиркәүнең нәрсә икәнен белмиләр, олысы инде намазда, кечеләре дә бисмилласыз авызларына ризык капмыйлар. Хәләл җефетем Гөләйзаны болай газапламасагыз иде... Ул соңгы вакытларда авырып тора, аны суд юлларында җәфаламасагыз иде...

Хәким җавап тоткан арада, Әхмәт мулла чыгып торды, Хәкимнән соң бүлмәгә аны керттеләр. Әхмәт мулла илле яшьләргә җитеп килә торган кеше иде, ул үзе Спас өязенең Урта Тигәнәле авылыннан булып, Чирүле Шонталасы мәчетенә Диния нәзарәте указы белән билгеләнгән. Әлбәттә, тирәнрәк төшсәләр, Әхмәт мулланың үзенә дә бүген тотып эш ачарлык, шуңа күрә ул да бөтенесен әйтеп бетермәскә булды. Әгәр мулла керәшен татары белән мөселманга никах укыса, аның үзен төрмә көтә, бу христиан кешесен диннән яздыру, дип атала. Шуңа күрә ул да моны яшерде, һәрхәлдә, Хәким белән Гөләйзага никахны үзе укыса да...

– Керәшен кызы Пелагея белән мөселман кешесе Хәким Камаевка никахны син укыдыңмы? Нигә аны христиан диненнән яздырдың?

– Юк, мин аларга никах укымадым, мөселман диненә дә өндәмәдем, чөнки Гөләйза монда килгәндә мөселман иде инде...

– Аларның балаларына мөселманча исемне син куштыңмы?

– Әйе, балаларның атасы чакыруы буенча, өйләренә барып, һәр туган баласына исемне мөселман йоласы буенча мин куштым. Бездә тәртибе шундый – атасы мөселман булса, балалары да мөселман була. Аларга Габделвахит, Габделҗәббар, Гыйниятулла дип матур исемнәр куштым.

– Бу исемнәрне кушканда, син аларның әниләренең нәселе белән

кызыксындыңмы? Керәшен хатынының балалары да чиркәүгә алып барып чукындырылырга һәм аларга христиан исемнәре бирелергә тиешлеген беләидеңме?

– Юк, мин Хәкимнең хатынын беркайчан да керәшен дип белмәдем, нәселе белән дә кызыксынмадым... Мин сорамадым, алар әйтмәде, хәер, нәрсә әйтсеннәр, алар башка мөселманнар кебек яшәделәр бит... Шуңа күрә, һичнинди җаваплылыктан курыкмыйча, мин Гөләйзаны да мөселман дип санап, аларның балаларын мәчет кенәгәсенә теркәп куйдым. Һәм хаклыгыма ышанып, сезгә дә ул метриканың күчермәсен алып килдем.

Шулай диде дә Әхмәт мулла Мейснер каршына мәчет кенәгәсеннән күчермәне китереп салды. Гарәп хәрефләре белән чуарланган бу кәгазь битен Котош атакае Николай Казанцев шактый азапланып укып чыкты һәм русчага тәрҗемә итте. Анда «Габделвахит 1835 елның 22 гыйнварында, Габделҗәббар 1837 елның 7 декабрендә, Гыйниятулла 1842 елның 16 августында Чирүле Шонталасында туганнар, әтиләре Габделхәким, әниләре Гөләйза», дип язылган иде.

Шуның белән, Чирүле Шонталасында сорау алу тәмамланды, алга таба нишлисен хәл итәргә кирәк иде. Үзе сорау алырга тиешле пристав күрше бүлмәдә капланып йоклап ята, киңәшер кеше юк. Шуңа күрә карарны Мейснер үзе кабул итте, башта сотник Әбуталипны чакыртып, аңа фәрман бирде.

– Иртәгә Кыр Шонталасында сорау алулар тәмамлангач, эш судка тапшырылачак, – диде ул. – Кимендә бер ай эчендә Чистай земство судында да каралачак. Шуңа күрә Пелагеяны авылдан беркая чыгармыйсыз, аны саклауны үз өстеңә алып, менә монда имзаңны куй. Хәзергә барысы да өйләренә кайтып торсыннар...

Әбуталип Мейснер күрсәткән урынга имзасын куйды, үзенә биргән кәгазьне алып, бүлмәдән чыгып китте. Аргы бүлмәдә аны Хәкимнәр көтеп тора иде, Әбуталип аларга хәлне аңлатты, бер айдан Чистайда суд буласы, хәзергә өйгә кайтырга куштылар, диде. Инде моннан ук Чистайга төяп алып китәрләрме икән, дип борчылганнар иде, өйгә кайтырга, дигәч, сөенештеләр. Әбуталип хатын-кызларга барысын да әйтеп тормады, Гөләйзаны авылдан чыгармыйча сакларга кушканнарын ул энесенә генә әйтте. Алар шушы хәбәрдән эшнең ни дәрәҗәдә җитди һәм куркыныч икәнен аңладылар... Мәчет янында таралмыйча үзләрен көтеп торган халыкка да барысын да әйтмәделәр, хәзергә җибәрделәр, берәр айдан Чистайда суд буласы икән, диделәр.

...Гөләйза, өйгә кайткач та, үзе белән алпавыт йортында ни булуын берәүгә дә сөйләмәде, аның бу хәлне исенә дә төшерәсе килмәде. Әмма күзен йому белән, теге исерекнең җикеренеп өстенә килүе, бугазыннан алып, болгап атуы хәтеренә төшә... Куркыныч иде ул кешенең йөзе, бер якка чалшаеп каткан, күзләре акаеп чыккан, аларда мәрхәмәт заты юк, авызыннан әшәке ис аңкый... Гөләйзаның беркайчан да мондый хәшәрәтне күргәне юк иде, ул чирканып, куырылып куйды. Нигәдер, әҗәле дә шушы бәндә белән бәйләнгән кебек тоелды аңа... Бераз тынычлану өчен, дисбесен кулына алды, әнисе аны яңадан җепкә тезгән иде. Санап карады – дисбенең бер төймәсе җитми! Гөләйза әллә нишләп китте, нигәдер, югалган бу төймәне үзе итеп сизде, алпавыт йортында, урыс итеге астында калып изелгән мәрҗән кебек хис итте ул үзен...

Гөләйзаның бу төне дә саташып үтте...

Башта, тимер келәшчәдәй кулларын сузып, аны теге исерек куды, тотса, ул Гөләйзаның бугазыннан алачак, буып үтерәчәк иде... Гөләйза аңа тоттырмас

өчен йөгерә, инде бөтен авылны урап чыкты, теге куркыныч кеше һаман аның артыннан калмый икән... Шулчак, әллә кайдан, каршына Әкълимә әби килеп чыкты, «Мин өйрәткәнне укы! Аннан монда кил!» диде. Гөләйза аның Актауда өйрәткән догасын исенә төшерде, сулышына капланып, шуны кабатлый башлады... «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Үә биһии нәстәгиину үә биһил хәүлү үәл кууәтү рабби сәһһил үә йәссир гәләйнәә йәә мүйәссира күлли әмрин гәсиир». «Раббым, җиңеләйт, ансат ит һәм безгә авырайтма. Йә, бөтен авыр эшләрне җиңеләйтүче Син, ярдәмеңнән ташлама!» Гөләйза, йөгерә торгач, авылның мөселман зиратына килеп чыкты... Зиратта бер кабер казып куелган иде, Гөләйза теге куркыныч бәндәдән шунда качып котылмакчы булды, бөгәрләнеп, ләхет уентыгына кереп ятты... Ул баш очында аяк тавышлары ишетте, кемдер авыр итеп сулый, нидер сөйләнә иде... Бераздан аяк тавышлары ерагайды, Гөләйза бу кешенең эзәрлекләвеннән котылды, тынычланып, мәңгелек йокысына талды... Шулчак фәрештәләр аның җансыз гәүдәсен ак канат очларына салып, югарыга алып менеп киттеләр, аста Чирүле Шонталасы, инде карлары эрегән урман-кырлар калды, алар болытлар арасыннан Гөләйзаның туган авылы ягына таба очтылар... Тукта, астан өзелеп-өзелеп бала елаган тавыш ишетелә, бу бит улы Гыйниятулла тавышы! Әнә ул, нәни кулларын сузып, ак болытка әйләнгән әнисенең рухы артыннан йөгерә... «Әни, мине дә ал!» дип елый... Гөләйза белә – улы да тиздән ак болытка әйләнеп, аның янына килер, ул да җирдәге бу эзәрлекләүләрдән, газаплардан котылыр, мөселман килеш, җаны күккә ашар...

Гөләйза баласы елаган тавышка уянып китте, Гыйниятулла да бүген борчыла, рәтләп йоклый алмый иде. Гөләйза аны күкрәгенә кысты, йокы аралаш имезде, үзе һаман теге саташулы төше турында уйлады... Көндез алпавыт йортында булган хәлләр, исерекнең чалшайган йөзе, өзелгән дисбесе тагын күз алдына килде... Төшенә кергән Әкълимә карчык, авыл зиратындагы кабер, үзенең башта анда кереп ятуы, аннан фәрештәләр канатында күккә ашуы исенә төште... Ә аста, «Әни, мине дә ал!» дип, улы йөгерә иде... Димәк, тиздән алар икесе дә китәчәк...

## Кызылъярда сорау алулар...

Икенче көнне иртүк торуга, Мейснер Котош атакае белән киңәшеп алырга булды, чөнки кичәге хәлләрдән соң бер карарга килергә кирәк иде. Сорау алуларда пристав җаваплы булса да, хөкүмәт эше белән йөргәндә, йөгәнсезлеккә юл куярга ярамый, чөнки моның бер очы чыгуы бар. Ә Шахт кичә ычкынды, эш вакытында эчеп исерүе үзе бер зыянлы булса, эчкән баштан котырып китеп, кешегә кул күтәрүе җинаять белән тәмамланырга мөмкин иде. Әгәр теге хатын кичә үлгән булса? Хәер, Шахт ул чагында да аның үзен гаепләп калдырыр иде... Ә бүген андый эшкә юл куярга ярамый, чөнки бүген ирләрдән – башбирмәс татарлардан сорау алу булачак. Алар моны Кыр Шонталасы авылында эшләргә тиеш, әмма Мейснерның анда баш тыгасы килми, чөнки ул авылның усаллыгы турында хәбәрләр Чистайга хәтле килеп ирешә. Ярты авыллары керәшен татары дип язылган булса да, берсе-бер христиан динен тотмый, үзләрен Кызылъяр чиркәвенә куып та алып барып булмый, ә мәчетләрендә өелеп яталар икән. Боларын Котош авылы атакае сөйләде, ул үзе дә Кыр Шонталасына барырга шүрләп тора.

– Дөрес әйтәсең, Генрих Фридрихович, Кыр Шонталасы белән болай гына

булмый... Алар бөтен тирә-якны мөселманлыкка кайтырга котыртып ятучылар бит! Бер Ишугы гына ни тора!

– Анысы кем тагы?

– Безнеңчә исеме – Измаил Ефремов, татарчасы – Ишмөхәммәт Уразманов, җитмешне узган карт коткычы! Бөтенесен шул бутап ята. Бүген сорау алу исемлегендә ул беренче тора.

– Аның бу Пелагея-Гөләйза эшенә катнашы бармыни?

– Аңа да катнашы бар, башкаларына да... Әйттем бит инде, исламга кайтырга төп котыртучы ул!

Шулчак бүлмәгә Алексей Шахт килеп керде, ул инде тагы өстәгән, тиле көчен кая куярга белми иде. Мейснер белән попның сөйләшкәнен ул да ишетеп калды, шуңа күрә үз фикерен әйтеп калырга ашыкты.

– Ботыннан асып куярга кирәк ул карт фетнәченең! Мин аның турында күп ишеттем. Аны Себергә сөрмичә, монда тынычлык булмаячак! Бүген үк аяк-кулларына богау салырга кирәк!

Болар хакында азмы-күпме Мейснер үзе дә белә иде, Чистайда вакытта бу хакта күп сөйләделәр, кайбер абруйлы кешеләр аша аның үзенә дә чыгып карадылар. Әмма Мейснер хөкүмәт эшендә алай астыртын гамәлләрне өнәп бетерми, аңа гаделлек булсын. Тик гаделлек тә һәркемнең үзенеке булып чыкты. Хөкүмәт, судлар бу татарларны христиан диненнән киткән өчен гаепли, ә аларның бу диндә булганнары да юк икән бит! Пелагея-Гөләйза тарихы да бик тетрәндергеч, урысның телен-динен белмәгән килеш, кешене ничек христиан динен тотарга мәҗбүр итәсең? Хатынның үз дине бар, ничек аны мәҗбүриләп үз диненнән аерасың? Моңа Мейснерның да җавабы юк, аның төп эше – бу татарлардан сорау алуда катнашу һәм, әлбәттә, тәртип бозылса, чара күрү. Бу становой приставның үз-үзен тотышына да кагыла иде.

– Алексей Иванович, әйдәгез, ул богауларны читкә куеп торыйк әле! – диде Мейснер. – Безнең бу юлы төп эшебез – сорау алу, аның беркетмәләрен Чистай земство судына алып кайтып тапшыру. Әгәр без кичәге кебек кул сугышына барып җитсәк, эшебез тукталырга мөмкин, без дәүләт бурычын үтәмәгән булабыз.

– Кичәге дигәннән! Кайда ул хатын?

– Кайда булсын – өендә! Безгә аны кулга алырга, дигән әмер юк, сорау алырга, дигән бурыч кына. Без моны эшләдек.

– Ул хатынны күзәтү астына алырга, авылдан чыгармаска, дип, сотник расписка бирдеме?

– Әйе, Камаев андый расписканы бирде, ул Пелагеяны күзәтәчәк.

– Ә башкаларын? Ирен, мулланы?

– Аларына да кирәк идемени?

– Алар бөтенесе дә бер шайка – барысын да күзәтергә! Барысына да суд булачак!

– Ярар, сотник Камаев безне озатырга килә әле ул, шунда алырбыз ул расписканы... Тагы киңәшәсе нәрсә бар иде. Алексей Иванович! Бүген сорау алуны әллә Кыр Шонталасында түгел, ә Кызылъярда уздырыйкмы?

– Нигә – Кызылъярда? Анда барысы да тәртип, чөнки урыслар гына яши! Ә сорау алуны ул басурманнарның үз ояларында уздырырга кирәк, сөяләренә дә шунда басарга кирәк!

– Сөяләренә бастыра торган халык яшәми анда, – дип, сүзгә Котош атакае да кушылды. – Ул авылга начар ният белән кергән кеше кире чыкмаска

мөмкин... Элек-электән шулай, анда поплар да керергә курка! Алар үзләре бер дәүләт – уттан да, судтан да курыкмыйлар, мишәр токымы, морзалар...

– Без хөкүмәт эше белән йөрибез, атакай! Кирәк икән, тезләнеп каршы алырлар! Сез ул басурманнарны аздырып бетергәнсез! Ничек инде үз кул астыңдагы колның кубызына биергә мөмкин – башыма сыймый бу хәл?!

– Алар кол түгел, Алексей Иванович, ә дәүләт крестьяннары, заманында корал тотып патшага хезмәт иткән татарлар! Һәм бу татарлар белән саграк кыланырга.

– Ә ник җинаятьчеләр исемлегендә соң алар?

– Татарларның дәүләт алдында төп гаепләре – христиан динен санламаулары, аны тотмаулары, үз диннәренә өндәүләре, – дип җавап бирде аңа Мейснер. – Законнар шундый, Алексей Иванович, бу дәүләт өчен алар җинаятьче санала. Алай да, мин бүген сорау алуны Кызылъярда уздыру яклы. Моның башка сәбәпләре дә бар. Менә Николай атакай әйтә, Кыр Шонталасында бу авылдагы кебек алпавыт йортлары юк, сорау алуны каравыл өендә уздырырга туры киләчәк, ди. Ә нигә кирәк бу безгә, абруйлы хөкүмәт комиссиясенә караңгы алачыкка кереп утырырга? Ә Кызылъярда – үзәк, әллә ничә казна йорты, таш чиркәү, алпавыт утарлары – барысы да кул астында. Андый-мондый хәл булса, хәрбиләр, полиция дә бар. Син үзең дә шунда яшисең бит әле, шулаймы?

Әйе, Шахт Кызылъярда яши иде, ул бирегә Зөя якларыннан күчерелде. Аның хәзер татар төбәгендә җир биләмәләре, Кызылъярда крепостной крестьяннары бар. Ә менә гаиләсе юк, дисәң дә була, бичара хатыны аның туктаусыз тукмауларыннан җан тәслим кылды, балаларын тәрбияләргә Шахтның ата-анасы алды. Хатыны булмаса да, Шахтның чиркәү кадәр йорты хатын-кызсыз тормады, кол-крепостной марҗалар тулысынча аның карамагында иде, чукындырылган татар хатын-кызларын да чыбыркылап бирегә алып кайтты ул. Кичәге татар хатынын да, суд карары чыгу белән, монастырьга алып киткәнче, өенә алып кайтып, ул үзе «чукындырачак», Шахт моны уйлап куйды инде. Чыбыркылап чукындырачак! Басурман булса да, чибәр иде, каһәр, борынгы ханнар-солтаннар нәселеннән икәне кыяфәтеннән сизелеп тора! Менә хәзер аңа хезмәт күрсәтәчәк бу сылу татар патшабикәсе! Бу уеннан аның күңеле күтәрелеп китте, теләбрәк сөйләшә башлады.

– Әйе, мин Кызылъярда яшим, – диде ул. – Әйе, сорау алуны анда да оештырырга була. Кыр Шонталасы Кызылъярдан ерак түгел, атлы казаклар җыеп алып килер ул басурманнарны. Шунда чиркәүдә тагы бер тапкыр чукындырып та чыгарырбыз, шулай бит, атакай?

Котош побы белән Мейснер бер-беренә карашып алдылар, Шахт һаман үзенекен алга сөрә иде.

– Бу юлы безнең эшебез алардан сорау алу гына, Алексей Иванович! Чиркәүгә керергә теләсәләр, күптән кергән булырлар иде инде, шул кермәгән өчен суд юлында йөриләр бит.

– Ярар, Казан аларны керерлек итеп кайтарыр! Килештек, атларны әзерләсеннәр, кузгалабыз!

Үзләрен озата килгән авыл башлыгы Әбуталиптан өстәмә белешмә яздырдылар, ул Хәким Камаевны һәм Әхмәт мулла Әхмәтовны да күзәтеп торырга, аларны авылдан чыгармаска, дип үз өстенә йөкләмә алды, шуны раслап, имзасын куйды. Аннан юлга кузгалдылар, авыл халкы кузгалып, тагы килеп җиткәнче, моннан исән-имин китеп баруың хәерле иде...

...Чыннан да, Кызылъяр авылы аларны гөрләп торган тормыш белән

каршылады – дәртләнеп биегән чиркәү чаңнары, көмешкәдән башлап дуңгыз итенә кадәр сатыла торган базарлары, купшы алпавыт йортлары, түрәләр туктала торган казна өйләре, хөкүмәт биналары – монда барысы да бар иде һәм монда урыслар яшәгәнлеген алар әллә кайдан кычкырып тора иде... Чистайдан килгән мәртәбәле комиссия дә эшен хөкүмәт бинасыннан башлады – Кыр Шонталасына татарларны алып килергә атлы казакларны җибәрделәр, аларны озата барган палисайларның кулына сорау алынырга тиешле кешеләрнең исемлеген тоттырдылар. Исемлектә беренче булып Ишмөхәммәт үзе, аның улы Бикмөхәммәт, Бикмөхәммәтнең хатыны Хөснижамал тора иде, аларның төп гаебе булып исламга кайтулары санала... Шулай ук Гөләйза эше буенча утызлап татардан да сорау алачаклар иде.

Сорау алу башлангач, комиссия каршына да беренче булып Ишмөхәммәтне керттеләр. Бу еллар эчендә ул шактый олыгайган, сакалы агарган, инде яше дә җитмешне узган иде, әмма әле кыяфәте гайрәт чәчеп тора, бу карт арыслан теләсә кайсы вакытта үзенең дошманнарын ботарлап атарга мөмкин иде. Картның башында түбәтәй, өстендә татар җиләне, аның астыннан буй-буй ыштаны күренеп тора, аягында киезката, кулында чукмарлы таяк... Түрдәгеләр гөрзидәй дәһшәтле бу таякка бераз шүрләп карадылар, Ишук карт аны теләсә кайсы вакытта эшкә җигәргә мөмкин иде. Пристав Алексей нәфрәт тулы күзләрен аңа текәде, кодрәтеннән килсә, ул бу картны хәзер үк, кул-аякларын богаулап, төрмәгә ыргытыр иде, нигә бу дин дошманнарыннан сорау алган булып азапланырга?! Әмма, имеш, тәртибе шундый – шул басурманнардан чакыртып сорау алырга, аның рапорт-хисабын судка тапшырырга, алар карар чыгара, шуннан соң гына боларны монастырьга яки төрмәгә олактырырга мөмкин.

– Йә, картлач, сөйләп җибәр, кем син?

– Минем татарча исемем Ишмөхәммәт, хөкүмәт кәгазьләрендә Измаил Җәпримов дип язылган, яшем җитмеш өчтә...

– Измаил Ефремов булгач, син христиан кешесе исәпләнәсең, шулай булгач, кулыңа Библия тотып, дөресен сөйләргә ант-присяга бирергә тиешсең! Николай атакай, бир үзенә изге китапны!

Котош побы, кичәге Библияне күтәреп, Ишмөхәммәт каршына килде, әмма аның китапны кулга алмасын белде, аламы соң инде бу карт фанатик?! Әле башка керәшеннәрне дә котыртып куйгандыр, әнә алар урамда кара болыт кебек кайныйлар... Инде бу яңа пристав кына кичәге кебек кызып китә күрмәсен, сөякләреңне дә җыеп ала алмассың!

– Мин христиан түгел, мөселман, бары тик Коръән тотып кына ант итә алам, – диде Ишмөхәммәт, сакал йоны да селкенмичә.

– Юк, син христиан, православ динендә, чиркәү кенәгәләрендә дә, ревизия кәгазьләрендә дә шулай язылган – керәшен татары Измаил Ефремов, диелгән! Син монда күзгә төтен җибәрмә, карт төлке! Үләр алдыннан булса да ялгышыңны таны, тәүбә ит!

– Минем сезнең алда тәүбә итәрлек ялгышым юк. Гомер буе мөселман булып яшәдем, инде Аллаһ каршына да мөселман булып барырга язсын!

– Барырсың! Бик тиз шунда олагырсың! Әмма анда без сине бу чаплашкаңны салдырып, муеныңа тәре асып җибәрербез! А ну сал башыңнан бу карга оясын!

Шулай диде дә, ул мәче тизлегендә картның түбәтәенә үрелде, әмма Ишмөхәммәт аның кулына каршы саллы таягын куеп өлгерде, пристав, сыны катып, читкә тайпылды, ахрысы, сөяге чатнады. Ул, яралы ерткыч кебек үкереп,

почмактан-почмакка бәргәләнде, имгәнгән кулын бер өскә күтәрде, сызлауга чыдый алмыйча, бер күкрәгенә кысты. Бу – кичә Гөләйзаны бугазлаган кул иде, һәм Аллаһы Тәгалә аны тиз тотты... Приставны тагы күрше бүлмәгә алып чыгып киттеләр, кулын чүпрәк белән бәйләп, муенына асып куйдылар, көмешкә эчертеп, авыртуын бастырырга тырыштылар. Сорау алуны Мейснер тагы үзе генә дәвам итте.

– Бу таягың өчен сиңа җавап бирергә туры килер әле, Измаил Ефремов! – диде ул. – Син хөкүмәт эшен башкарган кешегә каршылык күрсәттең, корал кулландың.

– Бу корал түгел, минем таянып йөри торган таягым, мин аннан башка сезнең каршыгызда басып тора алмас идем. Икенчедән, минем түбәтәйнең хөкүмәт эшендә ни катнашы бар? Мин аны гомер буе кидем һәм киячәкмен, Алла язса! Татарның түбәтәе башы белән бергә генә салына, шуны онытмагыз!

Мейснер бу татар картына куркып та, сокланып та карады, юк, бу тиле фанатлык түгел иде, бу аның үз абруен белүе, диненә тугрылыгы, үлгәнче аны бирмәячәге турында дәлиле иде! Кая анда динне бирү, хәтта башындагы түбәтәен дә бирми татар! Ни әйтсәң дә, Чыңгыз хан нәселе шул, борынгы Болгар-Биләрләрнең дәвамчысы! Болар белән сак булырга кирәк, әнә пристав та кулсыз калып тәгәрәп ята хәзер...

– Йә, сөйлә, Измаил Ефремов, моңа кадәр хөкемгә тартылганың булдымы?

– Әйе, башкалар белән бергә үз динемә кайтканым өчен, сезнеңчә әйткәндә, «мөселманлыкка аздырганым» өчен, аерым җинаять эше ачтылар... Имеш, хакимияткә каршылык күрсәткәнем өчен дә күзәтү астында торам.

– Син монда пристав Алексей Ивановичка үзеңне мөселман итеп күрсәтергә тырыштың. Ә хөкүмәт документларында син ничек теркәлгән – мөселманмы-керәшенме?

– 1834 елгы сигезенче ревизия документларында мин Кыр Шонталасы авылыннан керәшен татары, дип теркәлгән.

– Соң, шулай булгач, кем буласың инде син – христиан булмыйча! Нигә карт башың белән кеше башы бутыйсың син, Ефремов?

– Анда язылу ул әле бернәрсә дә аңлатмый, түрә әфәнде! Менә монда язылганы мөһим!

Шулай диде дә, Ишмөхәммәт күкрәгенә төртеп күрсәтте. Теге заманнарда көчләп чукындырылган ата-бабалары сәбәпле, аның да нәселе документтан-документка керәшен булып күчеп йөри, аны тутыручылар синнән сорап та тормыйлар, ул шуларны сорау алучыларга да аңлатырга тырышты.

– Моннан йөз ел элек ата-бабаларыбызны, Поп елгасына куып кертеп, көчләп чукындырганнар, шуннан бирле безнең барыбызны да керәшен, дип йөртәләр. Әмма без барыбыз да ислам динендә, без хөкүмәт кәгазьләрендә генә христиан, ә тормышта чын мөселман!

– Сезнең барыгызны да менә шул «хөкүмәт кәгазьләре» буенча хөкем итәчәкләр бит, Ефремов! Аларда сез барыгыз да – христиан, һәм диннән чыккан христиан буларак җавап тотачаксыз. Инде үзең генә азып калмагансың, асрамага алган улыңны да харап иткәнсең! Менә ул да хәзер мәхкәмә каршына басачак.

– Әйе, авылдашым Гөлзаданың, сезнеңчә Фекла Тимофееваның, улын үземә тәрбиягә алдым, гаиләм әгъзасы итеп яздырдым, аның өчен бөтен налогларны үзем түлим. Хөкүмәт документларында аның исеме Иван, без аңа мөселманча Бикмөхәммәт дип исем бирдек. Аңа хәзер 18 яшь, үз гаиләсе, баласы бар...

– Аны нәрсә дип үз динеңә өстерәдең инде? Йөрсен иде Иван булып, хәзер кайгысы булмас иде!

– Соң, без мөселман булгач, ул кем булсын инде? Анасы мөселман, мин мөселман, ул башка тормышны белми дә, чукынганы да, аларча укынганы да юк. Моннан өч ел элек мин аны керәшен кызына өйләндердем, Хөснижамалга, ул да ислам динендә... Әйттем бит инде, әфәнде, без кәгазьдә генә керәшен, ә тормышта барыбыз да мөселман! Ассагыз да, киссәгез дә, хәтта яткырып суйсагыз да яңадан урыс диненә кайтмаячакбыз! Без Себереннән дә, төрмәсеннән дә курыкмыйбыз, бу хөкүмәттән башкасын көтмибез дә! Безгә иман кадерле! Безгә татар булу кадерле! Һәр керәшен шулай дип әйтәчәк, сорап та тормагыз! Улым да, оныкларым да шулай дип әйтәчәк!

– Ярар, анысын үзеннән сорарбыз, бар, чыгып тор!

Ишмөхәммәт чыгып киткәч, Мейснер белән Котош побы киңәшеп алдылар. Әгәр һәр кешедән сорау-сорашу шулай озак барса, алар монда атна буе ятачаклар иде. Дилбегәне приставка бирсәң, ул сугыша ук башлаячак, хәзергә кысылмый торуы хәерле. Әмма болай җентекләп торудан да мәгънә юк, болар инде төзәлә торган кешеләр түгел. Нинди христиан булсын инде болар?! Кулларына Библия тотарга да җирәнәләр бит!

– Болар белән озак маташырга кирәкмәс, Генрих Фридрихович! – диде Котош побы. – Болар барыбер үзләренекен бирмәячәк, үгетләп торудан мәгънә юк! Әнә, Казанда үгетләрләр, безнең эш аларны шунда олактыру...

– Минем үзем өчен дә ачыклыйсым килә, Николай атакай! Нигә алар шулай үз диннәренә ябышып яталар икән? Үлемнән дә курыкмыйлар бит! Минем әле дин өчен үлемгә барган кешеләрне күргәнем юк иде... Шуңа акылымны җыя алмыйча торам, алар турында күбрәк беләсем килә. Әгәр без аларга Коръән белән ант итәргә рөхсәт иткән булсак, үзләрен ничек тотарлар иде икән?

– Без керәшен татарларына берничек тә Коръән тоттырып ант иттерә алмыйбыз, Мейснер әфәнде, ул чагында аларның мөселманлыкларын рәсми рәвештә тану булачак бу! Ә менә мөселманнары Коръән тотып ант итә.

– Йә, сөйләүләрендә аерма бармы соң?

– Шаккатарлык аерма, Мейснер әфәнде! Керәшен татары Библия тотып, теләсә нәрсә ялганларга мөмкин, чөнки ул аның изгелегенә ышанмый, шуңа күрә, үзен аклау өчен, әллә нәрсәләр уйлап чыгара. Ә менә Коръән тоткач, аларның кыяфәтләре үк үзгәреп китә, әйтерсең лә Ходайның үзе каршында басып торалар! Коръән тотып ялган сөйләүдән алар уттан курыккандай куркалар, менә хәзер яшен сугып үтерер, куллары корыр, дип котлары чыга... Татар кешесе, чын мөселман, Коръән тоткач, бары тик дөресен генә сөйли.

– Менә бу керәшен татарларына сорау алганда тоттырып карарга иде Коръән, ничек сайрарлар иде икән?

– Елый-елый шул Коръәнне үбәчәкләр, башларын бәрә-бәрә мөселманлыкка ант итәчәкләр, хөкүмәт кешеләренең Коръән тоттыруын – үзләрен тану, дип кабул итәчәкләр!

– Алайса, кирәкми! Тегеләй дә юк икән, болай да... Измаил Ефремовның асрамага алган улын кертсеннәр, анысы нәрсә сөйләр икән?

– Әй, Мейснер әфәнде, Мейснер әфәнде! Нинди асрамага алган улы булсын, үз улы бит ул аның!

– Ничек – үз улы?! Фекла Тимофееваның улын тәрбиягә алдым, ди бит!

– Соң, Фекла Тимофеева аның үз хатыны бит инде, моның шулай икәнен бөтен татарлар белә, ә менә урысларга теләсә нәрсә ялганлыйлар!

– Тукта, тукта, Николай атакай! Менә бит ревизия һәм чиркәү кенәгәләренә язылган – Измаил Ефремовның хатыны Настасия Афанасьева, диелгән, Фекла Тимофеева димәгән!

– Әлбәттә, шулай, әмма бу аның беренче хатыны, ә икенчесе – Фекла Тимофеева. Әмма безнең христиан динендә ике хатын белән яшәү тыелган булгач, алар менә шулай маташтыралар инде, үзләренчә никах укыталар да яши башлыйлар. Никахын да бездән яшерәләр, бергә яшәүләрен дә яшерәләр, балаларын менә шулай алдым-бирдем итеп йөртәләр... Һәр гамәлләре өчен бүген тотып утыртырлык инде бу татарларны, артыннан йөрүче генә юк.

– Гаҗәп хәлләр икән монда! Тукта, тукта, бу Фекла Тимофееваның кичә без сорау алган кызы... Пелагея-Гөләйза... нәрсә, ул да шушы Измаил Ефремовның кызы булып чыгамыни инде?

– Әйе, олы кызы... Шуңа күрә Ишук койрыгына ут капкан ата мәчедәй чабулый инде Чистай белән ике арада! Судларның сузылуы да, эшнең тоткарлануы да, Пелагеяның һаман шул басурман белән яшәп ятуы да, балаларының чукындырылмавы да шушы Ишук аркасында гына! Барысын да сатып ала бу татарлар! Үзләренә кирәккәндә, ялганына да баралар...

Мейснер хәзер барысын да аңлый башлады... Әйе, бу Пелагея мәсьәләсендә аның үзенә дә зур-зур кешеләр чыгып карады, татарлар гына түгел, старовер урыс байлары да кылларын тартты. Әмма ул – хөкүмәт кешесе, закон яклы, ахыргача гадел булырга тырышты, шуңа күрә уңга-сулга аумады. Ә гаделлек кайсы якта иде соң? Монысын ул урыннарга чыккач кына аңлый башлады – гаделлек менә бу татарлар ягында иде. Алар беркемне көчләми, беркемгә үз диннәрен такмый, беркемгә зыян салмый, үз диннәрен һәм кемлекләрен сакларга тырышалар иде. Әмма бу мөмкин хәлме соң?! Бу бит хисапсыз корбаннарга гына китерәчәк! Дөньяга аек карарга күнеккән алман кешесе бу корбаннарны аңламый да, кабул да итми иде, шуңа күрә кызганудан ары уза алмады.

Ул арада сорау алырга Бикмөхәммәтне керттеләр. Ул унсигез яшьләр тирәсендәге егет солтаны, атасы кебек Алып бәдәнле, карчыга карашлы, кырыс кыяфәтле татар иде. Мейснер шуңа да игътибар итте – бу як мишәрләрендә Чыңгыз-Бату ханнарның дала татарлыгы да, Болгар-Биләр солтаннарының аурупалы төсмерләре дә чагыла иде. Алар арасында кысык кара күзле, җәлпәгрәк каратут йөзле, ат кылыдай кара чәчлеләре дә бар, шул ук вакытта арыш саламыдай аксыл чәчле, күк йөздәй зәңгәр күзле, озынча ак йөзле һәм аурупалы туры борынлылары да очрый. Ә менә бу егеттә икесе бергә кушылган һәм антик риваятьләрдәге милли каһарман сурәте килеп чыккан. Кичә сорау алуда булган апасы Пелагея да шундый гүзәллек үрнәге иде бит, әрәм булып ята икән бу халык шушы кара урманнарда – алман Мейснерның башына әнә шундый уйлар да килде...

Бикмөхәммәт тә Библия тотып ант итүдән баш тартты, үзен мөселман, дип атады.

– Татарча исемем – Бикмөхәммәт, ә хөкүмәт һәм чиркәү кенәгәләрендә Ибан Денисов дип язылган, – дип сөйләп китте ул. – Яшем унсигездә. Моңа кадәр хөкемгә тартылганым булмады.

– Ә хәзер ни өчен тартылганыңны беләсеңме?

– Ислам дине өчен, дип уйлыйм...

– Әйе, дөрес уйлыйсың, син бөтен документлар буенча да – христиан кешесе, православ динендә, әмма аны тотмыйсың булыр? Дөрес әйттемме?

– Әйе, дөрес әйттең – мин сезнең кәгазьләрдә генә керәшен, ә чынлыкта – мөселман, үз динемне тотам.

– Ә аны кайда өйрәндең?

– Анам Гөлзада янында торганда ук, аннан беренче догаларымны өйрәндем... Ишмөхәммәт гаиләсенә күчкәч, аның балалары белән бергә намазга бастым. Безне ислам динен тотарга беркем мәҗбүриләмәде, читтән әллә ни тыю да булмады...

– Моны ничек аңларга?

– Чиркәү кенәгәләрендә керәшен дип язылсак та, без беркайчан чиркәүдә булмадык, чукынмадык, алар динен тотмадык. Моны поплар белә иде, бездән чиркәү өчен тиешле акчаларын алалар иде дә артык бәйләнмиләр иде... Без аларга, алар безгә күз йомдык. Кайбер авылларда поплар бик яман кыланганнар, бездә алай ук булмады, халык моңа ирек тә бирмәс иде.

– Ирек бирмичә, нишләрләр иде?

– Каршы чыгарлар иде. Бездә дә попларның йөреп-йөреп караган вакытлары булган, халык аларны капкасыннан да кертмәгән, казыкка тотынган. Шулай үз динен саклап калган. Хәзер дә шулай булачак, үз иреге белән беркем урыс динен алмаячак.

– Сүз урыс динен алу турында бармый, ә шул алган динне тоту турында бара, Иван Денисов! Ә аны тотмаган, диннән чыккан өчен җәза каралган. Син моны беләдеңме?

– Элегрәк шулай булганын беләдем, безнең әби-бабайларны дин өчен хәтта тереләй яндырып та үтергәннәр! Әмма Әби патша татарларга дин иреге бирде, көчләп дингә кертүне туктатты бит! Без шул закун буенча яшәргә тиеш.

Әйе, Мейснер ул фәрманнарны яхшы белә, милләттәше Екатерина II тәхеткә килү белән, чукындыру конторасын яптырды, ә инде 1773 елда Синод указы белән бөтен диннәргә ирек бирелде, чиркәүгә башка диннәр эшенә кысылу тыелды, мәчетләр салырга рөхсәт ителде. Әмма бу элек чукындырылганнарга исламга кайтырга ирек дигәнне аңлатмый, аларга христиан диненнән чыгу катгый рәвештә тыелган иде. Һәм күп керәшен татарлары шуның белән янды – дин иреге килде, дип, христианлыкны ташлап, үз диннәренә кайта башлады һәм шул сәбәпле закон бозучылар исемлегенә эләктеләр. Ә аның нәтиҗәсе – Себер, төрмәләр һәм монастырьлар, ике арада калган халык, һаман дәвам иткән суд эшләре... Дин иреге, дип башлагач, көчләп чукындырылганнарга үз диннәренә кайтырга да рөхсәт бирергә кирәк иде, бу хәлләр дә килеп чыкмас иде. Мөгаен, чиркәү моңа юл куймагандыр, татарлар һәм угры-финнәр китсә, үзләренә табыш китерә торган ярты халыкны югалталар иде бит! Шуңа күрә аларга теш-тырнаклары белән ябыштылар, юк, православ динен куәтләү өчен түгел, акча өчен эшләде алар моны! Христиан дине хакына эшләсәләр, бу җирле халыкны бераз аңа өйрәтерләр иде, мәрхәмәтлерәк булырлар иде, диннән һәм үзләреннән биздермәсләр иде!

Алман Мейснер боларны кычкырып әйтмәде, әмма башында шул уйлар бөтерелде. Кызганды ул бу татарларны, әмма аларга берничек тә ярдәм итә алмады, чөнки ул хөкүмәт эшендә иде. Бөтен ярдәме – аларга артык каты бәрелмәү, беркетмәләргә ничек бар – шулай язу.

– Гаилә хәлең турында сөйлә, хатының да чукынганмы?

– Әйе, хатыным Хөсниҗамал да үзем кебек исламга кайткан татар, Никитин авылыннан.

– Аның белән чиркәүдә венчаться иттегезме? Поп өйләнешкәнегезне белдеме?

– Юк, без чиркәүгә бармадык, поп та безгә килмәде, без үзебезчә өйләнештек.

– Никах укыпмы? Кем укыды?

Бикмөхәммәт артыграгын ычкындырганын аңлады, хәзер тиз генә ул хатаны төзәтергә кирәк иде. Әлбәттә, алар никах укытып өйләнеште, әмма ул турыда монда әйтергә ярамый, юкса, мулланы харап итәчәкләр.

– Юк, үзебезчә, мәҗлес җыеп кына өйләнештек...

– Хатының да ислам динендәме?

– Әйе, миңа кадәр үк үзебезнең диндә иде, бергә намаз укыйбыз, ураза тотабыз, башка мөселманнар кебек яшибез.

– Балаларыгыз бармы, аларны чиркәүгә алып барып чукындырдыгызмы?

– Мөфлиха исемле кызыбыз бар, аны чукындыру турында уйламадык та! Дин тотарга ул әле кечкенә, әмма исемне үзебезчә куштык. Урыс динен белмибез дә, белергә дә теләмибез, балаларыбызны да мөселман итеп тәрбиялиячәкбез, Алла теләсә!

– Әмма бу төрмә белән бетәргә мөмкин бит, Иван Денисов! Өчегезне өч якка аерып ташларга мөмкиннәр! Син әле яшь, тәүбә итеп, яңадан христиан динен тота башласаң, бәлки кагылмаслар, Казанда үгетләрләр дә кире кайтарып җибәрерләр.

– Адәм баласы кайчан үләсен белми, әҗәл теләсә кайсы вакытта килергә мөмкин... Әгәр ул әҗәл мин урыс диненә кайткач килсә, кяфер булып үләчәкмен бит, Аллам сакласын! Мөселман кешесенең иң курыкканы менә шушы инде – Аллаһ каршына кем булып бара? Өч көнлек гомер өчен мәңгелек тәмугка керер хәлем юк... Үзем дә шулай уйлыйм, гаиләм дә.

– Ярар, бездән әйтү булсын! Хәзергә чык, хатынын кертегез!

Бикмөхәммәт чыгып китүгә, артыннан хатыны Хөсниҗамал килеп керде. Ул кыяфәте белән башкалардан бераз аерылып тора иде – төп кебек нык гәүдәле, чем-кара кашлы, кара күзле бу татар хатынында ихтыяр көче сизелеп тора. Үз-үзенә ышанычы аяк атлауларында ук күренә, мескенлекнең эзе дә юк. «Хатын-кызлары шундый булганны, ир-атлары турында нәрсә әйтәсең бу халыкның!» дип уйлап алды Мейснер, аннан сорау алуга күчте.

– Кемлегеңне сөйлә – исемең ничек, нинди дин тотасың?

– Татарча исемем Хөснижамал, әтиемнең исеме Миндиян. Урысча исемемне белмим, үз авылыбызда яшәгәндә, Марфа дип эндәшкәннәрен хәтерлим, бәлки Мария яки Дарьядыр, хәзер оныттым инде... Динем – ислам, намаздамын, әлхәмдүлиллаһ!

– Үз авылыгызда Маша яки Дашадыр булгач, син керәшен буласың бит инде?

– Анда да яшереп үз динебезне тоттык, ул кәгазьдә генә шулай язылган... Чиркәүдә булмадым, тәреләрен асмадым, үзем дә чукынмадым, балабызны да чукындырмадык. Без башкалар кебек үз динебездә.

– Әмма патша рөхсәтеннән башка христиан диненнән чыккан өчен җәза каралган, Марфа! Сине ireңнән аерып, монастырьга ябарга, икенче кешегә, чын христианга кияүгә бирергә мөмкиннәр! Син моны беләсеңме?

– Әйе, ул турыда сөйләгәннәрен ишеткәнем бар... Ирем ничек – мин шулай. Иремне дин өчен Себергә җибәрәләр икән – мин дә аның артыннан җәяүләп чыгып китәчәкмен! Безнең динебез буенча, беренче – Аллаһ, икенче – ир. Аның сүзе минем өчен канун. Ул белмичә әйтмәс. Ул мине сезнең җәбергә бирмәс...

– Аннан сорап тормаячаклар бит! Тәүбәгә килегез, кайтыгыз яңадан христиан диненә – сезгә берни булмас... Юк икән, өчегезне өч якка аерып ташлаячаклар.

– Алла язмаган эш булмас. Тәкъдиребездә ничек язылган – шулай булыр. Үлмәс борын кабер казып кую безнең халыкта юк. Без өмет белән яшибез. Динне бирү – ул безгә җан бирүдән дә авыр, бу була торган эш түгел. Без намаз саен «Раббым, мөселман хәлдә җаныбызны ал!» дип дога кылабыз. Без Себердән курыкмыйбыз. Анда да татарлар, мөселманнар яши, диләр... Без бары тик кяфер булып үлүдән, үзебездән соң кяфер нәсел калдырудан куркабыз.

– Бөтен татарлар да шундыймы?

– Әйе, бөтен татарлар да минем кебек, мин бөтен татарлар кебек...

– Ярар, бар, чык, күрәм – әйтүдән мәгънә юк...

Хөсниҗамал чыгып киткәч, Мейснер шактый вакыт сүзсез утырды, үзенең кирәкмәгән эшкә ризалык бирүен аңлады. Пристав Шахтның бүген дә сорау алуда катнашмавы, бер яктан, яхшы булды әле, болар белән сугышып бетәр иде.

– Бераз ял итеп алыйк, Николай атакай! – диде Мейснер.

– Шулай, Генрих Фридрихович, туктап бераз сулыш алмыйча ярамас! Йөрәгемә тиде боларның кыланулары! Менә мин дә татар, искедән үк чукынган керәшен, әмма болар кебек диннән-дингә йөрмим бит! Ата-бабаларыбыз кабул иткән православ динен – без шунда калдык һәм бер дә үкенмибез! Башыбызда кайгы юк боларныкы кебек!

– Сездәйләр күпме соң?

– Бар инде, без күп идек, Әби патша барысын да бутап ташлады, шуннан соң керәшеннәр туфан кебек кузгалды, имеш, үз диннәренә кайталар! Мөселманнары котырта, Мейснер әфәнде, котыртып торучы булмаса, бу керәшеннәр әллә кайчан урыска әйләнә иде инде! Аларның муллалары күзләре тонган фанатиклар, кодрәтләреннән килсә, закун рөхсәт итсә, әллә кайчан бөтен урысларны да үз диннәренә кертеп бетерерләр иде! Алар көне-төне үз диннәре турында сөйләп тора ала! Даладагы бөтен кыргыз-кайсакларны агулап бетерделәр инде үз диннәре белән, мондагы чуваш-чирмешләрне әйткән дә юк! Татарның динен дә, телен дә алалар бит, ә урысныкын алмас өчен Себер китәләр... Мин аңламыйм бу хәлне...

Ә алман Мейснер аңлый башлаган иде – бу татарлар ягында гаделлек, шуңа күрә җирле халык аларга тартыла, аларга ышана, аларның ярдәмен күрә.

Мейснер шулай дип уйлап өлгермәде, пристав яткан бүлмәдән ниндидер тавышлар ишетелде, алар шунда ашыкты. Алексей Шахт урыныннан торып утырган, авырткан кулын тотып, ыңгыраша-аһылдый иде.

– Бик сызлыймы? – дип сорады Мейснер, аны кызганып.

– Әллә сынды, әллә чатнады шунда – теш сызлаган кебек газаплый, – диде Шахт. – Чистайга барып, өяз докторына күренмичә булмас... Ну ул картның иманын өшкерәм мин, ник туганына үкенер! Себердә черетәм, юк, монда ук бетерәм!

– Сабыр, Алексей Иванович, сабыр! – дип, Котош побы да сүзгә кушылды. – Алар монда күп, эт өере кебек, үзеңә зыян салмасыннар!

– Башлары ике булса салырлар! Сезнең анда эшләр ничек барды, каршылык күрсәтмәделәрме?

– Без шул Измаил Ефремов гаиләсеннән генә сорау алдык әле, эш әкрен бара, – диде Мейснер. – Авыл халкыннан өйләдән соң сорау аласы булыр, бәлки син дә катнаша алырсың?

– Әйе, мин үзем катнашачакмын! Ул басурманнарга, дин дошманнарына сабак бирергә кирәк, православ динен санламаганнары, мәсхәрә иткәннәре өчен җәза бирергә кирәк! Моны мин үзем эшләячәкмен!

Мейснер инде аны ник чакырганына үкенә башлады – сорау алу тагы җәнҗалга әйләнергә мөмкин иде. Монда инде Ишук карт кына түгел, әнә авыллары белән бүреләр кебек урамда үз чиратларын көтеп йөриләр, артыкка җибәрсәң, бугазыңны чәйнәп өзәрләр.

– Безнең эш аларга җәза бирү түгел, Алексей Иванович, моны суд эшләячәк! Безнең эш бары тик сорау алу гына, һәм шул беркетмәләрне Чистайга алып кайтып тапшыру. Зинһар, артыгын кыланмыйк! Безнең сәбәпле, фетнә, бунт чыга күрмәсен!

Котош попы да Мейснерны яклады, аның бу татарлардан сорау алудан тизрәк исән-имин котыласы килә иде. «Син дә безне җәзалауда катнаштың!» дип, алар авылыңа эзләп килеп, өеңнән өстерәп чыгарачаклар бит! Приставка нәрсә аңа, бер-ике тапкыр күккә шарт-шорт ата да, эше бетте, бөтенесен куып тарата. Ә попның бар коралы – тасмадай теле генә, ә ул татарларга кирәкми.

Инде Алексей Шахтны тынычландырдык, күндердек, дигәндә генә, тагы көтелмәгән нәрсә булып алды. Бераз ашап-эчеп, ял иткәннән соң, инде эшне башлап җибәрәбез, дип торганда, күзләре тәрәзәгә төште. Ә анда, чиркәү белән казна йорты арасындагы бушлыкта, ак кар өстенә тун-бишмәтләрен җәеп, татарлар намаз укый иде! Барысы бергә – керәшене-мөселманы янәшә басып, кар-буранга, кышкы салкынга карамастан, татарлар намаз укый иде! Бүген җомга, ә алар җомга намазын калдыра торган халык түгел, кая анда кяфер арасында гына, каберләреннән кубарылып чыгып та намаз укый торган халык бу! Курку да юк, урыс нәрсә әйтер, монда гел алар гына яши бит, дип уйлау да юк, бу гамәлебездән алга таба үзебезгә зыян килер, дип борчылу да юк – барыбер үзләренекен эшлиләр!

Моны күреп, Шахт тагы котырына башлады, кул сызлавы да онытылды, наганын тартып чыгарып, бүлмә буйлап чабуларга тотынды.

– Менә күрдегезме, менә күрдегезме?! – дип улады ул. – Ә сез һаман сабыр, сабыр, дисез! Ә алар безнең борын төбенә килеп, динебезне мыскыл итеп, басурман молитваларын укыйлар! Чиркәү каршында бит!!! Бер дә чиркәүгә кереп, анда гыйбадәт кылмыйлар, хәшәрәтләр! Бетерәм, атам, барысын да кырып салам хәзер!

– Чү, чү, Алексей Иванович, алай эшли күрмә, үзеңне дә, безне дә харап итәрсең! Аларның бүген изге көннәре бит – җомга, намаз шушы вакытка туры килгәч, нишләсеннәр инде!

– Әле син дә алар яклымы, чиркәү козгыны?! Үзең дә татар булганга аларны яклыйсыңмы?! Бәлки әле үзең дә яшереп кенә алар динен тотып ятасыңдыр?!

– Син нәрсә, Алексей Иванович, без синең белән бер диндә, слава Богу! Урыс белән бертигез...

– Синме урыс белән бертигез?! Син, үз динен сатып, урыска сыенган татарвамы безнең белән бертигез?! Поп булсаң да, сине урыс чиркәвенә кертмиләр бит, чын православлаулар беркайчан да синең арттан гыйбадәт кылмаячак, нечисть! Әнә быкырдап ят шунда үз керәшеннәрең белән!

Шахт татарларга булган бөтен ачуын Котош атакаеннан алды, аның өстенә пычрак атты, дин әһеле дип тормады, аяк астына салып таптады. Котош попы лапылдап барып урындыкка утырды, калтырый-калтырый чукынырга тотынды, әмма бу да сәрхуш приставны туктата алмады. Аның һаман попны талавын күргәч, Мейснер үзе сүзгә катнашырга мәҗбүр булды.

– Николай атакайны юкка рәнҗетәсең, Алексей Иванович! – диде. – Ул бит, яхшымы-яманмы, үз динен ташлап, христиан диненә килгән, аңа хезмәт итә!

Үзе кебек дин алыштырган керәшеннәргә поп булып хезмәт күрсәтә, аларны православлыкта тотып тора. Юкса, ул керәшеннәр урыс попларын бар дип тә белмиләр бит, аңламыйбыз, дип кенә җавап бирәләр!

– Ә нигә алайса менә болары белән дә эшләми?! Бу намаз укучылар арасында керәшеннәр дә бар бит!

– Менә анысын сорау алганда ачыкларбыз, ә хәзергә алар безгә комачау итми, тавыш чыгармыйк, аның ахыры начар бетәргә мөмкин!

– Син, немчина, тоже аларны яклыйсыңмы?! Кара син аларны – берсе татар побы – аларга тимик, ди! Икенчесе – немец католигы – татарларга кагылмыйк, ди! Берсенең дә шушы мәсхәрәгә йөрәге янмый!

– Бу аларның да иле-җире инде, Алексей Иванович! Кайда телиләр, ничек телиләр – шулай гыйбадәт кыла алалар...

– Булмас!!! Мин исән чакта монда андый хәл булмас! Һәм гыйбадәтне дә бары тик безнеңчә генә кылачаклар! Мәҗбүр итәрбез!

Шулай диде дә, Шахт урамга ыргылды, бераздан аның намаз укучылар янында шарт-шорт итеп һавага атканы ишетелде. Әмма татарлар бу тавыштан селкенмәделәр дә, хәтта ул якка борылып та карамадылар, ничек укысалар, шулай намазларын дәвам иттеләр. Пристав аның саен котырды, баш очында наганын болгады, үзе яман итеп сүгенде, ярдәмгә башкаларны да чакырды, әмма аның янына килүче булмады.

– Мейснер әфәнде, тизрәк янына чыгыйк, берәр нәрсә майтара бит бу хәзер! – диде Котош побы, калтырап.

– Әйе, аннан безгә җавап бирергә туры киләчәк – ник карамадыгыз, диячәкләр! Киттек, атакай, күрәләтә кан койдырып булмый инде бу воякадан!

Алар урамга чыкканда, татарлар намазларын укып бетергәннәр, ак кар өстеннән тун-толыпларын җыялар, аякларына киез итекләрен кияләр иде инде. Чәчләре тузган, күзләре калайланган, авыру кулын сөлге белән муенына аскан пристав, наганын болгап, алар арасына килеп керде, соңгы сүзләр белән сүгенә башлады.

– Татарва! – дип акырды ул, бөтен урамга ишетелерлек итеп. – Татарва проклятая! Сезнең урыныгыз әнә анда – чиркәүдә! Хәзер марш шунда барыгыз да! Югыйсә, мин сезгә кайда һәм ничек гыйбадәт кылырга кирәклеген күрсәтәм!

Ул шулай дип, ак сакаллы татар картларын эткәли-типкәли башлады, кайберләрен кар өстенә төртеп тә екты. Аның каршына, җир астыннан калкып чыккандай, тагы Ишмөхәммәт карт килеп басты.

– Без чиркәүгә кермибез, безнең үз динебез, үз Аллабыз, үз пәйгамбәребез, – диде ул, приставның күзенә туры карап.

– Ах, сволочи, здесь я ваш Бог, я ваш пророк! Аллагыз да, муллагыз да мин! – дип, Шахт аңа наганы белән селтәнде.

– Хәзер икенче кулсыз да каласың, Әләксәй Шайтан! – дип, Ишмөхәммәт аңа гөрзи-таягын аркылы куйды.

Шахтның наганы, таякка бәрелеп, карга төшеп батты, татарлар, аны таптап, казна йортына таба юнәлделәр. Пристав, кар өстендә мүкәләп, коралын эзли башлады, поп белән Мейснер аңа кызганып та, оялып та карап тордылар, чөнки ул мескен кыяфәттә иде. Әле генә татарлар Аллаһка тезләнгән урында хәзер ул мүкәләп йөри, мөселманнарның Раббысы аны шулай түбәнәйткән һәм мәсхәрәгә калдырган иде...

– Башы белән карга тыгыйммы, эти? – дип сорады Бикмөхәммәт, мүкәләп йөргән пристав яныннан үтеп барганда.

– Кирәкмәс, улым, татарлар тезләнгәнне типкәләми! – дип җавап бирде Ишмөхәммәт. – Сасыга кагылма, исе чыгар... Аны Аллаһ җәзалаган инде, күрмисеңмени – кеше кыяфәте дә юк анда.

Шулай үзара сөйләшеп, татарлар кабат казна йортына җыелдылар, алардан сорау алу башланмаган иде әле. Комиссия каршына кергәнче, алар киңәшеп алдылар – җавап барысының да бертөрле булырга тиеш иде – «Гөләйзаны беркем дә мөселманлыкка көчләп кертмәде, аңа кем никах укыганны белмибез, балаларына кем татарча исем кушканны да белмибез». Ә инде керәшеннәрнең ни өчен исламга күчүләре турында сорасалар – «православлаудан мөселманлыкка бергәләшеп күчтек», дип әйтергә кирәк. Артыгын сөйләмәскә, алар белән артык каршылыкка кермәскә.

– Бу яңа становой бик явыз күренә, сак булыгыз! – диде Ишмөхәммәт. – Бәлки, салкында бераз кикриге шиңгәндер, әнә, үзе дә кереп килә.

Ул арада теге котырган пристав та, алар яныннан тиз генә үтеп китеп, комиссия бүлмәсендә югалды. Аның кыяфәте суга төшкән сукбай этне хәтерләтә иде – өс-башы юеш, муенына ураган сөлгесе таралып төшкән, авыру кулы җансыз таяк кебек асылынып тора... Ул татарларга күтәрелеп тә карамады, әмма алардан сорауны бу юлы үзе алырга булды. Башта зур бүлмәгә аларның барысын берьюлы чакырдылар, кемнең керәшен, кемнең мөселман икәнлеген ачыкларга кирәк иде. Татарлар сорау алу бүлмәсенә кереп тулдылар, өске җылы киемнәрен ишек төбендә калдыргач, алар барысы да бер кыяфәттә күренә иде – башта түбәтәй, өстә озын җилән яки чапан, кәзәки... Утызлап кеше, яшьләре егерме биштән алтмышка кадәр. Араларында иң карт булган Ишмөхәммәт белән иң яшь булган Бикмөхәммәт монда юк, инде алардан сорау алынган иде...

Пристав аларга нәфрәт белән карап алды, ничек боларның керәшенлеген яки мөселманлыгын ачыкларга икән, дип баш ватты.

– Мөселманнар – уңга, керәшеннәр сулга басыгыз! – диде ул, бу эшнең очына чыга алмагач.

Татарлар барысы да дәррәү килеп уңга бастылар, сул тарафка беркем аяк атламады.

– Что, бараны, барыгыз да басурманнармыни?! – дип ярсып кычкырды Шахт.

– Әйе, барыбыз да мөселманнар, әмма сарыклар түгел! – дип җавап бирде олырак яшьтәге бер татар карты.

Бу сүзләрдән җене котыра башлаган Шахт өстәлгә шапылдатып Библия китереп куйды, Кыр Шонталасы мулласы Бикмөхәммәт Вәлитов авылдашлары каршына Коръән тотып килеп басты.

– Мөселманнар – Коръән тотып, керәшеннәр Библия белән ант итәчәк, – диде Котош побы.

Котош побы шулай диюгә, бөтен куллар Коръәнгә сузылды, Библиягә кагылып караучы да булмады. Моны күргәч, пристав акырып җибәрде:

– А ну, чаплашкаларыгызны салыгыз, антихристлар! Патша түрәләре каршында басып торасыз, шуны онытмагыз!

Әмма ул әйтә дип, беркем дә түбәтәен салмады, чөнки ул татарлык билгесе, мөселманлыкка ишарә иде. Эшнең болай бармасын белгәч, Мейснер үзе сүзгә катнашырга мәҗбүр булды, өстәлдә яткан кәгазьләр арасыннан бер исемлек тартып чыгарды.

– Менә бу исемлектә кемнең мөселман, кемнең керәшен татары икәнлеге бик ачык язылган, – диде ул. – Бу – соңгы ревизия документының күчермәсе,

аның буенча бирегә унтугыз мөселман, унбер керәшен татары чакырылган, моңа өстәп, авылдашыгыз Измаил Ефремов һәм аның асрамага алган улы һәм килене, алардан сорау алдык инде. Шулай булгач, сезнең кемлекне ачыклау безгә берни тормый...

Аннан ул, пристав ягына борылып, аның белән киңәшеп алды:

– Без болай эшлик, Алексей Иванович, боларны моннан чыгарып торыйк һәм сорау алырга берәм-берәм чакырыйк. Эшне мөселманнарыннан башласак, тизрәк булыр.

Приставның тагы үтереп кулы сызлый башлаган иде, аннан да болай, башы чатный, киемнәре юеш... Ул эшне тагы Мейснерга тапшырып, күрше бүлмәгә кереп китте, күшеккән тәнен һәм үле җанын көмешкә белән җылытып, тагы урынга ауды... Татарлардан сорау алу тагы ансыз гына үтте...

Иң беренче булып утыз яшьләрдәге Әбделмән Әбдразәковны керттеләр, ул Коръән белән ант иткәннән соң, үзенең татар мөселманы икәнлеген, дәүләт крестьяны булып торуын әйтте. Мейснер бу татарларның барысыннан да Пелагея-Гөләйза турында сорарга тиеш иде, ул шулай эшләде дә. Җаваплар да, алдан сөйләшеп кергәнчә, бертөрле булды. Башка мөселман-татарлар да Әбделмәннең сүзләрен кабатлады, шуңа күрә эш тиз барды. Сорау алу аша Кыр Шонталасыннан тагы Ишмөхәммәт Закиров, Хөсәен Әмәшев, Мөхәррәм Габделвәлиев, Ислан Батыров, Габделхәким Мәҗитов, Мөхәммәтәмин Юртаев, Әбсәлам Сәфәров, Хөснулла Сәлимҗанов, Фәтхулла Борһанов, Фәтхулла Сәйфетдинов, Гайнетдин Гобәйдуллин, Хәйбулла Зәбиров, Сәйфулла Борһанов, Габделвәли Батыршин, Җәләлетдин Кутеев (Котлымәтов), Ибраһим Ирназаров, Хөснетдин Сәйфетдинов, Сәфәр Баташевлар уза...

Инде чират керәшен татарларына җитте, мөселман буларак сорау алынмаганнар барысы да керәшен буларак җавап тотты. Әлбәттә, аларның берсе дә Библия тотып ант итмәде, сорау алуны присягасыз гына башкарырга мәҗбүр булдылар, бу үзе үк закон бозу иде. Тагы бер катлаулы хәл килеп чыкты – бу керәшен татарларының күпчелеге үзләренең урысча исемнәрен белмиләр иде, кемне әйтеп чакырсаң да, аптырашып басып торалар. Монда инде Котош атакае ярдәмгә килде, ул Кыр Шонталасы керәшеннәрен яхшы белә, шуңа күрә исемнәренең татарчасын да, русчасын да ул әйтеп торды. Шулай итеп, Гайнулла Фәтхуллин документларда Гаврила Константинов булып чыкты, Сөләйман Салаватов – Алексей Иванов, Яхъя Якупов – Алексей Яковлев, Әбдүш Атнаголов – Иван Ларионов, Мәүлет Юзиев – Николай Тихонов икәнлеге билгеле булды. Моннан тыш тагы Яков Куприянов, Иван (Миңнегол) Константинов, Николай Васильев (Колмәмәтов), Пётр Алексеев, Александр Алексеев, Дмитрий Ефремов дип язылган татарлардан сорау алдылар, аларның күпчелеге бу исемнәрен беренче тапкыр ишетә иде...

Түбәтәйле бу керәшен татарларыннан да Пелагея-Гөләйза турында сорадылар, алар барысы да Әбделмән Әбдразәковның әйткәннәрен сүзгә-сүз кабатладылар. Әйе, ул Чирүле Шонталасында Хәким Камаевта кияүдә, аларга кем никах укыган – белмиләр, балаларына кем исем кушканны да белмиләр. Гөләйзаны беркем дә мөселманлыкка көчләмәде, ул туганнан бирле ислам динендә, диделәр. Шулай итеп, Кыр Шонталасыннан бер генә кеше дә Гөләйзаны сатмады, аны ахыргача яклады. Ә инде үзләренең, ничек христиан динен ташлап, мөселманлыкка күчүләре турында сорауга, барысы да, без туганнан бирле мөселман, бары тик чиркәү кенәгәләрендә генә керәшен дип язылган, үзара килешеп, яңадан үз динебезгә кайттык,

дип җавап бирделәр. Җавапның нәкъ шулай буласын Мейснер да, Котош побы да чамалыйлар иде...

Шулай итеп, Кыр Шонталасы татарларыннан сорау алу тәмамланды, аларны кайтарып җибәрделәр. Авыл башлыгы, керәшен Иван Михайловны чакырып кертеп, аннан имзасы куелган белешмә алдылар, анда «Минем күзәтүгә тапшырылган авылдашларым – Фекла Тимофееваны, Измаил Ефремовны, аның тәрбиягә алган улы Иван Денисовны, соңгысының законсыз хатыны Марфаны, шушы эш тәмамланганчы беркая да җибәрмәм һәм таләп иткәндә китереп тапшырырмын», дип язылган иде...

Инде тагы бер кешедән сораштырасы калды, ул – Кызылъяр атакае Мифодей иде… Аны алырга кеше җибәрделәр. Дуамал пристав кысылмагач, эшләре тиз барды, фетнә-гауга килеп чыкмады. Әмма татарларның җаваплары да артык шома һәм бер калыпка салынган иде – берни белмим, берни күрмәдем, бернинди гаебебез юк... Килешеп кергәннәре күренеп тора. Татарлар бер-берләрен бирмиләр – керәшене-мөселманы бер сүздә. Хәер, аларның башка чаралары да юк инде, бер-берләрен сата башласалар, барысын җыеп ябарга туры киләчәк – берәүләрен – керәшенлекне ташлаган өчен, икенчеләрен – шуңа ярдәм иткән өчен. Татарлар моны яхшы аңлыйлар һәм бер-берләренә ябышып яталар...

Ул арада, Алексей Шахт та уянып, алар янына килеп утырды, бергәләп тамак ялгап алдылар. Мейсин аңа татарлардан сорау алуның тәмамлануын, бары тик Кызылъяр чиркәве побы белән генә сөйләшәсе барлыгын әйтте.

– Аның анысы да татарларга сатылып беткән! – дип, Шахт тагы дуларга тотынды. – Шул эчүе аркасында бер эше бармый! Үзем монда яшәмәсәм, боларны белмәс идем. Керәшен авылларына башын тыгарга куркып ята бит ул! Нинди кәгазь сорасалар, шуны язып бирә басурманнарга! Татарлары белән бергә аның үзен дә монастырь төрмәсенә ябып куярга кирәк, бераз акыл керер!

– Син, Алексей Иванович, боларны аның үзенә әйтә күрмә тагы! Ни әйтсәң дә, урыс дине вәкиле, чиркәү башлыгы бит! Аны халык алдында хурлыкка калдырырга ярамый!

– Ул үзен хурлыкка калдырып бетерде инде! Изге динебезне татарларның бер тәпән балына сатты, бер чирек көмешкәгә алыштырды! Тьфү!

Шулай сүгенә-сүгенә, Шахт тагы тәрәзә янына барып басты, урамдагы хәлләрне күреп, тагы акырып җибәрде.

– Вот! Вот! Карагыз! Тагы җыелган бу чуркалар! Чиркәү ишеге төбендә намаз укыйлар бит! Моңа ничек түзәргә кирәк!

Башкалар да тәрәзә янына килде, урамда, чыннан да, татарлар тагы намаз укый иде...

– Икенде намазларын укыйлар, чөнки авылларына кайтып җиткәнче, өлгермәүләре бар, – диде Котош побы. – Болар намаз калдыра торган халык түгел, таш яуса да, аны укыячаклар... Ә монда кар гына ява әле...

Чыннан да, урамда буранлап-буранлап кар ява иде...

Ул намаз укучы ир-атларның да өс-башларын агарткан, әйтерсең лә икенче дөньядан килгән әрвахлар, күктән иңеп, гыйбадәт кылалар иде... Менә берзаман алар бөтен мәйданны, юк, бөтен авылны каплады, урман-кырлар аларның карлы гәүдә-шәүләләре белән тулды, җир белән күк арасын тоташтырды... Һәм бөтен җиһанга илаһи моң таралды...

Аллаһу Әкбәр! Аллаһу Әкбәр!

Ләә иләәһә иллаллаһу!

Аллаһу Әкбәр! Аллаһу Әкбәр!

Шул чакта эңгер-меңгерне ярып, күктән җиргә салават күпере сузылды, ул намаз укучылар өстенә чатыр булып эленде, әйтерсең лә аларны саклап торырга Аллаһ әмере белән күктән фәрештәләр иңгән иде... Һәм бу, чыннан да, шулай, әмма аны иман күзе белән генә күрергә мөмкин иде...

... Ак карга батып, тун итәкләренә чорналып, бүлмәгә Мифодей атакай килеп керде, керү белән, шапылдап урындыкка килеп утырды, тиз-тиз чукынып алды.

– Господи, прости! Господи, прости! – диде ул, калтыранып. – Нәрсә бу?! Чиркәү каршындагы мәйданнан уза алмадым, кемдер читкә этеп чыгарды... Анда татарлар гыйбадәт кыла икән... Куып таратасы идем үзләрен, кемнәрдер мине шунда җибәрмәде, күземә күренмичә, аякларыма уралдылар, әллә ничә тапкыр егылдым... Монда чак килеп җиттем...

– Азрак эчәргә кирәк, Мифодей атакай! Күзеңә чёртиклар, койрыклы җеннәр күренә башлаганчы эчмиләр аны! Имеш, аны кемнәрдер этеп еккан! Татарларың аяк чалгандыр, алар андыйга оста!

Бу яңа приставның усаллыгын белә иде Кызылъяр побы, әмма аңа каршы килеп тә булмый, чөнки артында Биләр атакае тора. Бу явыз хәзер татарларны гына түгел, Мифодейның үзен дә козгын кебек күзәтә, бөтен чиркәү кенәгәләрен пыран-заран китереп бетерде, нәрсә тели – шуны эшли, шуны яздыра. Инде монда чакыртуы да җүнле хәл түгел иде... Әмма чиркәү әһеленнән татарлардан сорау алган кебек кыланырга ярамый, аның белән сораштыру гына уздырырга туры киләчәк. Алдан шулай дип килешкәннәр иде, әмма приставның уянып чыгуы бөтен эшне бозды һәм Гөләйзаның язмышын хәл итте...

– Йә, атакай, сөйләп җибәр, син рөхсәт иттеңме керәшен кызы Пелагеяга басурманга кияүгә чыгарга? – дип, пристав беренче соравы белән үк Кызылъяр побын диварга терәде.

– Ничек мөмкин?! Ничек мондый хәл була алсын инде, господа-әфәнделәр!

Сорашуның тагы талашка әйләнә баруын күреп, сүзгә Мейснер үзе катнашты, ул бары тик суд кәгазьләренә таянып эш итәргә булды:

– Әмма Пелагеяның анасы Фекла Тимофеева, Чистай судында биргән күрсәтмәсендә болай ди бит: «Гөләйзаны Чирүле Шонталасына мөселман кешесенә кияүгә бирер алдыннан, Кызылъяр побы белән киңәштем мин, ул вакытта инде анда яңа атакай иде. Ул чиркәү кенәгәләреннән кызымның исемен эзләде, әмма тапмады, ул керәшен буларак теркәлмәгән булып чыкты. Ничек теркәлсен – ул бит чукындырылмаган иде! Шуннан соң Кызылъяр побы Гөләйзаны мөселман кешесенә кияүгә бирергә ризалыгын бирде... Әйе, кызыңның атасы билгесез, үзе чиркәү кенәгәләрендә керәшен буларак теркәлмәгән, аның безгә бернинди катнашы юк, диде. Шуннан соң кызымны тынычлап мөселман кешесенә кияүгә бирдем», дигән. Шулай булдымы?

Кызылъяр побының аяк астында җир убылып киткәндәй тоелды, башта нәрсә дип җавап бирергә дә белмәде. Салган чагы булгандыр инде, ул боларның берсен дә хәтерләми бит! Шонталадан Ишукның үз тирәсендә бөтерелүен хәтерли, әле тегесен, әле монысын төяп китереп ташлый иде, аңа нindидер кәгазьләр дә язып бирде бугай. Ә нәрсә язды – үтерсәләр дә хәтерләми... Чиркәү кенәгәләренең рәте юк, анда шайтан үзе муенын сындырырлык. Хәзер, «Әйе, Фекла Тимофеева дөрес әйтә, аның кызы чиркәү кенәгәсендә юк», дисә, бу Пелагея-Гөләйза урынына попның үзен утыртачаклар. «Юк, алар чиркәүнең кайда икәнен дә белмиләр», дип дөресен әйтсә, ул вакытта да попны гаепләячәкләр, ник аңлатмадың, дип... Инде нишләргә?!

Аның шабыр тиргә батып, бу хәлдән чыгу юлы таба алмыйча газаплануын күргәч, пристав үзе Кызылъяр побына ярдәмгә килде.

– Христиан дине башлыгының керәшен кызына басурманга кияүгә чыгарга рөхсәт бирүе мөмкин хәл түгел! Әгәр, атакай, син шундый рөхсәт биргән булсаң, үзеңне Себер көтә бит! Син рөхсәт бирдеңме аларга мөселманча никах укытырга, әллә бу ялганмы?

– Ялган, чеп-чи ялган, господа-әфәнделәр! Мин ничек аларга андый рөхсәтне бирим ди?! Алар миннән беркайчан да рөхсәт сорамады! Әле кайчан ул татарларның поптан рөхсәт сорап, мөселманча никах укытканнарын күргәнегез бар?! Алар аны яшерен эшли, аннан соң, никахсыз яшибез, дип күзгә карап алдыйлар! Яшәтерсең ул басурманнарны никахсыз, бу бит хәрам алар өчен!

– Димәк, Пелагеяга мөселман Хәким Камаевка кияүгә чыгарга рөхсәт бирмәдең?

– Юк инде, юк, бог упаси! Как можно?! Берничек тә мин аларга ул рөхсәтне бирә алмыйм! Бирмәдем дә! Чөнки Фекла үзе дә, аның кызы Пелагея дә православлау динендә туганнар, шул диндә яшәделәр, христиан динен бөтен төгәллекләре белән үтәделәр...

Мифодей атакай арттырып җибәрүен үзе дә сизде, әмма ул үз ялганына үзе ышанып, сайравын дәвам итте, чөнки хәзер аңа үзен төрмәдән коткарып калу кирәк иде.

– Христиан динен бөтен төгәллекләре белән үтәгәч, ничек алай тиз генә мөселманлыкка ауды соң ул, Мифодей атакай?

– Димәк... Димәк котыртучылары булган! Алар авыллары белән шундый! Бер Ишугы гына да ни тора – аны йөзләгән поп та җиңә алмый! Кызын да шул котырткандыр!

– Ничек – кызын? Нәрсә, бу Пелагея шул антихрист Ишукның кызымыни?!

Кызылъяр побы телен тешләп, туктап калды, чөнки пристав алдында артыгын ычкындыруын аңлады. Юк, бу татарларны кызганудан түгел, ә андый хәбәрне тиешле урыннарга җиткермәгән өчен, тагы үзенә эләгер, дип уйлады.

– Шулай сөйлиләр бит, – дип кенә котылмакчы булды ул. – Имеш, бу Фекла аның икенче хатыны икән, Пелагея дә үз кызы, тәрбиягә алган Иван да үз улы, әле тагы берничә кызы бар, диләр...

– Һәм сез, христиан дине әһелләре, керәшеннәрнең шулай ике хатын белән законсыз яшәп ятуларына күз йомдыгызмы?! Бу бит үзе үк, барыгызны бер чылбырга бәйләп, Себергә сөрергә җитә!

Мейснер тагы приставны тынычландырырга ашыкты, чөнки эшләр тагы талашка бара иде.

– Соң, алар үзләрен христиан дип санамый бит, Алексей Иванович! – диде ул. – Үзләрен мөселман дип санагач, дүрт хатын белән дә тора алалар, шулай бит, Николай атакай?

– Әйе, Мейснер әфәнде, татар законы буенча, ягъни, ислам дине буенча, аларга берьюлы дүрт хатын белән яшәргә рөхсәт ителә. Әмма алар аерым яшәргә тиеш, һәм ир бу хатыннарның барысына да тигез карарга тиеш. Татарлар алай күп хатын белән мавыкмыйлар, әмма ике белән торучылар бар, бигрәк тә керәшен хатын-кызларын шулай үз якларына тарталар.

– Вот дикари! Кыргыйлар! – дип, пристав тагы сүгенеп алды. – Менә хәзер аңлашыла ул картның ертыла-ертыла җинаятьче кызын яклавы! Әмма озак яклый алмас, бу хәлләр өчен аның үзен төрмә көтә!

– Мифодей атакай, бу Пелагеяның исламга күчүенә тагы кемнәр сәбәпче булды икән? – дип, Мейснер янә сүзгә кушылды.

– Муллалар инде, тагы кем булсын! Кыр Шонталасыныкы да, Чирүле Шонталасыныкы да! Аларга анда кем никах укыган, дип беләсез? Шул авыл мулласы! Татарлар алар никахсыз яшәми, керәшеннәр никах укыта бит, хурланып үләрсең! Алар кем никах укыганны яшерәләр, чөнки моның өчен мулланы төрмә көтә. Балаларына да исемне шул мулла кушкан, тагы кем булсын?!

– Әйе, кичә күрдек без ул мулланы, аның үзен дә хөкемгә тартырлар, мөгаен...

Мейснерның бу сүзләреннән Кызылъяр побы тагы да дәртләнеп китте, чөнки аның өстендәге болытлар таралып бара иде.

– Фекла Тимофееваның элеккеге атакай Трифон Адрееевка нахак бәла ягуы да чеп-чи ялган! Имеш, Пелагея-Гөләйза чукындырылмаган икән, Трифон атакай аның нәсел чыгышын белмәгән икән... Ничек белмәсен ди, чиркәү кенәгәсенә акка кара белән язылган – Фекла үзе дә, аның зинадан туган балалары Пелагея, Федосья, Мария, Иван да – барысы да чиркәүдә чукындырылган керәшеннәр! Имеш, Трифон атакай аның балаларын чукындырмаган икән! Бу мөмкин хәл түгел!

– Димәк, Фекла Тимофееваның әле тагы башка балалары да бар? Нигә алар бу эштә күренми соң? Алары чиркәүгә йөриме, әллә аналары кебек, исламга кайтканмы?

Кызылъяр побы тагы сөрлегеп туктап калды, Мейснерның бу соравына аның төгәл җавабы юк иде. Җавап бар, әмма ул чиркәү файдасына түгел.

– Алары да аналары кебек, исламда инде, – дип мыгырданды ул, аяк астына карап. – Чиркәүгә йөрмиләр, авылларына барсаң, өйләренә кертмиләр, балаларын яшерәләр... Аларны христиан динендә тоту мөмкин түгел, көтүләре белән монастырьга бикләп куйсаң гына инде!

– Фекла Тимофееваның башка балаларын да эзләп табарга һәм җинаять эшенә кертергә! – диде пристав, кырт кисеп. – Сез монда аларны аздырып бетергәнсез, атакай! Эш чиркәү кенәгәсенә язып кую белән генә бетми шул әле ул, бу надан татарлар белән көне-төне эшләргә кирәк! Мифодей атакай сөйләгәннәрне беркетмәгә теркәп куегыз, Мейснер әфәнде, минем авыру кулым белән аны эшләп булмас.

– Мин барысын да язып бардым, Алексей Иванович, борчылмагыз!

– Менә мин үзем дә язып алып килгән идем, аны да калдырам, – дип, Кызылъяр побы өстәлгә аңлатмасын салды. Әмма ул биредә чиркәү кенәгәсен яңадан тутыруын, барысын да пристав Шахт әйткәнчә эшләвен язмаган иде.

Шулай итеп, Кызылъярда көне буенча сузылган сорау алулар бетте, утыз татарның Гөләйзаны яклап сөйләгән сүзләре бер урыс побының ялган күрсәтмәсе белән юк ителде. Һәм Гөләйзага хөкем шушы урыс побы ялганы нигезендә чыгарылачак иде...

## Соңгы суд

Бу юлы пристав Шахт эшне тиз тотты – февраль азагында Чистай земство судына сорау алу беркетмәләрен тапшырды, март башына инде мәхкәмә билгеләнде. Һәм бу җинаять эше Гөләйза турында гына булмыйча, аның ата-анасы, туганнары хакында да иде. Әйе, рәсми беркетмәләрдә эш «Христиан

диненнән мөселманлыкка кайткан Пелагея, Фекла Тимофеева, Измаил Ефремов, Иван Денисов һәм Марфа» турында, дип атала һәм аларның барысын бергә хөкем итәргә тиешләр иде. Пристав боларның барысы бер гаилә икәнлеген, Ишмөхәммәт белән Гөлзаданың законсыз ирле-хатынлы яшәүләрен, Гөләйза белән Бикмөхәммәтнең аларның балалары икәнлеген әйтеп караса да, кулларында моны расларлык дәлилләр булмаганга, анысын куертып тормадылар. Бу керәшеннәрне хөкем итү өчен башка дәлилләр дә җитә иде, һәм ашыгып эшкә керештеләр. Кыр Шонталасы һәм Чирүле Шонталасы авыл башлыклары шушы кешеләрне әйтелгән вакытка Чистайга китереп җиткереп, суд каршына бастырырга тиешләр иде...

Бу хәбәр килүгә, ике авылда да төянеп, иртүк юлга кузгалдылар, андамонда керми генә, туп-туры Чистайга барып кунарга уйладылар. Гөләйза һаман авырып тора иде, аны толыпларга төреп, чана башына утырттылар, балалар әтиләре янына сырышты. Дилбегәне Әбуталип үзе тотты, аларны китереп тапшыру аның өстендә иде, ул шуңа кул куйды, авыр вакытта туганнары янында да буласы килде. Кыр Шонталасындагы чанада Ишмөхәммәт үзе, хатыны Гөлзада, уллары Бикмөхәммәт һәм аның хатыны Хөснижамал иде, авыл башлыгы, аларга ышанып, үзләрен генә юлга чыгарып җибәрде. Хәер, авылда иң абруйлы кеше – Ишмөхәммәт, сотнигы да, мулласы да башта аның белән киңәшәләр, ул кушканча эшлиләр. Чистайга кичтән барып кунуны да Ишмөхәммәт үзе хәл итте, бу турыда хәбәрне кызы белән киявенә дә җиткерде, һәм менә хәзер алар юлда...

Чистайда бу юлы да Исмәгыйль морзаларда тукталдылар, Хәлимәбану абыстай Гөләйзаларны үз туганнары кебек каршы алды. Теге судлардан соң инде алты ел вакыт үтеп киткән, Гөләйзаның инде өч баласы тәгәрәп үсеп килә, ә һаман тынгылыкта калдырмыйлар икән әле! Иртәгә тагы суд, ди, бу юлы инде әти-әнисе һәм туганнарын да хөкем итәләр икән. Шуңа күрә ирләр аерым очрашып, бу турыда ныклап сөйләшеп-киңәшеп алырга булдылар. Чистай морзалары алты ел вакыт эчендә Ишмөхәммәткә дә, аның кызы Гөләйзага һәм башка мәкруһ татарларга да нык булыштылар, аларга каршы ачылган җинаять эшләрен туктатырга тырыштылар. Эшләр сузылды, әмма бөтенләй ябылып бетмәгән икән – Биләр побы һәм яңа пристав ярдәмендә, яңадан калкып чыкты. Бу юлы бик яман тотындылар, ярдәмгә теге старовер судья да юк, моңа кадәр бер тәпән балга теләсә нинди кәгазьне язып биргән җирле поплар да куркышып калдылар, татарларга гел киресен эшлиләр, түрәләрне инде әйткән дә юк. Мәхкәмәләренә әзерлексез барсаң, шунда ук утыртып куюлары да бар, Аллам сакласын!

Бу юлы кичке якта Гомәр абызларга җыелырга булдылар, ул үзе чакырган иде, әйтер сүзем бар, диде. Гомәр абыз Байбәк инде йөз яшенә җитеп килә, күзләре шактыйдан сукырайган, әмма Чистай төбәгендә ул иң абруйлы кешеләрдән санала, киңәшкә аның янына киләләр. Маңгай күзләре күрмәсә дә, ул дөньяны күңел күзләре белән күрә, һәм аның әйткәннәре күпләргә ярдәм итте. Бу юлы да ул Ишмөхәммәтләрнең судка килүләрен ишетүгә, үзләренә чакырды, чөнки бу соңгы мәхкәмә булачак, аның ничек тәмамлануы күпләрнең язмышын хәл итәчәк иде. Ирләр җыелып бетү белән, шул турыда сөйләшә башладылар. Чистайның зур-зур байларыннан тыш, Мәчкәрә мәдрәсәсеннән Мөхәммәтзакир Камали да кайткан, ул да шушы җәмәгатьнең мәртәбәле кешесенә әйләнеп бара иде. Гомәр абыз аңа аеруча зур өметләр баглый, үз яныннан җибәрми, фатихасын да аңа биреп калдырырга җыена иде.

– Заман ахырына таба бара, ыланнар! – дип, бик ерактан башлап китте ул сүзен. – Аллаһы Тәгалә бәндәләрен төрле авырлыклар биреп сыный – әмма аңламыйлар, төрле җәзалар белән кисәтә – әмма санламыйлар... Хәтерләсәгез, бу елларда Аллаһ күктән койрыклы йолдызлар да җибәрде, ут яңгыры да яудырды, җирләр тетрәде, сулар басты, Рәсәйдә ничә ел рәттән корылык сәбәпле, ачлык булды, ваба чире котырынды, халык кырылды – әмма гыйбрәт алмадылар... Кешеләрнең бер-берләренә карата гаделсезлекләре сәбәпле кан коела, җан кыела, дөньяның асты-өскә килә... Христиан дөньясы Гайсә пәйгамбәрнең яңадан килүен көтә, әмма бу хәл заман ахырында булачагын, аннан соң дөнья тормышы бетәсен онытып җибәрәләр. Дөнья бетүгә үзләре сәбәпче булуларын да танымыйлар. Дин исеменнән башкаларны рәнҗетәләр. Мин инде карт, Аллаһ гомер бирсә, йөз яшем тула... Бу дөньяда төрлесен күрдем, әмма милләтнең бәхетле чагын күрмәдем, шуңа йөрәгем әрни! Халыкны хәтта керәшен коллыгыннан да коткара алмадык, иркенләп үз динебезне тотарга да ярдәм итә алмадык... Моңа кадәр без татарларга ярдәм итү буенча эшне астан гына алып бардык, дәүләткә, ак патшага каршы сүз әйтмәдек, милләткә зыяны тияр дип уйладык. Ә алар аның саен азды, татар бугазыннан кулларын ычкындырмыйлар, барысын да кяфер ясамыйча тынычланмаячаклар. Бәлки, безгә инде ачыктан-ачык әйтеп, ачыктан-ачык көрәшкә күтәрелергә кирәктер? Барыбызны да чукындырып бетергәнне көтеп ятмаскадыр?

Ирләр бер-берләренә карашып алдылар, чөнки моңа кадәр сак һәм сабыр булган Гомәр морза авызыннан мондый гыйсъяни сүзләр көтмәгәннәр иде алар. Әмма ул башкалар күрмәгәнне күрә, башкалар белмәгәнне белә, шулай дип инде соңгысын әйткән икән, димәк, моңа сәбәпләре бар!

– Син хаклы, Гомәр әзи, халыкның хәле авыр, керәшен кардәшләребезнең хәле яшәү белән үлем арасында, – дип сүзгә кушылды Исмәгыйль морза. – Без кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышып карадык, кайсын төрмәдән, кайсын Себердән коткардык, судларны суза алган кадәр суздык, мөмкин булган җирдә попларын сатып алдык, мәкруһларга ярдәмгә адвокатлар ялладык, авылларда мәчетләр ачарга булыштык, дини китаплар кайтардык... Әмма хөкүмәт һәм чиркәү әһелләре дә йоклап ятмады, татарларны урыс динендә калдыру өчен, араларына телне белгән попларны җибәрә башладылар, хәтта атлы күчмә чиркәүләр оештырдылар, татар авылларында урыс-керәшен мәктәпләре ачтылар... Бер яктан – мәгърифәт аша, икенче яктан – куркытып, керәшен татарларын чиркәү карамагында калдыру өчен тиңе булмаган эш башлап җибәрделәр. Патша – алар яклы, хөкүмәт – алар яклы, палисайлар һәм судлар – алар яклы... Тәреләрен күтәреп, милләт өстенә туфан кебек ябырылдылар!

– Ә халык, халык каршылык күрсәтәме аларның бу явыз гамәлләренә?! Тәре асарга муеннарын сузып тормыйлардыр бит инде татарлар?

– Юк, Гомәр әзи, халык бик нык үзгәрде, – дип сүзгә кушылды Ишмөхәммәт. – Хәзер инде элеккеге халык түгел, каршылык күрсәтә башладылар. Шушы биш-алты ел вакыт эчендә генә дә көчләп чукындыруга, урыс авылларына күчерүгә каршы йөзләгән татар авылы баш күтәрде... Чөнки башка чара юк, алар әйткәнгә риза булып торсаң, бөтен татар дөньясын пыр туздырып ташлаячаклар! Аллам сакласын!

– Алай да, татарларның теш күрсәтә башлавы яхшы булган, безне үзебездән кала беркем якламаячак. Ак патша безгә каршы, яшел патша бездән ерак, үз патшаларыбыз юк, димәк ки, ыланнар, милләтне яклау татарның үзенә кала!

Мөхәммәтзакир Камали олыларның сөйләгәнен зур игътибар белән

тыңлады, милләтнең хәлен яхшы белә иде. Ул укыган Мәчкәрә авылы Вятка губернасына керә, анда да шушы ук хәл – татарын, ар-чирмешен урыс диненә кертер өчен, чиркәү әһелләре көне-төне чаба. Төбәк Казаннан шактый читтә, тирә-якта кара урманнар, төньякка таба сөрген җирләре... Мондагы кара, авыр тормышка татарлар гына нур өстәп, яктыртып тора, ислам дине сәбәпле урысларга бирешмиләр. Әмма керәшеннәр инде анда да бар, аларның җаны өчен, бер яктан чиркәү котырып көрәшсә, икенче яктан мөселман-татарлар үз милләттәшләрен алар тырнагыннан тартып чыгарырга тырышалар. Әмма андагы халык мондагы кебек гаярь түгел, дин өчен үлемгә баручылар сирәк, чиркәү ягыннан басым үзеннән-үзе туктар, бетәр, дип өмет итәләр.

– Бездә дә шушы ук хәл, агайлар! – диде ул. – Ар-чирмешләрне рәттән чукындырып баралар, урыска әйләнмәс өчен, алар хәзер үзләрен татар дип яздыра башладылар, динебезгә күчәләр. Татарларга да басым көчле, чит губерна булгач, чиркәү көчле, һәрхәлдә, Пугач яулары вакытында иң күп поплар шушы якта үтерелгән булган... Халык хәзер алай казык-сәнәккә ябышмаса да, ачуы эчтә кайный, ул еллардагы кебек, милләттән бер хәбәр генә көтәләр. Без исә бөтен көчебезне халыкны шул көнгә әзерләүгә бирәбез – Аллаһтан өметне өзмәскә, иманны-динне бирмәскә, татарлыктан чигенмәскә. Монда башкарак икән – сез инде вәгазь, үгет-нәсихәт чорын үтеп, үзегезне корал белән саклый башлагансыз, чөнки бу вазгыятьтә башка юл юклыгын аңлагансыз. Милләт буларак исән калу өчен, динебезгә беркемне дә якын китертмәс өчен, саклану чаралары гына аз, һаман аклану гына да җитми, ә ачыктан-ачык аларның үзләрен гаепләү юлына басарга туры киләчәк. Ягъни, көрәш алымнарын үзгәртергә...

Аны зур игътибар белән тыңлаган Гомәр морза җанланып китте, сукыр күзләре белән дә бу егеттә гайрәт һәм акыл көчен күрде, ул аның дәвамчысы иде...

– Йә, углым, син ничек күрәсең ул кяферләргә каршы көрәшнең яңа юлларын? – дип сорады ул. – Пугач заманнарындагы кебек, татарны яуга күтәрелергә чакырмыйсыңдыр бит?

– Юк, Гомәр абыз, вакытлы-вакытсыз яуга күтәреп, мин соңгы татарны урыс итеге астына салырга теләмим, безнең җиңәрлек көчебез юк әле, ә ул булачак, инша Аллаһ! Татарга бу җирләрдә үзенең хуҗа икәнлеген аңнарына сеңдерергә кирәк! Без – кан түгеп басып алынган халык, әмма урыс колы түгел, һәм булмаячакбыз да! Татар булганыбыз өчен, кайчандыр бөек дәүләтләр тотканыбыз өчен, мөселман булып яшәргә тырышуыбыз өчен без алар каршында гаепле түгел, ә алар безнең алда гаепле! Ил-җирләребезне басып алганнары өчен, миллионлаган төрки-мөселман халкын дәүләтсез калдырганнары өчен, безне көчләп, кыйнап һәм газаплап үз диннәренә керткәннәре өчен, милләт буларак юк итү максаты куйганнары һәм шуны тормышка ашырып килгәннәре өчен – алар безнең каршыда зур гаепле һәм гөнаһлы! Менә шушыны үз халкыбызга да, аларга да аңлатырга кирәк булачак. Юк, яңадан өелеп сугышу өчен түгел, ә һәркем үз урынын белсен өчен кирәк боларны аңлату! Коръәндә әйтелгәнчә – аларга үз диннәре, безгә үз хак динебез!

– Мең тапкыр хаклы син, углым! Татар мескенлектән, үзен гаепле итеп тоюдан арынырга тиеш! Үзенең асыл бәясен белеп, бер Аллаһның гына яраткан колы булып яшәвенә сөенергә, шуңа омтылырга тиеш! Әмма аның тормышы бүген ут эчендә бит... Менә бу мәкруһ кардәшләребезнең иртәгә судлары, аларның бөтен тормышларын пыран-заран китереп ташлаулары бар.

Син нәрсә тәкъдим итәсең аларга, син әйткән көрәшнең яңа алымын бу эштә файдаланып буламы?

– Ник булмасын, Гомәр абыз, нәкъ урыны шул инде аның! Ишетеп белүемчә, Ишмөхәммәт абзыйларны ул мәхкәмәгә каты җәза бирү өчен чакырганнар, ул барысы өчен дә төрмә, Себер, монастырь булырга мөмкин. Моннан да начаррагы үлем җәзасы, әмма ул керәшеннәр өчен хәзер Русиядә каралмаган. Ягъни, бу мәкруһларга иң каты җәзаны бирергә тырышачаклар. Ә аннан ничек котылып була? Аларның үзләрен гаепләп, бу эшләрнең барысында да сатлык-сәрхуш попларны, палисайларны, хөкүмәт түрәләрен гаепләп! Аларның бөтен гаепләрен суд каршында ачып салып! Аңладыңмы, Ишук әзи?

– Бик үк аңлап җиткермим әле, Мөхәммәтзакир энем! Без болай да аларны шактый тәнкыйтьлибез инде, әмма моңа берәүнең дә исе китми... Ай-һай, суд хәтле судны моның белән генә алдырып булырмы икән?

– Монда сүз тәнкыйтьләү турында гына бармый, ә гаепләү турында бара, Ишук әзи! Алайса, тагы да ачыграк итеп әйтәм! Менә син җитмеш елдан артык чиркәү кенәгәләрендә керәшен булып исәпләнәсең, әмма ачыктан-ачык ислам динен тотасың, моның өчен Себергә сөрелмәгәнсең. Поплар һәм түрәләр ярдәменнән башка моңа ирешеп булмый, ә ул ярдәм – аларны сатып алу гына булырга мөмкин!

Ишмөхәммәт аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңлый башлаган иде, әмма бу бик яшерен эшләр, алар кычкырып эшләнми, чөнки моның өчен барысына да эләгәчәк. Әйе, үзенә кирәкле белешмәне алу өчен, балаларын чиркәүдән коткару өчен, аңа попларын да, түрәләрен дә сатып алырга туры килгәләде, бер ул гына түгел, моны башкалар да кулланды. Әмма бу турыда ничек суд каршында сөйлисең?!

– Аңладым мин сине, Мөхәммәтзакир энем! Әйе, булгалады андый хәлләр, мин үзем дә, гаиләм-балаларым да чиркәүгә гыйбадәт кылырга йөрмәдек, керәшен саналсак та, мөселманча яшәдек. Әйе, моны поплар һәм түрәләр дә белде, бәйләнгәне булды, күз йомганы... Әйе, дәшмәсеннәр өчен бераз майларга да туры килде, чөнки башкача мөмкин түгел... Әмма аны ничек суд каршына чыгып сөйлисең инде?

– Ә нигә сөйләмәскә? Аларның үзләрен гаепләргә кирәк, чөнки бу мәхкәмәләр – ул инде нәтиҗә, аларның акчага сатылу нәтиҗәсе.

– Соң, бу бит инде үзебезне дә гаепләү булачак, сатып алучы – без бит, керәшен татарлары!

– Ә сезнең башка юл юк иде, чөнки шундый хәлгә куелгансыз! Сезгә дигән җәза әзерләнгән инде, Ишук әзи, үзең турында нәрсә сөйләсәң дә, шул булачак. Укны аларның үз якларына борып җибәрергә кирәк. Алар өчен чиркәү һәм хөкүмәт түрәләре – изге һәм гадел кешеләр, ә син аларның кемлекләрен ачасың! Иң мөһиме – сезгә иртәге судтан исән-имин чыгарга кирәк, вакытлыча булса да котылып торырга кирәк, ә моңа эшне сузып, яңа тикшерүләр башлатып җибәреп кенә ирешергә мөмкин. Аңлата алдыммы икән инде?

Соңгы фикеренә урабрак килсә дә, җыелган халык Мөхәммәтзакирның ни әйтергә теләгәнен аңлаган иде. Әйе, татарларга үз ирекләрен сатып алырга да туры килде, комсыз поплар һәм түрәләр акча өчен аларның керәшенлекләренә күз йомдылар, кирәкле кәгазьне язып бирделәр. Әмма бу барысы белән дә шулай җайлы гына булды, дигән сүз түгел, дин-ислам хакына Себер сөрелгән, төрмәләрдә газап чиккән, монастырьларда бикләнеп яткан, туган җирләреннән урыс арасына илтеп ташланган мәкруһлар да күпме?! Ишмөхәммәт үзенең

нәселен шушы афәтләрдән булдыра алганча саклады, бу поп-түрәләрне кирәк вакытта сатып алды, кирәк вакытта куркытты, әмма балаларына якын китермәде. Хәзер шушыларның барысын да ачып салырга туры киләчәк.

Гомәр абыз, Исмәгыйль морзалар да уйга калган иде, чөнки алар үзләре дә керәшеннәрне чиркәү тырнагыннан тартып алу өчен күп эшләделәр, законга каршы барган вакытлары да күп булды, чөнки башкача мөмкин түгел иде. Хәзер дә Чистай түрәләре белән дә, Казандагы зур-зур кешеләр белән дә эш алып баралар, монда инде берничек тә акчасыз булмый! Моның шулай икәнен күбесе белә, күпләр татар хәсрәтендә акча эшлиләр, әмма ярдәмнәре тигәч, ике як та канәгать. Хәзер шушыларны мәхкәмә каршында ачып бирергә туры киләчәк. Хәер, барысын да түгел, Ишмөхәммәтнең үзенә һәм гаиләсенә карагannарын гына, аны болай да хөкем итәләр, ә ул үз артыннан акчага сатылган урыс попларын һәм түрәләрен дә өстерәячәк. Куркыныч адым, әлбәттә, әмма судны сузу яки туктату өчен башка юл юк, бәлки шушыларны дөньяга чыгармау өчен, Ишмөхәммәтнекенә дә күз йомарлар?

– Бу бик хәвефле адым, ыланнар, таякның икенче башы үз җилкәбезгә дә төшәргә мөмкин, – дип нәтиҗә ясады Гомәр морза. – Әмма чама белеп сөйләгәндә, кайбер нәрсәләрне суд каршында ачарга мөмкин, бәлки, бу эшне сузар яки башка якка алып кереп китәр. Син, Ишмөхәммәт энем, Чистайдагы хәлләргә кагылма, анысы безнең эш, син күбрәк үзегезнең поплар һәм приставлар турында сөйлә, ә аларның хөкүмәт алдында гаепләре күптер, дип уйлыйм. Менә җавап тотсыннар синең кебек... Аллаһы Тәгалә шаһит – син бу эшкә мәҗбүри бардың, чөнки үзеңне, гаиләңне, балаларыңны чукындырудан саклап-аралап калырга кирәк иде. Син – иман хакына, ә алар комсызлыктан закон боздылар.

– Аларны кызганырга кирәкми, Ишук әзи! – дип, сүзгә Исмәгыйль морза да кушылды. – Без белештек инде – Кызылъяр побы хатының Гөлзадага каршы да, кызың Гөләйзага каршы да күрсәтмәләр биргән. Имеш, алар барысы да чиркәү кенәгәләрендә керәшен дип язылган икән, имеш, Гөләйзаны мөселманга кияүгә бирергә рөхсәт сорамаганнар, башка балаларыңны да ачып салган... Кыскасы, акчаңны да алган, үзен тери башлагач, баш-аягың белән саткан да. Чиркәү кенәгәсен теге явыз становой Шахт әйткәнчә яңадан тутырган... Гөләйзаны бары тик шушы попның күрсәтмәләре буенча гына хөкем итәләр, чөнки аңа каршы башка бер дәлил, бер кеше дә юк. Шуңа күрә үзләренең дә кем икәнлекләрен суд каршында ачып бирергә туры киләчәк.

Ишмөхәммәт хәзер аңлый башлады – бу яңа мәхкәмәләр артында өч кеше тора – Биләр атакае, яңа пристав һәм Кызылъяр побы, соңгысы татарлардан күргән яхшылыкларын онытып, аларга каршы күрсәтмәләр биргән. Димәк, Ишмөхәммәткә дә ничек бар – шулай сөйләп бирергә туры киләчәк, алар да кылган гамәлләре өчен җавап тотсын! Судны бу юлга алып кереп китү әллә ни файда китерер дип уйламый ул, карга карганың күзен чукымас, әмма уйланырга этәрер. Татар фаҗигасен кәсепкә әйләндергән поплар һәм түрәләр буа буарлык, алар шуның хисабына яшәп ята, ә керәшеннәрнең башка чаралары юк, соңгы тиеннәрен күтәреп, шулар каршына баралар. Иң аянычы – тегеләр акчасын да алалар, барыбер соңыннан хөкемгә дә тарталар. Һәм бу дәүләт күләмендә куелган талау, акча эшләү юлы, татарларны рәсми рәвештә христиан диненнән чыгармауның бер сәбәбе дә булып тора.

– Әйе, Мөхәммәтзакир энем, син хаклы! – диде ул. – Бу бит бер безне генә түгел, дәүләт күләмендә милләтне талау! Шуңа күрә үз диннәренә бәйләп

тоталар да алар – татар фаҗигасендә акча эшлиләр. Әгәр алар безне чыннан да урыс динендә калдырырга теләсәләр, татарга ярар өчен чәчләре белән җир себерерләр иде, үзләрен гел яхшы яктан гына күрсәтергә тырышырлар иде. Хәер, бу халык башкача эшли белмидер инде... Ярар, җәмәгать, мин, тәвәккәлләп, шулай эшләп карыйм! Өй җәмәгатемә дә шулай сөйләргә кушармын. Безгә хәзер соңгы дәлилләрне чыгарып салмыйча булмый, башка юл юк.

Шулай килештеләр. Иң мөһиме – бу судны өзү, туктату, сузу иде, аннан соң тагы уйлашырлар. Иң мөһиме – судтан соң ук барысын да, богаулап, Казанга озатмасыннар, югыйсә, шуңа җыеналар, дигән хәбәрләр йөри. Иң мөһиме – Гөләйзага кагылмасыннар, ул болай да чирләбрәк тора, Казанга да барып җитә алмас, юлда җан бирер... Бу хакта Ишмөхәммәт башкаларга да әйтте, барысы да аның белән килеште, тик Гомәр морза гына Ишмөхәммәт белән аерым сөйләшеп алырга теләде. Башкалар зур залда утырып калдылар, Гомәр морза белән Ишмөхәммәт аерым бүлмәгә күчтеләр. Киштәләрдә идәннән түшәмгә хәтле борынгы китаплар өелеп торган бу бүлмә Гомәр морзаныкы иде, күзләре күрмәсә дә, ул бергә гомер иткән китапларыннан аерылырга теләмәде, аларны моннан чыгартмады. Гомәр морзаның бүлмәсендә борынгы кулъязмалар, Болгар-Биләр тарихы турында истәлекләр, нәсел шәҗәрәләре дә бар иде, теге вакытта Морадбакый абыз биреп җибәргән язмалар да монда саклана.

– Мөхәммәтзакир дөрес юл күрсәтте, судта ул әйткәнчә эшлә, – диде Гомәр морза. – Ахыры хәерле булсын, дип дога кылыйк... Кызың Гөләйзаны алып китә алмаслар алар, Ишмөхәммәт энем, әмма аны югалтуга да әзер булып торыгыз...

Картның бу сүзләреннән Ишмөхәммәт әллә нишләп китте. Алар алып китмәгәч, ник юкка чыгарга тиеш әле Гөләйза? Әмма Гомәр морза артыгын сөйләмәде, Ишмөхәммәт кайтарып сорарга яхшысынмады, чөнки бу ачылып сөйләшә торган нәрсәләр түгел, бу бары тик Аллаһның яраткан бәндәсе аркылы кисәтүе генә иде. Моны икесе дә яхшы аңлады, икесе дә бу турыда башка сүз кузгалтмадылар, әмма Ишмөхәммәтнең йөрәге шул хәбәрдән соң урталай ярылгандай булды...

– Балаларын алып китәрләрме икән инде, Гомәр әзи? – дип сорап куйды Ишмөхәммәт сак кына.

– Ул хакта Исмәгыйль морза белән дә, башкалар белән дә киңәштем. Син каршы килмәсәң, бер юлын таптык без аның...

Шулай диде дә Гомәр морза шактый вакыт сүзсез утырды, әйтергәме-юкмы бу хакта, дигән кебек тирән уйга чумды. Үзе каядыр читкә караган, әйтерсең лә сукыр күзләре белән киләчәктән бу балаларның язмышын барлый иде... Озак дәшми утыргач, Ишмөхәммәт үзе сүз башларга мәҗбүр булды.

– Балаларны качаклыкка чыгарып җибәрергә, дигән уйга килдегезме, Гомәр әзи? Бигрәк кечкенә бит әле алар, пыран-заран килеп, чит-ят җирләрдә вәйран калып харап булулары бар...

Аның бу сүзләреннән Гомәр морза уянып киткәндәй булды, яңадан бу дөньяга әйләнеп кайтты.

– Юк, Ишмөхәммәт энем, балаларны алай сукбайлыкта йөртеп булмас, – диде ул. – Аларны барыбер тотып алып, кире кайтарырлар иде, аннан чукындырып, тәрбиягә бирерләр иде... Юк, балаларны алай газаплап булмас.

– Нишләргә соң алайса, Гомәр әзи? Ул балаларны ычкындырмаячак бит болар?! Шуларны чукындырмаган өчен башланды да бит инде бу эшләр!

– Сезнең үзегезне дә тиз генә ычкындырмаячаклар, Ишмөхәммәт энем!

Себергә үк сөрмәсәләр дә, чиркәүле урыс авылына яки христиан динен тоткан керәшеннәр янына күчерергә мөмкиннәр... Без бу хакта Исмәгыйль морзалар белән киңәштек инде, хәлегезне җиңеләйтү өчен, төрле юллар эзләдек...

– Таптыгызмы соң, Гомәр әзи?

– Без исән калу юлларын таптык, әмма ул шактый катлаулы һәм урау булачак... Башта балаларның язмышыннан башлыйм, аларны һич кенә дә урыс кулына бирергә ярамый, диннәрен алып, харап булачаклар!

– Барыбыз да шулай уйлый, Гомәр әзи! Әмма ул балаларны ничек саклап калырга?!

– Аларны саклап калу өчен, барыбыз да тырышабыз, әмма болар да ахыргача барачаклар, чөнки бу эшне хәзер Казан гына түгел, Питер да күзәтеп тора. Хисап шунда китә. Иртәме-соңмы, алар балаларны алырга киләчәк – моңа әзер булып торырга кирәк.

– Ничек итеп, Гомәр әзи?! Биреп җибәрепме?

– Әйе, биреп җибәреп, христиан динендә дип исәпләнгән үз керәшеннәребезгә бирергә кирәк булачак Гөләйзаның балаларын.

– Бер керәшеннән алып икенчесенә кем бирсен, Гомәр әзи?! Безнең беребезгә дә ышанмыйлар бит!

– Димәк, балаларны коткарып калу өчен, бик ышанычлы керәшен побын, бик ышанычлы керәшен татарларын, бик ышанычлы керәшен авылын табарга туры киләчәк. Ягъни, аларның чын христиан икәнлегенә хөкүмәт тә ышанырга тиеш, мөселман балаларына зыян салмасларына без дә ышанырга тиеш. Бармы күз уңында шундый авыл, шундый поп, шундый керәшеннәр?

Ишмөхәммәтнең күз аллары яктырып китте – бар, әлбәттә бар андый авыл, андый ышанычлы кешеләр – Актау авылы! Ничек үзенең башына килмәгән бу юл? Әйе, Гөләйзаның балаларын шуларга биреп кенә коткарып калып булачак!

Ә балаларны Василларга һәм Мәрьямбануларга тапшырырга була, алар абыйлы-апалы яшерен мөселманнар.

– Без дә монда шулай уйладык... Балаларны барыбер алырлар, ичмасам, ышанычлы кулларга эләксен, дидек. Якубны беләм мин, аның белән үзебез дә сөйләшербез, балаларны чукындырмыйча гына, Казан алдында хисап тотар. Ә теге яшерен мөселманнар ышанычлы кешеләрме соң, балаларны христиан диненә авыштырмасләрмы?

– Юк, Гомәр әзи, үзебезнең диндә, өйләрендә җомга намазларын бергә укыйбыз. Якуб атакай моны белә, әмма чакмый, теге урыс поплары кебек, акчага сатылганнан түгел, үзе татар кешесе булганы өчен яшерә ул аларны. Бераз куркаграк та, чөнки Биләр побы котын алып тора, әмма ул карагруһ та картайды инде, бик кысылып йөрмәс.

– Бик яхшы! Үзегезне чиркәүле урыс авылына күчерә башласалар да, шушы Актауны сайларсыз, оныкларыгыз янында булырсыз.

– Әйе. Эш шуңа барып җитсә, шулай эшләрбез, Гомәр әзи! Актауда безнең авылдан әле теге елларда ук күчерелгән керәшен татарлары бар, без дә сыярбыз.

– Ярар, Ишмөхәммәт энем, шулай килештек! Ни булса да, безнең чыгу юллары табылыр. Хәзергә шушыңа туктап торабыз, калганы Аллаһ кулында!

Ишмөхәммәт, Гомәр морза белән сөйләшүдән җиңеләеп, тынычланып чыкты, озын, авыр юлының аргы башында ниндидер яктылык пәйда булды. Гөләйза турында уйлаудан йөрәге әрнеп сулкылдаса да, аның язмышы Аллаһ кулында иде, инде оныкларны бу хәлләрдән коткарып калырга кирәк. Акыл иясе Гомәр абыз моның юлларын күрсәтте, укымышлы Мөхәммәтзакир

аны судта үзен ничек тотарга өйрәтте. Исмәгыйль морзаларга кайткач, ул хатыны Гөлзада белән кызы Гөләйзаны, улы Бикмөхәммәт белән килене Хөсниҗамалны да үзләрен мәхкәмәдә ничек тотарга өйрәтте, Актау турында хәзергә кузгатмады. Әле бу судтан исән-имин котылып чыгасы бар, югыйсә, инде аларны Казанга озатырга дигән олаулар әзерләнгән, белешмәләр язып куелган иде...

...Мәхкәмә иртәнге якта башланды, атларга төялеп, тагы суд бинасына килделәр. Бу юлы хөкемдар да, тылмач та башка кешеләр иде, татарчадан тәрҗемәгә Котош побы Микулай атакайны чакырганнар, судья яшь кенә бер урыс булып чыкты. Башта, төп гаепле кеше буларак, Гөләйзаны керттеләр, аның тарихын укып чыктылар, Гөләйза да шул ук җавапларны кабатлады. Кечкенәдән ислам динендә, урыс динен белми, чиркәүдә беркайчан булмаган, ире дә мөселман, шуңа күрә, балалары да мөселман, аларга авыл мулласы татарча исем кушкан... Моннан алты ел элек булган судта ул яралы кош кебек үз-үзен һәм балаларын ярсып якласа, бу юлы авыруы йөзенә чыккан, хәлсезлеге сизелеп тора, җавапны да бик акрынлык белән генә бирә иде. Судья аны Кызылъяр побының аңлатмасы белән таныштырып чыкты, ул анда барысын да киресенчә язган иде – имеш, Пелагея (Гөләйза) үзе дә, әнисе Фекла (Гөлзада) да, башка туганнары да чукынган татарлар, гомер буе чиркәүгә йөргәннәр, имеш, мөселманга кияүгә рөхсәтсез чыккан, поп күпме әйтсә дә, балаларын чукындырмаган, шулай итеп, христиан динен пычраткан, закон бозган икән...

– Болар барысы да ялган! – диде Гөләйза, бар көчен җыеп. – Минем ул попны гомеремдә дә күргәнем юк! Элеккегесен дә, хәзергесен дә белмим! Мине кем, кайда чукындырсын, ди?! Мөселман мин, чын мөселман! Һәм минем исемем Пелагея түгел, ә Гөләйза! Балаларым да урыс исемен йөртми. Без беркемгә тимибез, ник сез безгә үзебезчә яшәргә ирек бирмисез?! Нигә кирәк сезгә минем балаларым, үз ятимнәрегез дөнья тулы?!

Шулай диде дә, Гөләйза күкрәген тотып йөткерә башлады, саргайган йөзенә зур яшькелт күзләреннән яшьләре тәгәрәп төште. Судья бу ябык, авыру хатыннан андый гаепләү сүзләре көтмәгән иде, сорау бирүдән туктап калды, аның бераз тынычланганын көтте.

– Пристав Шахт Алексей Ивановичның рапортыннан күренгәнчә, 24 февраль көнне Чирүле Шонталасында сорау алган вакытта син, Пелагея, изге Библияне һәм тәрене идәнгә салып таптагансың икән. Бу – бик куркыныч гамәл, моның өчен җәза да бик каты каралган. Үзеңнең шушы гаебеңне таныйсыңмы?

Котош побы аның бу сүзләрен калтырый-калтырый тәрҗемә итеп бетерү белән, Гөләйза «Ялган!» дип кычкырып җибәрде.

– Бу сүзләр барысы да ялган! – диде ул, соңгы көчен җыеп. – Менә бу тылмачлык иткән поп анда булды, ул да раслар – мин урысларның китабын да, тәресен дә идәнгә салып таптамадым, мин аларны кулыма да алмадым! Ул исерек пристав китабы белән минем битемә сукты, тәресен йөземә төртте, идәнгә дә аларны үзе төшереп җибәрде... Аннан бугазымнан алып, үземне дә идәнгә бәрде, мин аңсыз калып аудым... Шуннан бирле мин мантый алмыйм – чирлим... Сезнең кайсы закунда язылган – хөкүмәт кешесе эш вакытында шулай кыйнарга тиеш, дип? Динегез шулай кушамы татарларны кыйнарга? Патша галиҗәнапләре шулай өйрәтәме? Җитмәсә, судка ялган күрсәтмә биргән! Моннан соң ничек без сезгә ышанырга тиеш? Динегезне алырга, сез кушканча яшәргә тиеш?! Аллам сакласын!

Котош побы боларны русчага тәрҗемә итеп бетергәч, судья сораулы

карашын аңа текәде, Николай атакай башын аска иде. Беркетмә буенча чиркәү әһеленнән сорау алу каралмаган булса да, аның дәшмичә читкә борылуы барысын да аңлатып тора иде – кыйнау булган. Хәер, моның шулай икәнлегенә судья үзе дә шикләнми, ә яңа становой приставы турында берсеннән-берсе куркыныч хәбәрләр килеп тора – кайда кыйнаган, кайда бәреп үтергән, кайда буа башлаган, кайда татарларның каберләрен актарып ташлаган... Үзен Казан һәм Биләр яклый, бу кыргый татарлар белән башкача булмый, тәртип кертергә кирәк, диләр. Менә бу хатын да шуның киләшчәләренә эләккән инде, димәк.

– Бу мәхкәмәдә безнең эшебез дин әһелләрен һәм хөкүмәт кешеләрен тикшерү түгел, – диде судья. – Нәрсәдәндер риза булмасагыз, югарырак оешмаларга шикаять итә аласыз... Инде соңгы сорау – син үз гаебеңне таныйсыңмы, аңа үкенәсеңме, тәүбә итәсеңме? Җавабыңа карата җәзасы да булачак.

– Нинди гаеп? Минем үз динемдә булуым гаепме? Ата-анам, әби-бабам татар, нәселебез белән гасырлар буе исламда булдык, нигә мин аннан баш тартырга тиеш? Мин үз динемне сөенә-сөенә тотам, шушы юлда булганым өчен Аллаһка мең рәхмәтләр әйтәм! Үз диннәрен урыслар үзләре тотсыннар, әмма мин бу исерек, ялганчы поп һәм явыз пристав белән бер диндә беркайчан да булмаячакмын! Үлгәндә дә аны кабул итмәячәкмен! Мине Себер дә, Казанның төрмә-монастырьлары да куркытмый, чөнки кайда да минем иманым үзем белән булачак! Һәм мин ышанам – Аллаһы Тәгалә мине сезгә ирекле кылмаячак, соңгы сүзне Ул әйтәчәк! Һәм соңгы хөкемне Ул чыгарачак.

Котош побы тәрҗемә итеп бетергәнче үк, судья бу татар хатынының ни әйтергә теләгәнен аңлады – әйе, ул үкенми, үз диненнән баш тартмый, аның өчен үлемгә барырга да әзер... Һәм аның белән алга таба сөйләшеп торудан мәгънә юк. Икенче кеше итеп Ишмөхәммәтне керттеләр, ул, карт булса да, алыптай гәүдәсен төз тотарга тырыша, ярдәмгә тагы гөрзи-таягын алган, башыннан түбәтәен салмаган, аңа бу турыда әйтүдән дә мәгънә юк. Шуңа күрә судья шундук сорау алырга кереште, әлеге эштә Ишмөхәммәтнең төп гаебе – керәшеннәрне ислам диненә кайтырга котыртуы иде.

– Кызылъярда тутырылган беркетмәләр буенча, син, Измаил Ефремов, бу керәшеннәрне яңадан исламга кайтырга төп station аздыручы булып торасың. Син аларны чиркәүдән биздергәнсең, син аларны, керәшен икәнлекләрен белә торып, мөселманнар белән кавыштыргансың, син аларны балаларын чукындырмаска котырткансың, син алар өчен махсус зиратлар ачтыргансың, керәшеннәр үлсә, мулла чакыртып, мөселманча күмдергәнсең. Син аларны чиркәүгә һәм патшага каршы котырткансың, кулга алынсалар, артларыннан йөргәнсең, адвокатлар яллагансың, урыс авылларыннан кире җыеп алгансың. Менә шушылар гына да сине мәңгелек каторгага җибәрергә җитә, Измаил Ефремов! Син үз гаебеңне таныйсыңмы?

– Әйе, син санаган бу гамәлләр мине сөргенгә сөрергә дә, җәннәткә кертергә дә җитә, хөкемдар әфәнде! Мин моны гаеп эш дип санамыйм, ә һәр мөселман кешесе башкарырга тиешле изге гамәл, дип таныйм, ә мин – мөселман, әлхәмдүлиллаһ! Исемем дә Измаил түгел, ә Ишмөхәммәт.

– Сигезенче ревизия документлары һәм чиркәү кенәгәләре буенча, син чукындырылган татар, Измаил Ефремов! Бу судка чакырылганнар барысы да керәшен, бернинди дә мөселман түгел! Ә чиркәүгә йөрмәгәнсез, попларны өйләрегезгә кертмәгәнсез, христиан дине кагыйдәләрен үтәмәгәнсез, чукынган килеш намаз укыгансыз! Православлау илдә моннан да зур кыргыйлыкның,

гөнаһның, гаепнең булуы мөмкин түгел! Һәм моның җәзасы да бик каты булачак бит! Ә син тәүбә итеп, үз гаебеңне танысаң, яңадан христиан дине кочагына кайтсаң, хөкем дә җиңелрәк булырга мөмкин, ашыкмыйча уйла һәм җавап бир, Ефремов!

Ишмөхәммәт кичәге сөйләшүне искә төшерде, аңа соңгы дәлилләрне чыгарып салыр вакыт җиткән иде. Әйе, боларның үзләренә һөҗүм итәргә, татарларның шушындый хәлдә калуларына аларның үзләрен гаепләргә кирәк!

– Син барлык гөнаһларда мине генә гаепләргә ашыкма әле, хөкемдар әфәнде! – диде ул. – Без ул гөнаһларны поплар белән бергә эшләдек, түрәләр дә булышты татарларга үз диннәрендә калырга...

– Син, Ефремов, кеше башын бутама, үзең кылган җинаятьне башкалар өстенә аударма! Ничек поплар һәм түрәләр сиңа христиан диненә каршы эшләргә ярдәм итсеннәр ди?! Сүзләреңне чамалап сөйлә!

– Ә минем дәлилләрем һәм шаһитларым бар шулай булганына! Чиркәү кенәгәләренә керәшен булып язылып та, ничек мин җитмешкә хәтле попларның борын төбендә мөселман булып йөрдем соң? Намаз укыдым, гаиләмне, балаларымны да шуңа өйрәттем, аларны мөселманча өйләндердем, кияүгә бирдем. Миңа кемнәр ярдәм итте дип беләсез бу эштә?

– Кемнәр ярдәм итте? Поплар һәм түрәләр түгел бит инде?!

– Нәкъ шулай, судья әфәнде, нәкъ шулар ярдәм итте! Әлбәттә, бушка түгел, акчага, ризыкка сатылдылар поплар һәм түрәләр! Керәшен була торып, мөселманлыкта калу өчен, миңа аларны сатып алырга туры килде.

Аның әлеге җавабыннан судья телсез калды, сорау алуны дәвам итәргә яки туктатырга белмәде, чөнки бу карт хөкүмәт кешеләренә һәм чиркәүгә каршы сөйли башлаган иде.

– Син монда дәлилсез сүзләрең белән судның вакытын алма, Измаил Ефремов! – диде ул, аны туктатырга теләп.

– Дәлилсез түгел, судья әфәнде, бер дә дәлилсез түгел! Башта акча һәм бүләкләрне Кызылъяр чиркәвенең элеккеге побы Трифон атакайга ташыдым, шулар хакына ул миңа кирәк кәгазьләрне язып бирә иде. Аннан монысына ташый башладым, Мифодей атакайга, әмма ул салырга ярата, эшенең рәте юк, кәгазьләре буталып беткән иде. Бу ике поптан да үземә дә, гаилә әгъзаларыма да кирәкле документларны тутыртып алдым, керәшенлек кирәк булса, анысын язып бирәләр иде, мөселманлык кирәк булса, бер тәпән балга, бер йөк икмәккә, ул безнеке түгел, дип мөһер басалар иде. Шулай итеп, моңа кадәр судларыннан да котылдык, чиркәвеннән дә...

– Әмма моны күзәтеп торырга, бу алдашуга юл куймаска тиеше становой приставлар, түрәләр бар бит!

– Аларын да сатып алдык. Элеккеге приставтан, чиновник Разумовтан, Михайловлардан сорагыз – алар, шушы бичара керәшеннәр сәбәпле, бик тук һәм яхшы яшәделәр, мондый эшләргә күз йомдылар. Әйе, без үзебезнең ирегебезне сатып алырга мәҗбүр булдык, бу юлның түбәнлек икәнен белсәк тә, башка чарабыз калмады. Без шушындый хәлгә куелган идек.

Судья гаепләүләрнең бик тирән китүен аңлады, әмма бу карт аларның исемнәрен әйтеп сөйли бит! Попларны һәм түрәләрне ничек сатып алуын суд каршында курыкмыйча әйтә, димәк, ул моны алдан ук уйлап кергән! Ә сәркатип барысын да язып, теркәп бара, чиркәү әһелләрен монда чакыртып хөкем итә алмасалар да, түрәләр өстеннән сөйләнгән гаепләүләрне алар тикшерергә тиеш.

– Син чиркәү һәм хөкүмәт кешеләренә бик куркыныч гаепләүләр ташладың,

Ефремов! – диде ул. – Хәзер без моны тикшерергә тиеш. Әгәр син сөйләгәннәр исбатланмаса, башың Себердә чери бит, шуны онытма!

– Тикшерегез, мин бу хакта әле Питерга, патша галиҗәнапләренә дә язып җибәрдем! Ә Себер белән куркытма, судья әфәнде, анда да безнең татарлар яши, без югала торган халык түгел!

Ишмөхәммәт шулай диде дә, башын горур тотып, суд залыннан чыгып китте. Ул аларны җиңгән иде. Аларның үзләрен гаепле итеп калдырган иде. Судья да моны аңлады, бер надан авыл картының, чукынган татарының, чиркәү хәтле чиркәүне, хөкүмәт хәтле хөкүмәтне шулай дәлилләп түбән төшерүе аны хурландырды. Әмма ул сөйләгәннәрнең дөрес икәнлеген белә иде Чистай земство судьясы, чөнки бөтен ил белән шулай яшиләр иде...

Ишмөхәммәттән соң Гөлзаданы керттеләр, судья аңа сорауны Кызылъяр побы аңлатмасы буенча бирүдән башлады.

– Син, Фекла Тимофеева, кызыңны мөселманга кияүгә бирер алдыннан, Кызылъяр чиркәве атакае Мифодейдан рөхсәт сорадым, дип җавап биргән булгансың... Имеш, Мифодей атакай чиркәү кенәгәсеннән кызыңның исемен эзләгән, әмма таба алмаган, шуннан соң аңа мөселманга кияүгә чыгарга рөхсәт биргән. Шулаймы?

– Әйе, шулай, без анда авылдашым Ишмөхәммәт белән бергә бардык, аның бераз урысчасы бар... Ул Мифодей атакай белән аерым да сөйләште.

– Ә менә Мифодей атакай алай дип әйтми! Фекла Тимофеева минем яныма килмәде, кызын мөселманга кияүгә бирергә рөхсәт сорамады, һәм мин берничек тә аңа ул никахны рөхсәт итә алмый идем, ди. Син нигә суд алдында ялган сөйлисең, моның өчен төрмә икәнен беләсеңме?!

– Мин ялган сөйләмим. Бу хәлнең нәкъ шулай булганына минем шаһитларым бар! Мифодей атакайдан шушы рөхсәтне алу өчен, без аңа бер сыер бәясе акча илттек. Тәпән-тәпән балны, олау-олау икмәкне әйтеп тә тормыйм инде, балаларыбызны чукындыртмас өчен, үз авызыбыздан өзеп, шул чиркәүгә ташыдык...

Судьяның бу турыда сүз куертасы килми иде, әмма попларның комсызлыгына исе китте! Көне-төне шушы надан, кыргый татарларны христиан диненә өндисе урында, динне сатып, алар өстеннән ашап ятканнар бит!

– Ярар, Мифодей атакайны шулай дип әйттегез, имеш, ул сезнең керәшенлеккә күз йомган, акчага сатылган... Әмма без моны тикшерәчәкбез, чиркәү әһеленә яла яккан булсаң, хатын-кыз дип тормаячаклар, Себергә озатачаклар сине, Фекла Тимофеева! Ә менә аңа кадәр эшләгән Трифон атакайны да гаеплисең бит син – имеш, кызыңны чукындырырга чиркәүгә алып баргач, ул кенәгәдән синең исемне таба алмаган, нәселең билгесез, дип, балаңны чукындырмыйча чыгарып җибәргән. Хәзерге поп моны кире кага, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, ди! Булдымы андый хәл?

Гөлзада моннан утыз елдан артык элек булган хәлләрне исенә төшерергә тырышты. Юк, алай ук булмады, нишләп ул баласын күтәреп, чукындырыгыз, дип, чиркәүгә барсын инде?! Ишмөхәммәт барды анда һәм барысын да хәл итеп кайтты, тагы шул акча төртеп инде...

– Юк, ул хәлләр башкачарак булды, – диде Гөлзада. – Мин үзем бармадым анда, ә авылдашым Ишмөхәммәт эшне җайлап кайтты... Без мөселманлыкка хокукыбызны сатып алырга мәҗбүр булдык, чөнки башка юлы юк иде... Ишмөхәммәт үзе атланып йөри торган ак юргасын чиркәү побына биреп кайтты, шулай итеп, кызыбызны чукындырудан саклап калдык.

– Ә башка балаларың – Иван, Федосья, Мария – аларның татарлыгын да шулай сатып алдыңмы?

– Улым Бикмөхәммәтне, сезнеңчә Ибанны, авылдашым Ишмөхәммәт тәрбиягә алды, аны мөселман итеп үстерде, әлхәмдүлиллаһ! Төпчек кызым Миңҗамал моннан берничә ел элек үлде, уртанчы кызым Шәрифҗамал үзем белән яши, ул да ислам динендә.

– Әйе, попларның борын төбендә елан оясы ясап яткансыз икән... Биләр атакае Михаил Лавров белеп башлаган сезгә каршы бу эшне! Һәм без моны ахыргача җиткерәчәкбез! Поплар һәм татар акчасына сатылган түрәләр үзләре җавап тотар, әмма бу сезнең гаепне бетермәячәк, һәркем үз җәзасын алыр!

Гөлзададан соң җавап тотарга Бикмөхәммәт керде, ул коеп куйган Ишмөхәммәт иде алыптай зур гәүдә, бөркеттәй үткен караш, башта – татар түбәтәе, өстә – тире кәзәки... Әкият батыры булу өчен, ук белән җәя генә җитми, хәер, бу татарларның чикмән асларында ни барын бер Ходай гына белә... Әлеге татар-мишәрләр сатып алырга да, салып егарга да мөмкиннәр, мескен халык түгел, үзләренә кирәккәндә, шайтанны да ат урынына җигәрләр һәм сыртына менеп атланырлар...

– Йә, Иван Денисов, сине нәрсә мәҗбүр итте хак диннән китәргә? Сиңа, япь-яшь кешегә, нигә кирәк булды бу фанатик ислам дине? Христиан динендә калсаң, бу кыяфәтең белән хәзер түрә булып түрдә утырыр идең, җинаятьче сыйфатында суд каршында басып тормас идең? Измаил Ефремов белән Фекла Тимофееваны әле аңларга да мөмкин – алар карт, дөнья күрмәгән, искегә ябышып яталар... Аларның киләчәге юк, аларны кабер генә көтә. Нигә алар үз артларыннан сине – яшь баһадирны да өстериләр, киләчәгеңне харап итәләр? Үзең аңлыйсыңмы моның шулай икәнен?

– Мин туганнан бирле тирә-ягымда мөселманнардан башка беркемне дә күрмәдем... Хәтта үземнең керәшен икәнемне дә белмәдем! Әнием миңа беренче догаларны өйрәтте, тәрбиягә алган Ишмөхәммәт әтием белән бергә намазга бастым. Авылыбызның һәр әбисе, һәр бабае мине, башымнан сыйпап, моның өчен мактыйлар иде, тәмле әйберләр белән сыйлыйлар иде. Югыйсә, алар да чиркәү кенәгәләрендә керәшен дип язылган булган бит, ә ислам дине өчен, бигрәк тә аны тоткан балалар өчен ничек сөенәләр иде бу карт-карчыклар! Безнең авылда, керәшеннәрдән тыш, чын мөселманнар да яши, ягъни, документ буенча да. Керәшеннәргә ислам динен өйрәтү аларга закон белән тыелган, югыйсә, үзләрен төрмәгә утыртырга мөмкиннәр. Әмма алар безгә беркайчан да кырын карамадылар, мәчеттән кумадылар, керәшеннәр белән янәшә басып намаз укыдылар... Ә менә Кызылъяр урыслары чиркәүдә керәшеннәр белән янәшә басып гыйбадәт кылырга җирәнәләр, аларны «нечисть», «нәҗес» дип атыйлар, кешегә дә санамыйлар. Поплар да бездән акча саву ягын гына карый, ә керәшен татарларына карата бернинди мәрхәмәт һәм ярдәм булмады. Алар безнең телне белми, без – аларныкын, дин аңлату, укыту турында сүз дә була алмый! Югыйсә, ислам диненең нигезе булган, Коръән иңгән гарәп теле дә татарлар өчен ят тел бит, ә без аны хәрефләп, сөенә-сөенә өйрәнәбез! Чөнки ул җәннәт теле! Без, керәшен татарлары, ислам динен мәдрәсәләр аша ала алмадык, без аны әби-бабаларыбыздан васыять итеп алып калдык... Без башка динне белмибез һәм белергә дә теләмибез! Мин үземнең балаларыма, нәселемә дә шушы изге динне әманәт итеп тапшырып китәчәкмен, инша Аллаһ!

Котош побы боларны чакка-көчкә тәрҗемә итеп бетерде, Кызылъярда пристав Шахтның үзен ничек мыскыл иткәне исенә төште. Әйе, ул аны да эткә

әйтмәс сүзләр белән талап ташлады, «Синме урыс белән бертигез?! Син, үз динен сатып, урыска сыенган татарвамы безнең белән бертигез?! Поп булсаң да, сине урыс чиркәвенә кертмиләр бит, чын православлаур беркайчан да синең арттан гыйбадәт кылмаячак, нечисть! Әнә быкырдап ят шунда үз керәшеннәрең белән!» диде. Әйе, урыслар аны тиңсенми, әле христиан динен тоткан, гомерен шуңа багышлаган чиркәү әһелен тиң күрмиләр, ә бу гади керәшен татарларын алар кешегә дә санамый инде!

Бикмөхәммәттән соң аның хатыны Хөсниҗамалны керттеләр, ул, барысын да өзгәләп ташларга әзер ана арыслан кебек, аларның каршына килеп басты. Нык бәдәнле, янып торган кара күзле, карашыннан ук утлы очкыннар чәчрәп торган егерме яшьләрдәге бу хатын алар каршында баш та имәячәк, баш та бирмәячәк иде. Һәм шулай булып чыкты да. Судья, «Йә, Марфа!» дип сүз генә башлаган иде, ул аны, «Минем үз исемем бар – Хөснижамал!» дип кырт итеп бүлдерде. Судья тотлыгып туктап калды, биредә аның белән болай сөйләшүче юк иде, аннан тешен кысып дәвам итте:

– Юк синең үз исемең, Марфа-Дарья, Мария! Үзең дә кайсы чын икәнен белмисең! Фамилияң дә юк! Динең дә юк! Шушы отпавший татарларга ияреп харап булган бер мескен бәндә син!

– Ник минем фамилиям булмасын, ник минем динем булмасын?! Әтиемнең исеме – Миндиян, динем – ислам, үзем – татар, ирем – Бикмөхәммәт. Миңа шуларны белсәм, бик җиткән!

– Соң син, документлар буенча, урыс авылында туып-үскән, чиркәүгә йөргән керәшен кызы! Ничек сине шулай агулап, үз диннәренә тарттылар бу татарлар?!

– Мин урыс авылында туып-үсмәдем, борынгы болгар авылы Тубылгытауда туып-үстем! Авылның бер башына урысларны китереп тутырдылар, аларга чиркәү салып бирделәр, безнең әби-бабаларыбызны көчләп чукындырып, шунда йөрергә мәҗбүр итә башладылар. Әмма татарлар үз диннәреннән аерылырга теләмәде, яшереп булса да, намаз укыдылар, ураза тоттылар, безгә дә шуны өйрәттеләр. Урысларның олы бәйрәмнәрендә безне чиркәүгә куып алып бардылар, татарлар, анда кермәс өчен, кайсы-кая качып бетә иде. Бер бәйрәмнәрендә шулай качып өлгерә алмадык, хәтерлим, яз көне иде бу, карлар эрегән вакыт... Безне палисай белән чиркәүгә куып керттеләр, әти әйтте, берегез дә чукынмагыз, аларча укынмагыз, әлхәм белән колһуалланы укып торыгыз, диде... Без, балалар, шулай эшләдек тә, кычкырып-кычкырып үзебез белгән догаларны укый башладык. Чиркәүгә җыелган бөтен урыслар безнең яннан качып бетте, попка барып зарлана башладылар. Безне, типкәләп, чиркәү ишегалдына куып чыгардылар һәм юеш кар өстенә тезләндерделәр, бу аларда иң хурлыклы җәза икән... Без көне буе шунда тезләнеп тордык, бик туңдык. Әти шул хәлләрдән соң салкын тиеп үлде... Чиркәүгә керүчеләр безгә төкереп үтте, урыс малайлары йомарлап битебезгә юеш кар аттылар... Алар аткан салкын кар минем кайнар күз яшьләремнән эреп, битем буйлап акты... Мин буй җитеп килә торган кыз бала идем, бу хәлгә бик хурландым. Әти моны күреп: «Елама, кызым, үзеңне чиркәү ишегалдында дип түгел, Аллаһ каршында тезләнгән дип хис ит һәм теләгәнеңне сора», – диде. Мин Аллаһы Тәгаләдән үземне монда калдырмавын, чиркәүсез татар авылына, мөселманнар арасына күчерүен тилмереп, ялварып, елый-елый сорадым... Аллаһ теләкләремне кабул итте – берничә көннән Тубылгытауга авыру әтиемнең хәлен белергә Шонталадан Ишмөхәммәт әзи килде, алар үзара килешеп, мине аның улына ярәшкәннәр.

Шулай итеп, Кыр Шонталасына килен булып төштем, Бикмөхәммәт исемле егет солтаны минем никахлы ирем булды, балабыз туды, аңа да татарча Мөфлиха, дип исем куштык.

– Димәк, Шонталада сезгә кемдер никах укыган? Кем була инде ул диннән station?

– Мин моны сезгә әйтер дип уйлыйсызмы? Коръәнне белгән һәр мөселман никах укый ала, ә Шонталада барысы да никах укырлык кына Коръән аятьләрен белә – керәшене дә, мөселманнары да...

– Әмма сезгә моның өчен Себер бит, Марфа... Дарья... Марья! Бу сиңа Никитин авылы чиркәве каршында тезләнеп тору гына булмаячак, бөтен христиан дөньясы сатлык керәшеннәрнең битенә төкерәчәк! Син шуңа әзерме? Син шуны телисеңме?

– Аллаһ моны ирекле кылмас! Үз төкерекләре үзләренә кайтыр!

Судья бу татар хатыны белән сөйләшеп торуны файдасыз дип тапты, чөнки ул дине һәм үзе өчен теләсә кемнең бугазын чәйнәп ташларга әзер иде. Аны тизрәк чыгарып җибәреп, мәхкәмә карарын игълан итәргә әзерләнә башладылар. Эшләр башта ук алар уйлаганча китмәде, чиркәү әһелләренә һәм хөкүмәт кешеләренә карата бик куркыныч гаепләү сүзләре әйтелде, хәзер аларны тикшермичә булмаячак. Бу татарлар бит әле Казан – Питерларга да шул хакта шикаятьләр язганнар, әгәр алар патша галиҗәнапләренә барып ирешсә, Чистай өязенең астын-өскә китерәчәкләр! Шуңа күрә бу эш белән ашыкмаска, яңа приставның кубызына биемәскә, ахыргача тикшереп бетерергә туры киләчәк. Мондый четерекле эшкә ноктаны бары тик өяз суды гына куя ала, димәк ки, әлеге эшне аларга тапшырырга кирәк булыр. Чиркәү әһелләрен дөньяви мәхкәмәләр хөкем итә алмаганга, алар турындагы шикаятьне Казандагы консисториягә җибәрергә. Үз попларына карата карарны да алар чыгарсын.

Шулай итеп, 1844 елның 4 мартында Чистай земство суды Гөләйза эше буенча тагын карар чыгара алмады, аны өяз мәхкәмәсенә тапшырды. Югыйсә, инде балалары белән бергә Казанга, чиркәү суды карамагына җибәрергә дип белешмәләр әзерләнгән, атлар җигелгән иде бит! Аллаһ моны ирекле кылмады, чөнки Гөләйза өчен башка язмыш әзерләнгән иде...

## «Балаларымны сезгә ышанып тапшырам...»

Кайтышлый, тагы Актауга тукталырга булдылар, чөнки Ишмөхәммәтнең Якуб атакай белән сөйләшәсе, ә Гөләйзаның Нәгыймәгә әйтер сүзләре бар иде. Мәхкәмәнең хәзергә бер нәтиҗәсез тәмамлануына алар сөенде, әмма моның вакытлыча гына тукталыш булуын барысы да аңлый иде. Хәзер эшне өяз суды караячак, попларның һәм приставларның гаебе булса-булмаса да, Гөләйзаны барыбер хөкем итәчәкләр – монысын да беләләр иде. Әмма атларның Казан ягына түгел, авыл ягына таба борылуы, эшнең сузылуы алар өчен файдалы, шуңа күрә калган эшләрне хәл итеп бетерергә кирәк иде. Гомәр, Исмәгыйль морзаларга, Мөхәммәтзакир Камалига зур рәхмәтләрен әйтеп, Чистай мәчетендә намазларын укып, кышкы юлдан тагы Актауга таба юнәлделәр... Алты ел элек тә шулай булган иде бит, менә хәзер алар тагы шушы юлда... Дин өчен көрәш юлында, язмышның мең сынаулы һәм газаплы юлында...

Аларны күргәч, Нәгыймәләр сөенергә дә, көенергә дә белмәделәр. Гөләйзаларны исән-имин күргәнгә сөенсәләр, аларның һаман суд юлында

йөргәннәренә борчылдылар. Җитмәсә, Ишмөхәммәт әзине һәм Бикмөхәммәтне, аның хатыны Хөсниҗамалны да мәхкәмәгә чакырганнар! Эшнең нәрсәдә икәнен сөйләп биргәч, киңәшеп алырга булдылар. Нәгыймә Гөләйзаның бик нык үзгәрүенә, ябыгуына, сулыгып калуына игътибар итте, берәр чире бармы икән, әллә бу мәхкәмәләр шулай йончытканмы, дип уйлады. Балаларны йөгертеп, тиз генә Мәрьямбануларны да алып килделәр, Гөләйзаның аларга да әйтер сүзе бар иде...

– Никахлы ирем Габделхәким, газиз ата-анам, кардәшләрем, бу сүзләрне сөйләү миңа никадәр авыр булса, сезгә тыңлау тагы да авыр булыр инде, әмма мин бу сүзләрне әйтми китә алмыйм, – дип башлады ул әкрен генә.

Барысы да тынып, сагаеп калдылар, әйтерсең, Гөләйза тормыш мәхкәмәсе каршында соңгы сүзен, әманәтен әйтә, бәхилләшә иде.

– Сизәм – бу дөньяда гомерем озак калмады, – дип дәвам итте ул. – Барыбыз да Аллаһтан килдек – Аллаһка китәбез... Ата-анама мине мөселман итеп тәрбияләгәннәре өчен мәңге рәхмәтлемен, үзләренә күпме авырлыклар алып, алар мине чиркәү афәтеннән саклап калдылар. Никахлы ирем Габделхәкимгә гомер буе рәхмәтле булдым – керәшен дип тормады, мине яратып хатынлыкка алды, какмады-сукмады, яратып яшәде, балаларыма иманлы ата булды... Балаларым тормышымның нуры, олылары инде намазга басты, сүземнән чыкмадылар, ярдәмчеләрем – шулар... Бу гомеремдә соңгы догам да алар өчен булыр... Әйе, соңгы догам, чөнки мин соңгы сәгатем җиткәнен сизенәм... Үтми дә, бетми дә торган бу авырулар юкка түгел инде, Аллаһ мине шулар сәбәпле китәргә әзерли... Казанның чиркәү-монастырьларында, Себер төрмәләрендә газап чиккәнче, бу дөньядан үз ирегемдә китеп бару хәерлерәктер... Аллаһу әгълам – Аллаһ белүче! Әмма мин – ана, соңгы мизгелемдә дә бар өзелгәнем балаларым өчен, соңгы сүзем дә алар турында... Мин китәрмен дә котылырмын, алар нишләр? Бу балаларны чиркәүдә чукындырып, урысларга бирмәсләрме? Менә шушы шомлы уйлар миңа тынычлап китәргә ирек бирми... Бу судлар яңадан башланган икән, алар аңа нокта куймыйча туктамаячак, үз-үзеңне юатырга һәм алдарга кирәкми. Күңелем сизә – иремнән ул балаларны тартып алачаклар... Әти-әнигә дә бирмәячәкләр – аларның үзләрен кимендә сөрген җәзасы көтә. Балаларымны, чит кулларга эләкмәсен өчен, ышанычлы кешеләргә әманәт итеп тапшырырга тиеш, урнаштырып китәргә тиеш... Ул кешеләр хөкүмәт өчен керәшен саналалар, әмма безнең өчен – мөселман. Андый кешеләр сез ул – Васил белән Нәгыймә, Сәгыйдулла белән Мәрьямбану! Мин үзем бу дөньядан киткәндә, балаларымны сезгә ышанып тапшырам, алар мөселман булып калыр, инша Аллаһ! Бу минем соңгы теләгем, соңгы догам, соңгы үтенечем, кире какмагыз аны?!

Шулай диде дә, Гөләйза тагы күкрәгеп тотып йөткерә башлады, ирен читендә ал кан тамчылары пәйда булды. Аны тизрәк сәкедәге урынга алып барып салдылар, Гөләйзаның йөзе ап-ак, анда яшәү дәрте сүнеп бара иде. Ишмөхәммәт кызының баш очында тезләнеп Коръән укыды, Гөлзада үз сулышын өреп өшкерде, балалары аның суынып барган кулларына килеп ябышты, елый башладылар. Гөләйза әкрен генә күзләрен ачты, җиңел сулап, «Мин соңгы сүземне әйттем...» – диде. Аның өстенә җылы юрган яптылар, башын күтәреп, үләнле-җиләкле кайнар чәй эчерделәр, Гөләйзаның бит очлары алланып китте, сулышы тигезләнде, ул арып, йокыга талды... Юк, якыннары бик курыкса да, бу аның мәңгелеккә китүе түгел иде әле, аның өчен Гөләйза

әле авылына кайтыр, анда сандугачлы язларны каршы алыр, язмыш әзерләп куйган соңгы сынауны үтәр...

– Әле ул мондый хәлдә түгел иде бит, нәрсә булды соң аңа? – дип, беренче булып Нәгыймә аңга килде.

– Соңгы вакытта бераз авырып торды ул, йөткерә башлады, ябыкты, – диде Гөлзада. – Шуңа күрә балаларын карашырга да үзем бардым. Бу көннәрдә Чирүле Шонталасына килеп сорау алдылар, шуннан соң кинәт хәле начарланды...

– Нәрсә булган соң анда сорау алганда? Хатын-кызга кул күтәрмәгәннәрдер бит инде? Ул мәлгуньнәрдән барысын да көтәргә була!

– Башта әйтмәде... Без бүлмәгә кергәндә, Гөләйза идәндә аңсыз хәлдә ята иде... «Хәлем бетеп китте, шуңа егылдым», диде. Менә бүген суд вакытында гына дөресен сөйләп бирде – теге явыз Әләксәй Шайтан дигән пристав аны буган икән, аннан идәнгә селтәп аткан... Без аның судта сөйләгәннәрен ишек аша ишетеп тордык. Чыккач әйттек, ник шул вакытта ук бу хакта безгә сөйләмәдең, дидек. «Ул вакытта дөресен әйтсәм, халык баш күтәрер, сугыш чыгар иде, барысын да төрмәгә утыртырлар, дип курыктым», – диде. «Шул чагымда эчемдә нәрсәдер өзелде, әни», – диде балакаем, шуннан мантый алмады инде, саргаеп кибә башлады...

Гөләйзаның әйткәннәре, Гөлзаданың сөйләгәннәре барысын да тетрәндерде, алар телсез-өнсез калдылар. Якыннары аның авырып торуын белсәләр дә, моның сәбәпләрен белмиләр, шулай васыять әйтә-әйтә үлеп китәсенә дә әзер түгелләр иде. Ә ул барысын да уйлап куйган булып чыкты – кайда, кайчанрак үлә, ул үлгәч, ниләр була, балаларын кемгә калдыра – барысы да исәпләнгән иде. Гөләйза йокыга киткәч, бу турыда җыелып сөйләшергә булдылар.

– Бу турыда үзем дә сүз кузгатырга уйлаган идем, әмма кызым әйтеп өлгерде, – дип сүз башлады Ишмөхәммәт, күз яшьләрен сөртеп. – Юк, Гөләйзаны үләр дип уйлаудан түгел, андый-мондый балаларын аерып алсалар, нишләрбез икән, дип исәпләүдән туган иде бу уйлар... Чистайда Гомәр морза да: «Ышанычлы керәшеннәр табып, балаларны шуларга бирергә тырышыгыз», – дигән иде. Кызым, балакаем, ул да шул турыда уйлап йөргән икән, ана йөрәге бит, тыпырчынып эзләнгән, бәгырькәем... Әйе, җәмәгать, безгә ул көннәр килергә мөмкин, чөнки суд әле тәмамланмады, карар чыкмады. Әгәр балаларны ата-анасыннан аерып алып, чукындырырга һәм христианнарга тәрбиягә бирергә, дигән карар чыгарсалар, алар аны эшләячәк. Миңа Чистайда Гомәр әзи әйтте: «Ышанычлы керәшен авылы, ышанычлы керәшен побы, балаларыгызны тапшырырга ышанычлы керәшен татарлары табыгыз!» – диде... Мин Актауны әйттем. Ягъни, әгәр шушы хәл була калса, балаларны суд карары белән аерып алсалар, чукындырырга теләсәләр, аларны Актау авылына, Якуб атакайга тапшырырга туры киләчәк. Ул, поп булса да, татар кешесе, үзебезнең авылдан, әле Гөлзадаларга туган да тиешле, балаларга карата мәрхәмәт күрсәтер, аларны чукындырмас, дип уйлыйм. Әлбәттә, бик яхшылап сөйләшергә туры киләчәк, Чистай морзалары да аның белән сөйләшәбез, диделәр... Әгәр ул балаларны чиркәүдә чукындырмыйча гына, «бу эш эшләнде», дип, Казанга белешмә җибәрсә, әлеге афәттән котылдык дигән сүз. Аннан балаларны тәрбиягә бирергә христиан ата-анасы табарга туры киләчәк. Ягъни, хөкүмәт аларны христиан динендә дип белсен, ышанып, балаларны тапшырсын, ә алар безнең кебек мәкруһлар, яшерен мөселманнар булсын... Мин үзем дә, Гомәр әзи бу

хакта әйтүгә, сезне уйладым, Васил энем! Гөләйза кызым исә күптән бу турыда уйлап йөргән икән, балакаем!

Ишмөхәммәт шулай диде дә туктап калды, тагы күз яшьләрен сөртеп алды. Шул чакта сүзгә Хәким кушылды, аның үзеннән башка балаларын бүлгәләп утыруларына бераз хәтере дә калган иде.

– Туктагыз әле, җәмәгать, монда мин дә бар бит әле – ул балаларның аталары! – диде ул. – Ник мин балаларымны үзем исән чагында уңга-сулга таратырга тиеш әле? Гөләйза да терелер, Алла теләсә, авыру сәбәпле генә сөйли ул бу сүзләрне... Авылга кайтып, яңадан элеккечә яши башларбыз, берни булмас!

– Элеккечә була алмый инде, кияү! Суд бүген үк әлеге эшкә нокта куеп, Гөләйза белән балаларны Казанга җибәрергә тиеш иде, Алла ярдәме белән, алай булмады. Әмма бу аларның вакытлыча гына туктап торулары, һәртөрле хәлгә әзер торырга кирәк! Бу юлы да Казанга җибәрергә атлар җигелгән, дүкәмитләре әзерләп куелган булган, шул тирәдә йөрүчеләр Исмәгыйль морзаларга әйткән. Әләксәй Шайтан дигән яңа пристав эшне ахырына кадәр җиткерәчәк.

– Ул вакытта, бәлки, безгә бөтенләй авылдан чыгып китәргә кирәктер? Нигә богаулап төрмәгә алып киткәннәрен көтеп ятарга?!

– Күрмисеңме, кияү, Гөләйзаның хәлен? Ул бүген васыятен әйтте, балаларын әманәт итеп Василларга, Мәрьямбануларга тапшырды. Урманнарда качак булып йөрерлек хәлдә түгел инде ул... Балалар да кечкенә, төпчегең Гыйниятуллага ике яшь тә юк. Хәзер качакларны да бик нык эзәрлеклиләр, тотсалар, каты җәза бирелә, менә анда чукындырудан качып булмаячак инде, сорап та тормаячаклар!

– Ярар, бабай, син әйткәнчә дә булсын, ди... Әмма миңа карата җинаять эше ачылмаган бит, алар өчен мин ирекле һәм гаепсез кеше! Шулай булгач, нигә ул балаларны миннән тартып алырга тиешләр?

– Чөнки син мөселман, ә аларны керәшен анадан законсыз туган, дип баралар... Урыс законы каршында син ата кеше булып саналмыйсың, чөнки аларча христиан кешесе бары тик христиан белән генә гаилә корырга тиеш. Әле үзеңә дә, керәшен кызын аздырган, дип эш башлап җибәрергә мөмкиннәр, менә безгә ачкан кебек. Кыскасы, Гөләйза исән калса да, сезгә бергә яшәргә ирек бирмәячәкләр, балаларны да сезнең белән калдырмаячаклар – аларда тәртибе шундый. Шуңа күрә, алар килеп тотынганчы, үзебез юлларын табып куярга тиешбез. Хәзер Якуб атакайның моңа ризалашуы кирәк, бу бик яшерен һәм куркыныч эш, аның өчен дә, башкалар өчен дә... Һәм, Васил энем, Нәгыймә сеңлем, Сәгыйдулла энем, Мәрьямбану сеңлем, сезнең ризалык кирәк. Бу бик җаваплы һәм саваплы гамәл, әмма куркыныч та... Сизә калсалар, сезгә дә җинаять эше ачарга мөмкиннәр, анысын да белеп тору кирәк...

Васил белән Нәгыймә бу хәлләрдән әле һаман аңнарына килә алмыйча утыралар иде. Гөләйзаны күрүгә үк, алар шомланып калганнар, чөнки ул бик ябыккан һәм хәлсез иде. Кая ул теге вакыттагы янып торган Гөләйза, дин-ислам турында дәртләнеп-очкынланып сөйләгән, аларны да шуңа рухландырган Гөләйза! Аның ханбикәләрнеке кебек затлы, гүзәл йөзе сулган, күзләрендә бетмәс моң, бары тик тавышы гына элеккечә калган, иманы, инануы элеккечә... Кеше бит мондый сүзне уйламыйча әйтми, димәк, ул аның күңелендә йөргән, инде соңгы сәгате якынлашканын сизеп, ул аны әйтеп калырга ашыккан. Кешенең соңгы гозерен, соңгы үтенечен үтәми мөмкин түгел, бигрәк тә Гөләйзаныкын.

– Ишмөхәммәт әзи, син безнең тарихны яхшы беләсең, – дип, ерактан

башлап китте Васил. – Яшь булсак та, без бу дөньяда аз күрмәдек... Әтине, керәшен башы белән намаз укыган, ислам динен тоткан өчен, төрмәдән-төрмәгә, авылдан-авылга куып йөрттеләр, ахырда аркасына мунча себеркесе бәйләп, тереләй яндырып үтерделәр... Әни һәм башка туганнарым ачтан үлде. Мәрьямбану апай белән мин шушы керәшен авылына эләгеп кенә исән калдык. Аллаһы Тәгалә безне, ятим балаларны, Әкълимә әбинең нәселе белән тоташтырды, сезнең белән таныштырды, чиркәүле урыс-татар авылында яшәсәк тә, исламга юлларыбызны ачты. Бу безнең иң зур бәхетебез, Ишук әзи! Ул бәхеткә сез дә сәбәпче булдыгыз – син, Гөлзада апай, Гөләйза... Сез сәбәпле, Мәрьямбану апай белән Сәгыйдулла җизнәй дә намазга бастылар, балаларыбыз намазда, Аллага мең шөкер! Без, үзебез ятим балалар, үзебез дин-ислам өчен күпме җәбер-җәфа күргән кешеләр, ничек инде шушы хәлдә калган милләттәшләребезгә, дин кардәшләребезгә ярдәм итмик ди?! Тыныч булыгыз – Гөләйзаның балалары безнең балалар булыр, кирәк дип тапсагыз, өчесен дә хәзер үк калдыра аласыз! Бу безнең өчен җәннәт саваплары булачак, шулай бит, Нәгыймә?

Нәгыймә әле һаман елавыннан туктала алмый иде, ул Гөләйза өчен үз йөрәген ярып бирерлек булып борчылды, үз гомерен бирерлек булып кайгырды. Әкълимә әбисе үлгәндә, палисайлар аны кабереннән актарып алганда, әтисе аның мәетен кырга алып чыгып мөселманча җирләгән өчен шул палисайлар тарафыннан кыйнап үтерелгәндә нәкъ шулай өзгәләнгән иде Нәгыймә... Менә хәзер Гөләйза да шушы хәлдә... Аны да Әкълимә әбинең язмышы көтә... Нәгыймә бу язмышны үзгәртә алмый, бары тик җиңеләйтә генә ала.

– Алар үз балаларыбыздан да кадерле булыр, Васил! Чөнки алар – Аллаһ алдында әманәт. Мин үз гомеремне биреп булса да аларны коткарырмын, аларны саклармын... Күңелебезнең дә, өебезнең дә түрендә булырлар...

Шулай диде дә, Нәгыймә тагы үксеп елап җибәрде, кечкенә Гыйниятулла да аның тезләренә капланып, мышкылдый башлады, сабый күңеле дә нидер сизенә иде. Гөлзада оныгын үз кулларына алды, тирбәтеп, йоклата башлады.

– Рәхмәт, Нәгыймә сеңлем, рәхмәт, Васил энем, авыр вакытыбызда хәлебезне аңладыгыз! – диде ул, сүзгә кушылып. – Гөләйза белән болай килеп чыгар дип һич көтмәгән идек... Төрмәсен дә уйладык, Казан монастырьларына җибәрмәгәйләре, дип тә курыктык, әмма монысын... үлем чирен... балаларын васыять итүен... юк, көтмәдек тә, моңа әзер дә түгел идек... Әле күңел ышанмый! Гел ниндидер могҗиза көтәм, элеккеге Гөләйзам янымда йөгереп йөрер кебек тоела... Юк, ышанмыйм... ышанмыйм...

Ул, оныгы өстенә капланып, сулкылдап елый башлады, Ишмөхәммәт баланы, аның кулларыннан алып, Гөләйза янына сәкегә илтеп салды.

– Безгә барысына да әзер торырга кирәк, Гөлзада! – диде ул. – Әгәр Гөләйза исән калса, төрмәләрдән котылса, балалары үзләре белән булыр. Әгәр дә инде... әгәр дә инде башкача булса... сөйләшкәнчә эшләрбез, Алла теләсә! Син дә борчылма, кияү, балалар монда гомерлеккә калмас, шул чукындыру шаукымы үтеп киткәч, дөньялар бераз тынычлангач, яныңа кайтырлар. Исәнлек кирәк. Аллаһ ничек язган – шулай булыр, ярдәменнән өметне өзмик.

– Ишук әзи, балаларны бүлсәләр, безгә дә бирә аласыз, – дип, сүзгә Мәрьямбану да кушылды. – Бездә дә алар мөселман тәрбиясе алыр, тамаклары тук, өсләре бөтен булыр, шулай бит, Сәгыйдулла?

– Син ничек әйтсәң, шуңа риза, Мәрьямбану! Улыбыз Салихҗанга да иптәш кирәк, бер янына ике дә сыяр, өч тә сыяр, күңел киң булсын!

Кечерәк балалар инде арып йокыга киткән, ә олыраклары җыелып Габделвахитны юаталар... Бигрәк тә Мәрьям өзгәләнә, кечкенә вакытта ул аны кулыннан да ычкындырмый иде, хәзер ояла, әмма янынннан китми. Салихҗан да алар янында, ул алардан бераз олырак, әмма әле балалыктан чыгып бетмәгән. Гөләйзаның йокыга китәр алдыннан сөйләгән сүзләрен барысы да ишетеп торды, аның тиздән үләсен, үлгәч, балаларын аларга васыять иткәнен алар да белде.

– Кайгырма, Габделвахит, энеләрең белән бездә торырсыз, бергәләп намаз укырбыз, Бахтада балык тотарбыз! – диде Салихҗан, аны юатырга тырышып.

– Юк, Вахит бездә тора! – дип, Мәрьям аңа чәчрәп каршы чыкты. – Без бергәләп куяннарны карарбыз, болыннан аларга үлән җыеп кайтырбыз! Урманга җиләккә йөрербез! Вахит бездә кала! Мин аны беркемгә дә бирмим!

Шулай диде дә, Мәрьям кып-кызыл булды, аннан уттай янган битләрен каплап, чаршау артына кереп китте. Габделвахит исә сәкедә сабый бала кебек йокыга талган әнисенә карады. Кодрәтеннән килсә, ул аны хәзер кулларына күтәрер иде дә урыслар эзләп таба алмаслык җирләргә алып китәр иде... Җылы илләргә, гел җәй һәм яшеллек булган җирләргә, бу газаплар булмаган урыннарга алып качар иде ул газиз әнисен! Бөтен дөнья буйлап кулларына күтәреп алып барыр иде, шушы кайгы-хәсрәтләреннән аралап алып калыр иде, җәннәт капкаларыннан кертеп җибәрер иде... Әни, әнием, бәгырькәем... Күз нурым! Үлмә генә, улың сине барыбер коткарачак, барыбер ул залимнәр кулына бирмәячәк... Әнисенең сөйләгәннәрен Габделвахит та ишетте – чукындыртмас өчен, ул аларны монда бирергә җыена. Әмма аны баш очында балта тотып та чукындыра алмасларын ул белми әле... Бөтен дөньясын кара болыттай тәреләр каплап китсә дә, ул аларны аралап, иман нурын табачак, әби-бабалары, ата-аналары динендә калачак, нәселнең догачысы булачак... Инде бу дөньядан китеп баручы әнисенең өстенә карап, Габделвахит шулай дип ант итте, шушыларны аңлаган вакыттан аның балачагы бетте...

Олыларның исә һаман үз сүзләре иде – алга таба нишләргә? Ахырда шулай килештеләр – эш балаларны христианнарга тәрбиягә бирүгә барып җитә икән, Актау авылын сайларга, аларны Василларга һәм Мәрьямбануларга бирү өчен тырышырга. Әмма моның өчен хәзер Якуб атакайны ризалатырга кирәк, ә ул бик сак һәм шактый куркак кеше, бу шикле эшкә башы-аягы белән каршы булачак. Каршы булса – бернәрсә дә килеп чыкмаячак, балаларны кан елатып урысларга бирәчәкләр. Кичке намазларны укыгач, Ишмөхәммәт белән Васил, киенеп, Якуб атакайларга чыгып киттеләр, алда авыр һәм җитди сөйләшү көтә иде...

...Якуб атакай аларны куркыбрак каршы алды, Ишмөхәммәт белән Василның кичке якта юкка йөрмәгәннәрен чамалый иде ул. Гөләйзаның эшен алты елдан соң яңадан карый башлаганнар, хәзер ата-анасын, энесен дә гаеплиләр икән, барысын да җыеп Казандагы чиркәү судына җибәрергә мөмкиннәр, дип ишетте. Моның шулай бетәсен Якуб атакай үзе дә чамалый иде, әмма шактый вакыт үткәч, бәлки, боларга кагылмаслар, дип уйлады. Юк, менә инде Ишмөхәммәт хәтле Ишмөхәммәткә дә чират җиткән, югыйсә ул Чистай байлары, Казан түрәләре белән генә эш йөртә иде бит! Якуб атакайның бөтен курыкканы – бу эшләргә аны гына катыштыра күрмәсеннәр, бу мәкруһ татарларның Василлар өендә җыелышып намаз укып ятуларын белә күрмәсеннәр, ул чагында аның үзен дә Казандагы чиркәү суды – консистория көтә...

– Киңәшеп аласы нәрсәләр бар, Якуб энем! – дип, Ишмөхәммәт керә-

керешкә төп сүзгә күчте. – Без Чистайдан, судтан кайтып киләбез, бу эшләр җүнле бетмәс ахры...

– Их, Ишук әзи, Ишук әзи! Минме сиңа әйтмәдем эшнең шулай бетәсен?! Тыңламадың! Әйдә, кергәнсез икән, бу бүлмәгә үтик, ишек төбендә озын колакларның ишетүе бар...

Якуб атакайның куркуы йөзенә һәм теленә чыккан иде, ул мосафирларын түрдәге кечкенә бүлмәсенә алып кереп китте. Бу юлы чәйләп-мәйләп тормадылар, шунда ук сүзгә керештеләр.

– Судны тагы кичектерделәр, хәзер өязнеке караячак, – диде Ишмөхәммәт. – Карарны бүген үк чыгарырга әзерләнгән булганнар, Гөләйза белән балаларын Казанга, чиркәү судына алып китәргә атлар җигелгән иде, үзем күрдем... Әмма Аллаһ аларны туктатты...

– Суд хәтле судны кичектерерлек нәрсә булды соң анда, Ишук әзи?

– Үзләренең гаепләрен чыгарып салырга туры килде, Якуб энем!

– Кемнәрнең? Судныңмы?

– Юк, попларның һәм приставларның...

– Аларның нинди гаепләре булсын суд каршында? Кызың Гөләйза эшендә ни катнашлары булсын?

– Син дөньяга бүген генә килмәгән, Якуб энем, шулар арасында кайныйсың һәм барысын да беләсең булыр... Без, керәшен башыбыз белән, ничек монда ислам динен тотып ята алдык соң, Себерләргә дә сөрелмичә калдык, балаларыбызны да үзебезнекеләр белән парлаштырдык?.. Акчага сатылган шул поплар һәм шушы эшләргә күз йомган хөкүмәт кешеләре ярдәме белән бит, үзең уйлап кара! Кызылъяр попларының да, приставларының да нәрсә белән шөгыльләнеп ятуларын ачып салырга туры килде.

Ишмөхәммәтнең бу сүзләре Якубның башына тиз генә барып җитмәде, барып җитсә дә, ул аңа ышанмады, ышанса да, бу эшләрнең фаш булуын танырга теләмәде. Шулай бераз миңгерәеп утыргач, ул болар турында Ишмөхәммәтнең үзенә дә әйтергә булды.

– Ышанмыйм, Ишук әзи! Үзеңә ярдәм иткән шушы кешеләрне суд алдында фаш иткәнеңә ышанмыйм! Бу синең динеңә дә туры килми, минекенә дә батмый... Бу хәл мөмкин түгел!

– Әйе, сыер һәм ат бәясенә, татарның соңгы акчасына алар безгә ярдәм итте, ягъни, кирәк вакытта керәшен, дип, кирәк вакытта чукындырылмаган, дип кәгазь язып бирделәр. Аларның бу кәгазьләре кайвакытта безгә булышты, кайвакытта аңа борылып та карамадылар – дин өчен ничек эзәрлекләсәләр, шулай дәвам иттеләр. Барысы да бездән акча көтте – мондагылары да, Казан түрәләре дә, хәтта Питерныкылар да... Иманыбызга зыян китереп булса да, без аларга ул акчаларны бирдек, чөнки шулай итеп дин ирегген үзебез сатып алдык...

– Ярар, анысын аңлыйм, Ишук әзи, монда һәр эш шулай хәл ителә, керәшенлек мәсьәләсе генә түгел. Әмма нигә боларны суд каршында сөйләдең син? Аңа карап, синең хәлең җиңеләйми, ә аларныкы начарланачак бит! Аларны да хөкемгә тартырга мөмкиннәр.

– Әйе, безнең хәл җиңеләймәс, әмма эш беразга булса да сузылачак, монысы да безнең өчен бик мөһим. Бәлки, аларны да хөкемгә тартырлар, бәлки, куертып тормаслар... Әмма мин бу хакта Питерга, патшаның үзенә дә хат язып җибәрдем, аларны барыбер тикшерәчәкләр. Һәркем үз җәзасын алырга тиеш – бу дөньяда да, тегесендә дә. Бәлки, шушылар фаш булгач, керәшен

татарлары мәсьәләсенә яңадан әйләнеп кайтырлар, милләтнең кимендә чиреге шулай газап чигә бит!

– Кызылъяр попы Мифодей атакайның болай да эшләре начар иде, эчүдән башы чыкмый, болай булгач, чиркәү судына тапшырырлар инде аны... Анда гыйбадәт уздырырга тагы миңа йөрергә туры килмәгәе.

– Мифодей атакаең оятсыз кеше булып чыкты, Якуб энем, миннән уч тутырып акчасын алды, ә яңа приставка белешмәне безгә каршы биргән! Чиркәү кенәгәләрен яңадан тутыруга хәтле барып җиткән! Бөтен сүзләребезне ялганга чыгарган! Гөләйзаны бары тик аның күрсәтмәсе буенча гына хөкем итәләр, аңа каршы башка дәлилләр юк! Син әле шул сатлыкны кызганып утырасың! Урыны шунда аның – чиркәү төрмәсендә!

Ишмөхәммәтнең өйне яңгыратып, кулындагы гөрзи-таягы белән идәнне төя-төя ярсып сөйләве Якуб атакайны бөтенләй куркуга салды, ул үзе турында борчылып уйлады. Дөрес, башка поплар кебек алай акчага сатылганы юк, әмма аның да борын төбендә шушы Ишуклар, керәшен татарлары өелеп намаз укып ята бит! Ә ул аларга күз йома, чөнки тавыш чыгуын теләми, чөнки ул аларны барыбер җиңә алмый. Бу Ишмөхәммәт хәзер аны да барып әләкләсә? Якубның башын Себердә черетәчәкләр бит, Себердә! Артыгын ычкындырмасын өчен, ничек тә күңелен йомшартырга кирәк бу картның, юкса, бөтен авылның башына җитәчәк, аның югалтыр нәрсәсе калмаган инде...

– Гөләйзаның хәлләре ничек соң, Ишук әзи? – дип сорады ул, сүзне читкәрәк бору өчен. – Шулай ук Казанга чиркәү төрмәсенә алып китәрләрме икәнни? Үзе дә, балалары да бик кызганыч, миңа Гөлзада ягыннан туган да тиешле бит әле ул.

Ишмөхәммәт сүзнең бу якка борылуына сөенде генә, үзе дә ничек ул турыда башларга белми утыра иде.

– Гөләйзаның хәлләре әйбәт түгел, Якуб энем! – диде ул. – Бүген Василларда васыятен әйтте... Балаларын аларга әманәт итте.

– Ничек – васыятен?! Казанга җибәрсәләр дә, үләргә китми бит ул анда! Керәшенлеккә ризалашса, чукынып, муенына тәре асса, балаларын да чукындырса, аңа әллә ни булмас, әмма иреннән аерырлар инде, мөселман белән яшәтеп яткырмаслар.

– Казанга барып җитә алмас ул, Якуб энем! Гөләйза бик каты авырый, әҗәл чире булмагае...

– Нәрсә булды, әле ул-бу ишетелмәгән иде бит?

– Салкын тиеп, бераз авырып тора иде ул, моңа тагы өстәлде... Ун көннәр элек бездә Чистайдан килеп сорау алдылар бит – Чирүле Шонталасында да, Кызылъярда да... Гөләйзадан сорау алганда, теге яңа пристав – Әләксәй Шайтан, котырып китеп, аның битенә Библия белән бәргән, тәресен төрткән. Гөләйза аларны тотарга теләмәгәч, бугазыннан алып, идәнгә бәргән. Гөлзадалар кергәндә, ул аңсыз хәлдә идәндә яткан. Шуннан соң ыклап чирли башлады, саргайды, ябыкты, ашаудан калды. «Эчемдә нәрсәдер өзелде», дигән, балакаем...

– Кеше түгел икән бу яңа пристав, аның турында, ерткыч, дип сөйлиләр шул! Ничә керәшен татарын үтергәнче кыйнаган инде ул. Әле беркөнне Котош попы Николай атакайны күргән идем, ул да аннан зарланды, безне, керәшен попларын, бөтенләй кешегә санамый икән, ди... Алайса, Гөләйза Шонталага үләргә кайта инде, бичаракай... Әйе, аңа карамаслар, балаларын барыбер аерып алырлар аның, мөселман ата белән яшәтмәсләр.

– Менә шуңа күрә үзе үлгәнче үк балаларын Василларга тапшырырга, дип васыять әйтте инде ул. Василлар да, Мәрьямбанулар да аларны алырга риза, хәзер синең сүзең, синең ярдәмең кирәк, Якуб энем!

– Балалар миңа әманәт ителмәгән бит, Ишук әзи, нинди ярдәм турында әйтәсең?

– Ярдәмнең дә иң зурысы, Якуб энем! Без Чистайда Гомәр әзиләр, Исмәгыйль морзалар белән җыелып киңәштек һәм шундый фикергә килдек – бу балаларны чукындырудан саклап калу өчен, ышанычлы керәшен авылы, ышанычлы керәшен побы, ышанычлы керәшен татарлары кирәк булачак. Ул авыл – Актау, ул поп – син, Якуб атакай, ул керәшен татарлары – менә Василлар...

– Ә мин... мин нәрсәгә кирәк? – дип, Якуб чакка-көчкә сорый алды, ул нидер сизенә башлаган иде.

– Әгәр балаларны урыс авылына бирсәләр, аларны чиркәүгә алып барып чукындырачаклар һәм муеннарына тәре асачаклар, ә үзләрен урысларга тәрбиягә бирәчәкләр. Бу инде балалар бетте, дигән сүз... Әгәр синең кулга эләксә, аларны чукындырмыйча гына да керәшен дигән кәгазьне язып бирә аласың, Казанга чукындырдык, дип хисап тотасың. Тәрбиягә дә урысларга түгел, Василларга бирелсәләр, алар ул балалардан үзләре кебек кеше ясарлар иде.

Менә хәзер инде Якуб атакайның башына барып җитте – болар аны да харап итәргә җыеналар икән бит! Ничек инде ул, чиркәү әһеле була торып, чукындырылмаган килеш чукындырылды, дип, Казанга хисап тота алсын?! Боларга шундый кәгазь бирә алсын? Бу бит баш китәрлек эш!

– Юк, юк, мең тапкыр юк! Бу эшкә мине бутый күрмәгез! Әле генә үзең сөйләп тордың – шундый ялган кәгазь язып биргән Кызылъяр попларын судта фаш иттем, дип! Бу юлга бассам, мине дә шул язмыш көтәчәк! Мине катнаштырмагыз, үзегез теләсә нәрсә эшләгез!

Шулай диде дә, Якуб урыныннан ук кузгалып китте, бу аның сүз беткәнгә ишарәсе иде. Әмма Ишмөхәммәт тә моннан болай гына чыгып китә алмый, чөнки балаларны чукындырудан коткаруда башка юл юк. Димәк, ничек тә Якуб атакайны ризалаштырырга, ул ризалашмыйча, моннан чыкмаска кирәк иде. Һәм ул мәсьәләгә икенче яклап килеп карады.

– Якуб энем, өең тулы бала-чага, инде буй җитеп килә торганнары да бар. Әгәр безгә бу эштә ярдәм итсәң, Чистай байлары сине бөтен гомереңә җитәрлек итеп бәхилләтәчәкләр, шулай вәгъдә бирделәр. Телисең икән – монда, телисең икән – Чистайда, Казанда үзеңә һәм балаларыңа таш ызбалар салып бирәчәкләр, абзарың тулы мал-туарың, кибетләрең булачак. Мин инде әҗер савабын әйтеп тә тормыйм – авыр чакларында мөселманнарга ярдәм иткәнең өчен Аллаһ сине һәм нәселеңне ярдәменнән ташламас, инша Аллаһ! Ә инде фаш итү турында уйлама син, үзләре безне сатмаса, мин тегеләрне дә әйтми идем. Василларда ничә еллар буе җомга намазлары укуыбызны берәүгә дә әйтмибез бит, без дә кайда нәрсә сөйләргә кирәген яхшы беләбез. Гозеремне тыңла, Якуб атакай, сүземне аяк астына салма, синең сүзеңнән ул бичара балаларның алдагы язмышы тора! Мин синең яныңа үзебезнең татар кешесе булганың өчен дә килдем бит, диннәребез төрле булса да, без бит бер милләт, бер авыл, бер нәсел кешеләре...

Ишмөхәммәтнең бу сүзләреннән Якуб атакай яңадан урынына килеп утырды. Юк, Ишмөхәммәт аңа алтын таулар вәгъдә иткәне өчен түгел, һәрхәлдә, анысы да комачау итмәс иде – итәк тулы бала... Ишмөхәммәтнең,

татар булганың өчен янына килдем, дигән сүзләре үзәген өзде. Әйе, каргалган язмышлары аларны урталай бүлде: бер якта – әлмисактан мөселман булган татарлар, икенче якта көчләп чукындырылган керәшен татарлары аерылып калды... Борынгы бәетләрдәге Сак-Сок кошлары кебек, алар мәңге кавыша алмаячак. Алар хәтта ахирәт көнендә дә бергә була алмаячак – һәркем үз диндәшләре белән кубарылачак... Олыгайган саен, Якуб атакай да менә шулар турында уйлана башлады. Юк, Ишмөхәммәтләр кебек, ислам диненә кайтмас инде ул, һәрхәлдә, әби-бабалары Шонтала мөселманнары булса да. Ул инде шушы христиан диненә күңелен бирде, аны кечкенәдән кабул итте, шуның буенча укыды, башкаларны укытты, гаиләсе-балалары да чиркәү әһелләре. Ул үзе генә түгел, аларның барысын да, хәтта ки керәшен авылы Актауны яңадан исламга алып кайтырга тиеш була, ә Якуб атакай моны эшли алмый, юк, эшли алмый! Соң инде, керәшенлек аларның яшәү рәвешенә әйләнеп бара, халык башканы белми, белергә дә теләми.

Якубның озак дәшми утыруын күреп, Васил да сүзгә кушылды.

– Син курыкма, Якуб дәдәй, без сиңа тел тидертмәбез! – диде ул. – Без, мәкруһлар, авылда шактый әле, бер-беребезне яклабыз. Син нинди карар кабул итсәң дә, без Гөләйзаның балаларын үзебезгә алачакбыз, Алла теләсә! Апай белән үзебез дә ятим калдык, авылдан-авылга сөрелдек, моның нәрсә икәнен беләбез. Гөләйзаның балалары алай газап чигәргә тиеш түгел, әниләренең күргәннәре дә җиткән. Без аларны үзебез кебек мөселманнар итеп тәрбияләрбез, инша Аллаһ!

– Ишмөхәммәт әзи, син мине беләсең – бераз саграк кеше булсам да, бөтенләй үк имансыз түгел мин, – дип башлап китте Якуб. – Монда ничә еллар буе җыелып намаз укып ятуыгызны да сатмадым, югыйсә, Биләр атакае үзәгемә үтте сорашып, гел, юк, дип бардым... Анысы башка, үз эшегез иде, мин белмәмешкә салыштым... Ә монысында минем турыдан-туры катнашым булачак бит! Мин бөтен җаваплылыкны үз өстемә алырга тиеш булам. Ул балаларны чиркәүдә чукындырмаган килеш, христиан йолаларын үтәмәгән килеш, чукындырдым, дип, югары оешмаларга хисап бирергә тиеш булам. Күрәләтә ялганга бару миңа бик авыр. Моны авыл халкы да сизәргә мөмкин, берәрсенең барып чагуы бар... Ул чагында бөтенебез кәтер китәбез бит, Ишук әзи!

– Курыкма, Якуб энем, чакмаслар, сатсалар, безне саткан булырлар иде инде... Актау халкы андый түгел ул, яртысы безнең авылныкы... Аннан, янында без дә булырбыз, дип уйлыйм. Әгәр безне гаиләбез белән чиркәүле урыс-керәшен авылына мәҗбүри күчерсәләр, без ничек тә Актауга эләгергә тырышырбыз. Бу хакта Чистайда эш алып баралар инде. Безне җәзасыз калдырмаслар, эшләр шуңа таба бара, әмма бу җәзаны да үз файдабызга бора белергә кирәк, мишәрләр бит әле без, Якуб энем! Ат өстендә туган халык, хәзер дә ат өстендә калыйк! Баш бирмик, беттек-беттек, дип елап утырмыйк! Бөтен җирдән дә чыгу юлы бар, кабердән генә чыгу юлы юк – шуны онытмыйк!

Шулай килештеләр. Мәсьәләнең иң авыры хәл ителгән иде. Инде эшнең ахырын көтәргә генә калды, ә ул ахырына таба якынлаша иде...

***

...Гөләйза бик югарыдан – җиденче кат күкләрдән соңгы тапкыр туган җирләренә карап тора...

Ә анда – бөтен Биләр-Болгар буйлары ап-ак киемле кешеләр белән тулган, алар, урман-кырларны тутырып, намаз укыйлар...

Юк, бу бит кешеләр дә түгел, ә кеше кыяфәтенә кергән рухлар – җаннар икән, әрвахлар шулай, туган якларына әйләнеп кайтып, гыйбадәт кылалар...

Дин-ислам өчен көрәшеп һәм сугышып шәһит киткәннәр, төрмәләрдә газап чиккән, монастырьларда аяк-куллары богаулап чукындырылган, Себерләрдә үлеп калган, иман хакына тереләй утларда янган, бозлы суларга ябышып каткан, каберләреннән казып алынган, күмәргә урын таба алмыйча, агач төпләрендә, елга ярларында, чокыр-чакырларда ятып калган татарларның рухлары шулай туган җирләренә әйләнеп кайткан...

Алар арасында Әкълимә әби һәм аның кыйнап үтерелгән улы Мөхәммәт тә, Гөләйзаның тереләй яндырып үтерелгән әби-бабасы Гөләйзар һәм Бикмөхәммәт тә, Урал-Җаек тауларында иман хакына утта яндырылып үтерелгән Хөснибикә дә, Василның ата-аналары, качаклыкта үлеп калган мәкруһ татарлар да – барысы да бар иде...

Һәм алар җәннәт ияләре иде...

Һәм алар арасында Гөләйза үзе дә бар иде...

Һәм ул өстән – җиденче кат күкләрдән – үз-үзенә карап тора...

Һәм ул, башкалар белән бергә, җирдә аерылып калган якыннары өчен дога кыла, Аллаһтан алар өчен иман һәм иминлек сорый...

Кара җирләргә тезләнеп, нәселенең мөселман булуын, үзеннән соң да Болгар-Биләр буйларында дога кылучылар калуын тели...

Бер Гөләйза гына түгел, гыйбадәт кылучылар барысы да шуны сорый, шуны көтә, шуны өмет итә...

«Сез җәһәннәм утында янмасын өчен, без җирдә вакытта тереләй утларда яндык...

Сезгә ислам нурын биреп калдыру өчен, без, аяк-кулларыбыз богауланып, салкын Себерләргә киттек...

Сез яшәсен өчен, без үлдек, иманның кадерен белегез, аны безнең кебек саклагыз!» – диләр иде алар...

## Мәңгелеккә кайту...

1844 елның 18 апрелендә Чистайда өяз суды, Гөләйзаны балалары белән бергә Казан рухани консисториясенә җибәрергә, дигән карар чыгара, бу юлы аларның үзләрен мәхкәмәгә чакырып та тормыйлар. Суд карарын үтәү земство мәхкәмәсенә йөкләнә, ул исә әлеге эшне апрель азагында приставка тапшыра. Һәм Алексей Шахт, җомга иртәләренең берсендә, үзе белән берничә атлы казакны алып, Кызылъярдан Чирүле Шонталасына кузгала... Авыру кулы һаман тынгы бирмәсә дә, Шахт чиксез канәгать, чөнки бар да ул дигәнчә бара! Ул бу татарларның оясын туздырды, христиан динен санламаганнары өчен, суд каршына бастырды, мәхкәмә карары да ул теләгәнчә булды – чукындырырга! Ай чабышты да соң татарлар андый карар кабул иттермәс өчен, бөтен өерләре белән кузгалдылар, кая гына бармадылар, нәрсә генә язмадылар, күпме байлыкларын туздырдылар – ә барыбер аларча булмады! Һәм булмас та! Бу башбирмәс керәшен хатынын да, балаларын да ботларыннан асып куеп чукындырачаклар, Казан чиркәүләре әле ул! Әмма аңа кадәр Шахт ул Пелагея-Гөләйзаны үзе «чукындырачак», Кызылъярдагы йортына алып кайтып, балалары каршында... Инде мәңге ислам дине ягына борылып карамаслык итеп! Ә бәлки әле үзенә хатын итеп алыр бу чибәр татар морзабикәсен, ул аңа итәк тотырып Иван һәм Марияларны табып үстерер! Татар хатыннарын бик

тырыш һәм сабыр, диләр бит, Шахтка нәкъ шундый бичә кирәк тә инде, үзе белән кара-каршы сугыша торганнар түгел...

Шахт, шундый уйлар белән дәртләнеп, атын кыр юлы буйлап Чирүле Шонталасына таба куа, ул авылга җомга турында барып керергә һәм Гөләйзаны да ир-ат мәчеттә вакытта алып чыгып китәргә ниятли. Анда халык усал, болай гына биреп җибәрмәүләре бар, алар өчен суд карары кәгазь кисәге генә... Шуңа күрә ул барысын да уйлап куйды – өйдә хатын-кызлар гына калган вакытны чамаларга һәм балалары белән арбага төяп, алып чыгып китәргә кирәк булачак. Инде болай барып чыкмый икән, берәр каршылык туса, авыл башлыгын ярдәмгә чакырырга, чөнки бу аның да эше. Бүген барысы да хәл ителәчәк, елларга сузылган мәхкәмә эшенә нокта куелачак, Шахт та Биләр атакаена биргән вәгъдәсен үтәячәк.

Әйе, ул Биләр побы Михаил атакайга тәре үбеп ант итте! Бу басурманнарны бугазларыннан алып христиан диненә кайтарырга вәгъдә бирде һәм шулай эшләде дә! Пелагея дигән керәшенне бугазыннан алып Библиягә төртте, эшне Чистай судына кадәр китереп җиткерде, һәм менә аның карары Шахт кулында! Ул шуны тормышка ашырырга бара! Эш беткәч, барып, Биләр атакаеның күңелен тынычландырыр, чөнки ул моның өчен бик борчыла, шушыны белмичә теге дөньяга да китә алмый... Соңгы вакытларда бик бетеренде ул, туксан белән бара бит, хәзер Биләрдән ары юл чыкмый. Шахт аңа үзе барып, барысын да сөйли, татарларны ничек артларына типкәләп, чиркәүгә куып кертүе белән мактана, картның шуңа күңеле була. Бу Пелагея эшенә нокта куелуына да ул, һичшиксез, сөенәчәк, моны Ходай бүләге, дип кабул итәчәк...

Чирүле Шонталасы өстенә азан моңы таралганда, Шахтның җәза төркеме авыл капкасы төбендә тора иде инде. Бераз вакыт үтүен көттеләр, ир-атлар мәчеткә китеп бетсен, ә хатын-кызлар белән алар эшне тиз тотачак. Ир-атлар очраса да, исләре китми, чөнки кулларында Гөләйзаны балалары белән Казанга озатырга, дигән карар бар, бу – хөкүмәт эше. Гөләйзалар капка төбенә килеп җиткәндә, өйдә, чыннан да, ир-атлар юк иде, Хәким дә, кызының хәлен белергә килгән Ишмөхәммәт тә, олы малайлар да мәчеткә киткән. Өйдә бары тик Гөләйза белән әнисе Гөлзада һәм кечкенә Гыйниятулла гына калган, хатын-кызлар да намазга әзерләнеп йөриләр иде.

Соңгы вакытта Гөләйза авырып торганга, Гөлзада да ире белән монда килде, балаларны карашырга, йорт эшләрендә булышырга кирәк иде. Күңелләреннән һич кенә дә кызларының Актауда бәхилләшеп әйткән сүзләре китмәде, алар шул көннәрнең җитүен куркып һәм шомланып көттеләр, бу хәлнең булмавын теләделәр. Инде Чистай судыннан кайтканнарына да ай ярым вакыт үтте, Гөләйзаның хәле яхшырмады, ул күзгә карап сүнде, китәренә әзерләнде. Алар Чистайда яңа суд булганын, аны үзеннән башка гына хөкем итүләрен, балалары белән бергә Казанга чукындырырга җибәрелергә тиешләрен белмиләр иде әле... Капка төбендә иблис ялчысы – Әликсәй Шайтан басып торганын да белмиләр иде...

Ә Гөләйзаны бүген төшендә фәрештәләр ак биләүгә төрде, башта зәм-зәм суы белән аны баштанаяк юындырдылар, озын чәчләренә хәтле тарап үрделәр, ул вакытта Шонтала өстенә күктән нур һәм моң иңеп торды, ә Гөләйза, сабый бала кебек, фәрештә канатларында тибрәлде... Алар аны җиде кат күкләргә алып менеп киттеләр, җиһан буйлап күтәреп йөрттеләр, җәннәт бакчасына әйләнгән ай-йолдызларны, Гөләйзаның андагы урынын күрсәттеләр... Аннан яңадан бөтен галәм буйлап җиргә томырылдылар, кара урманнар арасыннан

Гөләйзаның авылын эзләп табып, фәрештә канатларында аны яңадан үз йортына кайтардылар, чөнки ул әле монда соңгы сынавын үтәргә тиеш иде...

Гөләйза бу дөньядан бүген китәсен сизенде, шуңа күрә, әнисе ярдәме белән, кичтән мунча кереп чыкты, өстенә чиста ак күлмәген, башына ак яулыгын бәйләде... Урамда яз, карлар эрегән, агачлар яфракка бөреләнгән, киек кошларның сагынып туган якларына кайткан вакыты иде... Ә ул китәргә җыена, шушы язгы матурлыкны ташлап, балаларын ятим калдырып, Гөләйза күккә ашарга җыена... Чөнки адәм баласына нәрсә хәерле икәнен Аллаһы Тәгалә үзе белә...

Башларыннан сыйпап, балаларын мәчеткә озатты, күңеленнән генә ире, атасы белән бәхилләште... Алар киткәч, әнисе намазлыкларны җәеп куйды, Гыйниятулла да алар янына килеп утырды. Менә мәчеттә азан тавышы яңгырады, менә ул тынды, менә ана белән кыз да намазга тезләнделәр... Гөләйза намазының фарызын укып бетерде, кулына дисбесен алды, шул чакта Гыйниятулла чырыйлап елап җибәрде. Бала бармагы белән ишек төбенә төртеп күрсәтә, ә анда кораллы казаклар һәм теге явыз пристав басып тора иде... Әләксәй Шайтан нидер сөйли, кулындагы кәгазен болгый, әмма монда аны аңлаучы да, тыңлаучы да юк иде. Хатын-кызлар өйдә ят тавышлар ишеттеләр, әмма намазларын бүлмәделәр, Гөләйза гына, нидер сизенеп, йөзе белән сәҗдәгә капланды, ул үзен алырга килгәннәрен аңлаган иде. Борылып карамаса да, сүзләрен аңламаса да, ул аны тавышыннан таныды – бу теге явыз иде! Сорау алганда аны бугазыннан сөйрәп йөрткән, йөзенә тәресен төрткән, китабы белән бәргән палисай иде! Һәм ул аны алып китәргә килгән иде...

«Йә, Раббым, мине бу кяферләр кулына калдырма! – дип ялварды ул, сәҗдәләргә китеп. – Аларны тәнемә һәм җаныма кагылдырма! Миңа бу дөньяларда мөселман булып яшәү бәхете бирдең, инде синең каршыңа да мөэмин-мөселман булып килеп басарга насыйп ит, Раббым Аллам! Пакь һәм изге булган җәннәтләреңә хисап тотмыйча керү бәхете бир! Шәһитләр үлеме бир! Кяфер кулында газап чиккәнче, үлемем артык, газиз Раббым! Мөселман килеш җанымны ал, бу явызлар кулына бирмә!»

Ишек төбендә тагы шау-шу башланды, казакларның берсе татарча да белә икән, ул бөтен өйгә акырырга тотынды.

– Туктатыгыз бу «Ят та тор!»ларыгызны! Суд карары белән сез – христианнар! Ул карар кулыбызда, сезне алып китәргә килдек! Пелагея, үзең дә әзерлән, балаларыңны да ал, Казанга китәсез, монда шулай язылган!

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлзада, намазын тәмамлап, алар янына килде, яхшылык белән үгетләмәкче булды.

– Гөләйза чирле, юлга чыгарлык хәлдә түгел, олы балалар этиләре белән мәчеттә, – диде ул. – Ирләр кайтсын, алар хәл итәр ни эшләргә.

– Монда хәл итәсе калмаган инде, суд карары кулыбызда, җыеныгыз тизрәк! – дип, Шахт аның борын төбендә кәгазьләрен болгады. Әмма олы малайларның өйдә булмавы аны ярсытты, бу эшне тоткарлый иде.

– Тор, барышня, хәзер хан сараена китәбез, анда бу кыргыйлыгыңны тиз онытырсың, бергәләп чукынырбыз! – дип, ул, ботларын киереп, Гөләйза янына килеп басты.

Гөләйза сәҗдәдән башын күтәрде, янында палисайның пычрак итекләрен күрде, – алар ак келәмнәр өстендә кара таплар калдырып, татар өенең түренә үк үткәннәр иде... Һәм хәзер Гөләйзаның да пакь җанын һәм ак тәнен таптап узарга җыеналар... Юк, Аллаһ моңа ирек куймаячак!

Җан түрләреннән бәреп чыккан шушы соңгы ялвару һәм ачыргалану белән, Гөләйза тагы сәҗдәгә ауды һәм инде башка тормады...

Кипкән иреннәре белән соңгы догасын кылды: «Үә биһии нәстәгиину үә биһил хәүлү үәл кууәтү рабби сәһһил үә йәссир гәләйнәә йәә мүйәссира күлли әмрин гәсиир» – «Раббым, авырайтма, җиңеләйт! Көч-куәт бары тик Синдә, ярдәмеңнән ташлама!» Шәһәдәтен әйтте: «Әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вә әшһәдү әннә Мухәммәдүн габдүһү вә расулүһ».

Һәм җир вә күкләрне тоташтырып, бер аваз яңгырады: «Синең дөньяда өлешең бетте һәм бурычың үтәлде, Аллаһудан разый булганың хәлдә һәм Аллаһ синнән разый булган хәлдә Раббыңа кайт! Минем изге бәндәләрем арасына кер! Һәм минем җәннәтемдә мәңгегә кал!»

Һәм Аллаһ аны мөселман хәлендә үз янына алган иде...

Шулчак авыл өстендә күк күкрәде, беренче язгы яңгыр явып үтте, Болгар-Биләрләрне тоташтырып, урман-кырлар өстеннән салават күпере сузылды...

Биектә-биектә, күк төпкелендә, киек кошлар чылбыры күренде, алар нәсел калдырырга туган якларына кайтып бара иде...

Ә ул китеп бара...

Каңгылдашып кыр казлары кайтканда, агачлар яфрак ярганда, бөтен дөнья яшеллеккә күмелеп яңарганда, ул китеп бара иде...

Мөселман булып яшәп, җир йөзендә мөселманга нәсел калдырып, ул бу дөньядан да мөселман булып китеп бара иде...

Кыр казлары каршына, мәңгелек язлар ягына китеп бара иде...

Моның шулай икәнлеген иң беренче булып сабый бала һәм карт ана сизде... Гыйниятулла, елап, әнисенә килеп тотынды, аны урыныннан торгызырга тырышты, әмма Гөләйза соңгы сәҗдәсеннән тормады, аның җаны тәненнән аерылган иде инде...

Гөлзада да, нидер сизенеп, кызы янына тезләнде, аның дисбе тоткан кулына кагылды – баласының бармаклары инде суынып өлгергән иде... Гөләйза киткән, җан биргән иде...

Ул арада мәчеттән ир-атлар да кайтып керде, Гөләйзаларның капка төбендә чит атларны күреп, башкалар да борчылып аларга җыелды. Авыл халкының шикләнүе дөрес булган икән – Гөләйзаны һәм балаларын алырга килгәннәр, Чистай суды, аларны чукындыру өчен Казан чиркәвенә җибәрергә, дип, карар чыгарган. Халык бу кайгылы хәбәрдән айнып өлгермәде, башларына икенчесе китереп сукты – Гөләйза үлгән! Җомга көннәрендә, җомга турларында, сәҗдә вакытында, кулына дисбесен тоткан килеш җан биргән... Үзен алырга килгәннәрен белеп үлгән, әмма Аллаһы Тәгалә аны бу затларга ирекле кылмаган, үз янына алган! Изге җан пакь хәлендә мәңгелеккә киткән, җәннәттәге үз өенә кайткан...

Ишмөхәммәт халыкны аралап, кызы янына үтте, аның суынган тәнен кочаклап, сулкылдап елады, аннан кулларына күтәреп, сәкегә илтеп салды. Гөләйзаның сәҗдәдәге гәүдәсен турайттылар, зур яшькелт күзләрен мәңгегә йомдырдылар, йөзенә ак яулыгын, өстенә киндер җәймә капладылар... Шонтала халкы елый-елый Гөләйза белән бәхилләште, алга таба нәрсә буласын әле берсе дә белми иде. Ә алга таба Гөләйзаны күмәргә кирәк, мөселманча итеп, татар зиратына, ә монда авыл тулы атлы казаклар, урыс палисае! Инде нишләргә? Бу турыда татарлар гына түгел, Гөләйзаны алып китәргә килгән урыслар да уйлый иде, бигрәк тә Шахт нинди карар кабул итәргә белмәде. Гөләйзаның кинәт үлеп китүе аның бөтен эшен бозды, кәефен төшерде, җенен чыгарды! Нинди

авырлык белән, артыннан күпме йөреп, судта шушы карарны кабул иттерә алды! Бөтен Чистай байлары – татары, староверы күпме йөреп карадылар бу хатынны алып калу өчен, әмма барыбер ул әйткәнчә булды! Инде менә суд карарын тотып, ишек төбенә килеп баскач, бугазыннан алып, арбага аркылы салып, кул-аякларын богаулап алып китәм дип торганда – корбаның үлсен инде! Җиңү шатлыгын бөтен көченә татырга ирек бирмичә, үч алу ләззәтен кичертмичә – дошманың китеп барсын инде! Соң, шулай булгач, кем җиңүче соң монда – Шахтмы, Гөләйзамы? Ул дошманнарын җиңеп китте бит, ул барысы өчен дә үч алып китте, иң мөһиме – чукынмыйча, мөселман килеш китеп барды...

Шахт тешләрен шыгырдатып куйды, бу хәлдән чыгу юлын эзләде. Суд карарының да хәзер бернинди көче юк – җинаятьче үлгән... Ә балалары... Ул балалары турында хәзер аерым карар кирәк булачак, моны Чистай гына хәл итә ала. Аларны Казанга җибәреп торудан мәгънә юк, монда гына чукындырып та эшләрен бетерергә була. Хәзер Шахт өчен иң мөһиме – бу хатынны күмү, ягъни, аны христиан тәртибе белән җирләү. Менә шунда карарбыз – кем кемне җиңгән! Шахт белә – чукындырылган татарларның иң нык курыкканы – поп белән, урыс зиратына күмелү. Шуннан качып котылу өчен, алар нәрсә генә эшләми – попларны сатып ала, алай барып чыкмый икән, мөселманча күмеп, каберенә попларны якын җибәрми, инде алай да булдыра алмаса, арбага салып, мәетне урман-кырларга алып чыгып китә, шунда берәр чокырга булса да күмеп калдыра. Бу юлы да шулай кыландырып караячаклар. Бер караганда, Шахтның мәет өстенә килеп керүе яхшы булды әле, югыйсә, беркемгә белдермичә генә, мөселманча җирләп куярлар иде. Хәзер исә ул үзе мәеткә хуҗа, һәм бу керәшен хатыны христианча күмеләчәк!

Бу хакта ул Хәким белән Ишмөхәммәткә дә әйтте, «Пелагея – керәшен хатыны, ул христианча күмелергә тиеш!» диде. Гөләйзаның үлеме кайгысыннан әле аңга да килеп өлгермәгән якыннары өчен бу хәбәр яшен суккандай булды, алар телсез калдылар. Гөләйза гомер буе намазда булды, урыс динен белмәде, аны тотмады, намазда килеш җан да бирде – ничек аны христианча күмәргә мөмкин?! Бу аның рухын рәнҗетү, иң зур гаделсезлек булачак! Алар бу хакта приставка да аңлатырга тырыштылар, әмма тегесе үз фикереннән кайтмады – мәет христианча күмеләчәк – һәм бетте! Ул үз янына авыл башлыгы Әбуталипны чакырып китерде, аңа әмерләрен бирде.

– Мин Биләргә, Михаил атакайны алырга барам, – диде ул. – Ул килгәнче мәеткә кагыласы булмагыз – башыгыз белән җавап бирәсез! Авыл капкаларына казакларны куярбыз, мәетне алып чыгып китәрлек булмасын! Бернинди мөселман зираты, бернинди елга буйлары, урман-кырлар – ишеттегезме?! Пелагеяны чиркәүгә куеп, христиан зиратына җирләячәкбез! Суд карары нигезендә, ул – керәшен, һәм керәшенчә күмелергә тиеш!

– Бу хәл беркайчан да булмаячак! – диде Ишмөхәммәт, бөтен кеше ишетелерлек итеп. – Бөтен Биләр-Чистай этләрен җыеп килсәң дә, Гөләйзаны сезнеңчә күмдермәячәкбез! Йөрмә дә! Кызыбызны кабергә керттең, инде мәетенә тынгылык бир!

Ишмөхәммәт үзен чак тыеп тора, авыл халкы да пристав өстенә ташланырга әзер иде. Әмма хәзер иң мөһиме – Гөләйзаны кешечә җирләү, шуңа күрә, тавыш чыгармыйча, бу мәлгуньне тизрәк чыгарып җибәрергә кирәк.

– Суд карары нигезендә, ул Казанга чукындырырга җибәреләсе булган,

димәк, аның мөселманлыгын алар да таныган? – дип, Хәким дә приставка каршы төшеп карады.

– Надан! Ул Казанга чиркәү судына үгетләнергә җибәреләсе иде, ә балалары – чукындырылырга! Әгәр шунда үгетләнеп, христианлыгын таныса, аңа берни булмый иде! Кабергә дә керми иде!

– Аны кабергә сез керттегез! – Гөлзада сулкылдап елый башлады. – Яшәргә ирек бирмәдегез! Көтүегез белән артына тагылып йөрдегез! Балакаем изге кеше булган икән – нинди хәлдә дә динне ташламады, намазлык өстендә, сәҗдәдә җан бирде... Ничек аны урысча күмәргә мөмкин?! Юк, мондый хәл булмас, Аллаһы Тәгалә моңа ирек бирмәс! Бирмәс!!!

Шулай дип, ул кызының гәүдәсе янына тезләнде, аны кочаклап алды, әйтерсең лә аның каберенә дә үзе кереп ятырга тели иде... Моны күреп, җыелган халык та елый башлады, ир-атлар шауларга тотынды, алар Гөләйзаның мәетен бирергә җыенмыйлар иде. Моны пристав үзе дә аңлады, ярсыган авыл халкы белән көрәшергә аның казаклары да аз иде, шуңа күрә, ярдәмгә палисайларны һәм Биләр побын алып килмичә, мәеткә тотынмыйча торырга булды. Дөрес, ул ярдәмне Кызылъярдан да алып килә ала иде, әмма аның побы тагы салмыш булырга мөмкин, ышанычсыз. Шуңа күрә Шахт, тиз генә атына утырып, Биләр ягына чапты, казакларга авылны сакларга әйтеп калдырды, иртәнге якта ул Михаил атакай белән килеп җитәргә тиеш иде. Чөнки бу татарлар мәетне Кыр Шонталасына да өстерәп алып чыгып китәргә мөмкиннәр, аларның хәзер анда өч зират – татарча күмелгән мөселманнарныкы, христианча җирләнгән керәшеннәрнеке һәм урталыкта – мәкруһларныкы, ягъни, «отпавший»ларныкы… Алары да татарча күмелә, әмма бу каберләрне поплар тикшерми, муллалар аңа җавап бирми. Тирә-яктан алып киләләр дә күмәләр, алып киләләр дә күмәләр, хәзер дә шулай эшләргә мөмкиннәр. Әмма авыл башында атлы казаклар каравыл тора, кеше түгел, эт тә чыга алмас! Шуңа күрә Шахт тыныч күңел белән Биләргә юл алды.

Шахт чыгып киткәч, өйне җилләтеп, киңәш-табыш итә башладылар. Әхмәт мулла, азанчы Мөхәммәтша, мәчет картлары да монда иде, сүзне, ата кеше буларак, Ишмөхәммәт башлады.

– Гөләйзаны мөселманча күмәргә кирәк, җәмәгать, һәм бүген күмәргә кирәк! – диде ул. – Кыр Шонталасына гына алып кайтып китәр идек – авыл башына сакчылар куйдылар, мәет белән чыгып китә алмаячакбыз. Димәк, монда җирләргә кала. Кайда? Авылыгызда ике зират – керәшен зираты һәм мөселманныкы. Керәшен зиратына күмү турында сүз дә була алмый, ә мөселман зиратыннан казып алырга мөмкиннәр. Нишлибез?

– Әйе, Ишмөхәммәт әзи, дөрес әйттең – Гөләйзаны бүген һәм монда, мөселманча җирләргә кирәк, – диде Әхмәт мулла. – Башкача була да алмый – ул безнең күз алдыбызда мөселман булып яшәде, үлеме дә изгеләрчә – җомга көн, намазлык өстендә булды... Без, әйдәгез, йортка чыгып, ачык һавада бу хакта киңәшик, ә кыз-хатыннар мәетне юып, кәфенли торсыннар, кичкә хәтле җирләргә өлгермәвебез бар.

Ирләр урамга чыгып китте, хатын-кызлар мәет юарга әзерләнә башлады. Гөләйзаның кәфенлекләре сандыкта иде, ул барысын да үз куллары белән әзерләп калдырган. Гөлзадага ярдәмгә күрше-күлән, авылның абыстае килде, балаларны урамга чыгарып җибәреп, эшкә тотындылар. Тик кечкенә Гыйниятулланы берничек тә өйдән чыгарып булмады, ул әнисенең әле аяк очына, әле баш очына барып, аны уятырга тырышты... әмма Гөләйза

элеккеге кебек дәшмәде, улын кулларына күтәреп алмады, тын гына ята бирде...

Халык Гөләйзаны мөселман зиратына күмүне таләп итте, аның якыннары, авыл мулласы да шул фикердә иде. Әмма теге мәет козгыннары да килеп җитәчәк бит, зиратлар саен иснәнеп, эзләнеп йөриячәкләр! Нишләргә?

– Бирмибез! – диде халык.

– Зиратны да, каберен дә саклыйбыз!

– Шунда ятып үлсәк үләбез – каберен ачтырмыйбыз!

– Нигә алар безне һаман басымчак итәргә тиеш әле?! Кемне ничек, кайда күмәргә тиешлеген без үзебез хәл итәргә тиеш!

– Җитте, җәмәгать! Бүгенге көннән бернинди керәшен, мәкруһ юк – барыбыз да мөселманнар, әлхәмдүлиллаһ!

– Әйе, исән чакта урыныбыз – мәчеттә, үлгәч – мөселман зиратында!

Халыкны туктатырлык түгел иде, Гөләйзаның үлеме, бигрәк тә шушындый якты, гыйбрәтле китүе барысын да тетрәндергән, дин-ислам хакына үзләрен дә шулай үлемгә барырлык хәлгә китергән иде. Приставның сүзләре онытылды, иртәгә киләсе Биләр побы искә дә кермәде, авыл үзенең гасырлар буе барган тәртибенә тугры булып калды. Ирләр зиратка кабер казырга китте, хатын-кызлар Гөләйзаны ак биләүгә биләгәндәй, кәфенләп, ахирәт күлмәген кидерделәр... Икендегә хәтле инде барысы да әзер иде, Гөләйзаның җәсәден күтәреп, зират ягына юнәлделәр. Җеназа намазын Әхмәт мулла укыды, кабергә Ишмөхәммәт белән Хәким төшерде, ләхеткә дә алар куйды. Биләрдән тегеләр килеп җиткәнче эш беткән, Гөләйза җирләнгән иде инде...

Зираттан таралыр алдыннан гына күрделәр – Гөләйзаның балалары да монда, хәтта абына-сөртенә кечкенә Гыйниятулла да килгән! Үз кайгы-мәшәкатьләре белән бу балаларны күрмәгәннәр, ә алар әниләре белән мәңгегә аерылыша бит! Бүген иң авыр, үзәк өзгеч хәл – аларныкы: атасыз бала – бер ятим, анасыз бала – мең ятим, диләр ласа... Олылары – Габделвахит белән Габделҗәббар, әниләренең үлүен аңлыйлар, әмма моны кабул итә алмыйлар, һаман мышык-мышык елыйлар. Ә кечкенә Гыйниятулла берни аңламый, аңа әнисе кирәк, аның күкрәк сөте кирәк, үлем хәлендә булганда да, Гөләйза аны имидән аермады, сабый хәзер дә шуны көтә... Олыларның аяк араларыннан бала күреп торды – әнисен нигәдер чокырга төшерделәр, өстенә балчык өйделәр, ул шунда күмелеп калды... Гыйниятулланы калдырып китте... Сабый булып сабый да моны аңлады, ахры, әнисенең кабере өстенә капланып, үксеп-үксеп елый башлады.

– Әни, мине дә ал! Мин дә синең белән барам! Әни, чык аннан, анда караңгы бит! Әни-и! Әни-и!

Ишмөхәммәт, иелеп, оныгын кулына алды, инде алар бергә елый иде... Зиратка җыелган ирләр дә елый иде... Яңа яфракка бөреләнгән агачлар, аларда оя корган кошлар, авыл өстеннән искән җилләр – барысы да ыңгырашып-сыкранып елый иде... Яңгыр болытлары Гөләйзаның каберенә күктән күз яшьләре булып тамды, елый-елый, җирдән гөрләвекләр булып акты... Балалары, туганнары, якыннары, бөтен авыл халкы, бар табигать үзенең сөекле кешесе – Гөләйза белән бәхилләшә иде...

...Төне буе күкләр күкрәп, яшен яшьнәп, яңгыр яуды...

Аһылдап, сулкылдап, кайдадыр сугып, кайдадыр яндырып, кайдадыр сулар бастырып, яшенле давыл котырды... Әйтерсең лә күкләр нәрсәнедер кисәтергә, нәрсәнедер туктатып калырга тели иде...

Алексей Шахт Биләргә кичке якта, яңгырга кадәр үк барып җитте, туп-туры Михаил атакайның өенә китте. Карт ялгыз яши, хәзер чиркәүгә дә сирәк бара, якшәмбе гыйбадәтләрен генә уздыра, калган гомерен күбрәк өйдә үткәрә. Шахтның килүенә ул бик сөенде, чөнки аның бусагасын атлап керүчеләр аз хәзер, үзе исә кеше ярдәменнән башка чыгып йөри алмый. Шахтның килүе бер сөендерсә, әйткән хәбәре Биләр побын терелтеп җибәрде – аның хыялы тормышка ашкан иде! Дөрес, хәбәр катлы-катлы булды, Гөләйза турында суд карарын әйтү белән, Шахт аның үлү хәбәрен дә җиткерде. Биләр побын Гөләйзаның үлү хәбәре кайгыга салмады, әмма аның чиркәү үгетләвен үтмичә, шул басурманнар арасында, үз динендә теге дөньяга китеп баруы картны ярсытты. «Булмады, өлгермәдек!» дип өзгәләнде ул, соңгы хәбәрне ишеткәч. Әмма пристав аны тынычландырырга ашыкты: «Безнең өчен ничек үлүе түгел, ничек күмелүе мөһим!» – диде. Моны ишеткәч, Биләр побы тагы җанланып китте, әйе, ниһаять, аның сәгате сукты – ул бу керәшен хатынын, Пелагеяны христианча күмәчәк! Бөтен йолаларын туры китереп, мәетен чиркәүгә төн чыгарга куеп, үзенчә «отпевать» итеп, менә монда – урыс зиратына җирләячәк ул аны! Менә шуннан соң улап карасыннар инде татарлар – без мөселманнар, дип!

Аның әйткәннәре белән Шахт та килеште – әйе, мәетне монда алып кайтырга, чиркәүгә куярга, Биләрдә урыс зиратына күмәргә! Әмма күңелен бер корт кимерде – татарлар болай гына юл бирмәячәк, бөтен авыллары белән күтәреләчәкләр! Димәк, моннан гаскәриләрне алып барырга туры килә – авылны һәм Пелагеяның өен чорнап алырга, беркемне якын җибәрмәскә, мәетне арбага салып, алып та китәргә! Шулчак Биләр побы аны көтелмәгән сүзләр белән айнытып җибәрде:

– Инде күмеп куймаган булсалар...

– Ничек?! Күмеп куймаган булсалар?

– Син мондагы татарларны аз беләсең, улым... Алар үз дигәннәрен эшләү өчен кабер казып күмү генә түгел, тауларны күчереп куярга мөмкиннәр!

– Әмма мин анда казакларымны калдырдым! Авыл капкаларын сакларга куштым – мәетне анда-монда алып китеп күммәсеннәр, дип!

– Ә татар зиратына каравылга кеше куйдыңмы?

– Юк, анысы башыма да килмәгән... Анда барып керергә аларның да башына килмәс, мәет юкка чыкса, безнең туп-туры шунда барасын белеп торалар бит!

– Әйе, анысы да бар...

– Бүген үк чыгып китәр идек, әмма соңрак инде, хәрбиләрне дә тупламаган... Иртәгә иртүк кузгалырбыз, алар торганчы, барып та җитәрбез.

– Шулай, татарларның төнлә күмә торган гадәтләре юк, мәет барыбер иртәгә калдырылгандыр. Иртүк кузгалырбыз, чиркәү әһеле буларак, үзем башкарып чыгармын бу эшне, ә синең эшең – басурманнарны бастыру, улым! Алар безнең изге эшебезгә комачау итәргә тиеш түгел!

– Кыймылдый да алмаслар, батюшка! Авылны гаскәр саклаячак! Хәзер мин алар янына барып кайтам...

Шахт, стрелец-гаскәриләр белән сөйләшү өчен, бистәгә чыгып китте, аларны табып, эшне аңлатты, тегеләре шунда ук ризалашты. Аннан шактый вакыт сыйланып, кәефләнеп утырдылар, җырлап та алдылар, урамга чыгып, шарт-шорт атыштылар да. Шулай акырып-бакырып, урам тутырып айкалып йөргәндә, татарларның Хуҗалар тавы ягыннан көчле җил исә башлады, авылга килеп җиткәнче, ул өермәгә әйләнде, аннан давыл булып, өйләрне, каралты-

кураларны җимерергә тотынды. Ул арада күкнең түбе ярылып китте һәм аннан авыл өстенә яшен уклары ява башлады, ялтыраган һәм чалтыраган авазлардан Биләр дерелдәп торды, яшен сугып, агач чиркәү дөрләп янарга тотынды. Бу инде аның икенче тапкыр януы иде, беренчесе Биләрнең булачак попы Михаил Лавров Казанда, рухани мәктәптә укыганда янды, икенчесе – менә хәзер... Беренчесен Михаилның атасы Кондрати салдырган иде, монысын – Михаил Казанда укып йөргәндә, бистә халкы салган, югыйсә, ул үзе таштан чиркәү төзетергә хыялланган иде! Әтисе белән татар Биләреннән мәчет ташларын да ташытып куйган иде, аларын авыл халкы ул укып йөргәндә урлап бетергән...

Менә хәзер шушы агач чиркәү дөрләп яна, бистә халкы аны түгел, үз өйләрен саклый... Михаил атакай, давыл башлануга, шомланып урыныннан торды, Алексей Шахтның тизрәк кайтып җитүен теләде, аның өчен дә, үзе өчен дә курыкты. Биләрдә һәр язны диярлек янгын чыгып, урамы-урамы белән янып бетәләр, Ходай аларны ни өчендер шулай җәзалый... Моның ни өчен икәнен Михаил атакай үзе дә сизенә, әмма ул аны беркайчан да теле белән әйтмәячәк! Әйе, Ходай аларны татарларның изге саналган җирләренә килеп утырган өчен җәзалый, мөселман зиратлары өстендә дуңгыз абзарлары салган өчен, кабер ташларын юлларга җәйгән өчен, мәчет ташларын чиркәү идәннәренә түшәгән өчен – Ходай үч аладыр, мөгаен... Аларга монда беркайчан тынгылык булмады, бәрәкәт булмады, утырдылар да яндылар, өелделәр дә сугыштылар, менә хәзер тагы яналар... Чиркәү яна, ул гомер буе хезмәт иткән йорт яна! Иртәгә бу чиркәүдә керәшен хатынының мәете куелырга тиеш иде бит! Инде Ходай монысына да каршы төштеме?! Әллә соң бу татарларныкы дөрес булып чыгамы, әллә соң ул гомер буе ялгыш Илаһыга табындымы?!

Шул уй башына килүгә, Михаил атакай, соңгы көчен җыеп, урамга ыргылды һәм, бер адым да атлый алмыйча, гөрселдәп идәнгә ауды. Чиркәвен яшен сукса, аның үзен фәлиҗ чире – паралич бәргән иде... Һәм Алексей Шахт кайтып кергәнче, ул телсез-аңсыз булып идәндә ятты. Аны күргәч, Шахтның коты чыкты, Михаил атакайның чалшайган йөзе, акаеп чыккан күзләре яшен яктысында бигрәк тә куркыныч булып, шайтани бер кыяфәткә кергән иде. Шахт аны чакка-көчкә өстерәп, урынына алып барып салды, карт сөйләшә алмый иде...

Шахт хәрбиләре белән берүзе калды, берничәсен Актау побын алырга җибәрде, алар туп-туры Чирүле Шонталасына килергә тиешләр иде...

Шахт Кызылъяр побын башта ук хисапка кертмәде, ул теге хәлләрдән соң айный алмыйча эчә, исерек баштан әллә ниләр ычкындыруы мөмкин...

Төнге давыл Чирүле Шонталасының да агач башларын кыеп үтте, әмма Биләрдәге кебек зыян-зәхмәт салмады. Соңыннан әллә яшен, әллә язгы аҗаган төне буе күк йөзен яктыртты, аллы-гөлле төсләргә кертте, ат тояклары тавышы чыгарып, авыл өстеннән дөбердәп үтте... Көндез зур кайгы-хәсрәтләр кичергәнгәме, әллә яшен яшьнәп, яңгыр яуганмы, Ишмөхәммәтнең йокысы тынычсыз булды, гомер кермәгән төшләр керде. Бу төндә ул кызы Гөләйзаны төшендә күрде, ул баштанаяк акка төренгән, кулында дисбесе, йөзендә елмаю, үзе фәрештә канатларында каядыр очып бара иде... Менә алар зират өстенә күтәрелделәр, авыл өстеннән очып, Шонтала елгасы буйларына җиттеләр, яшен яктысында Ишмөхәммәт боларны ап-ачык күрде, кызын туктатырга теләп, артыннан йөгерә башлады... Ул күпме йөгерсә дә, Гөләйзаның зираттагы кабереннән ары китә алмады, әйтерсең лә аяклары шунда ябышкан иде...

«Иртән каберемне актарырга килерләр, әмма син курыкма, әти... – диде

кызы. – Мин анда юк инде... Алар минем үле гәүдәмә дә кагыла алмаслар... Аллаһның рәхмәте белән, мин туган авылыма кайтып барам... Инде мәңгелеккә... Бәхил булыгыз!»

Шул чакта аста, җир йөзендә сулкылдап-әрнеп бала елаган аваз ишетелде, бу – Гыйниятулла тавышы иде! Ул, елый-елый, абына-сөртенә, кулларын күккә сузып, әнисе артыннан йөгерә, «Әни, мине дә ал!» дип такмаклый... Гөләйза, күкнең төпкеленнән иелеп, кулындагы дисбесен улына ыргытты, ул аның үз каберенә килеп төште, әмма ул буш иде...

Бала елаган тавышка Ишмөхәммәт тә уянып китте, күргәннәреннән аңына килә алмыйча, як-ягына карады. Караңгы өйне вакыт-вакыт яшен уты яктыртып үтә, тәрәзәгә капланып елаган сабый бала да бер күренә, бер юкка чыга... Тукта, бу бит Гыйниятулла, төнлә уянып, әнисен эзли, «Әни, мине дә ал!» дип өзгәләнә...

Ишмөхәммәт, торып, оныгын кулына алды, аны күкрәгенә кысып юатты, «Әниең китте шул, балакаем, бик ерак китте!» диде, бала өстенә кайнар күз яшьләре тамды... «Мин күрдем... Әни очып китте... Мине алмады... Мин барыбер аның янына китәм...» – дип такмаклады Гыйниятулла. Ул, чыннан да, әнисенең фәрештә канатларында авыл өстеннән очып баруын төшендә түгел, өнендә күргән иде... Аллаһы Тәгалә бу сабыйга соңгы тапкыр әнисен күрсәтеп шулай юата, аның үзен дә тиздән мәңгелеккә китәргә әзерли иде...

Ишмөхәммәт иртәнге намазга кадәр гыйбадәт кылды, сәҗдәләргә китеп, тәһәҗҗүд намазында Аллаһтан ярдәм сорады. Әйе, бүген җәза отряды килеп җитәчәк иде, Гөләйзаның мәетен таптырачаклар, зиратка барачаклар, каберне актарачаклар... Авыл халкының аларны туктатырга көче җитмәс, тегеләрдә утлы корал, кырып кына салачаклар... Бу газиз балакайга кабердә дә тынгылык булмасмыни инде?! Аның җансыз гәүдәсен шулай чиркәүләр буйлап өстерәп йөртерләрмени?! Аннан урыс зиратына аларча алып барып күмәрләрмени?! И Раббым, Син кодрәтле, Син шәфәгатьле, ирек бирмә бер мөселман хатынының җәсәден шулай мыскылларга! Иң авыр вакытларда да Син ярдәм иттең, баламның мөселман хәлендә, намазлык өсләрендә җанын алдың – инде кабереннән дә ал! Син – могҗизалар иясе, бөтен җиһан Синең кулыңда, тагы бер тапкыр безләргә хикмәтеңне күрсәт, Раббым Аллам! Ал Гөләйзаны кабереннән...

Шулчак өй эче тагы яшен утыннан яктырып китте, һәм күк йөзендә бер сурәт пәйда булды... Бик еракта, җиде кат күкләр тирәнлегендә, бар җиһанны иңләп, фәрештәләр оча, ә аларның канатларында, сабый бала кебек, Гөләйза тибрәнеп бара... Ул ап-ак киемнән, яшь, матур чактагы кыяфәте, ә йөзендәге нур бөтен тирә-якны яктырта... Фәрештәләр, киек кошлар кебек чылбырдай тезелешеп, авыл өстен берничә тапкыр әйләнделәр, алар әллә Ишмөхәммәт картны тынычландырырга телиләр, әллә Гөләйзага соңгы тапкыр якыннарын күрсәтәләр иде... Тукта, Ишмөхәммәт бу күренешне төшендә күрде бит инде! Ә хәзер өнендә шуны күрә... Димәк, Аллаһы Тәгалә аны тынычландырырга тели, димәк, барысы да Аллаһ теләгәнчә булачак!

Иртәнге якта гаскәриләр, атларга атланып, Чирүле Шонталасына барып керделәр һәм авылны урап алдылар. Бераздан Актаудан Якуб атакайны да алып килделәр, ул бик нык курыккан, ни өчен чакырганнарын да белми, кая кушсалар – шунда бара, ни әйтсәләр – шуны эшли иде. Атлы җайдаклар иң беренче Гөләйзалар өенә юнәлде, Якуб атакайны кертеп җибәрделәр, әмма анда мәет юк иде. Бу хакта ул урамдагыларга да чыгып әйтте, Шахтның йөзе

күгәреп катты, ул шунда ук авыл башлыгы Әбуталипны алырга чапкыннарын җибәрде. Гөләйзалар капка төбенә халык җыела башлады, бу солдатларның нигә килгәнен барысы да яхшы белә иде – Гөләйзаның мәетен эзлиләр. Әбуталипны, әсир тоткан кебек, җилтерәтеп китереп җиткерделәр, ул үзен нәрсәгә чакыртканнарын белә иде.

– Мәет кайда?! – дип акырып җибәрде Шахт, ул килә-килешкә үк.

– Мин мәет хуҗасы түгел, аны сакламадым, син миңа андый әмер дә бирмәдең, – диде Абуталип, батыраеп. – Без казаклар белән авылны саклaдык, коеп яңгыр яуганда да китмәдек... Мәет авылдан чыкмады.

– Алайса, кайда соң ул?! Ире кайда, туганнары?! Мәетне кая куйдыгыз?!

Алга Ишмөхәммәт чыкты, ничек бар – шулай әйтеп бирергә булды.

– Мәет кайда булсын – зиратта! Татарларда мәетне үлгән көнендә үк җирлиләр, без дә шулай эшләдек.

– Нинди зиратка?! Ничек сез аны поп килеп җитмичә күмә алдыгыз?! Муллагыз күмдеме?! Мөселманча күмдегезме?!

– Мәрхүмәнең ире бар, без – якыннары бар, менә без күмдек. Әйе, мөселманча, татар зиратына күмдек, чөнки ул мөселман булып яшәде, мөселман хәлендә үлде...

Бу сүзләрне ишетүгә, Шахт бөтен хәрбиләрне җыеп, зиратка алып китте, алар, кулларына корал тотып, зиратны чорнап алдылар. Гөләйзаның каберен тиз таптылар, төнге яңгырдан соң туфрагы бераз иңсә дә, аның яңа кабер икәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде. Татарларның да бер өлеше зиратка керә алды, алар, ни эшлик, дигәндәй, бер Ишмөхәммәткә, бер Әхмәт муллага карадылар. Ишмөхәммәт бер хәрәкәт ясаса, кабер өстендә сугыш башлана иде, әмма ул дәшмәде. Менә Шахт үзе, батыраеп, көрәккә килеп ябышты, аны кабер туфрагына батырды, әмма авыру кулы кинәт ут токтандай чатнап китте, ул, яман үкереп, көрәген атып бәрде. Аннан Ишмөхәммәт белән Хәкимгә каберне казырга кушты. «Үзегез күмгәнсез, үзегез казып та алыгыз!» диде. Халык, гаҗәпләнеп, тагы Ишмөхәммәткә карады, ә ул көрәкне алды һәм кабер туфрагына батырды. Кешеләр «аһ!» итеп куйдылар, әле урыслар казыса, аларның бугазларына барып ябышырлар иде, ә монда – Ишмөхәммәт үзе! Гөләйзаның атасы!

– Ишмөхәммәт әзи, мөселманны кабереннән кузгатырга ярамый бит, син ник аларны тыңлыйсың?! – дип, беренче булып Әхмәт мулла сүз күтәрде.

– Әйе, ник тыңлыйсың син?! Алар кушар, шул кабергә кереп ятарга да кушар! Тыңлама, Ишук әзи, кагылма Гөләйзаның каберенә!

– Туктагыз әле, бәйләнмәгез аңа, үзе беләдер! Күрмисезмени – бөтен авылны, бөтен зиратны гаскәр чорнап алган, хәзер коралга ябышырга торалар!

– И Аллам, шушы хурлыкны күрер көннәр дә булыр икән! Гөләйзаның рухын рәнҗетәбез бит, җәмәгать! Кабереннән актарып алып, кемгә биреп җибәрергә җыенабыз! Юк, Ишмөхәммәт әзи, мондый хәл булмас!

Шулай дип, кемдер Ишмөхәммәтнең көрәгенә килеп ябышты, кемдер кабер өстенә ауды, аны куллары белән колачлап алды, эш тукталды. Шахт татарларның үзара бәргәләшүләрен читтән мыскыллап карап тора иде.

– Туктагыз, җәмәгать! – диде Ишмөхәммәт, эшләр болайга киткәч. – Кабер буш, курыкмагыз... Миңа бүген төшемдә Гөләйза шул турыда хәбәр итте... Аны төнлә фәрештәләр башка урынга күчерде...

Кешеләр Ишмөхәммәт картның кайгыдан башына зыян килгән, дип уйладылар, ә ул эшен дәвам итте. Менә кабер туфрагы чыгарылып бетте, барысы да, могҗиза көткәндәй, аска текәлделәр – ләхет эче буш иде... Кичә генә

Гөләйзаны кертеп салган куыш буш, җиргә җәелгән кабыклар гына калган... Әйтерсең лә Гөләйза, шушы хәлләр буласын сизенеп, күккә ашкан иде...

Моны күрүгә, татарлар җиргә ауды, сәҗдәгә китте, аннан сикереп торып, кулларын күккә сузып, тәкъбир әйтә башладылар...

Аллааһу Әкбәр, Аллааһу Әкбәр,

Ләә иләәһә илләАллааһу.

Үә Аллааһу Әкбәр, Аллаһу Әкбәр, үә лилләһил хәмдү.

– Нишлиләр алар?! Туктатыгыз! – Бу хәлне күреп, Шахт күккә ата башлады, аннан күреп, башкалар да коралга тотынды.

– Юкка көчәнмәгез – кабер буш! – диде Ишмөхәммәт. – Гөләйзаның мәете анда юк.

– Бу хәл мөмкин түгел! – дип акырды Шахт. – Яков Алякринский, төш кабергә, кара, нәрсә сөйли бу басурманнар?!

Ул Якуб атакайны төртеп диярлек кабергә төшерде, тегесе кулын ләхеткә тыгып болгады һәм аннан Гөләйзаның ... дисбесен тартып чыгарды.

– Дисбесе генә калган, – диде ул, кәфендәй агарып. – Бу безнең авылның Әкълимә карчык дисбесе... Ул аны кулыннан да төшермәде, чиркәүгә дә шуны тотып килә иде...

Куркуыннан үләр хәлгә житкән Якуб атакайны кабердән өстерәп менгерделәр, ул лапылдап җиргә килеп утырды, аның мондый хәлне күргәне юк иде әле... Кечкенә Гыйниятулла аның янына йөгереп килде һәм кулыннан әнисенең дисбесен тартып алды. Ә Шахт барыбер котыруын дәвам итте: «Сез мине алдагансыз, аны башка җиргә күмгәнсез!» – дип акырды ул, наганын болгап. Хәрбиләр тиз генә ике зиратны да әйләнеп чыктылар – башка яңа кабер юк иде.

– Мәет кайда?! – дип, ул тагы Ишмөхәммәт өстенә очып кунды.

– Гөләйзаның җәсаден Аллаһы Тәгалә үзенә алды, фәрештәләр аны башка урынга күчерде, – диде Ишмөхәммәт. – Мин моны төнлә үк белдем – башта төшемдә күрдем, аннан – өнемдә... Кызым фәрештәләр канатында авыл өстеннән очып бара иде... Мин кабернең буш икәнен шул чакта ук белдем, шуңа күрә курыкмыйча казый башладым. Менә бу Аллаһның могҗизасы һәм рәхмәте инде!

Шул чакта, зиратны яңгыратып, сабый бала кычкырып җибәрде, бу Гыйниятулла иде:

– Әни очты! Очты! – диде ул, кулларын күккә сузып. – Кош булып очты! Миңа тәти төймәләрне калдырды... Мин дә әни янына очам!

Халык тагы шашып калды, инде сабый бала да күргән икән, димәк, бу хәл, чыннан да, булган!

– Мин төнлә бала елаган тавышка уянып киттем, – диде Ишмөхәммәт. – Гыйниятулла, тәрәзәгә капланып, «әни, мине дә ал!» дип үксеп елый иде... Ул миңа да, әни очты, диде, димәк, ул бу хәлне тәрәзәдән күреп торган, Аллаһ аңа күрсәткән... Мин дә күрдем... Хәзер җаным тыныч.

...Ә хәзер күктә каурый болытлар йөзә, алар фәрештә канатларына охшаган, әмма канат түгел, бары тик болытлар гына... Күктән яз кояшы көлә, яшь яфраклар талгын җилдә лепердәшә, әйтерсең лә берни булмаган – төнге давыл да, коеп яуган яңгыр да, күзләрне камаштырган яшен дә... Әйтерсең лә әле генә мәет тә таптырылмаган, кабер дә казылмаган, мылтыклардан да атылмаган... Әмма авылда могҗизага тиң хәл булган, Гөләйза кабереннән күккә ашкан, Аллаһы Тәгалә үзенең яраткан бәндәсен янына алган иде...

Шахт, бернигә ирешмичә, авылдан өстерәлеп чыгып китте, хәрбиләре аңа иярде. Зиратта, Гөләйза кабере янында бары тик Якуб атакай гына утырып калды, ул хакыйкатьнең шушында булуын аңлады, әмма бу хакта телен әйләндереп әйтә алмады... Бу буш кабер һәр ике диндәгеләрнең һәммәсенә дә бер кисәтү иде – Аллаһның барлыгына һәм берлегенә, Аның кодрәтенә һәм могҗизасына, рәхмәтенә һәм мәрхәмәтенә, сынавына һәм җәзасына...

## Тарихи йомгаклау

Үзе үлгәч тә, Гөләйза тарихы әле шактый барды, судларда эше дәвам итте, чөнки исәннәрне хөкем итәргә кирәк иде. Иң беренче эш итеп Гөләйзаны кем, кайда, ничек күмгән – шуны ачыкларга кирәк була. Моның өчен 1845 елның 14 гыйнварында Гөләйзаның туган авылы Кыр Шонталасы авылы халкыннан сорау алалар. Бу эшне пристав Шахт үзе башкара, мөселман-татарлардан башта ант бирдерә, аннан Гөләйзаның мәете турында сораштырырга тотына. Унике кешедән – Бикчәнтәй Ибәтуллиннан, Хәбибулла Зәбиров, Фәтхулла Борһанов, Әбсәлам Сәфәров, Әбделмән Әбдразаков, Хөсәен Әмәшев, Исмәгыйль Нәзиров, Мөхәммәтәмин Таишев, Хөснулла Сәлимҗанов, Сәйфулла Борһанов, Билалетдин Котлымәтов, Сәгыйтдин Гайнетдиновтан сорау алына. Алар барысы да бер булып: «Чыннан да, Гөләйза 1844 елның апрель аенда, язгы чәчү алдыннан вафат булды, христианча да, мөселман йолалары буенча да җирләнмәде», дип җавап бирәләр.

Гөләйзаны кабереннән актарып ала һәм таба алмагач, Чистай судлары аның якыннарына ябышалар. 1845 елның 8 февралендә Чистай өяз суды карар бирә: христианлыктан мөселманлыкка күчкән Гөлзада – Фекла Тимофееваны, шулай ук керәшен татарлары Ишмөхәммәт – Измаил Ефремов, Бикмөхәммәт – Иван Денисов, аның хатыны – Хөснижамал – Дарья һәм кечкенә кызлары Мөфлиха – Марфаны, чукынырга үгетләү-эшкәртү өчен, Казан консисториясенә җибәрергә, бу эшне башкарып чыгуны Чистай земство судына тапшырырга. Шул ук елның мартында Ишмөхәммәт белән Бикмөхәммәтне, кул-аякларын богаулап, Казанга, чиркәү судына озаталар, ә хатын-кызлар, авыру сәбәпле, бармыйча калалар.

Җиденче, сигезенче, уникенче мартта Ишмөхәммәт белән Бикмөхәммәттән инде Казанда, консисториядә сорау алалар, анда чиркәү әһелләреннән тыш, дөньяви вәкилләр – депутатлар һәм семинариянең татар теле укытучысы да катнаша. Әмма аталы-уллы татарлар аяк терәп каршы торалар – алар мөселманлыкны беркайчан ташламаячаклар, православлау диненә беркайчан да кайтмаячаклар, урысның телен дә, динен дә белмиләр… Казан консисториясе бу татарларны үзе генә җиңә алмагач, эшне губерна идарәсенә тапшыра, ә Ишмөхәммәт белән Бикмөхәммәтне монастырьга ябалар, ул мәкруһлар өчен төрмә ролен үти… Мәхкәмә документларыннан күренгәнчә, аларны монда ел ахырына кадәр бикләп тоталар, әле 1845 елның 30 сентябрендә дә Ишмөхәммәт белән Бикмөхәммәтне, Казан Кремле эчендәге чиркәү судына богаулап алып килеп, «эшкәртеп» карыйлар, әмма алар мөселманлыктан чигенми, урыс диненә кайтмый. Шуннан соң эшне Җинаятьләр палатасына тапшыралар, бу инде үгетләү вакыты үтеп, җәза бирер чак җитте, дигәнне аңлата. Җәзаның иң авыры – Себер каторгасына сөрү булса, җиңелрәге – чиркәүле урыс авылына күчерү исәпләнә...

Яклаучы ир-атлары чиркәү төрмәсендә утыруыннан файдаланып, Гөлзада

белән Гөләйзаның балалары өстендә дә кара болытлар куера башлый. 1845 елның декабрендә Чистай өяз суды карар бирә: Гөлзаданың – Фекла Тимофееваның Федосья һәм Марья исемле кызларын эзләп табарга, алардан сорау алырга, нинди дин тотуларын ачыкларга. Апалары Пелагея – Гөләйза кебек, алар да мөселманга кияүгә бирелмәгәнме – эзләп табарга һәм суд каршына бастырырга! Ә Пелагея – Гөләйзаның мөселман Хәким Камаев белән зинадан туган балалары – 9 яшьлек Габделвахитны, 6 яшьлек Габделҗәббарны, 2 яшьлек Гыйниятулланы, ислам тәэсиреннән коткару өчен, аталарыннан аерып алырга, аларны округ идарәсенә китерергә, чукындырып, христианнарга тәрбиягә бирергә. Бу балаларга мөселманча исем кушканы өчен Әхмәт мулланы суд каршына бастырырга… Һәм бу эшкә җаваплы итеп тагы становой пристав Алексей Шахтны билгелиләр.

Җәза тегермәне әйләнә, аңа инде мулланы да тартып кертәләр, ә акчага сатылган попларга һәм кеше кыйнаган приставларга әле чират җитми…

Шахт, җиң сызганып, Шонталага сорау алырга килергә җыенганда, аның тагы бер корбаны үлеп котыла – 1845 елның җәендә кечкенә Гыйниятулла җан бирә… Әнисе үлгәннән соң, зираттан кайтып кермәгән, һавада кошлар очкан саен, «Мине дә ал!» – дип артларыннан йөгергән Гыйниятулла, сагышына түзә алмыйча, 12 июль көнне зыяндәш зәхмәте өянәгеннән үлә… Аны мөселманча итеп, әнисенең буш торган каберенә күмәләр…

Сорау алуларда Казан вәкиле дә катнашканга, пристав Шахт үзен бераз кысаларда тотарга тырыша, теге вакытлардагы кебек, һәркемгә котырынып ташланмый. Үзенең өстеннән дә шикаятьләр барлыгын, аны кеше кыйнауда, хәтта үтерүләрдә гаепләүләрен ул белә. Бер яктан, аңа татарлар теш кайраса, икенче яктан, өяз җитәкчеләре дә шикләнеп карый, һәр адымын тикшереп торалар. Ә иң куркынычы – теге вакыттагы хәлләр, Гөләйзаның кабереннән юкка чыгуы, Биләр побының өянәк белән егылуы, уң кулының корып баруы – болар барысы да татарларның каргышы булырга мөмкин, диләр...

1846 елның 12 гыйнварында Шахт Кыр Шонталасына сорау алырга килеп җитә, бу юлы ул оныгы үлү сәбәпле үзе дә авыруга сабышкан Гөлзададан кызларын эзләтә. Гөлзада, чыннан да, өч кыз бала табуын, аларның урысча исемнәрен белмәвен, олы кызы Гөләйзаны Чирүле Шонталасы авыл татары Хәким Камаевка кияүгә бирүен, ул кызының моннан ике ел чамасы элек үлүен, аны мөселман йоласы буенча шул авыл мулласы Әхмәт Әхмәровның күмүен әйтә. Шулай ук төпчек кызы Миңҗамалның да моннан алты ел элек үлүен, аны Кызылъяр побы христианча күмүен әйтә, әмма соңыннан билгеле булганча, Мифодей атакай приставка андый белешмә бирүдән баш тарта. Гөлзада уртанчы кызы Шәрифҗамалның үзе белән авылда яшәвен, кияүгә чыкмавын, аның да ислам динен тотуын яшермичә әйтеп бирә. Сабый вакытта ук үлгән кызы Хупҗамал турында әйтеп тә тормый...

Аннан соң Гөлзаданың уртанчы кызы Шәрифҗамалны сорау алырга чакыралар, Шахтның белешмәләрендә ул Федосья, дип теркәлгән. Шәрифҗамал үзенә 19 яшь икәнен, урысча исемен белмәвен әйтә, беркайчан да чиркәүдә тәүбә һәм арулануда булмаганын, аларның нәрсә икәнен дә белмәвен хәбәр итә. Ул шулай ук үзенең чукындырылуы турында әнисеннән дә, беркемнән дә ишетмәвен сөйли, кечкенәдән әнисе белән бергә ислам динен тотуын, хәзер дә бергә яшәүләрен әйтә. Документлардан күренгәнчә, укый-яза белмәгәнгә, аның өчен кулны «писарь Ильминский куйды», диелгән, димәк, бу мәкерле миссионер ул вакытта ук инде татар авылларында иснәнеп йөргән.

Шул ук көнне сорау алулар Чирүле Шонталасы авылында да дәвам итә. Башта Гөләйзаның ире Хәким Камаевтан сорау алалар, ул православ диненнән ислам диненә кайткан хатынының моннан ике еллар элек вафат булуын сөйли. Шулай ук төпчек уллары Гыйниятулланың да узган җәйдә үлеп китүен, хатынын да, улын да авыл мулласы Әхмәт Әхмәровның мөселманча күмүен хәбәр итә. Калган ике улы – Габделвахит һәм Габделҗәббарның хәзерге вакытта үзе белән яшәвен әйтә.

Инде чират мулланың үзенә дә җитә. Ул да дөресен әйтә – Гөләйзаны мөселманча күмдем, чөнки аны чукындырылган дип белмәдем, ди. Ә Гыйниятулланы ул өйдә юк вакытта азанчы Мөхәммәтша Мөхәммәтсәлимов күмгән, Гөләйзаның үлеме метрика кенәгәсенә язылмаган, ә Гыйниятулланы үзем язып куйдым, чөнки тууын да мин теркәгән идем, ди.

Азанчы Мөхәммәтшаны кертәләр, ул Хәким Камаевның 1845 елның җәендә үлгән улы Гыйниятулланы җирләмәвен әйтә, минем моңа хокукым юк, ди. Күрсәтмәләрдә каршылык килеп чыкканга, сорау алынучыларны шул көнне үк йөзгә-йөз очраштыралар. Монда җаваплар тагы аерыла, мулла белән Хәким Гыйниятулланы азанчы җирләде, янында авылның элеккеге башлыгы Әбуталип Камаев кына бар иде, диләр, инде ул да үлгән икән. Ә Гөлзада оныгын кем күмгәнне инде хәтерләми икән.

Эш шулай бутала башлагач, авыл халкыннан сорау алалар, Чирүле Шонталасыннан 26 мөселман татары җавап тота. Беренче булып 60 яшьлек Ишмөхәммәт Билаловны кертәләр, ул азанчы Мөхәммәтша турында бераз мәгълүмат бирә, аның күрше Түбән Тигәнәле авылыннан булуын, һаман указсыз эшләвен әйтә. Ә Хәким Камаевның улын кем җирләвен белмәдем һәм күрмәдем, дип бара. «Аның азанчы Мөхәммәтсәлимов тарафыннан җирләнүе турында Хәкимнән ишеттем», ди. Аннан соң җавап тотарга кергән Газиз Гобәйдуллин, Тимербулат Тимергалиев, Бикмөхәммәт Тимергалиев, Нигъмәтулла Мәмәдәлиев, Алимбәк Мәмәдәлиев, Әхмәди Әхтәмов, Фәхретдин Әхтәмов, Мөхетдин Чуручин, Бикмөхәммәт Сәйфуллин, Идрис Әдәлиев, Рәхмәтулла Кадералиев, Әхсән Ярмөхәммәтов, Хисаметдин Ишмөхәммәтов, Мөхетдин Тимербулатов, Сәйфетдин Сәгыйтов, Сәмирхан Ташаев, Вәлиулла Гобәйдуллин, Гайнетдин Хәсәнов, Әхмәди Ярмөхәммәтов, Мөхетдин Сәгыйтов, Әхмәт Әхтәмов, Хәмит Йомранаев, Мифтахетдин Ярмөхәммәтов, Биккенә Алиев, Фазаргали Юлдашев та Ишмөхәммәт Билалов кебек күрсәтмә бирәләр.

13 гыйнварда Шахт эшне тәмамлап, земство судына тапшыра, аның рапортында: «Өстәмә тикшерүләр тәмамланды, христиан диненнән исламга кайткан Фекла Тимофееваның, оныклары Габделвахит белән Габделҗәббарның, мулла Әхмәт Әхмәров һәм азанчы Мөхәммәтша Мөхәммәтсәлимовның хөкемен сезгә тапшырам», диелгән була. Эш земство мәхкәмәсеннән өяз судына китә, алар исә 1846 елның 17 гыйнварында катгый карар чыгаралар: «Мулланы җинаятьче буларак хөкем итәргә, Гөләйзаның балаларын һәм азанчыны округ идарәсенә тапшырырга, алардан балаларны христианнарга тәрбиягә бирүне, ә азанчыны мәҗбүриләп туган авылына кайтарып җибәрүне сорарга».

Шул көнне үк өяз судында Әхмәт мулланы хөкем итәләр, әмма ул нык тора – Гөләйзаның чукындырылган икәнен белмәдем, мөселман ире белән яшәгәч, балаларына да үзебезчә исем бирдем, аларны мәчет кенәгәсенә теркәдем, ди. Маңгаена терәп, «Ник ул хатынның керәшен икәнен белгәч, аны мөселманча җирләдең?» дигән сораугa, «Аны мин күммәдем, ә ире белән иренең абыйсы

җирләде», ди, үзенә шаһитлыкка авылдашларын санап чыга. «Авылда сорау алганда, мин күмдем, дип әйткән идең бит», дигәннәренә, «Урысчам начар, тәрҗемәче булмады», дип җавап бирә, «Гөләйза христианча да, мөселманча да күмелмәде», дип тә өсти. Бер караганда, Әхмәт мулланы да аңларга була – әгәр ул суд каршында, «Гөләйзага мин никах укыдым, үлгәч, мөселманча күмдем», дисә, аны шуннан ук кул-аякларын богаулап, Себергә озаткан булырлар иде.

Әхмәт мулланың эше әле шактый вакыт дәвам итә – тагы Чирүле Шонталасына барып, халыктан сорау алалар, әмма татарлар берсе дә мулла өстеннән сөйләми, инде үлгән Әбуталип Камаевка күрсәтеп котылалар. Гөләйзаны мөселманча күмгән өчен, Җинаятьләр палатасы Әхмәт мулланы барыбер алты ай төрмәгә хөкем итә, әмма ул, бу карар белән ризалашмыйча, шикаятьләр яза башлый, эш Сенатка кадәр барып җитә. Нәтиҗәдә, 1850 елның башында Әхмәт мулла барыбер бер ай төрмәдә утырып чыга, азанчы исә штраф белән генә котыла. Күрәсез, бу эш Гөләйза үлгәч тә тагы алты елга сузыла, алты ел буе кем күмгән, каян һәм ничек күмгән, дип, халыкның теңкәсенә тияләр, соңгы ноктаны куймыйча туктамыйлар.

Хәер, мулла гына түгел, Кызылъяр чиркәве побы Мифодей да Казанда, консисториядә җавап тота, ул да берничә ай монастырь төрмәсендә ятып чыга. Аның төп гаебе – чиркәү кенәгәләренең тәртиптә булмавы, пристав таләп иткән күчермәләрне бирмәве, керәшен татарлары белән ныклап эшләмәве була. Инде явыз пристав Алексей Шахтка да чират җитә, аны эшне сузуда, Хәким Камаевка һаман балалары белән яшәп ятарга ирек бирүдә, керәшен татарлары арасында тәртип урнаштыра алмауда гаеплиләр һәм 1846 елның апрелендә Чистай өязеннән алып, Казан ягына күчерәләр. Әмма Шахт анда барып җитә алмый, Биләр урманнарындагы бер чокырда аның үле гәүдәсен табалар. Кем үтергән, кайчан, ни өчен үтергән – моны ачыклый алмыйлар, әмма барысы да татарлардан шикләнә, чөнки ул аларның палачына әйләнә... Бу хәбәр Биләр побы өчен табутына соңгы кадак була – аның хәлен белүче, ярдәм итүчесе, таянычы калмый. Берьялгызы урын өстендә ятып, череп үлә ул, кешеләрнең күз яше аны да картлык көнендә куып тота. Биләр побы Михаил Лавров, Гөләйзага каршы эш кузгатып җибәргән, аны гүргә керткән бәндә, 1847 елның 20 октябрендә тилмереп, газапланып үлә...

Инде Гөләйзаның балалары язмышына килик. Билгеле булганча, әле 1846 елның 17 гыйнварында ук Чистай өяз суды Габделвахит белән Габделҗәббарны, аталарыннан аерып алып, христианнарга тәрбиягә бирергә, дип карар чыгарган була. Һәм шулай эшлиләр дә – Гөләйзаның балаларын Актау авылы керәшен татарларына тәрбиягә бирәләр, бу хакта архивларда Якуб Алякринскийның дини идарәгә рапорты саклана. Ул анда 1846 елның 13 июлендә Гөләйза Измаилованың балаларын чукындыруын, беренчесенә – Афанасий, икенчесенә Андрей исеме кушуын хәбәр итә. Габделвахит Актау авылы керәшене Василий Афанасьевка, ә Габделҗәббар – шул ук авылда керәшен татары Стефан Ивановка тәрбиягә бирелә. Ә 1847 елның 22 сентябрендә Чистай өяз мәхкәмәсе Гөләйза эшен яңадан карый һәм карар бирә: христиан динен ташлап, мөселманлыкка кайткан Гөлзада – Фекла Тимофееваны һәм аның исән балаларын, шулай ук Ишмөхәммәт – Измаил Ефремовны һәм аның гаиләсен чиркәүле, православ динендә булган урыс авылларына күчерергә. Урыс хакимияте бу иманлы татарларны, аларның нәселен ахыргача эзәрлекле, барысы өчен дә алардан үч ала. Болар – тарихта сакланып калган чыганакларда теркәлгән.

...Ә хәзер яңадан шул заманнарга әйләнеп кайтып, ул чордагы тормышка күз салыйк, бу әсәр каһарманнарының язмышын барлыйк...

...Ишмөхәммәт белән аның улын 1845 елның мартында, кул-аякларын богаулап, Казанга, чиркәү судына озаткач, бу нәсел турында кайгырту тулысы белән Чистай морзалары өстендә кала. Берьюлы берничә мәсьәләне хәл итәргә кирәк була – Ишмөхәммәтләрне Себергә сөрүдән саклап калырга, аларны ничек тә исән-имин монда кайтарырга, Гөлзада белән киленен Казанга, чиркәү судына җибәрүне өзәргә, Әхмәт мулланы төрмәдән аралап калырга, аңа төрле урыннарга хат-шикаятьләр язарга булышырга, Гөләйзаның балаларын аталары янында калдыруны сузарга, эш барып чыкмаса, аларны, сөйләшенгәнчә, Актау керәшеннәренә тапшырырга... Һәм, әлбәттә, татарларның үзәгенә үткән становой пристав Алексей Шахтны моннан кудырырга. Бу эшләрне башкарып чыгу тиз генә булмый, чөнки хөкемгә тартылган татарларның барысы да диярлек хокук оешмалары, мәхкәмә карарлары белән богауланган, аларны өзү өчен айлар гына түгел, еллар кирәк була. Бу эшләрнең башында Исмәгыйль морза тора, зирәк киңәшләрен, һәрвакыттагыча, йөзьяшәр Гомәр абыз бирә, аларга ярдәмгә Мөхәммәтзакир хәзрәт тә кайтып җитә. Әйе, соңыннан бөтен Чистай төбәгенең дини юлбашчысы булып китәчәк, мәдрәсәсенә урыс телен һәм укытучысын кертмәгән өчен 90 яшендә үзенә каршы да җинаять эше ачылган, сөрген язмышы әзерләнгән, моннан үлеп кенә котылган данлыклы ишан Закир Камали-Ваһапов... Аны 1846 елның 17 сентябрендә Казан губерна идарәсе карары белән Чистай мәчетенә имам-хатыйп итеп билгелиләр.

Шуны гына көтеп торгандай, инде йөз яше белән барган Гомәр морза, яшь муллага фатихасын биреп, бакыйлыкка күчә, аны Закир хәзрәт үзе юып җирли. Үләр алдыннан ул аңа шушы сүзләрне әйтә: «Дин-милләт өчен көрәшне син дәвам итәсең, улым! Бәйгатемне сиңа тапшырам, кулымны бирәм – миннән соң милләтне син иманга һәм азатлыкка өндә! Милләтне керәшенлектә калдырма – васыятем шул! Һәр татар, һәр мәкруһ өчен көрәш! Болгар-Биләрне яңадан күтәрегез, аны ислам үзәгенә әйләндерегез, бу җирләрдә мөселман-татар дәүләте төзегез! Әмма моның өчен әле сезгә бик күп авырлыклар күрергә, бик күп югалтулар кичерергә туры киләчәк, Аллаһ бу бәхетсез милләтемә сабырлыклар бирсен һәм җиңү насыйп итсен иде...»

Шулай итеп, Гомәр морза китү белән, Болгар-Биләр төбәгендә зур бер тарихи чор тәмамлана, милләт белән эшләү Закир хәзрәт кебек яшь татар имамнары кулына күчә. Ул бирегә килеп урнашу белән, татарларның бөтен кайгы-хәсрәтен үз өстенә ала, бигрәк тә рәсми кәгазьләрдә «отпавший» дип аталган мәкруһлар өчен җаны әрни, аларга булышуны иң саваплы гамәл итеп күрә. Әле Чистай мәчетенә имам итеп билгеләнгәнче үк, ул берничә тапкыр Актау побы Якуб атакай белән очраша, эшнең нәрсәдә икәнен аңлата. Шулай ук аның белән Чистай байлары да очрашып сөйләшә, Гөләйзаның балаларын, аталары янында калдырып булмый икән, үз канаты астына алуын сорыйлар. Якуб Алякринский аларны үзенең җавабы белән шаккатыра:

– Сорап телегезне әрәм итмәгез, байлык белән дә кызыктырмагыз, – дип башлый ул, аларны куркытып. – Миңа Ходай күрсәтте инде хикмәтен... Гөләйзаның төн эчендә кабереннән юкка чыкканын күрмәсәм, әле, бәлки, икеләнгән дә булыр идем, куркыныч заманда яшибез бит! Әмма тагы да куркыныч һәм дәһшәтле нәрсәләр бар икән, туганнар, ул – Ходайның җәзасы! Сез, мөселманнар, моңа әзер, чөнки Ходайның рәхмәтенә өмет итәсез, ул кушканча яшисез. Ә без нишләрбез? Без дә дөрес яшибез, дип beләбез, әмма

күрәбез – Ходай безгә түгел, сезгә ярдәм итә. Гөләйза кыйссасы миңа бик зур сабак һәм гыйбрәт булды, бөтен вөҗүдемне актарып ташлады... Мин инде сезнең дингә кайта алмам, дөрес икәнен белсәм дә... Чөнки минем артта халык тора, ә алар бер көндә генә үзгәрә торган түгел, керәшенлек инде аларның каннарына сеңгән... Ә Гөләйзаның балаларына булышырмын мин, ул хатын җәннәт иясе бит, балалары да җәннәт кошлары! Казан төрмәсенә киткәнче, Ишмөхәммәт әзи дә бу турыда әйткән иде... Килешенгәнчә эшләрбез, Ходай кушса!

Һәм шулай була да – мәхкәмә Гөләйзаның балаларын христианнарга тәрбиягә бирергә, дигән карар чыгаргач, Чистай морзалары аларны ничек тә Актауга, Якуб атакай кулына тапшырту өчен эшкә керешәләр. Округ идарәсендә сүз сыярлык кешеләрне табалар, аларга старовер урыслар аша эшне аңлаталар, әлбәттә, бөтен серләрен ачмыйлар, төп дәлил булып балаларны татарча белүче христианнар арасына күчерү тора, ә алар – Актау керәшеннәре. Чиркәве дә бар, урысы да җитәрлек, побы да татарча белә, тәрбиягә алган кешеләре дә татар булса, балаларга ул тормышка кереп китәргә җайлырак булачак, диләр. Һәм шулай эшлиләр дә – Габделвахит белән Габделҗәббарны Актауга китереп, Васил-Василийга һәм Сәгыйдулла-Степаннарга тәрбиягә бирәләр, Якуб атакай кәгазьдә «чукындыра», ә гамәлдә – юк. Гомер буе керәшен татарлары өстендә мәет козгыны кебек иснәнеп йөргән Биләр атакае ул вакытта үзе үлем белән тартышып ята, ә Шахтны Биләр урманында бәреп үтерәләр... Шулай итеп, Гөләйзаның догалары кабул була – аның балалары мөселманнар кулына күчә...

Ул арада, Чистай морзалары йөреп, Ишмөхәммәт белән Бикмөхәммәтне дә Казан төрмәсеннән чыгаралар, алар авылларына әйләнеп кайта. Монда да күп вакыйгалар булып үткән, күп нәрсәләр үзгәргән булып чыга. Ишмөхәммәт төрмәдә утырганда, олы хатыны Әминә үлеп китә, аны Кыр Шонталасы авылы мулласы Бикмөхәммәт Вәлитов яшерен рәвештә мөселманча җирли. Гомер буе таянычлы терәге булган, икенче хатыны Гөлзаданы да, Аллаһ сынавы, дип кабул иткән, уртак балаларын карап үстергән, үзеннән соң иманлы нәсел калдырган хатынын, Ишмөхәммәт догалары белән искә ала, үлгәннән соң булса да бәхиллеген бирә. Икенче хатыны Гөлзада да авырып тора икән, аны да төрмәдәге ире һәм улы, бу дөньядан китеп барган кызы һәм оныгы кайгысы аяктан еккан. Җитмәсә, үзен тагы суд юлларында йөртә башлаганнар, кызлары Шәрифҗамалның теңкәсенә тияләр икән, имеш, чукынганмы-юкмы, кайда-ничек яши? Инде ул баланы да урнаштырырга кирәк булачак, үз тормышы булсын.

Оныклары Габделвахит белән Габделҗәббарны да, аталарыннан аерып алып, Актауга җибәрәләр. Бер яктан, аларны христианнарга тәрбиягә бирмәүләренә Ишмөхәммәт сөенә, ул балаларның хәзер эзен дә тапмас идең. Ә монда – ышанычлы кешеләр, үз татарларыбыз. Калганы көйләнер, авылларына да кире кайтырлар. Кайткан көннең икенчесендә үк, җомгага туры китереп, ул Актау авылына чыгып китә, хатыны Гөлзада белән уртанчы кызы Шәрифҗамал да шунда була. Бабаларының килүенә иң нык сөенүчеләр – оныклары, әйтерсең лә әниләрен күргәннәр...

– Аллаһның рәхмәте белән, менә без тагы бергә, – ди Ишмөхәммәт, намаздан соң. – Беренче тапкыр бу йортка моннан сигез-тугыз ел элек аяк баскан идек, беренче намазларны да шунда укыдык. Аннан соң башыбыздан күп хәлләр кичте, үлемен дә, төрмәсен дә, судларын да күрдек, иң газиз кешеләребезне югалттык, аларның урыннары җәннәттә булсын!.. Әмма ни

генә күрсәк тә, иманны җуймадык, Аллаһ ярдәменә өметебезне өзмәдек, әлхәмдүлиллаһ! Бу хәлләрне Аллаһның сынавы, дип кабул иттек, иман өчен көрәштек, авырлыкларга сабыр иттек... Шушы хәтле көчле дәһшәт астында да исән калуыбызны, мөселманлыкта калуыбызны Аллаһның рәхмәте, дип кабул итәргә кирәк. Һәм аның кадерен белергә кирәк. Динебез тыелган вакытта да өйләренең түрләрендә безнең өчен намазлыкларын җәйгән, аннан үзләре дә намазга баскан Васил энем белән Нәгыймә сеңлемә, беренче булып безгә килеп кушылган Мәрьямбану сеңлем белән Сәгыйдулла энемә, Актау өстенә иман нуры җәелдергән барлык мөселман кардәшләремә мин чиксез рәхмәтле, бу дөньяда бергә булган кебек, ахирәт көннәрендә дә бергә булырга насыйп итсә иде! Инде шушы нигездән иман белән бакыйлыкка күчкән, дин-ислам хакына адәм баласы күтәрә алмаслык газаплар кичергән Әкълимә әби белән аның улы Мөхәммәтнең, төрмәләрдә үлгән якыннарының, тереләй янып үлгән милләттәшләребезнең, дин кардәшләребезнең дә урыннары җәннәтнең түрендә булсын иде, Раббым! Алар безгә шушы иманны, шушы рухны, шушы тормышны биреп калдырдылар, инде балаларыбыз, оныкларыбыз, нәселебез дә шушы изге юлны дәвам итсен иде!

...1847 елның көзендә Ишмөхәммәтнең ишле гаиләсен – үзен, улын, киленен, оныгын, Гөлзаданы, буй җиткән Шәрифҗамалны да, суд карары белән, чиркәүле урыс-керәшен авылы Актауга күчерәләр, ул авылның бер почмагы ислам утравы икәнен белмиләр. Хәер, аларның Кыр Шонталасы белән дә, Чирүле Шонталасы белән дә аралары өзелми, балалар аталары янына гел кайтып йөри. Ә инде аз гына ирек килү белән, бөтенләй күчеп кайталар. Габделвахиткa уналты яшь тулуга, аңа Василларның кызы Мәрьям белән никах укыйлар, алар Чирүле Шонталасында, аталары йортында яши башлый. Ул көнне ике туй була – тол калган Хәкимне дә Гөләйзаның бертуган сеңлесе Шәрифҗамал белән ярәшәләр, аларга никах укыйлар, шул рәвешле, өзелә язган тормыш, бернигә карамыйча, дәвам итә. Бер елдан аларның кыз балалары туа, аңа Әхмәт мулла Гөләйза, дип исем куша, Әкълимә әбинең дисбесе яңадан Гөләйза кулына күчә...

...Николай I патша үлгәч, 1855 елның язында Ишмөхәммәт тә, гаиләсен алып, янә Кыр Шонталасына һәм бөтенләйгә күчеп кайтты. Бу чорда Актауда унөч җан керәшенлектән мөселманлыкка кайткан булып чыкты, алар да чиркәүле урыс авылын калдырып, Кыр Шонталасына күчте, араларында Васил һәм Нәгыймә гаиләсе, Сәгыйдулла һәм Мәрьямбану гаиләсе дә бар иде. Якуб атакай аларны авыл башына хәтле чыгып, үзе озатып калды, барысы белән дә кочаклашып аерылыштылар, еладылар. Якуб атакай алар белән китмәде, чөнки аның халкы монда иде... Хакыйкатьне белсә дә, Аллаһның могҗизасын үз күзләре белән күрсә дә, ул үз динен, үз кавемен, үз авылын ташлый алмады... Ул аларны авыл башына чыгып, озатып калды, чаларган сакалына күз яшьләре тәгәрәп төште... Кыр юлы буйлап, арбаларга төялеп, аның милләттәшләре китеп бара иде... Үз авылларына, үз асылларына, үз тамырларына кайтып баралар иде... Сак-Сок кошлары кебек, язмыш аларны аерган, дин төрле, әмма милләт бер, шул сәбәпле, бу аерылу бигрәк тә аянычлы һәм фаҗигале иде...

Ишмөхәммәт 1856 елда, 85 яшендә вафат булды, аны зурлап, Кыр Шонталасы зиратына мөселманча җирләделәр, кабере Гөләйза кызы янында икән, диделәр...

...Ул төнне күк йөзен Болгардан-Биләрләргә хәтле йолдызлар бизәгән иде...

Әйтерсең лә милләт дисбесеннән бар җиһанга чәчелеп киткән рухи мәрҗәннәр!

Әйтерсең лә җиде кат күкләрдән җем-җем килеп нур чәчәләр, юл күрсәтәләр, татар тарихын сөйлиләр, гыйбрәт алырга чакыралар...

Әйтерсең лә бу дисбе төймәләре түгел, ут эченнән нур булып күккә атылган милләт улларының һәм кызларының җаны караңгы күктә йолдыз булып яна – Хөснибикә һәм Гөләйзар, Әкълимә һәм Гөләйза, Бикмөхәммәт һәм Бикмулла, Мөхәммәт, Абдуллаларның җаны йолдыз булып яна иде... Алар йөзләрчә һәм меңнәрчә... Күктә дә, җир йөзендә дә...

Көчләп чукындырганда да иманда калган, мөселманлыгын һәм татарлыгын бирмәгән, иң авыр, кара заманнарда да милләт дисбесен өзмәгән, аны киләчәккә васыять итеп калдырган халкыма мәңгелек дога булсын бу әсәрем!

...Җиргә тагы яз килде, шау чәчәкле май килде...

Болгар-Биләр хәрабәләре өстендә, Шонтала күгендә тагы кыр казлары күренде, тормыш дәрьяларын гизеп, алар бирегә нәсел калдырырга кайталар иде... Җырлый-җырлый, елый-елый, бетмәс дәрт һәм өмет белән, алар туган якларына кайтып киләләр иде... Киек кошларның моңлы тавышына галәм төпкеленнән тагы бер аваз килеп кушыла, үзәк өзгеч бу сагыш бөтен җиһан буйлап тарала:

– Минем исемем Гөләйза... Минем исемем Гөләйза! Минем исемем Гөләйза.

Иман хакына туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган татар качакларының да рухлары, дога һәм җыр булып, милләт күгеннән үтеп бара... Ак болытларга сары сагыш белән язылган җан авазы аларга да барып ирешә:

– Минем исемем Гөләйза... Минем исемем Гөләйза! Минем исемем Гөләйза.

Моңа җавап итеп, авыл өстендә беренче күк күкри, галәм бар дөнья ишетерлек итеп аңа җавап бирә:

– Әйе, синең исемең Гөләйза! Синең исемең Гөләйза... Синең исемең Гөләйза.

Ә аста, яшел чирәм өстендә, алтын чәчле, яшькелт күзле кыз бала, нәни кулларын сузып, ак болытлар артыннан йөгерә... Җиһаннан килгән бу серле авазны ул да ишетә, ул да аңа җавап бирә:

– Минем исемем дә Гөләйза! Минем исемем дә Гөләйза! Минем исемем Гөләйза!!!

Күкләр аңа көлеп, беренче язгы яңгыр белән җавап бирә...


Кыр казлары аның аяк астына көмеш каурыйларын сибә...

Мәчет манарасыннан яңгыраган азан моңы шәһәдәтлек бирә...

...Һәм милләт яшәгәндә, мәңге шулай булыр, инша Аллаһ!

*Тәмам.*

*2018 ел, 9 май.*



Рим
Идиятуллин

# ДӨНЬЯЛЫКТА КЫЛГАН СӘФӘРЕМ...

## Бик җиткән!..

Халкым хакны әйткән:
Ак Иделләрнең лә аръягында
Бер энәгә – симез бер сыер;
Тир түкмичә мул сый көткән бәндә
Чит җирләргә барып сыеныр да
Кеше кояшына кызыныр.

Иллә-мәгәр кемнәр
Читтә каңгырганның: «Монда оҗмах», –
Дип әйткәнен кайчан ишеткән?!
Салма коткы! Кусалар да китмим.
Туган илкәемдә хәсрәт чигеп
Дөнья көткәнем дә бик җиткән...

## Шулай ук та...

Атармы таң, туармы көн, диеп,
Багып торган чакта баешка,
Ил-күршедә утлы яулар күреп,
Батамын да куям сагышка.

…Сүриядә көннәр – комдай кайнар,
Төн – күмердәй кара Донбасста;
Иблис алкышларлык хәлләр анда:
Гаярь ирләр сабый җанын кыяр,
Баш кискәне – яшәр оҗмахта.

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) – *шагыйрь; «Хәерле иртә», «Хәерле көн», «Хәерле кич» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Уфада яши.*

Ай кителеп җиргә төшәр кебек,
Кояшта да серле шартлаулар.
Ходай ерак,
кырга сыймас кыргый
Суешлардан безне кем саклар?

Купса күктә афәт, иксез Җир дә
Кысан читлек сыман тоелыр;
Бәндәләр соң, чебеш төсле, җанын
Җанга терәп кая сыеныр?

Явызлыклар тәмам авызлыксыз.
Хәерлегә булсын!.. Оныклар
Шулай ук та Кабил илә Һабил
Язмышларын янә кабатлар?

## Иртәгәне күзәткәндә

Бәндәләргә кара! – Көн итәләр,
Акча исләренә исереп;
Кара таңнан торып, кара тиргә
Батасы юк, кара җир сөреп.

Безгә ни! – Ике дөнья – бер акча;
Иртәгәне ишәк кайгыртсын.
Вәт ихтыяҗ килеп тугачтын,
Марсианнар төшеп, алмагачта
Үстерерләр ипи, ә оныклар
Өзеп кенә алыр агачтан…

***

Кай тарафка гына юл тотса да,
Кемнәргәдер җил гел уңайга;
Әнә берәү, очын-очка ялгап,
Дөнья көтсә, байлар – шыр майда.
Калкыр микән хаклык шулай да?..

## Табигать һәм кеше

Табигатьтә барча терек – бөек;
Бак әле син моңлы кошларга! –
Кайда тели, кайчан тели, – сайрый.
Масаю юк. Рәхмәт аларга!
(Өсләренә төзәп таш атыгыз,
Бер-бер ялгыш нота тапсагыз.)

Табигатьтә бармы бер үсемлек,
Шау чәчкәсез, татлы җимешсез?
Томырылып күзгә карар җиләк
Хас кул сорар сабый ич үксез.
(Юмартлыгын кара: тулгач сутка,
Бар байлыгын бирә ул бушка.)

Табигатьтә артык җан тапмассың;
Быжгак бөҗәк, шакшы хәшәрәт,
«Калма безнең хәлгә, аң бул, адәм!»,
Дип кылмыймы алар ишарәт?
(Сөйрәлмикче, тиңләшербез кошка,
Тиеп торса башлар кояшка.)

Табигатьтә чиксез көч-кодрәт;
Ярсу давыл, шашкын өермә
Кисәтүле җан ачысы аның:
«Бума суны, тауны җимермә!»
(Тимер өзәр тиле генә белмәс, –
Җимерергә акыл кирәкмәс.)

Табигатьтә олуг мәрхәмәтлек;
И Илаһым, җирнең тере килеш
Тунап бетергәч тә тиресен, –
Һомай коштай янә тере син!
(Ачы уйлар баса шул мәлләрдә:
Кем икән ул кеше гамәлдә?)

.......................................................
Һаваланма, кешем! Бак үзеңә! –
Ни аермаң кыяк үләннән?
Икегез дә кояш үсентесе:
Кара җиргә тамырларын җәеп,
Көйдерәчәк күккә үрелгән...

## Чүт-чүт кенә...

Үкенечләр генә тудырдымы
Дөньялыкта кылган сәфәрем?
Тоттым тәки, дисәм, бәхет кошын,
Җитмәде буй чүт-чүт, каһәрең!

Тулган Айдай иде тәүге ярым, –
Булмас монда тамчы ялганым;
Их-ма, кыска чәчләремне озын
Толымнарга ялгый алмадым.

Кызыгыпмы данга, аны җирнең
Җиде катларыннан эзләдем;
Хәерсезең, чүт-чүт алдан килеп,
Төяп алып киткән кемнәрдер.

Җир томанга батты. Күп уйладым:
Ничек чыгарырга яктыга?
Күчәреннән тотып күчерергә
Җитми калды куәт чак кына.

Күзгә җиле тиде, тоттырмады
Киләчәкнең өркәк тулпары;

Ялларына ябышырга кылдай
Ара гына иде нибары.

Узды гомер бушка, бетте тузып
Кешелеккә кигән күлмәгем;
Язмышымдыр, сыңар сөенечнең
Сынык шәүләсен дә күрмәдем.

Кемнәр янар, кемнәр генә ямар? –
Еллар кара, заман сүтелгән;
…Шыпын басып әҗәл килә ята,
Ә кибәнне очлап бетмәгән,
Тфү, шайтаның!..

## Вакыт хакында

Вакытларның узганына көймә,
Узачак ул бездән башка да;
Җисми булса, байлар хөр яшьлеген
Сатып алыр иде акчага.

Җилә вакыт ярсу тулпарларда,
Йотып каласың тик тузанын;
Кеше кадере артыр, суырып
Бетерсәләр тизрәк җир канын.

Вакытларның моңсулыгын тойдым,
Аяк баскач туган ягыма;
Җанкаемны өзеп алып, элеп
Китәрләрдәй булдым каенга.

Вакытлар да сыктап елый икән,
Сугылса җил кабер ташына;
Бай тирәктә кош сайраса, йөрәк
Хәсрәтләрдән бераз бушана.

Вакытларның тукталганын күрдем,
Яшь күкрәкне пуля тишкәндә;
Җирдәге җан исәбеннән күбрәк
Үлем хәзерләдең ник, бәндә?!

…Вакыт Галиҗәнаплары! Булмас
Дәвамыңа һичбер катнашым;
Узып киткәч, йотып яшең, ачы
Тузанында аунап каласың…



Әхтәм
Зарипов

# КҮПЕР

ПОВЕСТЬ

*Язмамны ахырыннан башласам да, башыннан тотынсам да, иң кирәкле бер «кисәге» төшеп калыр һәм «чылбыр» ялганмас кебек тоела. «Кисәк»ләргә генә түгел, аерым сүзләргә дә кагыла бу искәртү. Әйтик, «детдом» сүзен ник «балалар йорты» дип кенә язмыйм? Чөнки «детдом» – ул балалар йорты гына түгел, ул без үскәндә «башка дөнья», «үзгә тормыш», «могҗизалар иле» дигәнне дә аңлата иде.*

*Тагын бер кисәтүем: вакыйгалар минем исемнән язылса да, кайберләре ишетелгәннәргә таянып, «чылбыр»га ялганыр. Кайдадыр сүз ялганга таянып ялгана икән, аның да нигезендә чын дөреслек ятар. Икенче төрле әйткәндә, ялган чыннан башлана.*

### Карга боткасы

...Безнең авыл «Мәнәвезтамак» дип атала, чөнки ул Агыйделгә коючы Мәнәвез елгасы буена урнашкан. Елганың теге ягында – «дөньяның иң биек» тавы, тау өстендә – дөньядагы иң куе имән катыш нарат, каен урманы. Урман артында, Агыйдел буендагы Актау башында, детдом. Ачылган чагында детдомда тирә-як авыллардан җыелган ятимнәр генә тәрбияләнсә, сугыш башлангач, ул Белоруссиядән, Литва белән Латвиядән, Молдавиядән эвакуацияләнеп килгән төрле милләт балалары белән тула.

«Тутыру» сүзен безнең авылдан детдомга менеп эшләп йөрүче «воспитательница»ларның өйләренә бала ияртеп кайтуы әйттермәдеме икән:

«Ятар урыннары юк – китереп тутырдылар».

«Бер кашык белән биш авыз тутырырга».

«Төпсез коены су белән тутырып буламы?..»

...Эшләр җайланып киткәч, мондый сөйләшүләр кимесә дә, тәрбиячеләренә ияреп кайтучы балалар артты. Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр. Һәрхәлдә, бертуган ике малай, Гомәр бабайның кызы Кәшифә апага ияреп кайтып, атналар буе безнең авылда яшәде. Детдомга «отмечаться» итәргә генә менәләр икән.

...Кәшифә апа (минем туган абыем Әүдахның «ярәшелгән» кызы) икесенә дә унсигез яшь тулуга, загска кереп, туй ясаячаклар. Алар шуны көтеп яши. Болар турында мин әткәй белән әнкәй сөйләшүеннән аңладым. Хәзер инде,

эткәй «трудәрмиягә» алынгач, абыйның көн-төн шул Кәшифәне сагалавыннан, әнкәйнең аны «сабыр бул, ашыгып өзмә пешмәгән алманы», дип акыл өйрәтүеннән, бу эшләрнең ахыры якынлашуын сизенеп, мин дә туй булуын көтә идем. Тик абый түгел, мин ашыкканмын.

...1943 елның елгаларда боз киткән кояшлы бер җомгасында, әнкәйнең фин сугышыннан гарипләнеп, үпкәсенә салкын тидерүдән авырып үлгән энесе Шәрифулла абзыйдан калган кәчтүм-чалбарларны киеп, кулына думбрасын алып («гитара» дигән сүзне сирәк әйтәләр), ике иптәш егете белән абый каен суе эчеп хозурланырга киттеләр. Урманга. Әнкәй: «Кем инде урманга юньле кием киеп бара», – дип, сукранып калды.

Ул көнне авыл малайларына ияргән детдом балалары белән, кешедән-кешегә кереп, кәрҗин-чиләкләребезгә «карга боткасы» пешерергә ризык җыябыз. Күпләр йомырка бирсә, кемдер уч тутырып ярма, сыерлылар – сөт, кайберләре кашык тутырып май сала. Сугыш чоры булса да, һәр йорттан нидер тама. Ире, чулакланып, әрмиядән котылып калган (әнкәй «качып калган», ди) Хәкимәттәйнең хәтта «кәрәмил» дигән ике кәмфит белән бер шакмак чын шикәр бирүе олырак малайларны сугыштыра язды. Учак тергезү өчен кәрәчин шешәсе тоткан Җәүдәт белән коры утын күтәргән Сәгыйть кәрәмилне алып капсалар да, шикәрне, бүлә алмагач, кәрҗингә салдылар. Ризыклар җыелып беткәч, Җәүдәт белән Сәгыйть җитәкчелегендә «боткачылар» Мәнәвез елгасының теге ярындагы «Сыер кулы» дигән тау ышыгына юл тота. Мин дә шунда. Мәнәвездә бозның тыгылган чагы. Теге якка турыдан-туры чыгып булмаса да, боздан бозга сикереп, кырыйларга салынган иске такталар аша кичү мөмкинлеге ясаганнар. Ул чакта яшем җиде тулып узганлыктан, миңа, озатучысыз, үземә генә бару рөхсәт ителгән иде. Алай гына да түгел, эвакуацияләнеп килгән Вәсилгә күз-колак булуда аның абыйсы Вәдимгә ярдәм дә итәргә кушыла. Кушучысы – киләчәктә үз җиңгәчәм буласы кеше, шуңа күрә, «күз-колак» булу ни икәнен аңламасам да, йомыш кушылу, йомыш алу абруемны үстергәч, «ярый», дип ризалашам.

Мәнәвезне кичү урынындагы тау итәгендә абый ике иптәше белән, боткачыларны дәртләндереп, думбра чиртә, такмак әйтә. Әлегә «җиңгәчәй» дияргә рөхсәт ителмәгән Кәшифә апа, детдомнан төшкән һәр балага нидер әйтеп, озатып кала. Тәрбияче! Боткачылар төркеме, Мәнәвезне кичеп, «Сыер кулына» күтәрелгәч, нәрсәне ничек пешерү мәсьәләсен хәл итте дә, Җәүдәт белән Сәгыйть учак тергезеп җибәрделәр. Безгә, «мешайт» итмәс өчен, ботка пешкәнче чүпрәк туп тибеп, пыяла ватыгы салып, аксаклы уйнарга куштылар.

Күпме вакыт уйнаганбыздыр, кинәт, кемдер берәү: «боз китә», «боз ага», дип кычкырмасынмы! Без моны шатлыклы хәбәр буларак кабул итеп, «ура» кычкырышсак, учак тирәсендәгеләр исә, тиз-тиз җыенып, таудан елгага таба чабыша башладылар. Кемдер кая барырга, нишләргә белми елый; кемдер кемнедер чакыра, кемдер (соңыннан олыларча әйткәндә) «чын-чынлап паниковать итә», авыл ягына чыгарга ашкына. Ә мин, шул буталыштан файдаланып, Хәкимәттәй биргән шикәр шакмагын эзлим. Юк бит! Юк! Таба алмавымнан гаҗиз булып, башымны күтәреп карасам, Вәсил белән Вәдим миннән нидер көтеп торалар.

– Нигә кайтмыйсыз? – дип акыруымны сизми дә калдым.

– Кая? – диде Вәдим.

– Кая булсын – өйгә!

– Безнең өй Белоруссиядә калды ич!

– Мондагысына!

– Детдомгамы?

– Кәшифә апаларга!

Елап интегүче Вәсилне җитәкләгән Вәдим үзе елый да, йөгерә дә алмый һаман аптырап тора. Елар иде – юатучысы юк. Әтисе сугышта, әнисе эвакуацияләнеп килүләренең икенче елында ук кинәт авырып вафат булган. Ятим калган ике улы рәсми детдом балалары саналсалар да, әниләре исән чакта яшәгән колхоз йортында Кәшифә апа карамагында көн күрәләр.

Силсәвиткә килгән пичәтле язу буенча, әтиләре «хәбәрсез югалган» офицер икән. Әмма аның табылуы ихтимал булганлыктан, малайлар шул табылу хәбәрен көтеп яшиләр. Күпмедер пособие дә, «эвакуацияләнгәннәргә» бирелүче икмәк тә алалар. (Әнкәй аларны ике сыерны имүче бозаулар, ди.) Имеш-мимешләргә ышансаң – Кәшифә апа шул ятимнәр ризыгы исәбенә аларны карап яши, имеш.

...Боз агудан яшәү агышына күчеп, читкә китеп барам икән...

Без, өч малай, аксап-туксап, елый-елый кичү турына килеп җиткәндә, боткачыларның барысы да диярлек елганың авыл ягына чыгып, айдан төшкәндәй, көтеп торучы – каршы алучыларга күргән-белгәннәрен сөйлиләр. Тау итәгендә думбра чиртеп, такмак әйтеп утырган өч абыйның өчесе дә, тыгылган боз өемнәренә куллары белән ишарәләп, безгә юл күрсәтәләр. Ә мин, алар сүзенә карамый, ярга чыгарып ташланган озын тактаның бер башын ярда калдырып, икенче башын ләмгә утырган бозга аудардым да, сикерә-сикерә, теге якка чыгып егылдым. Яткан җирдән күрәм – Вәдим дә әнә Вәсилгә минем арттан барырга, сикерергә куша, этә, төртә, өстери, куркыта. Тегесе курыкмый, тыңламый, карыша. Энесен кулыннан ычкындырып, яр буенда яткан таякны алыйм дисә, Вәсил инде упкын эчендә – чоңгылда. Күрмәдем – әллә инде ләмгә утырган боз кисәге күтәрелеп, әллә ялгыш басудан тактасы шуышып, суга батуын Вәсил үзе дә сизми калгандыр. Әмма бу хәлнең үлем икәнен тау итәгендә тамаша кылып утырган абыйлар бик яхшы аңлаган, күрәсең. Күз ачып йомган арада, өч егетнең берсе таудан чабып төшә дә чоңгылга сикерә. «Ух, ах, уф»!..» Авыл ягына чыкканнар арасында тавыш күтәрелә. Янәсе, ничек-ничек итәргә, ничек чыгарга өйрәтәләр. Алар өйрәтә, ә Вәсилне эләктергән егет күздән югала. Үлем тынлыгы урнаша.

Яр башындагылар берсен-берсе кочаклап, кемнедер гаепләп сүгенгән, елашкан арада, бөтенләй көтелмәгән яктан, Вәсилне күтәреп, коткаручы абый килеп чыга. Аптыраудан, гаҗәпләнүдән тагы тынлык булып ала. Шунда мин өстеннән су саркып торган коткаручыга карасам – ул үземнең Әүдах абыем икән. Абый! Ул аны-моны карамый, өйрәтүчеләр сүзенә колак салмый – Вәсилне, костырып, ясалма сулыш алдыру белән мәшгуль. (Ясалма сулыш алдыруның ни икәнен мин шунда күрдем.) Тыгылган боз өемнәрен басма итеп, абыйның иптәш малайлары Вәдимне дә чыгарып бастырдылар. Абый, киемен сыгып киюгә, миңа кычкырды:

– Ятма, җир салкыны тияр!

Иптәш егетләре белән алар авылга таба чаптылар. Мин дә аларга иярдем. Яр буена нидер сизенеп төшкән безнең әнкәйгә Вәсилне коткаргандагы батырлыклары турында мактана башладылар.

Җәүдәт: «Мин аңа су агымына карама, минем арттан баруыңны гына бел! – дисәм дә, малай тыңламады – агымга карады».

Сәгыйть: «Яр буендагы колганы тот! – дим, ә ул колагын тота».

Ә Хавадис исемле малай Җәүдәт белән Сәгыйтьнең йомырка тутырган кәрҗиннәрен кулдан ычкындырмый, боздан-бозга сикереп, өйләренә таба чабуларын күргән...

...Бу гайре табигый хәл, авыл халкы өчен, озак гомерләр онытылмаслык бер вакыйга булса, ышанганнар өчен Вәсил – бер үлеп терелгән кеше, безнең абый исә, Хозыр галәйһиссәламгә тиң изге җан буларак, телдән телгә күчеп яшәде.

...Хәзер туган көннәрне елына ничә тапкыр кирәк, шулай бәйрәм итеп үткәрәләр, элек бит авылда туган көннәрне үткәрү йоласы, гомумән, юк иде.

Карга боткасы пешерәсе көнне егетләрнең каен суы эчәргә дигән сылтау белән урманга менәргә җыенулары – абыйга унсигез яшь тулуны билгеләү, ә тау итәгендә утырулары исә Кәшифә апаның килүен көтүләре булган икән. Ул көнге вакыйгаларның җанлы шаһитлары булсак та, Кәшифә апаның тоткарлануына сәбәпне без белмибез әле.

Вәсилнең суга батачагын күңеле белән сизенгән дияр идең – бу ышанычлы сәбәп түгел. Чөнки Кәшифә апа, авылдагы җиде комсомолның берсе буларак, төрле хорафатларга ышанмый, ә менә үзендә юк авырулар табып, төрле үләннәр кайнатып эчәргә дигәндә, ул кызларның иң «азгыны». Абыйның Вәсилне суга батудан коткаруы турында ишетүгә үк, ул, малайларның өйгә кайтуларын да көтмичә, «митпунктка», суык тиюдән саклар өчен таблеткалар, үләннәр сорап килә. Үләннәре булмаса да, «митпунктта» «барлык авырулардан иң тиз терелтә торган» аспирин дигән дару бар икән, шуны алып кайтып, ике малайга да көчләп эчерә дә, телефоннан детдомга хәбәр итү өчен, силсәвиткә йөгерә. Ул чак бердәнбер телефон шунда гына була. Тик ул көнне кайдадыр чыбыгы өзелгәнлектән, телефон эшләми. Кәшифә апа, «ах-ух» килүдән соң, сәркатип кызның көтелмәгән хәбәренә: «Син, Сәрия, шаяртасыңмы, чынлап әйтәсеңме?» – ди.

– Армиягә чакыру хәбәре шаяру уены түгел. Хәрби комиссариатка шалтыратып та ачыклар идек – телефон эшләми. Комиссарның миңа телефонограмма тапшырганда әйткәне шул: 15 апрельдә егетнең туган көне узмыйча, хәбәрне әйтми тор», – диде. Мә, укы: «15 майда юл капчыгына бер атналык азык-төлек, ватылмас савыт, кашык-чәнечке салып, комиссариатка килергә».

– Әүдах үзе беләме бу хакта?

– Каян белсен – унбишенче апрель иртәгә ич әле. Иртәгә әйтермен, дип тора идем.

– Әйтмә, сиздермә, Сәрия. Хәбәрне мин үзем, үземчә йомшартып җиткезермен.

– Әйтмичә ярамый. Уналтынчы числодан да калмыйча, ул үзенең кайчан китәсен белергә тиеш».

...Бу хәбәр Кәшифә апа өчен абыйның Вәсилне коткарырга ташланган чоңгылыннан да хәтәррәк булганга, тезгенне үз кулына ала ул. Кеше аркылы гына бик тиз абыйга чакыру язуы җибәрә. Авыл советында силсәвит дежуры булып эшләүче Хәерниса әби ул язуны миңа бирә. Мин бит әле укый белмим, «Әткәйдән хат бар», – дип язуны абыйга бирдем, әнкәйгә дә әйттем. Абый, караңгы төшәр-төшмәс, киенде дә, «клубка барам», дип чыгып та китте. Әнкәй моңа бик тә аптырап калды.

– Ягылмаган, утсыз клубта нишләр икән ул, артыннан күзәтеп бар, – дип, мине абый артыннан «шпионлыкка» җибәрде. Абый клубка кермәде, силсәвит алдында тукталып калды. Шунда ук Кәшифә апа, силсәвиттән чыгып, абыйга

нидер әйтте дә аны өстери, кыстый башлады. Аларга күренми генә тыңлаган сүзләреннән мин шуны аңладым.

Кәшифә апа: «Сәрия котә, барысын да сөйләштек, язылышу чын законча булачак», – ди.

Абый: «Туган көнем иртәгә ич әле, шаһиткә иптәшләрне дә чакырып язылышырбыз, күпкә түзгәнне, бер көнгә түзик, ашыкмыйк», – ди.

Кәшифә апа: «Безнең инде никахыбыз бар, нигә түзәргә?»

Абый: «Йоласы шул ич».

Кәшифә апа: «Минем йола колы буласым килми», – ди дә кинәт клубка таба атлый. Абый аңа иярә.

Мин күренмәдем, кайтып киттем. Клубта ниләр булуын сизенсәк тә, ул турыда абый да, әнкәй дә, Кәшифә апа да беркайчан сүз чыгармадылар, «йоттылар».

Ике-өч көннән абый Кәшифә апа янына, колхоз йортына күчеп яши башлады, миңа Гомәр бабайны «кода», Камәрия әбине «кодагый» дияргә куштылар. Тавык суеп, токмачлы аш пешереп, Мөгътәбәр белән Шәрифҗан абыйны, кода-кодагыйны, Хәерниса әбине, тумыштан сукыр Миңнехан бабайны чакырып, Коръән укыттылар да, «бу мәҗлесне туй буларак кабул итәрбез», дип, бер-берләренә хәер, кода белән кодагыйга сөлге, башкаларга кулъяулык өләшкәч, кабат кишер чәе эчеп, амин тоттылар. Бу инде «шуның белән бетте» дигән сүз иде.

...Кәшифә апаны мин шул көннән «җиңгәчәй» дияргә тиеш булдым. Ул миңа һаман исемем белән дәшеп, чигүле кулъяулык бирде. Туйлар шулай «шаулап» узгач, дөньялар иркенәеп, табыннар кечерәеп калгач, яшь парлар артыкка әверелгән Вәсил белән Вәдимне, Мәләвез елгасы аша Зәкәрия абзый көймәсендә тау якка чыгарып, детдомнарына меңгезеп төштеләр. «Каникулга» дисәләр дә, укымаган Вәсил моңа ышанмый, Вәдиме серне аңлагандыр, ахры – ни әйткәнен белмим.

Өч-дүрт көн абый үзебезнең өйгә кайтып күренмәгәч, әнкәй, җиңгәчәйне гаепләп, мине аларга тагын «разведкага» җибәрде. Әллә фронтка алып киткәннәрме, дип борчылуыннан булгандыр. Повесткасын куен кесәсендә йөртсә дә, китү көнен әнкәйгә ишеттерүдән икесе дә сакланалар иде.

Сакланмагае, шартласалар да, унбишенче май бик тиз килеп җитте. Абыйны, Мөгътәбәр абый пожар атларын тарантаска җигеп озата барды. Башкаларны, гармуннар уйнап, елап-җырлап озатсалар, безнең абый думбрасын чиртеп, җиңгәчәйне юатып барган. Мөгътәбәр абыйга ышанганда, еламаган да, җырламаган да – шигырь сөйләгән. Солдатларны пароходка төяп алып киткәнче, җиңгәчәй абыйның үзен генә калдырмаган, пристаньда булган, шкипер белән сөйләшеп, бер кич аның каютасында кунганнар. – «Каюта нәрсә ул?» – дип сорагач, җиңгәчәйнең «пароходлар хуҗасының кабинеты» дигән җавабына әнкәйнең шатланганын онытмыйм. Күрәсең, улының зур кешеләр кабинетында кунарлык абруйлы булуына, фрунттан да, сүзе үтеп, тиз әйләнеп кайтуына өметләнүдән шулай шатлангандыр.

Китүләре тиз булса да, кайтучылары күренмәгән чак иде. Көн дә булмаса да, бик еш «хәбәрсез югалды» яисә «батырларча һәлак булды» дигән «извещениеләр» килә. Кулына мылтык тотарлык ир-атлар алынып беткән. Сабан туйлары узуга, Шәрифҗан абый белән Мөгътәбәр абыйны да алдылар.

Авыл тынып, бушап калды. «Хаты килмәгәнме?» дип сорарга җиңгәчәй янына көн дә барам, тик аның елавыннан башка җавабы юк иде.

Беркөнне ул үзе безгә килде. Ниһаять, кулында өчпочмаклы солдат хаты. «Алкино» дигән лагерьда какладылар, инде озаталар, дигән. «Какладылар» сүзе бозылган булса да, җиңгәчәй аны танып укыды. Әнкәй, шул бозылган сүз турында ишеткәч, җиңгине гаепли башлады:

– Күзенә трахум, тәненә корчаңгы йоктырасың калган. Сезгә шул чибәрлек кирәк. Менә утыр инде хәзер бозылмаган «извещение» көтеп.

– Тәүбә, диң, әнкәй.

– Ичмасам, үзеңнең әнкә булуыңа оеткы салынмаган, бик җиңелдән җилфердисең...

– Минем гаебем юк. Ул үзе: «Әткәй дә булмагач, әнкәйнең үз хәле хәл, ялгызыңа ятим бала үстерү авыр булыр», – дип, үзе мине саклады.

– Нигә әле син хаты килгән тере кешегә ясин чыгып, «ятим бала», дисең?

Мин аны Вәсил белән Вәдимне күздә тотып әйткәндер дип аңладым.

– Ятим бала асрасаң – авызың-борының кан булыр, әмма ләкин – ятим бозау асрасаң, өстәлеңдә май булыр, диләр. Оныт шул детдомныкыларны. Бәлки әле... калгансыңдыр? Беренче бала үзенең барлыгын бик сак сиздерә ул.

– Юклыгын сиздергән хәбәрләр булмаса, көтәр идем, инде икенче хәбәр килерлек вакыт узып бара. Исән-имин әйләнеп кайтуын көтәбез.

Әнкәй белән җиңгәчәйнең бу сөйләшүләре, миннән яшермичә, ачыктан-ачык булганлыктан, мин дә аны хәтеремдә саклангача язам.

...Сүзне озынайту яки кыскарту безнең ихтыярда булса да, гомерләр башка зат ихтыярында. Яхшы хәбәрләрне озак көтеп алсаң, яман хәбәр көттермичә, көтмәгәндә килә. Абыйдан хат килүне көтеп көтек булган көннәрне язып тормыйм. Алар бер-берләренә охшаш озыннар да, моңсулар да. 1 сентябрь узып, укулар башланган беркөнне өченче класс укучысы Әдһәм миңа пичәтле конверт сузды:

– Мә, укы!

– Мин әле укырга өйрәнәм генә ич.

– Алайса укыма, өйрәнгәч укырсың. Мондый конвертта урысча извещение генә була.

Җиңгәчәй детдомда кунып эшли иде ул чак. Ул кайтканчы ятсын, дип, конвертны матчага кыстырдым. Борчылыр, дип, әнкәйгә әйтмәдем. Ләкин Әдһәм миннән өлгеррәк булган, кемне очратсам шул: «Извещение килдемени?» дип сорый. Икенче көнне мәктәптән кайтуыма елый-елый шешенеп беткән әнкәй миңа ташлана:

– Үлемне яшереп буламыни? – ди.

Шул ук кичне, Вәсил белән Вәдимне җитәкләп, җиңгәчәй детдомнан кайтты. Аңа да хәбәрне ишеттергәннәр иде, чөнки Әдһәмнең җиңгәсе Гыйльмениса почтада эшли. Почтага хәбәрнең үз вакытында, үз кешесенә ирешүе кирәк – әйткәннәр, җиткергәннәр. Җиңгәчәй, конвертны кулына алгач, бер сүз әйтми күкрәгенә кысты да, билгесез ераклыктагы абыйга дәшкәндәй: «Сүзеңне тыңлап, сүземдә торып, Вәсилне үз исемемә оформить иттерәм. Тыныч ят, мин аны синең безгә калдырган бүләгең буларак тәрбияләп үстерермен».

– Бүләкне үстереп буламы, аны бары тик саклыйлар гына... – диде әнкәй, инде елаудан туктап.

– Бергәләп сакларбыз, – диде җиңгәчәй җавабында.

Безнең авыл клубында, үлү хәбәре килгәч, абыйга багышланган җеназа намазы укылу – моңа кадәр булган хәл түгел, хәтта ишетелмәгән дә бер эш иде.

Аннары, Вәсил белән Вәдим, эвакуацияләнеп килгән Белоруссия

гражданнары булганлыктан, ниндидер закон буенча, детдом мәктәбендә русча гына укырга тиешле булсалар да, һәр икесе дә башлангыч классларда Мәнәвезтамак мәктәбендә укып, бишенче класстан гына детдомга йөреп укыдылар. Бусы бер, икенчесе – Кәшифә җиңгәчәй детдомда да эшләде, бәрәңге җирен үзендә саклар өчен, колхоз эшеннән дә баш тартмады.

Ике малайның икесе дә, «милләтең кем?» дип сораганда, «татар» дигән җавапларына авылдашлар гаҗәпләнми иде. Чөнки, алар, чыннан да, Белоруссиядә яшәүче төрки телле караимнәрдән булып, диннәре дә иудаизмның кайсыдыр безгә якын бер төре икәнен сугышта аягын өздереп кайткан Әфкат абый аңлаткач, әнкәй өчен алар, дога өйрәнеп, иманлы булырга йөрүче иң ушлы мөселман шәкертләр иде.

Шуларга өстәп, малайларның әнисе Зәнәбирә апа мөселман зиратына, ислам дине кануннары кушканча җирләнгән. Каберенә гарәп хәрефләре белән дога сүзләре язылып, ай сурәтле мәрмәр таш куелган булу, матур чардуганның буявын һәр ел яңартып, чистартып торулар барсы да караимнәрнең үз булуын раслый иде. Бу изге эшләр детдом ябылып, андагы тәрбияләнүчеләргә һәм тәрбиячеләргә туган илләренә кайтырга рәсми рөхсәт ителгәнгә кадәр дәвам итә.

Вәсил дә, Вәдим дә табынга утырганчы кул юарга, ашагач «амин» тотарга өйрәнгәч, аларны миңа үрнәк итеп күрсәтәләр иде. Миңа гына түгел, алар авылдагы барлык үсмерләр өчен үрнәк булгандыр. Догалар укый белүдә генә түгел, ә, гомумән, укуда – мәктәп фәннәрен үзләштерүдә дә. Чөнки детдомда мәктәп укытучыларының күбесе Бөре, Уфа (Өфе), Стәрлетамак техникумнарыннан монда күчеп эшләргә мәҗбүр ителгән репрессия корбаннары. Әлбәттә, без бу хәлләр турында бик соң белдек. Алдан яки, үз вакытында белсәк тә, ул чак детдом тормышына бернинди үзгәреш кертә алмаган булыр идек. Детдом укытучылары һәм анда тәрбияләнүчеләр үзләре безнең авыл халкы тормышына тәрәккыять, яшәүдә үзгәреш кертүчеләр булганлыгын әле һаман сагынып хәтерләүчеләр бар.

Безнең авыл зиратына элек чардуган куючы да, гранит яисә мәрмәр һәйкәл кую да булмаган. Беренче һәйкәл Вәсил белән Вәдимнең әнисе Зәнәбирә апага куелган; аннан соң детдомда чирләп мәрхүм булган сабыйларга куела. Зиратны чистартып тору, чәчәкләр, куак агачлары утырту йоласын да детдомчылар башлап калдырган.

...Вәсил, миннән ике касска түбән укыса да, математика, физика, химия фәннәреннән мәсьәләләр чишәргә ярдәм итә; Вәдим, миннән ике яшькә өлкәнрәк булганлыктан, һәр эштә остазым кебек. Пособие алабыз дип тормады ул, безнең белән бергә кәлҗемә дә казыды, сөяк җыеп тапшыруда да катнашты, колхоз эшенә дә йөрде. Кәшифә җиңгәчәйгә иптәш булып, колхоз сушилкасына икмәк киптерергә йөрүе хәтердә.

Безнең әнкәйне сушилка мичено ягарга салам көлтәсе бәйләргә куйдылар. Бер кичне бу эштә ярдәм итешергә мин дә әнкәйгә иярдем. Бераз эшләгәч, ул миңа сушилка эченә керергә рөхсәт ите. Янәсе, «туйганчы борчак ашарсың!»

«Сушилка» дигән корылма ул өй зурлыгындагы мичнең мич башы. Бу исә сушилканың идәне булып, анда киптерелергә тиешле ашлык салына. Кизү торырга килүчеләр шул ашлыкны болгатып, җилләтеп торырга, киптерергә тиешләр. Мин туйганчы куырган борчак ашарга дип керсәм – Вәдим дә, Кәшифә җиңгәчәй дә анадан тума ялангачлар. Сушилка эче мунчадагы кебек парлы, эссе. Кердем дә, бу хәлләрне күреп, өнсез калдым. Алга да, артка да

адым ясый алмыйм. Вәдим миңа: «Чишен, тирләрсең!» – дип кычкыра, Кәшифә җиңгәчәй, берни булмагандай, аягы белән борчак болгата. Аның моңа кадәр мин күрмәгән кавын кебек күкрәкләре, җиңгәчәйнең гәүдә хәрәкәтләре саен, йә уң якка, йә сул якка күчкәнгә, аларны ул турылап, «бастырып» куярга тырыша, үзе шыбыр су булып тирләгән... ...Хәрәкәтсез басып торган миңа ул чакта җиде-сигез яшь булса, Вәдимгә ун-унбер яшьләр булгандыр. ...Әнкәй кереп алганчы, мин баскан урынымнан кузгалмадым. Сушилкага бүтән менмәдем, борчак ашарга кермәдем. Хәзергәчә борчак яратмыйм. Вәдим язга кадәр көн аралаш шунда булды, ә Вәсил исә минем янда куна башлады. Әнкәй шулай хәл итте. «Абыең рәнҗеп ятмасын, бар, Вәсилне аш суынганчы алып кайт!» – дип аңа җибәрә иде. Хәер, Вәсилне чакырасы да юк, детдомнан туры безгә кайтырга тиз күнекте ул. Үз булып китте. Вәдимне дә чит итмәдек – җиңгәчәйгә ярдәм итә, эшчән егет. Хурлау, кимсетү сүзләре ишетелгәндә дә, әнкәй аларны «көнләшүдән, гайбәт», дип уздыра иде.

Тугызынчы, унынчыларда укыганда, Вәдим күбрәк детдомда кунып кала. Авылда – шимбә, якшәмбе көннәрендә кичләрен клубта – гитарасында уйнап, бии белгәннәрне биетә, җырлый белгәннәрне җырлата, кемнәрнедер елата иде. Авылдашларны шатландырып, күбрәк борынгы татар көйләрен уйный. Бу нинди көй, дип сорасалар, Әүдах абый репертуарыннан дигән җавап була. Шундый «бичерләрдәге» сөйләшүләрне ишетеп, әнкәй бик куана, коймакмы, пәрәмәчме пешереп, Вәдимне чәйгә чакырырга мине җибәрә. Шул рәвешле аралашулар Вәдим өлгергәнлек аттестаты алып, Өфөгә укырга киткәнче дәвам итте. «Авиационныйга кердем», – диде ул, соңгы килүендә. Медальгә бетергәнлектән, институтка имтихансыз гына үткән икән. Общежитиедән дә урын алган. Моңа җиңгәчәй дә, мин дә, әнкәй дә бик шатлансак та, шатлык озакка бармый – малайларын алырга дип, Вәсил белән Вәдимнең әтиләре килеп төшә. «Кайтып төшә», дип яза алмыйм.

Аның килүе көтелмәгәнлектән түгел, гаугалы, судлашулы көннәр белән хәтердә калган. Иң элек ул хатынының каберенә барып, аның исеме «Зәнәбирә түгел, Зинаида», дип, исемне алыштыруны таләп итә, аннары ислам дине догаларын җуйдырып, үз диннәре догаларын яздыруны, ай урынына алты җәпле йолдыз куюны шарт итеп куя. Ул чактагы авыл советы рәисе Тимерҗан абзый, «уйларбыз», дип, киңәшкә авыл картларын чакырта, картлар «малайлары шулай теләде», дип, үзгәртүләргә ризалашмыйлар. Ата кеше мәсьәләгә икенче яклап килә: «Сез аңа медицина ярдәме күрсәтми үтергәнсез, ветеринария врачын урман кисәргә җибәреп, салкын тидергәнсез, судка бирәм», – ди. Булганин белән танышлыгын корал итеп кизәнә. Бу сөйләшүләрнең шаһиты булган дежур Хәерниса әби әйтүенчә, Вәдим белән Вәсил аталарының шулай холыксызлануларына хурланып, силсәвиттән чыгып китәләр. Бер атна аларны таба алмый эзләгәч, ата кеше, районга барып, милиция, Өфөдән юрист белән следователь чакыртып китерә. Эш зурга китә. Дулкыннары Мәскәүгә барып җитә. Ата кеше Норильскида хаксызга утырып акланган полковник булганлыктан, сүзне белеп сөйли, эшне законга таянып эшләтә. Нәтиҗәдә, малайларының үз исемнәре «кайтарыла», җиңгәчәй эшләткән документлар «подделка» дип табыла, яндырыла. Детдом директоры белән Тимерҗан абыйга шелтә бирелә.

Вәсил – Василий Игнатович Крот, Вәдим – Владлин Игнатович Кротка әверелеп, әтиләре Игнатий Сергеевич белән Белоруссиягә китәргә тиеш булалар. Җиңгәчәйнең үтенече буенча, детдом директоры Стяшкин Игнатий

Сергеевичтан, укуларын тәмамлаганчы, малайларның детдом җилкәсендә (балансында) калуларын сораса да, сигез ел гаепсезгә утырып чыккан сагышлы полковникның җавабы әзер: «Минем үз балансым!» – ди ул.

Китеп күпмедер вакыт узуга (һичшиксез, үз кешегә әверелеп, туганлашкан Вәсил-Вәдим үтенече белән язылгандыр дип уйларлык), серле хат килә, авыл советы адресына: «Күрсәткән яхшылыкларыгыз өчен рәхмәт, яманлыкларыгызны кичерәбез. Олы улым Владлин – Мәскәүнең Бауман училищесына, ә Василий Губкин институтына урнаштылар. Хәбәрләшеп торуга вәгъдә итә алмыйбыз, үз көннәрен үзләре күрә башлагач, үзләре карарлар.

Офицер сәламе белән, Игнатий Крот.

1953 елның 13 сентябре».

Шушы кыска хатның озын эчтәлеге белән силсәвиттә танышкач, җиңгәчәйнең йөзен күргән Хәерниса әби әнкәйгә нидер сөйләгәч, аның соңгы сүзләреннән мин җиңгәчәйгә нәрсәдер булуын аңладым: «Озак йөрмәс, йөзендә кан, күзендә нур юк», – диде дежур әби.

## Гитарист бүләге

Җиңгәчәм Кәшифә апа «кош теле хәтле» хат-хәбәрдән соң күзгә күренеп үзгәрде. Кинәт детдомдагы эшен ташлады, кешегә күренми, өендә генә ята башлады, паспорт алды. Ә беркөнне аның, тәрәзәләрен такта белән каплап, ишеген бикләп, Свердловск өлкәсендә торф чыгару эшендәге агаларына китүе турында хәбәр таралды. Һәрнәрсәне белеп, ишетеп, күреп яшәгән күршеләр бу ашыгыч югалуының чын сәбәбен сизенсәләр дә, аны кычкырып әйтергә кыймыйлар. Әмма серле тынлык озакка сузылмый: һәр авылдашының хәленә кереп, серләрен уртаклашып яшәүче дежур Хәерниса әбигә җиңгәчәйдән хат килә. Хатында ул кияүгә чыгуын, балага узуын, бәбәй көтүен белдерә. Хатны аңларга тырышып, авылда төрле «риваять»ләр тыңлап күпме вакыт узгандыр, каз өмәләре чорында, улын күтәреп, җиңгәчәй үзе кайтып төшә. Кемгә дисезме, безгә! Китүенә биш ай да тулмаганда! Әнкәй бу хәлдән бик тә кыенсынып хурланса да, сүз әйтүен ишетмәдем. Миңа гына җиңгәчәйне «җиңгәчәй», димәскә, «Кәшифә апа», дияргә боерды, «оятсыз, ул», диде. Шунысы гаҗәп дия иде әнкәй: бу хәлгә күршеләрдән беркемнең дә гаҗәпләнмәве гаҗәп. Әйтерсең лә шулай булырга тиеш һәм шулай булган. Малай башта исемсез һәм фамилиясез үсә. Күпмедер вакыттан соң гына атасыз туган балага пособиесен алыр өчен, аңа Кадерҗан дигән исем кушып, отчествосына моннан ун еллар элек үлгән абыем исемен – «Әүдах улы» дип язалар. Моны ишеткәч, әнкәй түзми, уйнаштан туган балага изге җан улым исемен кушуыңа ризалыгым юк, ди, Гомәр кодаларга барып. Кәшифә апа, шуны белүгә, улын күтәреп, бездән үз өенә кайтып китә.

Шулай күпме вакыт узгандыр, мин укырга кереп, каникулларга чыккач, әнкәй Кәшифә ападан абыйның думбрасын алып кайтырга җибәрде.

– Җилдән туган баласыннан минем улым истәлеген ваттырмасын, – диде.

Бардым. Кадерҗан инде, кашык тотып, үзе ашый башлаган, сораганга җавабы да була иде.

– Бу кемнеке? – дидем мин, гитарага күрсәтеп.

Кадерҗан, дивардагы абый фотосына күрсәтеп: «Абба», – диде дә гитарага үрелде, аның кылын чиртеп, елмайгандай итте. Шушы хәрәкәтләре

коралсызландыргач, мин, ирексездән, буш кул белән кайтып китәргә мәҗбүр булдым. Ул бала гитарада уйный башлаган, аны рәхәттән мәхрүм итәсем килмәде, дидем әнкәйгә. Икенче бер кайтуыма, Кәшифә апаның, Кадерҗанны имидән аерып, кодаларда, ягъни Гомәр бабайларда калдырып, читкә китүен әйттеләр. Шулай итеп, дөнья мәшәкатьләре безне җинде, минем үз хыялларым, үз өметләрем үз юлына тартты, Кадерҗан-Кәшифә тормышына түгел, үз тормышыма да күз-кул җитми башлады. Укуымны бетергәнче үк өйләнеп, үз балаларымны карарга да вакыт һәм акча җитмәү сәбәпле, һөнәремне алыштырырга туры килде. Яңа эш мине тәмам үзенә суырды, авылга кайтулар бетте, трудәрмиядән чирләп кайткан әткәйне, күпме йөрсә дә, дәвалый алмадылар, мәрхүм булды.

Йомышларым белән Мәдәният институтына баргач, очраклы рәвештә Кадерҗан белән күрештем.

– Мин бит хәзер эшлим, заочныйга күчтем. Театр оркестрында гитаристмын. Рольләр дә биргәлиләр. Мин бит дипломлы артист та, музыкант та. Менә, үзем кыллы инструментлар оркестры оештырып йөрим әле, – ди Кадерҗан. – Мин Мәнәвезтамакка кайтканда гел сине сүгәләр. «Авылны бетерделәр, председательне кинога төшерергә дип кайта, ә күлләр коруын да, Агыйдел бетүен дә күрми. Шул кешене режиссёр дип буламы, – диләр.

– Сине дә мактамыйлар. Актаныш районына командировкага баргач, үзебезнең авылны да күреп кайтырга булдым. Хуҗалар алышынган булса да, хуҗасызлык шул ук калган. Синнән «исемен алыштырган, һөнәре шул ук думбра чиртү», дип көләләр.

– Бик хаклы көләләр. Кадерем булмаганда, «Кадерҗан» булып йөрү көлке тоелганлыктан, дөрестән дә исемемне «Камил»гә алыштырдым. Әмма ләкин исем алыштырып кына камиллеккә ирешеп булмый икән.

Бу очраклы күрешүдән соң миндә төрле хыяллар чишмәсе «бәреп чыкты». Шуларның берсен эләктереп, хуҗабызга кердем, табигатьне саклау һәм экологияне байрак итеп, Башкортстандагы авылыбыз базасында документаль-нәфис фильм төшерү тәкъдиме ясадым. Хуҗабыз, бернинди каршылыксыз, тиешле барлык документларга кул куеп, Өфө шәһәрендәге танышлары аша аларның телевидениесе белән газеталарын да эшкә җикте. Бу инде миңа оештыруда зур ярдәм иде. Озакка сузмый гына, план төзеп, сценарий язарга утырдым.

Барысын да исәпләп, санап чыккач, экспедициядә концерт кую мөмкинлеге дә ачыкланды. Тик сметага кул куелса да, анда концерт группасы аерым күрсәтелмәгәч, мин Камилгә мөрәҗәгать итәргә булдым. Эстрада артистлары арасында танышлары күптер дигән өмет белән эзләп киттем аны. Ял вакытлары иде. Үтенечемне аңлаттым. Ул ризалашып кына калмады, үз группасының чыгымнарын үз театры күтәрәчәгенә дә ышандырды, бәлки әле «левый» концертлар да оештырырбыз, диде. Баксаң-күрсәң, «Кыллы квартет» төзеп, алар үзләрен-үзләре тәэмин итеп яшәүгә күчкәннәр икән. Камилнең яшь балалы хатынына да вазифа таптык. Ул концертта биюче буларак катнаша, экспедициянең пресс-секретаре да булачак. Без әзерләнгән арада Башкортстан дуслары бездән өлгеррәк булып, кино төшерергә килүебез турында газетада русча да, башкортча да язып чыгалар. Телевизион тапшыруга Өфөгә мине дә чакыралар. Мин музыкантым белән киләм, дидем. Бардык, күрдек, сөйләдек.

Шул эшләр белән йөреп, расписаниебездән бераз соңласак та, афишалар әзер булуга, экспедициягә киттек. Җәмгыбыз – ундүрт сәнгатькәр. Безне, колхоз

идарәсе, элек детдом булган урындагы бердәнбер сакланган кунак йортына урнаштырып, ашханәсенә ризык әзерләүче билгеләде, эшкә йөрергә трантаска җигелгән ат бирде. Бу хәтле үк комфорт көтмәсәк тә, шулай булырга тиеш дигән тәэсир калдырырга тырыштык. Съёмкалар башланганчы, урыннарны карап, кайда ничек төшерү мәсьәләләрен хәл иттек. Камил бригадасы концерт программасын эшләде.

Беренче концертны җомга киченә билгеләделәр. Интервьюлар алу өчен, кешеләрне чакыртып, мин сөйләштем. Сөйләргә теләүчеләр күп икән. Ләкин һәркайсының сүзе нефтьчеләрнең авылны, табигатьне бозуларына барып терәлә. Колхоз рәисенең тәкъдиме белән, берәү күлләрнең коруы турында сөйләсә; икенче «оратор» Агыйделнең бетүе, пароход тавышларын сагынуы турында; хатын-кызлардан ике җиңги чишмәләрнең бозылуы, аларның хәзерге суы чәйгә ярамавы турында «зарланырга» тиеш, дип килештек. Тәнәфестән соң, икенче бүлек алдыннан, колхоз рәисе нефтьчеләргә «ультиматум» куярга тиеш: «Колхоз җирләреннән суыртып чыгарылган нефть өчен, керемнең һичюгы 30%ын колхоз кассасына!» Моңа рәис ризалашмый, «бозылган болыннар өчен нефтьчеләр түләде һәм һаман түлиләр, качалкаларын гына сүтеп алсыннар, 30% лы түләү таләбен мин түгел, әнә 83 яшьлек Әгъзам абзый әйтергә тиеш», – ди. Әгъзам бабай исә: «Миңа качалкаларның зыяны юк», – ди.

Уртак фикергә килә алмыйча, концерт көнен көтәргә булалар. Янәсе, ситуациягә карарбыз! Ә ситуация бөтенләй көтелмәгән «концерт» күрсәтә: республиканың русча газетасында, Агыйдел бетүдә Иштуган сусаклагычының гаебен исбатлап, мәкалә басылып чыга. Шул мәкаләнең татарчасын район газетасында да бастырып чыгаралар. Бу хәбәрләр Мәскәүгә дә ишетелеп, үзәк телевидениедә Иштуганнан репортаж бирәләр: табигать бозылуга, Агыйдел саегуга, күлләр коруга нефтьчеләр түгел – сусаклагыч гаепле. Дәүләт 500 миллион сум акчалата зыян күрә. 6000 гектар сөрүлек җир, шуның кадәрле үк көтүлек болыннар, урманнар югала. Урманнар белән бергә, вак елгалар, инешләр, чишмәләр, җәнлекләр югалуы, кешеләрдәге нәфис хисләр, тойгылар тупаслануы турында уйласак, «сусаклагыч» исеме астындагы афәт, табигый, биологик нигездә яшәүнең технологик нигездә яшәүгә күчү икәнен күрербез. Бу – кешенең үзенә-үзе кабер казуына тиң».

Авылдашлар, берсе икенчесенә әйтеп, икенчесе өченчесенә берне биш итеп сөйләүдән безнең кино төшерү «әрмиясенә» ышаныч кимесә дә, концертка кеше күп килгән иде. Интервью бирүчеләрнең сүзләрендә өметсезлек, кешегә ышанмау сизелә. Дежур Хәерниса әбинең: «Безгә Агыйдел саегу да, әллә кайдагы урманнар кырылып, елгалар коруы да куркыныч түгел, ә менә авылыбыздагы шифалы «Күз чишмәсе»нең суы бетеп, «Зирек чишмәсе»нең эчәргә ярамас тозлыга әверелүен белә торып бөлү, агулану әкренләп үлү, дип сөйләве клуб тулы халыкны уятып җибәрде. Хәерниса әбинең сүзләрен хупламаган кеше калмагандыр. Без, әлбәттә, барсын да тасмага төшереп, тавышларны яздырып бардык. Концерттан соң Камил Әүдаховичның абруе бермә-бер күтәрелеп, исеме бөтен районга яңгырады. Талант, диделәр. Район җитәкчеләре тәкъдиме белән, аның «Кыллы квартеты» биш колхозда «гарантийный концерт» куярга ризалашты. Ә без исә Мәнәвезтамак клубында саубуллашу концертына кадәр планлы эшебезне дәвам иттек. Теләгәннәрне диктофонга яздырып, бозылган табигатьне, тагы да «бозыбрак», киногa төшердек.

...Һәммәбез әйтелгән вакытына килсә дә, рәис агай сүз башламый утырды.

Башка чакта сүз алдыннан чәй тәкъдим итсә, бүген ул көтмәгәндә тәмәке кабызды, безгә дә тәкъдим итте. Тәмәкесез дә һәркайсыбыздан гаҗәпсенү, шикләнү төтене чыкканлыктан, рәхмәт әйтеп, көтеп утырабыз.

Бераздан ул, кулына газета алып: «Укыдыгызмы?» – диде.

Беребез дә укымаган иде.

– Мәкаләнең исеменә игътибар итегез: «Иштуган кемгә иш тә, туган да түгел?» дигән сорау куелып, шунда ук җавабы да язылa. Тыңлагыз: «Иштуган татар артистларына иш тә, туган да түгел. Алар өчен безнең хөкүмәт планы буенча төзелешебез халык ризалыгыннан тыш төзелеп ятучы башбаштаклык, афёра, партизанщина икән...» Дальше, «Түбән Каманы бугач күтәрелеп, болыннарга зыян килмәсен өчен өйдерелгән дамбалар язгы ташу вакытында су җәелүне туктатса да, халыктагы ялгыш уйларны туктата алмый. Халык бу эштә Иштуган төзелешен гаепли. Шул фикерне Татарстан сәнгатькәрләре куәтләп, махсус фильм төшерәләр, авылдан авылга йөреп, корыган күлләргә, тозлы чишмәләргә җеназа укыйлар».

Дәвам итимме?

– Аңлашылды, – диде Камил. Безгә хушлашу концертында бу мәкаләгә генә түгел, мондый фикернең яшәвен туктатырлык җавап бирергә кирәк.

– Газетада хаклык та бар ич, энем.

– Табигатьнең үзгәрүе, экологиянең бозылуы – исбатлауны сорый! Безнең миссия хөкем карары чыгаруда түгел, ә... гаепләне күрсәтү.

– Мәкалә авторы прогрессны, энергетикларны гаепләп, Татарстанга таш ыргыта.

– Ни дигән сүз бу?

– Хушлашу концерты булмаячак, дигән сүз.

## Катнаш йорт

Концертлар өчен колхозлар белән исәп-хисапны түгәрәкләмичә, безнең китмәячәкне аңлап, рәис безгә китү өчен соңгы көнне билгеләмәде. Элеккечә яши бирдек. Оператор Таһир, монтаж вакытында кирәге чыгар әле, дип, кадрларны сайласа, квартет музыкантлары исә репертуарларын шомартты. Ә мин, эткәй үлгәч, кул тимәгән каралты-кураларны караштырырга булдым. Чөнки авылга тиз генә кайтып булмаячагы сизелә иде. Шулай, балта тотып ишегалдында селкенгәндә, капка төбенә председатель «УАЗ»игы килеп туктады. Кабинада шофёр Хәтифтән тыш, хатыны белән Камил, оператор Таһир утыра иде.

– Нигә кермисез? – дигәнемне сизми дә калдым.

– Председатель көтә. Төшерелгән барлык видеоматериалларны алып килергә кушкан.

– Проявлять ителмәгәнне белә ич ул. Нигә кирәк икән?

– Нигә кирәк булуын әйтмәгән, тизрәк килсеннәр, дигән. Әйдә, утыр, «очтык кансага чатыр-чотыр».

Канцеляриягә барып җиткәндә, идарә каршына обком машиналарындагыча «02» номерлы «Волга» килеп туктады. Аннан күзлекле, күн дипломатлы, куртка кигән адәм чыкты да, болдырда көтеп торган рәис белән күрешкәч, эчкә узды. Рәис, кереп барышлый борылып, кулы белән генә ымлап, ашыгып кермәскә боерды. Ничә минут утырганбыздыр, безне чакырырга чыккан рәиснең кызарып бүртенгән йөзеннән мунча кергәндәге хәтле вакыт

узгандыр кебек тоелды. Кабинетка кергәч, рәис күннән киенгән адәмгә күрсәтеп:

– Таныш булыгыз – корылтай депутаты, президент аппаратының сәнгать эшләре инспекторы – Абрам Ильич Букштейн.

Инспектор, урыныннан тормый гына, кулын күтәреп исәнләште дә:

– Егетләрнең кем булуын әйттеләр, ә менә бу чибәр ханымның вазифасын әйтмәделәр.

– Безнең пресс-секретарь. Квартетның атказанган биючесе, – дидем мин.

– Иң мөһиме – минем хатын, – дип өстәде Камил, көлемсерәп.

– Котлыйм сезне, – диде дә Абрам Ильич, ни өчендер дипломатын ачып карады: – Сезнең белән кайсы телдә сөйләшү уңай булыр? – диде ул бераздан, русчалап.

– Үзебезчә инде – татарча.

– Сез бит безнең республиканың кунаклары. Кунак – хуҗалар телендә сөйләргә тиеш. Ягъни, «Кунак хуҗаның ишәге».

– Без кайсы телдә дә аңлаша алабыз. Кешечә сөйләшү булса.

– Ышанам: әйтсәгезче кешечә! Эшләрегез ничек бара?

– Планлаштырганнары бетте, дияргә була. Монтаж вакытында кирәге чыгардай кадрларны гына төшерәсе бар.

– Эшегез монтажга җиткәнче тукталса?

– Эш планында каралганны үтәми калган юк.

– Юк икән – булыр, дисәм?

– Сез безнең республика түрәләре кебек сөйләшәсез. Хуҗаларча!

– Вәкаләтем шундый.

– Эшкә аяк чалумы? – диде Камил.

Хатыны аның аягына басып, сүзеннән туктатты да Абрам Ильичка үзе сорау бирде:

– Хөрмәтле инспектор әфәнде, кинаяле сүзләрдән максатыгызны аңлатырлык сөйләшүгә күчә алмассызмы?

– Безнең максат – сезнең максатны белеп, башкарып чыгара алмастай эшегездән коткару...

– Аңлашылмый, – дидем мин.

– Аңлашыр өчен әүвәл мин сезнең смета белән танышыр идем.

– Сметада барлык реаль чыгымнарны күрсәтү мөмкин түгел. Эш барышында үзгәрешләр күп керә. Менә карагыз... Кул куелган...

...Абрам Ильич, сметаны алгач, тәрәзә яктысынарак барып, блокнотына нидер язды да:

– Әгәр мин сезгә сметада күрсәтелгән суммадан өч мәртәбә артыграк хак биреп, тасмага төшерелгән һәм диктофонга язылган материалларыгызны миңа бирәсез дисәм – ни диярсез?

– Монтажланмаган черновой материал белән сез нишли аласыз? – диде оператор Таһир.

– Эшли белүчеләр табарбыз.

– Анда безнең исем-фамилия сакланырмы?

– Шартнамәдә андый статья каралмаган.

– Тагын нинди статьялар юклыгын белергә рөхсәтме?

– Мәгез – укыгыз, танышыгыз.

...Әзерләнгән шартнамәдә «Иштуган сусаклагычы турында фильм төшерүдән дә, газеталарга язудан да, телевизион тапшырулар күрсәтүдән дә баш тартып, тәкъдим ителгән шартларга ризалашабыз», – дигән сүзләр иде.

– Минем комитет исеменнән кул кую вәкаләтем юк бит.

– Комитет белән комитет үзара аңлашырлар. Син үз группаң исеменнән генә сөйләшәсең һәм, нигездә, үз хезмәтегез өчен хак аласың. Әлбәттә, тасма хаклары, техника амортизациясе өчен түләүләр, бухгалтериягез белән исәп-хисап сезнең өстә кала.

– Шуннан?

– ...Шуларның барсын күздә тотып, без сезгә сметада каралган суммагыздан өч тапкыр күбрәк хак бирәбез.

– Моңа ризалашу идеалларыбызга хыянәт итү булыр иде.

– «Халтурабыздан баш тартуга ризалашу», дисәгез – дөресрәк түгелме?

– Эшләнеп бетмәгән эшне «халтура» дип атавыгыз сезне бизәми, абый, сез бездән гафу үтенергә тиеш, – диде пресс дамабыз, һәммәбезне шатландырып.

– Урынсыз чагыштыруым өчен гафу үтенеп, җавап көтәм. Шартнамә кулыгызда.

– Тәкъдим ителгән сумманың реальлектән ерак булуы шикләндерә, – диде Камил.

– Уйлагыз. Вакытым тар булса да, ашыктырмыйм. Тагы шуны әйтергә тиешмен: сусаклагычның хәзерге дирекциясе сезгә үз бүләген дә җибәрәчәк. Ялгышмасам, машиналары юлда булырга тиеш.

– Эшләмәгән эш өчен Америка долларына өстәп машиналы бүләк алу хәрәм малга алданып, ил мәнфәгатьләренә хыянәт итү түгелме?

Таһир шунда «шыпырт» кына:

– Шпионаж? – диде.

«Күнле» инспектор Таһирның сүзен ишетепме, башка нәрсә уйлапмы, кабат рәис бүлмәсенә кереп китте. Таһир үзенекен үстерде: «Без төшергән бозык табигать күренешләрен Рәсәйнең һәр почмагында очратып була. Бу кеше кассеталарны Америкага сатып, Голливудта кино төшермәкчедер. Хакны арттыруын сорарга кирәк. Ун тапкыр!» Шуны гына көткәндәй, Абрам Ильич, рәис бүлмәсеннән чыкты да, долларларын өстәлгә җәеп салды, саный башлады. Ул санаганда, Таһир, тасмалар салган калай мичкәне («яуф») миңа тоттырды. Санаулар бетеп, күзгә карашып сынаулар узгач, Абрам Ильич, кочагына сыйган долларларын кысып, дивардагы зур фото астына басты да: бүләкләрне үз республикагызда табигать бозуларны фаш иткән фильмнар төшерергә аванс буларак кабул итсәгез дә ризабыз. Шартнамәдә күрсәтелмәгән, үзегезне фаш иткән фильмыгызның бер нөсхәсен безгә бүләк итсәгез, тугандаш милләт халкы сезгә мәңге рәхмәтле булыр. Бу минем генә сүз түгел, безнең лидерыбыз да шул фикердә.

Безнең эшне туктатырга махсус җибәрелгән күнле инспектор, кинәт дивардагы башкортка «честь» биреп, сәгатенә карады. Бездән бер сүз дә чыкмагач, ул: «Җир әйләнә, сәгать бара», – диде дә кабат рәис бүлмәсенә узды. Бу юлы долларлары өстәлдә таралып калды. Күрәсең, безне сынавы булгандыр. Таһир тагы «пырлады». «Уникаль бер кадр да юклыкны белә торып, кул куймавыгызга гаҗәпләнәм», – диде.

– Ә мин синең үз эшеңә «2»ле куюыңа гаҗәпләнәм, – диде пресс дамабыз.

– Ул бит иҗаттан баш тартуыбызны сорамый. Ялган патриотлар сез...

...Шунда мин шартнамәгә кул куеп, аны пресс дамабызга тапшырдым. Таһир, урамда көткән «Волга» шоферы ишетелерлек итеп, «Кул куелды!» дип кычкырды. Күн инспектор председатель бүлмәсеннән залга чыккач, долларларны кулына алып:

– Мин бу бүләкне группагызның фәрештәдәй затына тапшырып, дуслык дулкыннарында кабат очрашулар көтеп калам. Өлешегезне гадел бүлеп биреренә өметләнәм.

– «Өметсез шайтан», диләр. Минем хатынны фәрештәгә тиңләвегезгә рәхмәт. Анабыз Һава фәрештәдәй зат булса да, оҗмахта – гөнаһ кылучы. Бу долларлар безне гөнаһлы итмәсә иде инде.

– Сез бит оҗмахта түгел, энем.

– Сез биргән долларлар безгә дөнья оҗмахы ишекләрен ачтырсын, – диде пресс дамабыз, тапкырлыгын сүзендә раслап.

Күрсәтеп шатланмасак та, барыбыз да канәгать идек.

Абрам Ильич, яуфны алып, канцеляриядән чыгышлый, рәис белән хушлашкач, аңа нидер сөйләде дә, «Волга»сына утырып, район үзәгенә таба «очты». Рәис кул болгап калды. Котылуына шатлануданмы, куштанлануданмы – аңламадык. Икесе дә булгандыр.

Долларларны кире кереп алуыннан куркып, һаман тәрәзәдән карап торуыбызны күрде рәис.

– Сезгә эшләмәгән фильм өчен, дөресе – эшләтмәү өчен доллар белән гонорар түләделәр. ...Мине кисәтү белән генә калдырсалар ярар иде дә, эштән алулары ихтимал.

– Эшсез калу – эштән чыгу түгел, – диде Камил, үзенчә акыллы сүз әйткәндәй.

– Сезгә минем хәлдә калырга язмасын. Бу могҗиза – сәнгатьнең сәясәттән көчлерәк икәненә гыйбрәтле бер дәлил булса, ә менә бусы срочно кайтырга чакырган телеграмма. Комитет хуҗагыз имзасы белән.

Шиксез, бу телеграмма безнең яшәү рәвешен (яшәү ритмын) 180 градуска үзгәрткән документ иде.

Хезмәтләре өчен түләп, квартетны озаткач, ялгышуларыбызның кайда һәм нәрсәдә булуын белергә теләп, күпме уйлансак та, эшебездән хата-хилафлык таба алмадык.

## Аерылышу

Гәүһәр – Арсень «МАЗ»ында, Камил Хәтиф «полуторкасында» паромга юл тоттылар. Шуннан соңгы булганнар турында мин яңа өйне күрә алмый калган әнкәйне мәңгелек йортка озатырга кайткач кына ишеттем... Гөнаһлымын...

...Дөнья мәшәкатьләреннән арынып, эштәге интригалардан котылып булмау тоткарлады дияргә җыенмыйм. Барысы да булды. Җайлаштык һәммәсенә. Әнкәй килгәләсә дә, үземнең авылга кайта алмавымның сәбәпләрен дә, гамьсезлегемне дә акларлык түгел. Хәтиф сөйләгәннәргә өстәп, Кәшифә җиңгәчәй әйткәннәргә ышанганда, әнкәй мине актык сулышына кадәр кайтыр дип көткән.

Инде, читкә тайпылмаска тырышып, Хәтиф сөйләгәннәргә күчәм:

«Паромга кадәр юл әйбәт булды. Чулманны чыккач, начарланды гына түгел», бетте юл: урман арасы чокыр-чакыр, асфальт күрмәгән, тракторлар боздырган баткаклык.

Камилнең «юкка ризалаштым» дип үзен сүгүдән, хатынын гаепләүдән башка сүзе булмады. Паром чыгып, дүрт сәгатьлек алтмыш чакрым юлны күз алдына китерерсең. Ә менә Чыршылыга җитеп, ашханәдә тамак ялгап чыккач, булганнарны күз алдына китерү дә минем җенемне чыгара...

...Сайланып торырлык түгел – ни тәкъдим итсәләр, шуны ашагач, Арсень тәмәке тартам, дип, алданрак чыкты, Югары Калҗалыдан күчкән Гәүһәр, авылдаш хатыннары белән очрашып, гәпләшеп калды. Мин Камилнең буфетчыга акча түләгәнен көтеп тордым. Янәсе, «чит җир, ни булмас!»

Ашханәдән чыксак, минем «полуторка» янында өч-дүрт ир машина тәгәрмәчемә карап торалар иде.

– Тәгәрмәчең шартлаган ич, нәрсә көтәсең? – диде Арсень.

Төрле яктан киңәшләр башланды. Кемдер гараждан алмаш көпчәк сорауны хупласа, күпчелек «ямарга» дигән фикердә иде. Үзем дә ямау яклы идем.

– Күпме вакыт кирәк? – диде Камил, сәгатенә карап.

– Кимендә 45 минут.

– 45 минут көтеп торганчы, без барып, түбәсен булса да сүтә торабыз, – диде Гәүһәр.

– Шулай дөрес булыр, – диде Арсень.

Камилнең бу якларга кайтканы булган икән – «юлны беләм», дип, хатынын Арсеньга утыртып озатты да, почтаның кайдалыгын сорап, шунда китте. Ә мин, камераны сулы мичкәгә салып, тишеген эзләп калдым. Күпме маташсам да, тишек табылмады. Нипельне борып, тынын чыгарганнар иде. Тәҗрибәм булса да, башта ук шул нипельне тикшермәвемә хурланудан, моны беркемгә дә сиздермәдем; насосны алып, «тын кереттем» дә башка көпчәкләрне дә тикшердем. Маташа торгач, ярты сәгатьләп вакыт узган да булып чыкты. Камилне көтеп, ничә минут утырганмындыр, ул күренүгә, тиз-тиз моторны кабыздым.

Акча ваклатып йөргән икән.

– Йөк төяшергә анда кунып ятучы көтүчеләрне яллarбыз, – диде. Без кузгалып киткәндә, 45 минут вакыт узган иде. Урын юлдан турыга гына барырга булдык. «Тегеләр киткән болын юлыннан өч-дүрт чакрымга кыскарак», – диде Камил.

– Югары Калҗалы авылына Калҗалы елгасының күпере аша чыгарга кирәк булганлыктан, зур «МАЗ» машинасының күперне җимерүеннән куркып калдык. Шөкер, күпер исән, «МАЗ» теге якка чыккан иде инде. Тик аның күперне чыккач туктaлуы, Арсень белән Гәүһәрнең киемле килеш су керүләре генә гаҗәпләндерде. Судагыларга «Ни булды?» дип кычкырдым.

Арсень: «Күрмисеңмени? Буксуем! Комга утырдык!» – диде, машинасы астында аунап яткан чыбык-чабыкка күрсәтеп.

– Сез бит көнне комга утыртасыз! – диде Камил аңа, «синнән» «сезгә» күчеп.

Мин, тросны алып, «МАЗ»ны «полуторкага» тага башладым. Иң гаҗәбе шул: мин тарттырганчы ук «МАЗ» урыныннан купты. Камил аны сиздеме-юкмы, сорамадым да, әйтмәдем дә. Сүтеләсе йортка җитеп тукталдык. Өйне ничек сүтеп төяү турында сөйләү озакка китәр. Кыскасы, шушы авылда үсеп, Ижевскидан ялга кайткан ике егет очрап, безгә бик зур ярдәм күрсәттеләр. Үпкә дә белдерделәр:

– Аккош күле чокырында туктaлып торган чагыгызда никадәр кычкырсак та ишетмәдегез. Без бит Иж елгасының теге ягыннан чыгарга көймә көтә идек, сез ишетмәгәч, йөзеп чыгарга туры килде.

– Мотор кызган иде. Шуны суытырга туктaлган идек.

– Суыттыгызмы соң? – дип көлешү белән сүз бетте.

Бу сөйләшүне дә Камил ишеттеме-юкмы, белмим. Әмма йөзе кып-кызыл иде.

Эшне бетереп, көнендә кайтырга никадәр тырышсак та өлгермәдек. Көтүче Вакыйф абзыйның ташландык өендә төн кунарга туры килде.

...Кайту юлын бару юлыннан кыскарак та, шомарак та, диләр. Шулайдыр: унике сәгать килгән юлны җиде сәгатьтә кайтып, йөкне аударгач, Арсень йөгеннән бер бүрәнәнең төшеп калганы беленде. Ул турыда сүз куертмый гына рәхмәт әйтешеп, Кәшифә апа пешергән бәлеш белән «пирәшләгәч», тәнәфескә чыктык. Шунда мин Арсеньнан: «Бүрәнәгез төшеп калганны да сизмәслек сүзегез булдымыни?» – дип сорарга җөрьәт иттем.

– Сүз түгел – күз җитмәгән. Арттан килүчегә ышанылган, – диде Арсень, безгә төрттереп.

Ул хаклы иде. Гаебемне танысам да, Камилгә сиздермәдем. Ә менә аның әйткәннәрен сиңа әйтми кала алмыйм. Чөнки, ...чөнки ул рәнҗетте мине.

– Кем?

– Камил.

– Ничек?

Ашау әйбәт, хуҗалар юмарт, сүз күп – тәнәфес озакка сузылды...

...Икесе дә гарип туган кызларыбызны җитәкләп, мине чакырырга дип хатыным килгән иде. Балаларны кешегә күрсәтеп, кызганган сүзләр ишетмәс өчен, бик тиз генә кайтып та китте ул. Камил аптырап калды. Беренчедән, аның шундый гарип туган балаларны күргәне булмаган. Икенчедән, «каннарыгыз туры килмәгәнлекне белә торып, икенче бала табуыгыз гаҗәпләндерә», – диде ул миңа.

– Бездән рөхсәт белән тумый ич алар.

– Рөхсәтне син бирергә тиеш!

– Кемгә?

– Хатыныңа!

– Минем рөхсәтсез тапкан балабыз юк.

– Димәк, гарип балаларыңның башкадан туган булуы ихтималда юк?

– Ничек?

– Ничек булсын? Бер кичкә – кер мичкә, дип, «үтечкәгә» биреп торасың да икенче каннан сәламәт бала үстерәсең. Эт тә, бет тә белми. Икегезнең, юк – өчегезнең арада гына кала.

– Син үз инициативаң белән хатыныңны, чит бер егеткә биреп, урманга җибәргән кебекме?

...Шунда мин искәрми калдым: кулында нәрсә булгандыр – ул авызга сугып бер тешемне сындырды. Күрәсеңме – буш урын шуның истәлеге. Авызым тулы канны төкереп тормадым, Арсеньга утырып, үзебезгә кайттым. Ул бездә кунды. Шунда иң кәттә серен сөйләде.

– Гаҗәп тә серле кеше булган икән коллегаң.

Сернең гаҗәбе соңрак әле:

– ...Әрәмәлек юлларын узганда, тизлек рычагын тотып барган кулым, машина сикергәндә ычкынып, янымдагы ханымның тезенә төшә. Ул, минем кулымны алдыра, ләкин аягын кыймылдатмый. Минем кул һаман, машина сикергән саен, бот буйлап өскә шуыша, – дип дәвам итте ул монолог сөйләгәндәй. – Менә торгач, кулым «мамык күпергә» җитеп тукталды. Бармакларым кайнар «чишмәгә» юлыгып, коена башлауга, машина кабат тирән чокыр аша сикерде. Сикерүгә кинәт сүнде дә. Ә мин үземне-үзем тыя алмаслык хәлдә калдым. Шунда Ижның теге ягында көймә чыгаруны сорап кычкырдылар. Кирәк бит! Ул чак без инде үз көймәбездә тибрәлә идек.

– Ышанмыйм.

– Мин дә ышанмыйм. Әмма дөресе шул. Ушыма килеп, машинаны кабат кабызганда, үзем дә, аунаган утыргычым да кан гына... Тиз-тиз барып, күперне чыккач, суга ташландык. Калганын беләсең. Су кешене батыра да, коткара да икән. Хатын-кызлар кебек...

...Икенче көнне иртә белән иртүк Камил миннән теш өчен гафу үтенергә дип килгән. Арсень, документларына кул куйдырып, кайтып киткән иде инде.

Мин Камилгә: «Телемә күрә тешемә эләкте, үзем гаепле, гафу үтенмә, хатыныңны гаепләмә», – дигәч, без аерылыштык. Кич белән мин, янгын машиналарының Камилләр ягына баруын күреп, рәискә сораулы караш ташласам, ул: «Камил алып кайткан бурасына ут төрткән», – диде.

Шул кичне салынасы йортның бурасы түгел, ә минем Камилгә ышанычым, хөрмәтем, өметем янды. Минеке генә түгелдер, бөтен авыл халкы өчен көтелмәгән чир килү иде бу.

Камилнең эчүе шул дәрәҗәгә җитә, аңа «белая горячка» булган дип сөйлиләр, аның белән очрашудан качалар, Кәшифә апаны кызганалар. Күпме вакыт узгандыр, хатыны Гәүһәр, кызын алып, ташлап киткән икән, дип сөйләделәр.

Шул хәбәрдән соң Камилнең үлеп терелүе турында сүз таралды.

– Сүз генәдер шәт?

– Сүз үтерә дә, терелтә дә.

Хатыны ташлап киткәч, матчага кыстырып куелган хат конвертына: «Ашауның тәме, яшәүнең яме калмады», – дигән язу калдырып, урам коесына сикерә ул. Пинжәген кое чыгырына элеп, түфлиләрен бурага сөяп калдырырга ушы җитә. Иртә белән кое суына дип чыккан Зөлфирә, әүвәл чыгырдагы пинжәкне, аннары затлы түфлиләрнең кемнеке булуын белеп, гаҗәпләнсә дә, тиз генә чиләгенә су алып китмәкче була. Коега караса, анда кеше башы! Камилнеке! Зөлфирә авылны аякка бастырырлык тавыш белән кычкыруын сизми дә кала:

– Камил үлгән, Кәшифә Камиле!

Тавышны ишетеп җыелган халык арасыннан Гыйният абзый, кулындагы дилбегәсен тиз-тиз биленә бәйләтеп, үзен коега төшертә дә, Камилне кочаклап, өскә күтәртә. «Мәетне» җиргә сузып салып, Кәшифә апага әйтергә кемнедер чаптыралар. Кәшифә апа чыга, ә синең әниең – безнең иң кадерле Ак әбиебез, ишеткән хәбәрдән һушсыз калып егыла. Шуннан мантый алмый, дөнья куя. Урыны оҗмахта булсын...

Ә Камил җирдә «ах-ух» килеп бераз аунагач, күзләрен ачып: «Миңа ни булды? Мин кайда?» – дип сорый. Кемдер аңа «тәмугта», ди. Урам коесының суы тирән түгел – иякка кадәр генә икән... Халык Камилне «үлеп терелде» дип сөйләсә дә, рәисебез, нефтяниклардан таныш начальнигы белән сөйләшеп, аны мәҗбүри дәвалый торган профилакторийга озаттыра. Ак әбине Кәшифә апа безнең зиратта күмелгән Зәнәбирә апа кабере белән янәшә җирләтә. Үзең күрерсең. Шуннан соң күпме гомер узса да, Камилнең исәнлеге турында да, кайдалыгы турында да ишеткәнем булмады. Кызын «садикта икән, хатыны биеп йөри икән, Камил фатирында яши икән», дип, Казанга бал сатарга барган Рамил сөйләде. Малаен артистлыккамы, гитаристкамы укытмакчы булып, белгән кеше эзләп театрга барган икән, Камил эшләгән оркестр җитәкчесе – Бакиров фамилияле композитордан ишетүенчә, аны штаттан чыгарсалар да, күңелләрдән чыгарып ташлый алмаганнар. Башта ул «Туймазынефть»

карамагындагы профилакторийда дәваланган. Аннары, үзара килешеп, «Әлмәтнефть» санаториена күчергәннәр. Шунда ятып, ул пациентлардан ансамбль оештырган, эчүдән туктаган, бакчачы булып хезмәт хакы ала икән.

Кайсы мәгълүматлар хакыйкатькә якындыр – минем өчен ул атасыз үскән баланың имансызлыгына дәлил генә, – диде Хәтиф. Минем өчен дә ул онытылып барган хатирә генә иде. Мин аның турында «онытмадым», дип әйтә-яза алмыйм. Ул минем хәтердә дөньяга килүе дә, югалуы да серле булган, театр артистлары арасында еш очраган фаҗига каһарманы буларак яши иде. Режиссёр буларакмы, сценарист буларакмы – әсәр иҗат итәргә туры килсә, «запас персонажым» буларак, аның миңа зыяны юк иде.

Мөмкинлек булмауданмы, талант җитмәүдәнме, «запасыма» дөньяга чыгарга һаман чират җитмәде. Камилне күрмәвемә, аның оста гитарист булуын онытуыма күпме вакыт узгандыр, бердәнбер көнне эш телефоным шалтырады: «Беларусфильм»нан килгән режиссёр ассистенты шалтырата икән. Аларга Макаренконың «Педагогическая поэма»сы буенча төшерелгән фильмны «озвучивать» итәргә ике татар артисты кирәк икән. «Желательно, музыкант-актёр. Фильм многонациональный», – диде ассистент.

– Театрга мөрәҗәгать иттегезме?

– Ерак гастрольләргә киткәннәр. Бер айсыз кайтмаслар.

Ризалашып, сценарийларын алып калдым да уйга талдым: берсенә үзем барсам, икенчесенә кем?

– Камил! – диде хәтер.

– Бу юлы үзем Бакировны эзләп киттем. Ташкент гастрольләрендә икән. Телефон номерларын табып бирделәр. Сөйләшергә заказ биреп, ике көн узуга, ниһаять, Ташкент: «Композитор Бакиров тыңлый. Сез кем?»

– Мин – мин!

Максатымны әйтеп, шаярып сөйләшүдән, «Ташкент ягы» мине аңлап: «Камил хәзер Каменка шифаханәсендә дәвалана ич!» – диде.

– Туберкулёз эләктергәнмени?

– Маскировка өчен. Аны чыгару өчен телевидениедән «опекага алабыз», дигән язу китереп, баш врачка бирергә кирәк. Санаторийга акчаны нефтьчеләр бирә. Язуың алардан булса, абруйлырак. Очрашканга кадәр хуш. «Пип-пип...»

Бакиров кушканнарны анынча эшләп, дәваланучылардан интервью алырга дигән сәбәп-сылтау табып, оператор Таһир белән Каменкага килсәк, Камил, кеше җыеп, гитара чиртеп утыра. Гаҗәпләнүен дә, шатлануын да сиздермәде, ишек ягына күрсәтеп, «тамашачыларын» чыгаргач: «Монда да килеп таптыгыз. Ни кирәк?» – диде, исе китмәгән кыяфәттә.

– Үзең кирәк?

– Өч борынга керергәме?

Барысы турында да аңларлык итеп сөйләгәч, ул: «Бу гитара белән булмый, үземнекен китерергә кирәк», – диде.

– Проблема булмас, дидем мин, аның ризалыгына ышангач.

– Мине чыгарырлармы соң? Чыгарсалар күпмегә? Нинди шартларда? – диде ул, курыккандай.

...Камилнең һәр соравына канәгатьләндерерлек җавап биреп, билетлар алып, Минскига барып урнашканда, «Беларусфильм»дагы эшләрнең иң кызган чагы иде. Безне, иң «шәп» дигән очсыз гына кунак йортына урнаштырып, килүнең икенче көнендә «озвучка»га чакырдылар. Ун сменалык эшне өч сменада бетергәч, безгә «унбиш смена эшләделәр», дигән ведомостька кул

куйдырып, кесә тулырлык акча бирделәр. Кибетләрдә йөреп, күчтәнәчләр алуга, режиссёр ассистенты кайту өчен билетлар китерде. Иртәнге сәгать җиде тулгач китәсе. Төне буе алган бүләк, күчтәнәчләребезне төрештердек. Шунда Камил: «Упаковка – тоже искусство», – диде дә туктап калды.

– Нәрсә булды? – дип сорадым.

– Синең бүләк бирер хатының, күчтәнәч бирер балаларың бар. Ә мин боларны кемгә дип алдым инде? – диде ул.

– Синең дә хатының, кызың бар.

– Алар миннән бернәрсә дә алмыйлар шул.

– Алырлык итеп бир, сез бит аерылышмаган.

– Үземне җиңә алсам ярый ла... Ә җиңә алмасам? Атып бәрергәме?

Сүз җаен китереп, үзем белән булган хәлне сөйләдем.

– Бер елны миңа Казан янындагы Васильево санаториена путёвка бирделәр. Мин анда барырга хатынны күндердем. Шатланмаса да, ризалашып китте хатын. Мин өч бала белән өйдә калдым. Икенче көндә борылып кайткан бу. Бассейнда коенырга эчке киемнәр кирәк икән. «Су процедуралары билгеләделәр», – ди. Китте дә ун көн кайтмады. Күңелгә корт керде бит. Нигә кайтмый? Өч баланы ияртеп киттем. Регистратурадан аның кайсы палатада ятуын сорасам: «Ул квартирага урнашты, ике бүлмәнең берсендә алар...» – диде марҗа.

– Кем белән?

– Иптәше белән.

– Аның иптәше мин. Менә паспортым.

– Мин бит сезгә «ире белән», димәдем. «Иптәше белән», дидем. Иптәше аның Рабига атлы. Әнә журналга шулай теркәлгән.

Бераз тынычланып, хатынның фатирын эзләп киттек. Барып керсәк, мич янындагы эскәмиядә хатыным кер юып маташа.

– Нигә син процедурада түгел?

– Сәгате җитмәгән.

Сәгать карарга дип диварга карасам, мич кырыена сузылган бауда ирләр күлмәге эленгән.

– Иптәшең кайда?

– Бильярдка китте.

– Палкой күкәй толкать?

– Белмим – нәрсә толкать итәдер. Ул үзе аерым дөнья, күп сөйләшми.

– Сөйләшмәсә дә, керен синнән юдырамы?

– Кем әйтә?

– Әнә ич, юып элгәнсең, – дидем дә тартып алдым күлмәкне баудан.

– Син нәрсә, мине кеше белән дошманлаштырасың киләмени? Элеп куй урынына!

– Дошманлаштырасым түгел – аерасым килә, балалар хакына! – дидем дә, берни аңламаган балаларны елатып, пригородный поезд платформасына киттем. Хатыным аптырап, сүзсез карап калды. Кичкә чемоданы белән әйберләрен алып кайткан. Елый да балаларны сөя, миңа бернинди сорау да бирми.

...Соң дип тормадым – кабат Васильевога киттем. Теге йортка барып керсәм, хатынымның ике фатирдашы да аптыраашта иде, өченчеләре (ягъни минем хатын) кая китүен әйтмәгәнгә. Фатирдашларының берсе – минем хатын белән бер бүлмәдә яшәгән икән, ирләр киеме киенеп, ирләр булып йөрүче өченчеләре

аерым бүлмәдә ялгыз яшәүче «трансвестит» («кыз тәкә») икән! Нихәл итим, ул кичне эш бүлмәмдә генә йоклап, икенче көннең иртәсендә гафу үтенергә кайттым.

– Гафу иттеме соң?

– Итмәсә, минем белән илле ел яшәмәс иде.

– Минеке гафу итмәячәк!

– Ә син аңа багышлап махсус көй яз да, итальянлылар кебек, тәрәзенә килеп, серенада җырла. Кызың ишетеп, сезне кавыштырыр.

– Минем аңа багышлап язган өч көем бар. Уйнап күрсәтимме?

Уйнады Камил. Аның көйләре сүзсез монолог, тойгылар көлтәсе, хисләр дулкыны иде. Бераздан ишекне шакып, купебызга проводница килеп керде дә:

– Сезгә кунаклар бар, кабул итегез! – диде.

Шунда ук билендәге каешына кобура таккан иргә ияреп, ап-ак сакал-мыеклы бер карт керде дә:

– Не удивляйтесь, мы не надолго, – дигәч, портупеелысы чыгып, ишекне япты.

– А вы продолжайте, играйте, – диде карт, Камилгә карап, үзе минем янга утырды. Күкрәгендәге депутат значогы, кораллы озатучы белән йөрүе аның гади пассажир түгеллеген күрсәтә иде.

Камил уйнавыннан тукталмады. Игътибар белән тыңлаучы «тамашачыбыз», көй алышынган саен, аның исемен атап, сүзләрен хәтерләргә тырышып утырды: «Өй артында шомыртым, серен сөйли миләшкә», «тиз генә кайтырмын дигән идем», дип, һәр көйгә иярергә маташты. Үзеннән-үзе: «Сез татарча беләсезмени?» – дип сорарга мәҗбүр булдым.

– Мин – татар авылы детдомында үскән кеше, – диде значоклы. Яшен тизлегендә күңелемдә төрле хатирәләр уянгандай булды. Мин бу сәер пассажирны таныган кебек тә идем. Тик бу турыда аңа әйтеп, сораулар бирергә базмадым. Ныгымаган ышанычым югалудан курыктым.

Камил чираттагы көен уйнаганда, кунак «Идел бит ул, киң бит ул, Идел өсләрендә йөзгән аккошларга тиң бит ул», дип җырлагач, карт, борылып, күз яшьләрен сөртте дә: «Рәхмәт сиңа, улым!» – диде.

– Улым, дидегезме? – диде Камил.

– Әйе, – диде бабай – шулай тоям.

Мин тагын аның йөзенә карадым. Аның «ул» булуына ышанычым артты гына түгел, шигем бөтенләй калмады. Ә Камил, уйнаудан туктап, берсеннән икенчесе урынсызрак сорауларын яудыра.

– Иделнең юклыгын беләсезме? Ул бит хәзер җырларда гына калды.

– Җырны онытмавыгыз мактауга лаек.

– Сез татар музыканты идегезме әллә?

– Мин музыкант та, татар да түгел. Әйттем ич, татар авылы детдомында тәрбияләнеп, Уфада институт, Мәскәүдә аспирантура, Минскида докторлык катыргылары алып, хәзер номерлы объектта, исемемне әйтергә ярамаган субъект булып, радиация үткәрми торган пыяла формуласы өстендә гомер кыскартучы вазифасындагы гади академик мин.

Шунда мин «сушилкада борчак киптерүне хәтерлисезме?» дип чак-чак сорамый калдым. Сорауларны Камил тезде:

– Безнең академик Арбузов нефтьтән аракы ясарга өйрәткән. Сез пыяла формуласы эзлим, дисез.

– Инде таптым!

– Шуның өчен сезгә бу значокны тактылармы?

– Значок – ышаныч символы.

– Символга караганда дәүләт премиясе өстенрәк түгелме?

– Алары миндә икәү.

– Детдомыгызда беләләрме бу хакта?

– Без тәрбияләнгән детдомны япканнар, – дип ишетәбез.

– Япсалар да, анда тәрбияләнгәннәр кайтып йөри, – дип әйтүемне сизми дә калдым мин. Авыздан ычкынганны кул белән тотып булмый – хәбәремнең тәэсирен көтеп утырам. Кунагыбыз, борылып, миңа карады. Нидер әйтергә теләде. Камилдән гитарасын сорап алды да, «Сагыну» көен уйнады. Аннары кинәт:

– Бу гитараңның тарихын беләсеңме? – дип сорады.

Камил: «Миңа аның тарихы түгел, яңгырашы кирәк», – диде.

– Алты кыллысы да, җиде кыллысы да, гавайныкы да әйбәт яңгырыйлар. Аермалары нидә?

– Аерма кемнең ничек уйнавында.

– Тапкыр җавап. Шуны раслап Сәйдәшнең «Әдрән диңгез»ен» уйнасаң, мин канәгать булыр идем.

– Ул көй гавай гитарасында әйбәт чыга.

– Ә мин шушы гитарада да әйбәт яңгыратам. Бир әле...

Чынлап та әйбәт уйнады ул. Гитараны Камилгә кайтарып биргәндә: «Кеше дә шулай үзгәрми сакланса иде. Кызганыч, бөтен дөнья үзгәрә. Без су коенып үскән Мәләвез елгасы хәзер инеш кенә булып калган, имеш.

– Мәләвез безнең елга ич!..

– Ул безнеке дә. Минем энем шунда икенче тапкыр туган кеше.

Мин тагын, түзә алмый: «Исеме кем аның», дип сораганыма үкенәм.

– Хикмәт исемдәме? Ул хәзер кара алтын чыгарудагы яңа ысулларның төп авторы.

– Кайда соң ул?

– Мәскәүдә.

– Мәскәүдә дә нефть чыгамыни? – диде Камил, тагын дорфа гына.

– Чыгара белсәң, кайда да чыга ул. Чыгара белүчеләрне Губкин институтында энем әзерли. Башкортстан, Татарстан нефтьчеләренең күбесе аның шәкертләре.

– Мактанучылардан ишеткәнем булды, – диде Камил, сөйләшүне туктатырга теләгәндәй.

Ә мин исә сүзне башларга да, аннары барысы турында ачыктан-ачык сораштырырга да инде әзерләнеп беткән идем. Кунагыбыз, урыныннан калкынып, визит карточкасын миңа сузды да: – Вакытыгызны алганым өчен гафу итегез, рәхмәт белән үз купема чыгам. Әле юл озын. Сорауларыгыз булса, әңгәмәне минем купеда дәвам итәрбез, – диде.

Сорауларым күп иде, әлбәттә. Ни өчен әле ул безне танымаганга сабышты, аннары нигә Кәшифә апаның язмышы белән кызыксынмады, баласы бармы, булса, кайда һәм кем ул хәзер? Аның мине тануы шиксез, әлбәттә, әмма Камилне үз улы дигәне шикләндерә. Сәбәпләрне дә табарга була иде.

...Безнең бу очрашуга тиңләшерлек вакыйгаларны әдәби әсәрләрдә дә, киноспектакльләрдә дә укыганым, күргәнем юк иде. Уйланып, хыялланып күпме ятканбыздыр, ишек шакып тагын керде әрсез кунагыбыз.

– Гафу итегез, зинһар, – диде ул, Камилгә карап, сезнең туган елыгыз кайчан?

– Мин карт инде, Сталин үлгән елны, 5 мартта туганмын.
– Әтиегез кайда, кайчан вафат?
– Ватан сугышында.
– Кайсы?
– Наполеонга каршы сугышта, – диде Камил, дорфа гына.
Урынсыз сорау бирүен аңлаптыр:
– Гафу үтенәм, – диде дә үз купесына чыкты төн кунагы.

Камил ятып йоклагач, кердем мин бу серле академик карт янына. Озак сөйләштек. Әтисе детдомнан алып китеп, яңа тормышы башлангач, Мәләвезтамак авыл Советына хат язып караса да, «Сез эзләгән кеше Свердловск өлкәсендә, торф эшендә, бала үстерә», дигәннән тыш җавап килмәгән. Өйләнмәгән, мәхәббәтенә хыянәт итмәгән. Турыдан-туры булмаса да, кинаяләп сөйләшүдән, без кемнәр турында сүз алып баруыбызны да, бер-беребезне дә аңладык, кемнең кем булуын белдек шикелле.

Әтисе күптән вафат икән аның, туганнары Польша белән Литвада яшәп, кайберләре шунда җирләнеп, исәннәре белән хәбәрләшеп торалар икән. Диннәре төрле булса да, телләре төрки, имеш. Әңгәмәбез озакка сузылса да, аерылышканда, бер-беребезгә ниндидер вәгъдәләр дә бирешмәдек, кунакка да чакырышмадык. Шунысын тану кирәктер: бу кеше минем берәр әсәремнең каһарманы булырга лаек, дигән нәтиҗәгә килдем шикелле.

Минскидан кайтып төшкәч, безне үз машинасында улым каршы алды. Аның шатлыклы йөзе, елмаеп сөйләгәннәре хәзер дә колагымда, күз алдымда.

Улым турында шуны гына яза алам: безне каршы алгач, дачасына бәрәңге утыртырга дип китә дә, орлык бәрәңгесен чүпләп тутырырга дип нәүрәпкә төшкәч, метан газы белән агуланып шундук вафат була. Аның фаҗигале үлеме турында без икенче көнне генә ишетеп беләбез. Шул хәбәрдән мин, инсульт бәреп, инфаркт булып, шикәр авыруы башланып, урын өстенә аудым. Хәрәкәтсез, үлем килүенә ышанмыйча, берничә тапкыр больницада ятып, өч ел дигәндә, ниһаять, өйгә чыгарылгач, пенсиягә озатылуымны, озак эшләгән «специалист» буларак, рәхмәт йөзеннән, гади хәбәрче итеп вакытлыча эштә калдырылуымны белдем. Үз хәлем хәл дигәндәй, әллә кайдагы Польша-Литва төркиләренең шәҗәрәсен эзләү түгел, ул хакта уйланырга да теләгем юк иде хәтта.

Дүрт чатлы таякка таянып, даруханәгә һәм кибетләргә чыга башлагач, ниһаять, беркөнне эшкә барып, күренергә булдым. Һәркемнең үз эше, үз мәшәкатьләре баштан ашканлыгын беләм, тиз-тиз хәл белештем дә документларымны алырга кадрлар бүлегенә кердем. Анда минем исемгә килгән телеграмма көтеп ята икән. Шуны бирделәр. Карчыгым белән икебезне «Бер очрашу – бер гомер» дигән якташлар бәйрәменә чакырганнар. Телеграммага «Рәис» дигән имза куелган.

– Колхоз беткән – дигәннәр иде, нинди «рәис» булыр, – дип, аптырашта калдым да, Камилне табып, сораштырырга булдым. Бәлки, Кәшифә апа аңа хат язадыр, хәбәрләшеп торалардыр, дип уйладым.

Театр оркестры дирижёры Бакировны телефон аша табып сорагач, Камилнең күптән авылына кайтып китүен, хатыны Гәүһәр белән кушылуын белдем. Бу эшкә үземнең дә катнашым бар, дип шатлансам да, минеке ише чирдән котылган кешеләрнең кабат «ычкынулары» ихтималыннан, Кәшифә җиңгәчәй исеменә «Нинди бәйрәм?» ул дип телеграмма «суктым». Рәтләнсә, җавапны Камил бирер, дип уйладым.

Ялгышмаганмын, Камилдән: «Праздник встречи воспитанников детдома, праздник встречи односельчан, праздник открытия моста и других объектов. Камил» дигән хәбәр килде.

Бәйрәм 15 июльдә буласы икән. Аңа кадәр әле егерме көнләп вакыт бар иде. Ничек кайту, күчтәнәчкә ниләр алу, даруларымның кайсылары кирәклерәк булыр, дигән вак-төякне хәл итү белән вакыт узуын сизми дә калганбыз. Китәргә өч көн калды дигәндә, Минскидан Садриев атлы кинооператор килеп төшә. Командировкага. Миңа да шалтыраттылар, ул сине белә, дигәч, бардым. Станислав Говорухин белән Казан телевидениесендә бергә эшләп, Мәскәүдә укыгач, Белоруссиягә практикага җибәргәннәр икән. Шуннан ул «Беларусфильм»га урнашып, кинооператор булып эшләп калган. Аның катнашы белән дөнья күргән «Педагогическая поэма» фильмы республикада бик абруйлы депутат-академикның күңеленә хуш килгән. Садриевның әйтүенчә, «ул үзе авыл детдомында тәрбияләнеп, кеше булганнар турында фильм төшерү кирәклегенә хөкүмәт чиновникларын инандыра алган. Чыгымнарны нефтьчеләр институты да, министрлыгы да үз өстенә алыр», дигән.

– Белоруссиядә андый институт та, министрлык та, нефть тә юк, – диләр аңа.

– Юк икән – үзем түлим, үзем күтәрәм, – ди дәүләт премияләре лауреаты.

Тәкъдим сүзе, уеннан чынга әверелеп, утыз минутлык документаль фильм төшерергә режиссёр һәм аның группасын билгелиләр. Татарстаннан килеп, дәрәҗәләргә ирешкән Садриев фильмның операторы була.

...Ул Казан студиясе тарихын оешуының беренче көннәреннән үк белә, мине дә театрда эшләгән чактан телевидениегә күчкән көннәремә кадәр хәтерли икән. Үземне яхшы яктан күрсәтергә теләп, кайчандыр аның белән төшергән туган авылым күренешләрен, дусларым тәрбияләнгән детдом, Агыйдел, Мәләвез кадрларын архивтан табышып бирергә вәгъдә иттем. Садриев андый кадрлар сакланырга тиешлеген белеп килсә дә, табылып, кулына алгач, чиксез шатланды.

Тиешле рәсмилекне үтәп, документлары әзер булуга, кайтып китәргә дә ашыкты. Фильм эшләнеп беткәч, худсоветка тапшырганда хәбәр итәрбез, ничек тә килергә тырыш, диде. Әлбәттә, ярар, барырмын, дидем, бара алмасымны белсәм дә. Дөресен әйткәндә, фильм төшерү өчен мин табып биргән архив материаллары гына җитмәсен аңлый идем.

Иртәгә бәйрәм дигән көнне оныгым машинасында юлга чыктык. Ерак арага... Көтү кайткан чакка туры килгәч, сыер сауганда бүлдермик дип, Кәшифә апаларга кергәнче, әткәй-әнкәй каберләрен зиярәт кылырга бардык. Хәтиф тә мәрхүм булган икән. Гыйният абзый да, Зөлфирә җиңги дә. Һәркайсының рухына белгәнебезчә дога кылдык. Аннан урап кайтуга, безнең килгәнне белгәннәр, табын әзер, чәй кайнаган иде. Татарстан нефтьчеләре эшләп биргән яңа чишмә суыннан икән. Тастымалларны сыкканчы, самавырны екканчы, яңа чишмә суының чәен эчеп, гөбәдия ашап сыйлангач, хатирәләребез белән уртаклаша-уртаклаша, таң атуны да сизмәгәнбез. Күбрәк Камил белән Гәүһәр сөйләве, алар сөйләгәнне Кәшифә җиңгәчәйнең дөресләп, кайчак «арттырмагыз», дип утыруы хәтердә. Кыскасы, һәркайсыбыз шат, бәхетле иде ул кич. Кәшифә җиңгәчәй кызыл кирпечтән салынган йортын мактаса да, коляска белән кереп-чыгып йөрергә баскычларының биеклегеннән канәгать түгел иде. Кияү коймагы белән чәй эчкәч, бәйрәм булачак мәйданга, Мәләвез елгасы аша салынган күпер янына киттек.

Елганың ике ягында да, бәйрәмчә киенгән халык. Учак якканнар. Кайсы шашлык кыздыра, кемнәрдер пылау казаны тирәсендә таптана. Тауны тишеп чыккан кара торбадан мәрмәр улаклар буйлап берсеннән икенчесенә агучы яңа чишмә суында бит-кулларын юып, учлары белән су эчәләр, берсен-берсе фотога төшерәләр, су сибешәләр. Мәләвезнең ике як ярына да кунаклар килгән машиналар тезелгән. Күбесе Татарстанныкы булса да, Башкортстаннан да, Удмуртия белән Пермь өлкәсеннән, Саратовтан, Самарадан да бар иделәр.

– Иң зур машиналар Мәскәү кунакларыныкы, – диде Камил.

Хуҗаларын мәчеттә Рәис хәзрәт кабул итә икән. Сәгать унике тулуга, мәчеттән унҗиде кеше чыгып, ике башы да тарттырып бәйләгән чаршау белән капланган күпер янына ясалган эстрада-сәхнәгә менеп тукталдылар. Танышлар күп булмаса да, әүхәтле кешеләр иде. Халык такта эскәмияләргә утырды. Колхоз бетеп, авыл советы «җирле үзидарә»гә әверелгәч, шуның рәисе булган безгә таныш – Рәис абый, хәзер «по совместительству» мәчеттә халыкка хезмәт итүче мулла – сүзне башлады. Иң әүвәл, килештереп, кыска гына дога укыды. Аннары килгән кунакларның һәркайсын исеме белән атап таныштырып чыкты. Күбесе фән докторлары, кандидатлар, дәрәҗәлеләр иде. Барысына да биргән хәер-сәдакалары, бигрәк тә төзүчеләргә хезмәтләре өчен рәхмәт әйтеп, дога кылды хәзрәт.

Аннары, сүзне кунакларның кайсына бирергә белми, киңәшләшеп алды да, арттарак торган берсенә карап:

– Сүз нефть министрлыгы вәкиле, Мәскәү кунагы профессор Кротовка бирелә, – диде.

Профессор чыгып басуга, бөтен мәйданга күз йөртеп алды да:

– Хөрмәтле авылдашлар, исән-саулармысыз, һәммәгез дә?! – диде, саф татар телендә.

Халык моны көтмәгән, ахры, дулкынлануын сиздерде.

Мин аның беренче сүзеннән үк үзебезнең Вәсил икәнен таныдым. Олыгайган, картайган иде, әлбәттә. Ул детдомда үсүе, Мәләвезтамакта Кәшифә апаның кул астында тәрбияләнүе, анасының кабере шушы авыл зиратында булуы, этисе килеп алгач, кайларда укып, кем булуы, хәзер кайда һәм кем булып эшләве турында сөйләгәч, абыйсы Вәдим турында сөйләргә күчеп, аның турында чыккан китапларны кызыксынучыларга таратырсыз, дип, Рәис хәзрәткә бирде. Аннары ярдәмчесеннән папкасын сорап алды:

– Хөрмәтле авылдашлар! Якташлар! Кунаклар! Бик авыр булса да, әйтергә тиешмен. Бу бәйрәмгә без абыем белән бергә кайтырга дип сөйләшкән идек. Әмма аның Чернобыль фаҗигасеннән соң эләктергән авыруы теләгебезне үтәтмәде. Абыем шушы авыл, детдомга кагылышлы фильм төшерү мәшәкатьләре белән йөргәндә, көтмәгәндә вафат булды. Үз акылында, васыятьләрен әйтеп үлде. Мәләвезтамак детдомын тулысынча тергезеп булмасын белгәнлектән, ул, кайчандыр аның бер бүлеге булып эшләгән сукырларны музыкага өйрәтү мәктәбен тергезү турында хыялланды. Шуның өчен дип ул дәүләт премиясе, төрле уйлап табулары өчен бирелгәннәрдән җыеп барган акчаларын шул мәктәп төзелешенә бирүне миңа йөкләде. Мин әлеге эшне бик теләп башкарам һәм сертификатны җирле үзидарә рәисе Рәис хәзрәткә тапшырам.

Гадәт буенча, халык бик озак кул чапты, сөйләшүләр булып алды. Шаулашу беткәч, халык тынычлангач, Вәсил тагын сүз алды. Үзенең суга батуы, авылның яшь бер егете, котырып аккан суга ташланып, аны коткаруы, үлемнән алып

калуы турында хисләнеп сөйләде дә сүзне Татарстан нефтьчеләре исеменнән килгән вәкилгә бирде.

Бу вәкил бик матур нотык әзерләгән икән. Башта татар-башкорт милләтенең ике тән, бер җан булуы турында, какшамас дус булырга тиешлекләре турында сөйләде. Аннары күпер башларына тарттырып эленгән чаршауларны чишеп алырга боерды. Чаршаулар төшүгә, күпернең ике башында да аркылыга тарттырылган кызыл тасмалар күренде. Вәкилгә ике кайчы китереп бирделәр. Берсен ул үзендә калдырды, икенчесен Рәис хәзрәткә бирде дә тасмага якынлашты. Рәис хәзрәт күпернең тау ягы башына чыкты.

– Мин бүген, тасмаларны кисеп, дуслык, татулык, бердәмлек күпере ачуны игълан итәм. Бу безнең Татарстан нефтьчеләренең Башкортстандагы дусларга бүләге, – диде вәкил. Кул чаптылар.

– Күпер, җирле үзидарә әһелләренең киңәше белән, «Дуслык күпере» дип атала. Гранит тактага язылып, күпернең ике як баганасына да беркетелгән сүзләр озак яшәсен иде. Яшәсен дуслык! – дип сүзен бетерде ул.

Шунда, коляскада утырган Кәшифә җиңгәчәй, дулкынлануыннан: «Без аны «Әүдах күпере» дип йөртәчәкбез», – дип кычкырды. Аңа каршы әйтүче булмады. Шуннан соң тасмалар киселеп, күпер аша башта җәяүлеләр, аннары машиналар чыгып, әзерләнгән нигъмәтләре белән бер-берләрен сыйлашу, бәйрәм итү башланды.

Татарстан вәкиле тагын сүз башлады: «Төзеләчәк сукырлар мәктәбенең утыз кешелек штатын тотуны безнең оешма үз өстенә ала. Әлбәттә, абитуриентлар составының яртысы Татарстаннан булу шарты белән. Тиешле документларны әзерләп, тиз арада җибәрербез. Детдом янындагы комлы чокырдан сузылган яңа чишмәнең суын авыл өйләренә кертү безнең өстә кала.

Рәис хәзрәтнең күзләре яшьләнгән иде.

– Хөрмәтле кунаклар! Мондый бөек эшләрне башкарып чыгарга минем генә көчем җитмәс. Шуңа күрә, халык җыелудан файдаланып, бу эшләрне тормышка ашырыр өчен, мин җаваплы бер кеше билгеләүне сорар идем.

– Андый кеше бармы соң? – диде Вәсил.

– Бар, – диде Рәис, – ул – безнең авылдашыбыз Камил Әүдах улы.

– Гаепләмәгез, авылдашлар, – дип, тагын сүзгә катышты Вәсил. – Улым сүзен кемнән ишетсә, бала, шуның гына улы була ала.

– Ә ул сүзне әйтер кеше мәрхүм булса? – диде Кәшифә җиңгәчәй, Вәсилне аңламыйча.

– Мин ул сүзне ишеттем һәм бер генә дә түгел, әнкәй, – диде Камил, ышаныч белән.

Җыелган халык шаулашып, дулкынланып алды. Өлкәнрәкләр серне беләләр, белсәләр дә, кычкырып әйтмиләр, яшьрәкләр өчен бу мөһим мәсьәлә түгел, аларга тизрәк концерт-биюләр башлану кирәк иде.

Камил дә шуны көткән булса кирәк:

– Авылның – күперле, минем әтиле булуым хөрмәтенә концерт карагыз! – диде ул.

Калганын язып торуның кирәге юктыр...

# ХИСЛӘРЕМДӘ ИРЕКЛЕ МИН...

## ФӘҮЗИЯ СОЛТАН ШИГЪРИЯТЕНӘ КҮЗӘТҮ

Сүз сәнгатенең поэзия дип аталган төренә килүнең юллары төрле. Бәгъзеләр шигърияткә үз өйләренә кайткандай, ишек-капканы киң ачып, шау-шу белән, дәррәү килеп керсәләр, икенчеләре озын-озак өйрәнү чорын узалар, өченчеләре табигый сәләтләре, дөньяны шигъри күзаллаулары үзенчә булса да, поэзиягә күршегә ут сорап кергәндәй, оялып-тарсынып, түргә үтәргә кыймыйча, вакытларын уздыралар. Иҗатка соңлабрак аяк басуына карамастан, ике китабын чыгарып өлгергән («Учларымда җиләк» – 1999; «Үзәк өзелгән чак» – 2003») Фәүзия Солтан өченче төр шагыйрәләр сафын бизи.

Тормыш дигән могҗизага, туган халкына, әти-әнисе васыять һәм олы бүләк итеп калдырган туган теленә, акыл нурына, хисси дөньяга мәхәббәтен иң нәзберек укучыга да җиткерерлек сүзләрен табигый шигъри алымнар аша әйтү сәләтенә ия тыйнак шагыйрәбез Фәүзия Солтан.

Аның әсәрләрен мин соңгы елларда гына укый башладым. «Казан утлары»нда, «Мәдәни җомга»да басылган әсәрләре һәм журналда чыккан сурәте игътибарны җәлеп итте. Кремль янында җәлилчеләрне искә алу митингында Фәүзия Солтан укыган шигырь үзенчәлекле калыбы, афоризмга якын өслүбе, аһәңнәре белән бик мәгънәле әсәр булып яңгырады. Шуннан китапларын кулга алдым. Алардагы шигырьләр бу ханымның сагышлы җанын, ихлас хисләрен, якты күңелен күз алдына китереп бастырды.

Аның бөтен иҗаты күңел лирикасыннан тора. Ул – күләмле эпик жанрларда ут уйнатмый. Океан арты «юлбасарларына» йодрык күрсәтми, әрәмтамакларга сатира утын кадамый, йөрәк серләрен, Идел-йортына мәхәббәтен, якыннарына мөнәсәбәтен белдерү өчен, лирик гомумиләштерү мөмкинлекләре аңа бик җиткән.

Гомәр Хәйям белән Дәрдемәндне поэма язмаганнары, Кол Галине күләмле эпик жанрга өстенлек биргәне өчен гаепләргә җөрьәт иткәнебез юк кебек. Фәүзия Солтан тын лирика, хис-кичереш садәлеге тарафдары, язарына азыкны күктән эзләми, гадәти язмыш, шатлык, борчу аның кичереш дөньясын уятып, үзләренә бәрабәр шигъри калып аша укучыга барып ирешә. Кыскасы, шагыйрә рухи дөньясын, тормыш тәҗрибәсен шигъриятнең иң универсаль төре – лирикага ышанып тапшыра.

Аның иҗатында татар авылында туып-үскән лирик затның туган нигезенең гүзәллеген, ата-ананың газизлеген аңлау аша, тормыш казанында кайнап, чуер ташлар өстеннән ялан тәпи аягын каната-каната атлау, дөньяга карашы урнашу, холкы-фигыле калыплашу юлларын тоясың, аерым сурәтләрдә күрәсең.

Фәүзия Солтан – поэзиябезнең реалистик традицияләренә тугры шагыйрәләрнең берсе. Ул һәртөрле шаккатризмнарга, шәкли яңалыкларга мөкиббән китми, әмма аңа күк, йолдызлар, ягъни космогоник образлар, романтика, илаһилык чит-ят түгел.

Кеше иҗтимагый тормыш кысаларында яшәргә мәҗбүр булса да, аның уй-хис дөньясына берәү дә богау куя алмый.

*Хисләремдә ирекле мин,*
*Уйларымда дөнья гизәм,*
*Күккә менәм, йолдыз булып*
*Галәм киңлегендә йөзәм.*

(«Кол түгел»)

Фәүзия Солтан кебек лирик хисле шагыйрәнең интим кичерешләрне, мәхәббәт, сөю-сөелү кичерешләрен үзәккә алган шигырьләргә мул өлеш чыгаруы табигый. Хатын-кыз язмышы, аның бәхете, киләчәге турында уйланып язылган самими мотивлар, үрмә гөлдәй, шигырьдән шигырьгә күчеп үстереләләр. Татар поэзиясенә хас тотнаклылык, тыйнаклык, яшертен сөю, ике йөрәк серләрен чишкәннән соң да, мәхәббәтне чит-ят күзләрдән (С.Хәким әйтмешли, күрше-күләннән) саклау, самимилек – Фәүзия Солтан каләменнән төшкән мәхәббәт гөләндәмен бизәүче сыйфатлар. «Күңел назы», «Өмет гөле», «Бармак очында очкыннар», «Исәнме, мәхәббәтем», «Бер-береңә», «Бер мизгелдә», «Серлелек», «Җиләк» шигырьләрендә лирик зат эчке кичерешләре, олы мәхәббәте, януы-көюе турында нәзакәтле саклылык белән, хиснең кадерен белеп бәян итә, кайчак ишарә ясап, рухи халәтенең берише сыйфатларын киная белән сиздереп үтә.

*Көчле син, дип мине ялгышасың,*
*Күзләремә туры кара әле.*
*Тормыш йөген бүлешергә сине*
*Көткәнемне генә аңла әле.*
(«Көчле син, дип...»)

Үзәктә күбебезнең башыннан узган яшерен сөю, эчтән вулкандай янып, ярсып ташыган хисне әйтә алмый йөргән, шуның аркасында күпме газап-михнәтләргә тарган кичереш, моң елавы. Шагыйрәнең лирик герое Таһир-Зөһрәләрдән килгән саф сөю хисе алдында баш исә дә, кайнар тойгылары бөтерелә-бөтерелә ташыса да, алдашу, көнләшү кебек гамәлләрне гафу итми, горур булырга чакыра.

*Җавапсыз мәхәббәт каршында баш имә!*
*Ялынма! Тезләнмә! Сер бирмә!*
*Дәрвиштәй иркле, горур бул!*

Лирик зат фикеренчә, үзеңне бәйсез, мәгърур тота белгәндә генә «Сөю сиңа үзе киләчәк».

Кыскасы, Фәүзия Солтанның мәхәббәт лирикасы күңел тулылыгы, үзара аңлашуга, яратышуга мохтаҗ шәхес дөньясының, табигать фасыллары кебек, төрле чагылышларын эченә алган мул сулы елганы хәтерләтә.

Бөтен иҗаты буйлап ак төснең узуы (карны яратуы да ак булганы өчен дип уйларга кирәк) күңел аклыгыннан, кешеләргә гел изгелек теләүдән, акның, ахыр чиктә, барча начарлыкны, хөсетлекне җиңәчәгенә ышанудан килә. («Намуссызлык кичерелми беркемгә дә...»)

Фәүзия Солтан лирикасында татар кешесенә хас фикерләү үзенчәлекләренә, халык иҗаты энҗеләренә, бигрәк тә мәкаль-әйтем, хикмәти сүз байлыгына киң таяна. Бик күп мисалларның берничәсен искәртеп үтик. Буйсыну һәм коллык психологиясен чагылдырган «Иелгән башны кылыч кисмәс», дигән мәкальне шагыйрә «Баш иелгән» парчасына нигез итеп ала да аның эчтәлеге белән бәхәскә керә, баш иеп, тез чүгеп яшәүне кабул итми. Чөнки «...Күккә баш чөймәсәң, дөньяларны ничек танырсың?», ничек итеп күк йөзенең күркәмлеген, галәмне бизәгән энҗе-мәрҗәннәрне күрми яшәрсең? Шулай да назлы йөрәкле адәм баласы бер очракта, үзе дә сизми калып, баш июдән котыла алмый икән. Ул гүзәллек алиһәләре, күңел күрекләре – матур гөлләргә баш ию, мондый «буйсыну» белән кемгәдер кол булып, түбәнсенеп яшәүнең аермасы җир белән күк арасыдай икән.

Фәүзия Солтанның соңгы елларда вакытлы матбугатта басылган шигырьләре үзен поэзиягә алып кергән лирик аһәңен, туган якка, нигезгә соклануын саклаган тәкъдирдә, Кеше рухы бөеклекләрен ачуның фәлсәфи, әхлакый нигезләрен эзләвен, тел-өслүб берәмлекләренә таләпчәнлеген арттыра баруын күрәбез. Димәк, шагыйрә бер ирешкән үрендә таптанмыйча эзләнә, уйлана, очкыннан ялкын үрләтә.

**Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,**
*филология фәннәре докторы*



Фәүзия
Солтан

# ТОЯСЫ КИЛӘ ЯҢГЫР ТАМЧЫСЫН...

## Юлчы килгән

Юл тузанына күмелеп,
Юлчы килгән – каршы ал!
Икмәк куй да алларына,
Самавырга күмер сал.

Тормыш юллары, дип юкка
Әйтмидер инде халык.
Юлга ашыгып чыкмыйк без
Һәм чыкмыйк соңга калып.

Юлга ашкына йөрәкләр,
Өметле күзләр – юлда.
Күктә – кояш! Хәерле юл
Телидер безгә ул да...

## Яшисе килә

Күрәсе килә таңнар атуын,
Иртән офыктан кояш калкуын,
Чишмәләрнең дә челтерәп агуын,
Кичке шәфәкъны – кояш баюын.

Тыңлыйсы килә кошлар сайравын,
Яфракларның да җилдә шаулавын.
Кояш нурларын, суның салкынын,
Тоясы килә яңгыр тамчысын –
Барысын!

Яшисе килә! Бары яшисе!

Фәүзия СОЛТАН (1958) – *шагыйрә; «Учларымда җиләк», «Үзәк өзелгән чак» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Өмет

Суык өткән яфракларын,
Тамырлар... исән әле.
Өметләнәм: гөлкәйләрем
Яңарып үсәр әле,
Чәчәкләр атар әле.
Күңелләрдә яшәү көче,
Мәхәббәттән яну хисе
Яңарып кайтыр әле.

## Җибәрмим!

Китәм, дисең. Көчем бетте,
Көрәшә алмыйм, дисең.
Минем дә синнән калмыйча
Китәсемне белмисең.

Алда булыр, киләчәктә,
Ямьле, назлы гомерләр.
Сыкранулар калыр артта,
Килер кояшлы көннәр!
Юк, җибәрмим!..

## Җилгә

Ишегемне җил кага,
Тәрәзәмә сугыла...
Нинди хәбәр алып килгән,
Кайда йөргән, ни күргән?..
Шомландырма йөрәгемне,
Тәрәзәмне дә какма.
Хәбәреңне тә тыңламыйм,
Кире кит килгән якка.

Какма әле, җил, тәрәзәмне...

## Аңларга иде

Байлык җитми кешегә,
Килгән төсле мәңгегә!
Дөнья куа, мал җыя –
Алып китәрме гүргә?!

Йә авыр чир, йә бәла
Борып сала бер мәлдә.
Бөтенесе дә кала...
Аңларга иде, бәндә!

## Давыл

Көчле җил...
Актара тамырдан –
Авадыр агачлар.
Түбәләр каера.
Ватыла, ишелә
Диварлар.
И кеше,

Никадәр тырышып,
Тырмашып көрәш тә...
Барыбер табигать көчлерәк.

Ә кеше
Кырдагы бер башак
Төслерәк...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Мәдинә
Маликова

# ТАТЛЫ ГЫЙШЫК ҖИМЕШЕ

хикәя

Ай бу гыйшык хәлләре! Нигә ул гөлбакчаларда сандугач сайрауларын тыңлап, кочаклашып үбешүдән генә тормый икән? Каян килә газаплану, әрнү, үкенечләр?

Әйләнеп үтеп тә булмый бит ичмасам, кирәкме-кирәк түгелме, яшьлегеңдә гыйшык сине таба, йөрәгеңә ут булып каба. Зәрияне дә яндырды, көйдерде, көл итте бу афәт.

Урта мәктәпне тәмамлагач, институтка документларын биреп караган иде дә керә алмады. Авылда сыер савучы булып эшләде, аннары шәһәргә китеп барды. Соңрак, ник киттең, дип сораганнарга, гомеремне абзарда үткәрәсем килмәде, дип җавап бирә торган иде. Очраган бер кешегә йөрәгеңне ачып, андагы төзәлмәс яраны күрсәтеп булмый бит инде! Ә яраны яшьли сөйгән яр ясады, җырларда җырланган, кыйссаларда нурга төреп тасвирланган беренче мәхәббәт аны ялкын теледәй булып ялмады.

Сөю учагы, күпләргә хас булганча, мәктәптә укыганда кабынды. Авылда балаларның саны кимеп барган чак, яңа мәктәптә класслар яртылаш буш иде. Аларның сыйныфында сигез укучы – биш кыз, өч малай. Нәфкать шул өчнең иң кәттәсе иде. Муен текә, баш югары, ияк чыгынкы, туры кашлар астыннан соры күзләр кистереп карый. Гомумән, ул үзен егетләрчә тота, һәрхәлдә Зәриягә шулай тоела иде. Гашыйк булыр чак җиткән, табигать шуны таләп итә, Нәфкатьтән узып кемне сөясең? Дөрес, малай тәнәфесләрдә командир булса да, дәресләрдә мыштым утыра, укытучыларның соравына чәчрәп торып җавап бирми иде. Мәктәпне тәмамлагач, кая да булса укырга керергә ашкынмады, колхозда калды, механизатор булды. «К-700»ы белән урамны дер селкетеп узса, Зәриянең йөрәге дөпелдәп тибүгә чыдарлык булмый иде. Шундый биектә утыра, шундый кодрәтле булып күренә иде егет аның күзенә... Нәрсәсе бар инде югыйсә? Авылда егетләрнең күбесе тракторда-комбайнда эшли. Гадәти һөнәр алар өчен!

---

Мәдинә МАЛИКОВА (1935) – *язучы; ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. «Кар сулары», «Шәфкать», «Алтын ятьмә», «Өермә» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Егетнең борынына күптән ис кергән, Зәриянең мөлдерәп караганын шундук сизеп алды. Һәм, табигатенә хас гадәтенчә, малайларга гына түгел, аңа да баш булды. Клубтан кайтканда озатып куйгалый. Тик назлы сүзләр сөйләп, нечкәләп маташмый. Кочаклап үбә дә шуның белән вәссәлам.

Кызганычка каршы, Зәрия класстагы биш кыз арасында беренче түгел иде шул. Уку ягыннан да, чибәрлек ягыннан да. Көзгегә күз салса, бөтенләй күңеле төшә. Болай караганда кешедән ким җире дә юк үзе: уртача буй, нык бәдән. Томрап торган түгәрәк битендә бетчә-фәлән дә, калкып торган миң дә юк. Тик менә борын! Каян килгәндер, кайсы әби-бабасы мирас итеп калдыргандыр аңа шундыйны! Уртада бөкресен чыгарып дигәндәй калкып тора, ирен өстенә таба очлаеп, сузылып килә. Борын яфраклары икесе ике киңлектә. Шул сәбәпле, кызның алтынсу керфекләре арасыннан мөлдерәп караган зәңгәр күзләрен дә, тулышып торган иреннәрен дә, тыгыз ак тешләрен дә күрмиләр. Шул борын аркасында аңа «Торма» кушаматы тактылар. Аңа «ачы» сүзен өстәделәр. «Ачы торма» дип аны беренче булып шул Нәфкать атады да бугай инде.

Торма начар нәрсә түгел дә бит үзе, әмма кыз балага аны ишетү рәхәтме? Җитмәсә бу кушамат бик ябышып та тора, чөнки гәүдәсе тулы, тыгыз. Кайсы кызның шундый буласы килсен! Җырларда, китапларда биле кушучка сыярлык кызларны мактыйлар, торма-шалкан кебекләрне түгел!

Нәфкать авылдагы егетләрнең иң кәттәсе булса да, иң мактаулысы түгел иде. Үзсүзле, башбирмәс, бик иртә тәмәкегә ияләште, салгалаганы да сизелә. Күзеңне ачыбрак карасаң, акыл белән уйласаң, аңа күз салырга кирәкми иде дә бит. Гыйшык акылны җиңә шул! Нәфкать никадәр өстәнрәк караса, Зәриянең башы шулкадәр түбәнрәк иелде. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, бер ел алар әйле-шәйле очраштыргалап йөрделәр. Инде авылда, болар йөриләр, дигән сүз дә таралып, Нәфкатьнең әнисе Сәҗидә моңа бик канәгать икәнен сиздереп куйгалый иде.

– Ими баласы чакта ук колакларын тешләштеләр! Без аларны кайчакта бер арбага сала идек, – дип көлеп сөйли иде.

Икенче көзне Нәфкатьне армиягә алдылар. Солдатка китәр алдыннан кунак җыеп, үзенә бер бәйрәм ясыйлар бит инде. Сәҗидә табынга улының классташларын да чакырды.

Зәриянең башын томан сарган иде, ризыкның тәмен тоймады, сүзләрнең мәгънәсен аңламады, йөрәге бер сүзне кабатлап тибә иде: «ки-тә, ки-тә, ки-тә». Ашны-бәлешне ашап, чәй эчкәннән соң таралыша башладылар. Зәрия соңгы кеше булып калганын үзе дә сизмәде. Моның бер гаҗәбе дә юк – башкалар аның хәлен сизеп, күреп торалар, кайсы-берсе мәгънәле елмаеп, башын чайкап куя иде. Ә Зәриядә кеше кайгысы идемени соң! Баш селкүләре генә түгел, үзләре дә күзгә күренми иде!

Нәфкать капка төбенә кунакларны озата чыкты. Егетләр тәмәке кабызып җибәрде, Нәфкатьнең иңнәреннән кагып, андый чакта әйтелә торган изге теләкләрен әйттеләр. Зәрия исә тоткарланды, егет кире кергәндә, ул ишектән чыгып кына килә иде әле. Табигый ки, Нәфкать аны озата китте.

Шыксыз төн иде, күкне болыт каплаган, күшектергеч ачы җил исә. Егет кеше кыз баланы ачы җилдән ышыкламый димени? Нәфкать курткасының изүен ычкындырды, Зәриянең иңенә кайнар кулын салды, бөтен тәнен сары майдай эреткәндәй итте. Тик менә юл гына бик кыска булды, кайтып җиткәннәрен дә сизмәделәр. Аларның өе тыкрык кырыенда, ә тыкрыкта печән кибәне. Нәфкать шул кибән турында туктап калды да, Зәрияне кысып кочаклап, шашып-шашып

үбәргә кереште. Аһ, нинди татлы иде аның иреннәре, хәмер катыш тәмәке исе дә хушбуй булып тоелды!

Калганын тәфсилләп сөйләп тормасаң да буладыр. Хисләр ялкыны уйларны көйдергән, тән пешеп изрәгән. Салкын сүзләр белән аңлатырлык түгел, үзе кичергән кеше генә белә. Аның шунысы да бар бит әле: бу – соңгы кич, ике ел буе күрешү мөмкин булмаячак. Зәриянең исә аны үзенә беркетәсе килде... Печән кибәне генә серне сакласын иде.

Печәннең теле юк, гайбәт таратмас. Серне Зәрия үзе, дөресрәге тәне саклый алмады. Ай ярымнан аның күңеле уйнаклый башлады. Баштарак, аш ачыган булган, күрәсең, эремчекнең тәме киткән кебек иде, дип үзен юатырга тырышты. Әмма тора-бара аңлады: сәбәп ризыкта түгел, печән кибәнендә кичергән ләззәттә иде... Ата-анаңа хурлык, күрше-күләннән оят. Их, шул тыкрыкта, аулакта тагын очрашсаң иде... Сөйгән ярыңның саллы, үзенә бер исерткеч хуш ис килеп торган җылы курткасына төренеп, башыңны таза күкрәгенә салсаң иде... Татлы күз яшьләреңә уралып, сереңне ачсаң иде!..

Аралар бигрәк ерагайды шул, йөгереп кенә барып җитәрлек түгел! Хәлеңне аңлатырга бердәнбер чара – хатлар гына кала...

Байкал күле артыннан килде аның беренче хаты. Сүзгә осталыгы юк, «службага күнегәбез инде, дуслар да табыла» кебектән узмаган. Дүрт-биш хаты атна саен килеп торды, аннары сирәгәеп китте. Беркөнне Саҗидә Зәрияне урамда очратып, авызын ерып: «Нәфкатьнең хатлары килеп торадыр бит? – дип сорады. – Җавабыңда бездән дә сәлам кыстырып куй, нишләптер сирәк яза», – диде. Кызарынып башын иде Зәрия, дәшмәде. Сөйгән егете турында аның анасы белән урам уртасында авыз күтәреп гәп сатып торырлык кыю түгел иде ул. «Корсакка уздым бугай мин», – дисенме әллә тагын! «Миңа да сирәк яза башлады әле Нәфкать...» – дип тә зарланып булмый...

Кайсы гына егетнең анасыннан мондый очракта ярдәм көтеп буладыр... Әнисе нәрсә, егетнең үзеннән дә кызгану, мәрхәмәт өмет итеп булмас шикелле. Һәрхәлдә соңгы хатында, Зәриянең үз хәлен аңлатырга тырышып язганына каршы бер генә җөмлә бар иде. «Очрашкач сөйләшербез», – дигән. Кайчан очрашкач?.. Ул хезмәтен тәмамлап кайткачмы? Тагын бер ел да ун ай үткәчме? Аңарчы бит... аңарчы Зәриянең башы бетәчәк! Бу хәлен атасы белеп алсамы? Әллә соң поездга утырып, янына үзең барыргамы? Буага килеп туктаган поездларның берәрсе ала да китә!

Ләкин... бу хәлеңдә ничек барасың? Билетына каян акча табасың?.. Көтеп тә булмый, очрашып киңәшергә мөмкинлек тә юк. Бары бер нәрсә ап-ачык: ничек тә булса тиз арада өйдән чыгып китәргә кирәк!..

Зәрия анасына, бер-ике көнгә Казанга барып кайтам әле, диде. Гомеремне абзарда үткәрмәм бит инде, рәтлерәк эш табып булмас микән, дип күптәннән әйткәләп килә иде, шунлыктан кызының мондый нияте ана кешегә сәер тоелмады. Казанда туган-тумача, таныш-белешләр бар. Берничәсен күздән үткәргәннән соң, туп-туры барып керер өчен Резидә кулай булыр, дигән фикергә килделәр. Туган ук булмаса да, кодача. Ике бүлмәле фатирда ялгызы яши, гомере буе шәфкать туташы булып эшләгән, пенсия яшенә җиткәч тә эшен ташламаган. Сирәк күрешәләр күрешүен, алай да очрашканда бик ачык сөйләшә, кунакка чакыра. Бу җәйдә дә Сабан туена кайткан иде, Зәрияләргә кереп чәй эчеп чыкты, тагын бер тапкыр адресын язып бирде.

...Казанга ике генә сәгатьлек юл, тик бу баруда ул бик озын тоелды. Авылдан ярты сәгать калтырча автобуста селкенеп барганда, Зәриянең эче актарылып

чыккандай булды... Менә шунда аңлады инде ул, юл азабы – гүр газабы, дигәннең асыл мәгънәсен. Аңарчы әле сирәк-мирәк коскалап алуларны берәүгә дә сиздерми генә үткәреп җибәреп була иде. Ә бу юлы тимер юл вокзалында кассага чират тору да газапка әйләнде. Ул билет алып, эскәмиядә миңгерәп утыра иде, янәшәсенә көньяк кешесе килеп урнашты да, зур төргәк чишеп, эре помидорлар, кыяр, суган, ипи, ит таратып ташлады һәм тәмләп ашый башлады. Зәриягә карап елмайды: «Угощайтесь!» Зәрия укшып урыныннан кузгалды.

Юлга чыгу булмады, чиргә чуму булды бу. Аңарчы Зәрия белми дә иде вагонның шушы хәтле чайкалганын. Янәшәсендә утырган олы яшьтәге хатын, кыяфәтенә караганда чуваш апасы, аны кызганып: «Мондый чакта юл йөрүләр читен шул инде-е!.. – диде сузып. – Син менә болай ит: поезддан төшүгә үк, тозлы кыяр сатып алып кап. Мин үзем гел тозлы кыяр белән кабыклы бәрәңгедән җиңеллек таба идем». Зәрия башын читкә борды: «Бу хәлемдә кире авылга кайту юк миңа...» – дигән уй телдә бәгырьне. Күршесе исә ничек тә аңа ярдәм итәргә тырыша иде. «Син менә моны ал әле, кирәге чыгар, – дип иелеп, идәндәге олы кара сумкасыннан ярты литрлы буш пыяла банка чыгарды. – Тозлы кыярның суын сорап алырсың».

Казанга килеп җиткәндә, Зәриянең бер хәле дә калмаган иде. Ул инде авыз читен сөртеп өлгерә алмый, иреннәренә ярты литрлы банка терәгән иде. «Моңа берәр чара булырга тиеш бит! Даруы бардыр!» – дигән уй баштан китмәде.

Вокзалда халык күп, медпункт янында озын чират. Ишектән ак халатлы бер хатын килеп чыкты да, Зәрия каршысында туктап: «Токсикоз?» – дип сорады. Зәрия, «әйе» дигәнне белдереп, баш какты. «Өеңә кайт!» – диде хатын. «Кайтып җитә алмам! Хәлем авыр»... – диде Зәрия. «Җитәрсе-е-ең!» – дип сузды хатын һәм, аны әйләнеп узып, үз юлы белән китеп барды. Ишектән эчкә керсәң дә, шуны әйтәчәкләре көн кебек ачык иде. Вокзал халкы төрле яктан ышкылып, шул ук вакытта аның дөньяда барлыгын да сизмәгәндәй, тулгануында иде. Шушы халык арасында Зәрия берьялгызы калганлыгын тойды. Кемдер аңа ярдәм итәргә теләсә дә, булдыра алмаячак! Шунда Зәриянең бәгырен телеп, Нәфкатьнең хатындагы: «Очрашкач сөйләшербез», – дигән сүзләр искә төште. Ничек очрашасың аның белән? Ярый, ничек тә булса юлга акча юнәттең, ди. Зәрия Буа–Казан арасында шулхәтле интекте, тәүлекләр буе вагонда чайкалуга түзә алыр микән? Ярый, үлем хәленә җитеп булса да барып төштең, ди. Ярый, Нәфкатьне эзләп таптың, ди. Нишли ала ул? Зәриянең укшуын туктата алмый – андый дару юк, рисвайлыктан коткара алмый – андый чара юк... Дөрес, язылышсалар, хәл бөтенләй башкача булыр иде. ЗАГС дигәннәре анда да бардыр. Солдат кешегә тиз арада моны эшләү мөмкин микән? Аннан да бигрәк, егетнең теләге булырмы соң? «Сөйләшербез», дигәне әле ул «өйләнешербез» дигән сүз түгел...

Резидә түтәйнең ишеге бикле иде, шактый вакыт биек тупыл астындагы эскәмиядә көтеп утырырга туры килде. Караңгы төште, багана башларында утлар кабынды. Ярый, Зәриянең курткасы җылы, капюшоны да бар, баш өстенә тартып куйгач, утлар яктысыннан ышыклый... Баш иелгән, күңел тулган... Нишләргә? Нәфкатькә бару юлларын куе томан каплаган... Авылга кайту мөмкин түгел... Нәрсә аркасында?.. Карынындагы төер хәтле генә яралгы аркасында бит... Анысы да Нәфкатьнең нибары бер тапкыр кочагына алып, печән кибәнендә аунатып иркәләве аркасында... Никләр туктады икән Зәрия ул кибән янында?.. Башыңа мондый гамьнәр төшкәч, ләззәт кичергән минутлар онытыла, мәхәббәт ялкыны да сүрелә икән. Нәфкатьне сагыну хисен

чарасызлык басып китте... Хәер, бар бит бер чарасы... Карындагы төердән котылырга гына кирәк... Врачлар, беренче баланы төшерергә ярамый, дип куркыталар икән куркытуын да, һәр очракта да алай булмый, диләр бит. Нишләп әле бөтен бәхетсезлек Зәриягә генә килергә тиеш? Ачы җил кочагында әледән-әле банкага укшып утырганда, ул шулай уйлады.

Аның нияте турында ишеткәч, Резидә ачуланыр, бәлки. Мондый очракта яшисен яшәгән түтәйләрнең ни әйтәсе билгеле: «Анаң әйтмәдемени, башыңны сакла, дип!» Әйтте, әйтмәгән кая! Аңа халыкның шаян сүзен дә өстәде: «Башымны саклаган идем – печәнгә тыккан идем, дигән, ди корсакка узган бер кыз». Мисалы да күз алдында иде: Түбән очның Илзирәсе Ульяннан ирсез килеш көмәнле булып кайткан да, аның, корсагын бүлтәйтеп, урамнан узып барганын тәрәзәдән күреп алгач, Зәриягә әнисе: «Күр әнә, зина үзе балдан татлы, исе нәҗестән сасы, дип шундыйларга әйтәләр», – дигән иде. Чыннан да, битен тимгел баскан, бәдәне юанайган кыз ифрат кыяфәтсез күренгән иде ул чакта...

Резидә түтәй алай ук каты бәрелмәс, бәлки, тупас сүз әйтмәс... Әмма хупламас та инде. Хәлгә керергә тырышса да, хафаланыр, беренче баланы төшерергә ярамый, дип, гадәти сүзләр сөйләп куркытыр. Әмма Зәрия һәммәсенә түзәр. Теләсә нәрсә дисен, тик ярдәменнән генә ташламасын! Озак яшәгән, тәҗрибәсе зур, мондый хәлләрне күп күргәндер...

Багана башыннан төшкән яктылык түгәрәгенә кергән Резидәне ул ерактан ук күрде: кызгылт-сары курткасыннан, җыйнак гәүдәсеннән, җиңел адымнарыннан. Йөзен күрмәсәң, нинди кыз диярсең!

Олы сумка күтәреп каршына атлаган Зәрияне күрүгә, кояш кебек балкыды, кочаклап алды...

Өченче катка менгәч, сумкасын актарып, ачкычын эзләгәндә, кунак кызның кых-кых килүен сизеп:

– Салкын тидердеңме әллә? – дип сорады.

– Юк... Болай гына...

Резидә маңгаена сибелгән сары бөдрәләре астыннан аңа кистереп карады. Ишекне ачып, бусагадан атлагач, тагын кистереп күз сирпеп алды.

– Син чишен, кулларыңны ю, – диде. – Хәзер ашап алырбыз. Ачыккансыңдыр.

– Рәхмәт, ашыйсым килми...

– Болай итик әле без: кабыклы бәрәңге пешерик. Тозлы кыярым да бар...

...Чыннан да, тозлы кыяр хәл кертә икән, күңел болгануы басылып киткәндәй булды, тел җиңелрәк әйләнә башлады. Зәриянең мәсьәләне тизрәк хәл итәсе килә иде. Резидә:

– Казанда нинди йомышларың бар? – дип сорауга, суга чумгандай тәвәккәлләп:

– Туры сиңа килдем, Резидә апа, – диде. – Бөтен өметем синдә.

Аның шар ачык күзләреннән ике яшь тамчысы, керфекләренә эленеп, лампа яктысында җемелдәде.

– Нинди ярдәм кирәк соң сиңа? – дип сорады Резидә, карашын төшереп. Эшнең нәрсәдә икәнен чамалаган иде инде ул.

– Больниска кереп чыгарга кирәк миңа...

«Кай төшең авырта», дип сорамады Резидә. Зәриянең әлегә яссы корсагына күз сирпеп алды да, тагын аска карап:

– Анаң беләме? – дип сорады.

– Әйтсәм, башны бетерә... Әти белеп алса... үтерә...

– Ә егетең ни ди соң? Ник язылышмыйсыз?

– Армиядә бит ул! – диде Зәрия, өзелеп. – Байкал күленең аръягында.

– Хат алышасыздыр бит?

– Язган идем...

– Соң?

– Очрашкач сөйләшербез, дигән җавабы килде...

Резидә, өстәлдәге савыт-сабаны тегеләй-болай шудыргалап, шактый гына вакыт тынып торды. Аннары тирән сулап, аска караган килеш тавышын сүрелдереп, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

– Сөенәм, мин кайткач өйләнешербез, дигән сүзе юк инде алайса... Син аңа рәнҗемә, – диде, тагын бераз уйланып утырганнан соң. – Егет кешенең бит аның күңеле болганмый, корсагы бүлтәйми. Гамьнәре башкада. Армия хезмәте солдатны иләп киптерә, бөтенләй икенче кеше итә. Йөргән кызыннан: «Мин корсаклы», – дигән хат килеп төшкәч, нишли дисең инде син аны?

Зәрия дәшмәгәч, апакай сүзен дәвам итте:

– Кем беләндер киңәшәсе, эчен бушатасы килә аның. Казармадагы егетләр арасыннан дус күренгән берәрсенә серен чишә ул. Ә теге нәрсә ди?

Зәрия, аптыраганын белдереп, җилкәләрен сикертеп куйды: күз күрмәгән адәмнең ни әйтерен каян беләсең?

Резидә, ачы көлемсерәп, башын чайкады.

– Егетләрдә көнчелек көчле, бик шикчән бит алар. Икеләнә-микеләнә башлыйлар. «Син монда, ул авылында, нишләп йөргәнен каян беләсең? Капкасыннан бүтәннәр керми микән? Син аны ачык калдыргансың бит!» – дибрәк сөйләнәләр алар. Күңеленә шик корты салалар.

Зәриянең күзләре шар ачылды, бит очлары пешеп чыкты.

– Нәфкать алай уйламас! – диде, кадак каккандай каты итеп. – Минем беренчем бит ул!

– Ә егетләр, беренче артыннан икенчесе тиз килә, дип уйлый. «Күрше кызы ирдән кайткан, бар да безнең бәхеттән» дигән такмакны ишеткәнең бармы?

– Мин андый түгел! – диде Зәрия.

– Андагы солдатлар сине белми бит, гомуми фикер йөртә. Күргән булды инде андыйларны. Кыз өендә елап ята, егет җәһәннәм артында тәҗрибәле дуслары белән киңәшеп йөри. «Хатларыңа сүзләреңне үлчәп яз, киләчәгеңне уйла. Армиядән кайтуыңа бала табып куеп, йә өйләнәсең, йә алимент түлисең дисә, нишләрсең!» – ди алар. «Очрашкач сөйләшербез», диюе дә шулар киңәше беләндер. «Ялгыш сүз ычкындырсаң, хатларыңны күтәреп, бу баланың атасы шушы бит инде, дип судка бармагае! Кызлар андыйга оста! Тегермән ташыдай бурыч асып куярлар муеныңа-а. Унсигез елга!» Котын алырлар егетеңнең... Сине үлеп яратса, кеше сүзенә карамас иде дә бит... Нишләп соң ул киткәнче өйләнмәде?

– Вакыт калмаган иде...

– Ә монысына вакыт табылган бит әнә...

Өстенә кайнар су коелгандай җебеп төшкән Зәрия бу сүзләрдән кинәт айныгандай сынын турайтты, күзләрен мөлдерәтеп, инәлеп карады:

– Коткар мине, Резидә апа! Соң түгел бит әле, ай ярымлык кына. Ул бит... ул... әлегә бер төер генә... Аннан котылмасам, яшәү юк миңа!..

– Чәең суынгандыр, кая, кайнарлап килим әле, – дип, урыныннан торды Резидә. Чәйнеген күтәреп, кухня ягына чыгып китте дә, анда озак юанган кебек тоелды. Кире кергәндә, йөзе дә, тавышы да тыныч иде.

– Минут эчендә хәл ителә торган мәсьәлә түгел, – диде. – Син юлдан килгән кеше, аргансыңдыр. Хәзер тагын берәр чынаяк эчеп алыйк та, шул утырган диваныңа урын җәеп бирермен. Бер төймә лимон кислотасы эчеп куйсаң, әйбәт булыр. Иртән күз күрер.

«Борчылма, ярдәм итәрмен», – димәде... Зәриянең күңелендә ризасызлык туды, тик бәхәскә кереп булмый, түзәргә генә кала!

Диванга ятып, утларны сүндергәч: «Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, дигәннәре дөрес шул», – дип уйлады ул...

***

Хәлбуки, ул бер дә дөрес уйламады. Резидә аның хәлен бик яхшы аңлый, чөнки... нәкъ шундый хәлләр яшьлегендә аның да башыннан узган иде...

...Кече бүлмәдәге караватына кереп яткач, тәрәзәнең челтәрле пәрдәсе аша урам баганасыннан төшкән яктылыкка карап, авыр уйлар өермәсендә бөтерелде ул...

Катырак бәрелде бугай ла бүген бу бәхетсез кызга! Йомшартыбрак әйтсәң дә була иде. Ләкин ул Зәриянең гаме турында түгел, үзенең үкенечләре турында сөйләде бит – хәтерендә тулып шешкән чуанын ярып җибәргәндәй итте...

Ничектер шулай килеп чыкты, үз вакытында парын табып, оя кора алмады ул. Моңа, беренчедән, артык тыйнак, хәтта йомыкый табигате сәбәп булса, икенчедән, әнисе комачаулады. Уңган, актив кеше иде Гайшә, районның профсоюз оешмасында эшләде. Резидәнең әтисе заводта цех җитәкчесе, һич уйламаганда, фаҗигагә юлыкты. Иртән тәмләп ашап-эчеп, шимбә өмәсенә чыгып киткән иде. Завод ишегалдында тәртип урнаштырырга керешкәннәр, гөл түтәле буласы җирдә аунап яткан юан торбаларны машинага төяр өчен кран китерткәннәр. Шул торбаларның иң озынын күтәртеп машинага салганда, кранның югары очы өстән сузылган электр чыбыгына тигән, икенче очын, чайкалмасын дип, астан Резидәнең әтисе тоткан булган... Күз ачып йомганчы юк булган кеше.

Аның хәсрәтеннән Гайшә күз алдында картайды, чиргә сабышты, буыннары шеште. Медицина училищесында укып чыккан Резидә, еллар узган саен, хәле начарая барган анасын карарга, тәрбияләргә тиеш булды.

Тормыш бер җайга салынгач, гомер тиз үтә бит ул. Әйләнеп карасаң, исләр китә: ничә дистә еллар шулай икәү генә яшәп узган бит. Сагынып искә алырлык зур вакыйгалар булмаган да шикелле.

Әмма... Берәүнең дә сер капчыгы буш түгел, дигәннәре дөрес, Резидәнең гомерендә дә булды күкләргә аштырып, аннары чоңгылга томырган вакыйга.

Әтисе эшләгән заводның профилакториена шәфкать туташы булып урнашкан иде ул. Көннәрнең берендә аның каршына алсу җилкәннәрен киергән кораб килеп туктагандай булды. Аннан яшь капитан төшеп, Резидәгә баш иеп сәлам бирде... Әйе-әйе, бу очрашу Резидәнең алсу-зәңгәрсу томан белән өртелгән хәтерендә нәкъ менә шундый булып саклана иде. Егетнең янып торган бит очлары, аяз күкнең зәңгәрлеген сеңдергән күзләре, иртәнге кояштай җылы, назлы карашы, диңгез төбеннән җыелган мәрҗәннәрдәй тешләре, күңел бакларының капкаларын ачкан иркә сүзләре, тәнне балавыздай эретеп назлаган кайнар куллары...

Кызның тыйнаклыгын, кыюсызлыгын бик тиз җиңде, дәрте, егәре икесенә дә җитәрлек иде егетнең...

Резидәнең эш өстәленә китереп куйган кәгазьләренә караганда, егетнең

бирегә килүе бик гади иде үзе: Иделдә йөзә торган метеорда эшли икән, ниндидер афәткә юлыгып, кулын имгәткән, ядәч сөяген сындырган. Хастаханәдә дәваланганнан соң, профилакторийга сәламәтлеген ныгытырга килгән.

...Битараф кешеләрнең куллары кәгазьгә нәрсә генә терки соң? Күз күремнәре тар, күңел күзләре сукыр бит аларның! Ә гашыйк кеше хисләр биеклегеннән карый, алар күрмәгәнне күрә!

Ләкин, ничаклы югарырак күтәрелсәң, мәтәлүе шулхәтле читен булыр, дигәннәре дә бар бит әле...

Егетнең тагын бер көн киләсе бар иде. Шунда алар киләчәккә матур планнарын аныкларга тиешләр иде. Аңарчы: «Ташлашмабыз! Мәңге бергә булырбыз!» – кебек сүзләр генә әйтелгән иде.

Ә ул соңгы көнне килмәде. Әллә тагын берәр афәткә юлыгып имгәнгәнме? Төшкә хәтле ничек кирәк алай чыдады Резидә, сәгать ике җитеп, ял итүчеләр ашханә тарафына атлый башлагач, сабыр канатлары сынып, өенә шалтыратты. Трубканы нечкә тавышлы хатын-кыз алды: «Аны эшенә чакырдылар бит! Иртүк бик ашыгып чыгып китте, – диде. – Берәр әйберсе калганмы әллә? Үзем барып алырмын, хатыны мин аның».

Резидәнең эчендә нинди утлар дөрләде, дип сорамагыз, үзе кичергәннәр генә белә. Зәрия кебекләр, мәсәлән.

...Күзгә ак-кара күренми, ми түнә, тамактан ризык үтми. Андый хәлдә вакыт-вакыт күңелнең уйнап алуы була торган хәл... Буйга узмадым микән, дигән шик тумый калмады, әлбәттә, әмма моңа ышанасы килмәде. Миңгерәп йөргән чакларда вакыт бик әкрен үтә, әмма сәгате тиз суга. Монда да шулай булды. Өч ай гомер нәрсә ул! Беркөн айнып, күзен ачса, вакытны ычкындырган булып чыкты. Нәкъ шул вакытта әнисе аяктан егылды, аның буын чире нык көчәйде. Бик сызлана, интегә иде, шуңа тагын җан газабын, хурлык йөген дә өстәргәме?.. Әнисе бик дөрес яшәде, башкалардан да шуны таләп итә, бигрәк тә кызының саф көзгедәй балкып торуын, һәрьяктан өлге булуын тели иде. Аңа әйтеп тә булмый, күпмегәдер калдырып китеп тә булмый...

Резидә йөгеннән котылу чарасын үзе күрергә булды. Төрлесен кыланып карады, тик осталыгы җитмәдеме, әллә башка сәбәп беләнме, эченнән тыелгысыз кан коела башлады. Операция ясадылар, аналыгын алдылар... Дөрес, хирург аның хәленә керде, нинди операция икәнен Гайшә апага әйтмәделәр, аппендицит, диделәр...

Хәзер уйласаң, үкенеп туймыйсың: табарга кирәк булган ул баланы, җанын кыймаска! Әнисе хәсрәтләнер иде, билгеле, әмма кичерер иде. Ләкин, Тукай әйтмешли, үткән эш кайтмый, үкен син, үл, ела...

Моннан бер ел элек әнисе бакыйлыкка күчеп, ике бүлмәле фатирда Резидә берүзе калды. Ул ялгыз яшәргә өйрәнмәгән иде. Аңа читен иде. Янында якын кешесе булсын, аны карарга, кайгыртырга кирәк булсын, ул шуңа күнеккән иде. Берәр ятимне тәрбиягә аласымы әллә соң, дип тә озак уйланып йөрде. Әмма ялгыз калган пенсионер карчыкка тәрбиягә бала бирмиләр икән. Бәлки, үзенең үҗәтлеге җитмәгәндер, һәрнәрсәне озаклап, нечкәләп, төпченеп уйлый, эшкә килгәндә тәвәккәлли алмый интегә иде шул... Шуның аркасындадыр да, олыгайган көнендә ялгыз калды ул. Инде хәзер бер мәгънәсезгә ипи черетеп, гомернең ахырын көтеп, көннәрне үткәрергәме?

Ә монда Ходай биргән баланы юк итәргә йөриләр. Кулыңа ал да үстер бит инде югыйсә. Тәрбиягә бала бирмәссез микән, дип, чит-ят кешеләр каршына

басып, үзеңнең ипле-тәртипле, хәлле икәнеңне исбатлап торасы да юк, тырнак астыннан кер эзләгәндәй итенеп, гаеп-кыегыңны да тикшермиләр... Аннары аның шунысы тагын: чит-ят ятимнең нәсел тамырын белмисең, ата-анасының нинди икәне дә билгесез, балалары кем булып үсәр бит. Алма агачыннан ерак төшми. Нәселдән килгән чире азса? Холкы-табигате чорсыз булып чыкса? Үги бала асрасаң, авызың-борының кан итәр, дигәннәре юкка түгел. Ә монда үз бәгырең парәсе...

Зәрияне үзенеке кебек язмышка дучар итәргәме? Алла сакласын! Үгет-нәсихәт белән генә бу кызыйны хәвефле ниятеннән ваз кичтерү мөмкин түгеллеге көн кебек ачык иде, Резидә хәйләләргә карар кылды.

***

– Син ни әйтерсең, мин болай уйладым әле, – диде ул, иртән чәйгә утыргач. – Безнең хастаханәдә эшләп торсаң, ничегрәк булыр икән? Санитаркалар җитми, аннан, сиделкалар да гел кирәк. Сәгатьләп түлиләр.

Зәрия аңа шаккатып төбәлде. Нинди санитарка, нинди сиделка?

– Хәзер үк бергә барыйк та сөйләшик, – дип дәвам итте Резидә аңа, озак уйланырга ирек бирмичә. – Әлегә авылга кайтып йөрмәсәң дә була, телефоннан сөйләшерсең, эшкә урнаштым, диярсең, миндә яшәгәнеңне әйтерсең.

– Ә... кайчан ятармын?

– Кайда?

– Абортка...

– Күз күрер анда... Больницага эшкә урнашсаң, сөйләшү җиңелрәк булыр, – диде Резидә. – Анда бик тәҗрибәле белгеч бар безнең, шуңа күренеп, киңәш сорарбыз.

...Өлкән яшьтәге кырыс чырайлы юан табибә Зәрияне карады да:

– Бусын алдырсаң, бүтәне булмаячак, – диде. – Нәрсәгә чыраеңны җимерәсең? Резидә апаңда яшисең икән бит. Урының җылыда, корыда, иписез дә калмассың, эшкә керергә ниятләгәнсең икән. Калганын балаң тугач карарсың.

– Кирәкми ул миңа, кирәкми!

– Алла, харап икән! Кирәкмәсә, тапкач, отказ бирерсең, хөкүмәт үстерер. Йә берәрсе тәрбиягә алыр. Бала да исән калыр, син дә сәламәтлегеңне сакларсың.

...Туганчы ук ата-анасына тансык түгел, артык җан иясе булды бу. Дөньяга беренче авазын салуга, Зәрия башка аналар кебек:

– Күрсәтегез! – димәде. «Үлмәде дә ичмасам!» – дигән уй чагылып узды аның кызган башыннан...

Аның урынына сабый Резидәгә тансык булып чыкты. Тудыру йортыннан ул каршы алды, исемне дә ул сайлады – бай булсын, алтынга чумып яшәсен дигән нияттән «Динар» дип кушты. Керләрен юды, коендырды, елаганда күтәреп йөрде. Әллә күңеле әйле-шәйле булганга, әллә бүтән бер сәбәп аркасындамы, яшь анага сөт төшмәде, ике атна узуга, сабыйның тамагы туймавы ачыкланды. Резидә сабыйлар кухнясыннан вак шешәләр алып кайтып, шуларны бирә башлагач, бала ананың буш күкрәген суырудан бөтенләй бизде.

Мәшәкатьләр күбәеп, көйсезлекләр чыгып торса да, тормыш үзенә бер җайга салынды: Резидә көндез эшли, Зәрия төннәрен каты чирләүчеләр янында утыра иде.

...Менә шулай яшәп ятканда, Мәскәүдән Резидәнең туганнан туган Ландыш исемле сеңлесе килеп керде. Буага ата-анасы янына кайткан да, Казанда

йомышы булып, бер төн кунып чыгарга кирәк икән моңа. Кыска чәчле, очкын күзле, ачык йөзле, күп сүзле бу апаны кырыкка җитеп килә, дисәләр, ышанмассың, биеп кенә тора. Ул киемнәре! Челтәрле кара кофта, сәйлән белән чигелгән кара чалбардан. Табын уртасына сары башлы шампан шешәсе китереп куйды, шартлатып ачты, Резидәнең өстәлгә сирәк менә торган озын торыклы бокалларына күбекләндереп тутырып салды.

Берне тәмләп эчеп куйгач, хәл-әхвәлләрен сөйләшеп алдылар: пенсия акчасына гына калса, Резидәгә көн итү авыр булачагын; Зәриянең больниста авырулар карап акча юнәтүен... Икесенең дә хәлләре шәптән түгел иде. Ә менә Ландышның тормышы көйле икән: ире, ике баласы бар, үзе Думада эшли.

– Депутат булыпмыни? – дип сорады хәйран калып Зәрия. Ландыш мәгънәле итеп башын чайкап куйды.

– Минем урын төплерәк, ышанычлырак, – диде. – Депутатның эше вакытлы бит аның, бер срокка сайлыйлар, икенчесендә әллә сайлана, әллә юк. Үтмәсә, прощай, Дума. Ә мин даими эштә.

– Нинди эш соң ул?

– «Менеджер по клинингу» дип атала минем должность. Чисталык, тәртип өчен җавап бирәм.

– Туктале, – диде моңарчы аңа зур ихтирам белән карап утырган Резидә. – Хәзерге вакытта кайбер урыннарда идән юучыларны шулай дип әйтәләр...

– Урыны нинди бит аның! Дума! Анда үсү мөмкинлекләре бар, – диде Ландыш, түшен киереп. – Югарырак должностька күчәргә тәкъдим иттеләр. Кайтуга, курьер булып эшли башлаячакмын. Урам буйлап чабасы түгел, арбага кәгазьләр тутырып, бүлмәдән бүлмәгә өләшеп йөрисе. Бик җайлы эш. Күңелле дә. Кемнәрне генә күрмисең...

Зәриянең күлдәй күзләре төбендә телевизордан күргән күренешләр яңаргандай булды. Ак йорт, кызыл келәм түшәлгән иркен, биек коридорлар, баскычлар. Тоткалары путаллы ишекләр артында даны илгә таралган шәхесләр. Син шулар белән бер үк келәмнәрне таптыйсың, шул ук саллы-затлы ишекләрне ачып керәсең...

Ә монда кеше фатирында елак бала кочаклап утыр менә...

Зәриянең йөрәгендә кайнаган тойгыларны сизде Ландыш. Гәүдәсе белән аңа борылып:

– Минем урынга кеше алмадылар әле, – диде. – Их, сине үзем белән алып кына китәр идем. Монда хасталар янында саргайганчы, рәхәт җирдә эшләр идең ичмаса! Койрыгың бозга каткан шул!..

– Нишләп алай дисең? – дип сораган Резидәгә:

– Моның белән эшли аламыни ул, – диде, аның тезендә утырган сабыйга ымлап. – Аннары балалы хатынны алмыйлар да. Урыны бик җаваплы. Бөтен җир ялтырап, балкып торырга тиеш.

– Бик теләсә, барып карап кайтсын соң... – диде Резидә.

– Бала күтәрепме?

Резидә бераз тынып утырды.

– Баланы мин карап торырмын... – диде, бер тын уйлагач. – Мондый форсат гел чыгып тормый. Ә мин нәрсә... Пенсионер карчык бит инде... Узган елгы отпускам да алынмаган... Барасы килсә барсын... Карап кайтсын... Аннары күз күрер....

Ул, башын иеп, әкрен сөйли, Зәриянең исә башы күтәрелә, йөзе аллана барды. Думада эшләргәме? Бөтен Рәсәйнең өстендә балкып торган Ак

йорттамы? Исеме илгә таралган шәхесләр белән бер ишекне ачып керергәме? Жириновскийның үзен бер күрү генә дә ни тора! Бу инде сиңа урын өстендә яткан карт-коры янында бөрешеп утыру түгел!

Һәр эшкә иң элек тәвәккәлләргә кирәк. Алдыңа максат куеп, беренче адымны ясасаң, калганы үзеннән-үзе алга барыла. Бу очракта икесе дә озак уйлап тормыйча гына тәвәккәлләделәр: Резидә – сабыйны карап торырга, Зәрия – Ландышка ияреп Мәскәүгә барырга… Юлы уңса, анда Ак йортка эшкә урнашыр, нияте барып чыкмаса, кире кайтыр.

Юлы уңды Зәриянең, һәммәсе Ландыш сөйләгәнчә булып чыкты. Яшәү урыны табу кыенрак икән, әмма анысы да хәл ителде: башта Ландышларда торып торыр, бер-ике ай эчендә тулай торакка урнашу җае табылыр.

Ә менә бала... Аны кая куярга? Тулай торакның биш кешелек бүлмәсенә алтынчы итеп бала алып килеп булмый...

– Бер-ике айга миндә калып торсын соң, – диде Резидә Мәскәүдән шундый хәбәрләр алып кайткан Зәриягә.

...Әйе, шулай, бер-ике айга гына дип уйланылган иде, вакытлыча гына дип. Ләкин күптән әйтелгән бит инде, вакытлыча дип уйланылган эш дәвамлы була дип. Монда да шулай килеп чыкты. Тулай торакта аерым бүлмә алу мәсьәләсе сузылды, ике айдан соң өченчесе дә, дүртенчесе дә үтте. Зәрия кулына кергән акчаның төгәл яртысын Резидәгә җибәрә торган итте.

Билгеле инде, яшь ананың сумнарына кызыгып кына бала карарга алынмас иде Резидә. Сәбәп аның күңелен мөлдерәмә тутырган, моңарчы тамчысы да сарыф ителмәгән саф, кодрәтле хистә – ана мәхәббәтендә иде.

Сабый бала пенсионер карчыкны яшьлегенә кайтаргандай итте, чын мәгънәсендә яшәү шатлыгы бирде. Ни генә дисәң дә, сәламәт баланы тәрбияләү хаста ананы карау түгел инде. Сабый туктаусыз куаныч китергәндәй тоелды Резидәгә. Сырхап алулары, борчу-елаулары күңелне суындырмады, аларын тәҗрибәле шәфкать туташы җиңел үткәрә, тиз арада дәвалый белә иде. Резидәне күрүгә яктырып елмаюлары, тез өстендә очынып сикеренүләре, йомшак куллары белән муеннан кысып кочаклаулары белән истә калды Динарның сабый чагы. Аның тәненнән килгән хуш истән затлырак хушбуйлар юктыр дөньяда. Аның сөеп каравыннан нурлы караш юктыр. Кайчакта вак кына нәрсәләр дә зур сөенеч булып күңелгә сеңеп кала. Менә Резидә баланы идәнгә, чәчкәле келәм уртасына утыртты да, бераз ара калдырып, каршысына уенчык машина куйды. И үрелә аңа сабый, алырга тырыша, буе җитми. Ниһаять, түшенә ятып, үрмәләп барып алды бит! И шуннан сөенүен күрсәң!.. Бала үскәндә, мондый куанычлар көн саен булучан. Резидәгә «әни» дип теле ачылуы үзе генә дә ни тора! Андый чакта кем генә киләчәкне уйлап баш катыра икән? Бүгенгесе белән яши ана! Әйе-әйе, күңеленең түрендә Резидә үзен чын-чынлап ана дип тоя иде. Бала, аның баюга барган гомер кояшын үз юлыннан туктатып, яңадан таң аттыргандай итте!

Беренче кыңгырау Динар бишен тутыргач шалтырады. Резидә аның туган көненә матрос костюмы алып кидергән иде. Малай ак тасма тегелгән якаларын, итәкләрен сыпыргалады да: «Яшь әни дә булса, әйбәт булыр иде», – дип куймасынмы! Күзе ачыла башлаган, чагыштырып карарга өйрәнгән нарасый: бакчадагы бүтән балаларның әниләре яшь, аныкы гына карт карчык. Резидәне күргәч, Динарга: «Әнә, әбиең килә!» – диләр еш кына.

Аңа кадәр үзенең картлыгы, чит кеше баласын тәрбияләве турындагы

уйларны куарга тырыша иде Резидә. Зәрия баштарак, ял саен булмаса да, бәйрәм саен кайта торган иде, баланың кадердә яшәгәнен күреп күңеле тынычлангангамы, тора-бара кайтулар сирәгәйде, сәбәпләре табылды. Алай да, Динарның теле ачылгач, аннары бераз аңлый башлагач, Резидә күрмәгәндә, ул аңа: «Синең әниең ул түгел, мин синең әниең», – дип әйткәли иде. Әйтә дә китеп бара, озак кына югалып тора.

Ул инде баласыз яшәргә көйләнгән, акчасын үз вакытында түләп барам, хәлен белеп торам, дип, үз намусы каршында аклана иде. Бер дә гаҗәп түгел бу, алимент түләүчеләр һәммәсе шулай уйлыйдыр.

Бөтен ил өстендә биегәеп балкып торган бинада эшләү аның күңелен үсендерде, тормышын чынлап торып җайга салу теләгән уятты. Нәфкатькә булган хисләрне тормышындагы үзгәрешләрнең дулкыннары юып алып китте. Аларга күрешүләр насыйп булмады: егет армиядән кайтмады, якут кызына өйләнеп җибәргән, контрактник булып ялланган, дигән сүзләр генә колакка килеп иреште. Атна-ун көнгә генә кунакка кайтып киткән икән үзе, тик моны Зәриягә хәбәр итеп тормаганнар.

Бу хакта ишеткәч, Зәрия әлләни кайгырмады. Авылда калган булса, авырга туры килер, хурлык койрыгы артыннан калмас иде. Мәскәүгә ул койрык тагылып килмәде. Анда халык күп, Ак йортның үзендә дә күз кунардай егетләр бар, арадан тиң булырлыкны табарга була иде. Һәм ул табылды да.

Ак йортта слесарь булып эшләүче Изаилнең язмышы үзенчә көйсез икән. Ул да Буадан, армиядә танкист булган, авариягә эләгеп, билен сындырган. Дәваланырга Мәскәүгә озатканнар. Яшьли сөйгән кызы, бу хәбәрне ишеткәч, дәшми-тынмый гына Буадан китеп барган... Бөтенләй кире якка – Ульянга. Шунда барып эшкә урнашкан. Имгәк егет белән язмышын бәйлисе килми икән, моның өчен аны кем гаепли ала?

Тернәкләнеп аягына баскан Изаилне якташлары Ак йортка урнаштырганнар. Тулай торактагы аерым бүлмәдә берничә ел ялгызы яшәп яткан.

Ике китек күңел тиз аңлаштылар. Әйе, күңелләре китек иде шул: Зәриянең – борыны белән баласы аркасында, Изаилнең – билен кысып тоткан корсеты аркасында. Серләр килешкәнгә күрәдерме, Изаил кызның борынында гаеп-кыек күрмәде. Улы барын исә бөтенләй белмәде. Кыскасы, табыштылар, кавыштылар болар, озакка сузмыйча, Зәрия кыз бала табып куйды. Аның тормышы шулай көйләнгәнгә иң нык сөенгән кеше Резидә булды. Көйсезлекләре исә Казаннан – сигез йөз чакрымнан караганда күренми иде.

Мәскәүдән караганда, Казандагы җайсызлыклар да бик күренми иде шул. Ә алар бала зурайган саен ишәя башлады. Малай атасына охшый барды: бүтәннәргә баш булырга, сугышырга яратты, укуга исә дәрте чамалы, икелеөчле тирәсендә тулганды. Үсә-үсә, Резидәне санга сукмый, сүзен тыңламый торган булып китте, тәмәке тарткалаганы сизелде. Аның татлы сулышын иснәп, йомшак кулларының назын тоеп, йөрәгенең кош баласыныкы кебек еш-еш тибүен ишетеп ләззәтләнүләр бетте. Малай бу карчыкның чит кеше икәнен инде яхшы аңлый, «әни» дип әйтергә дә авырсына, шул ук вакытта анасына да тартылганы сизелми, акчасын гына ярата иде. Аның бит әле акчасы да үскән саен күбрәк кирәк, ә чишмәсе саекты: семья коргач, бала тапкач, Зәриянең дә кесәсе такырайды. Улы барын иренә озак әйтми килде хатын, тора-бара форсатны ычкындырганын аңлады. Һәр эшнең генә түгел, һәр сүзнең дә үз вакыты бар икән!

Динарның киләчәген уйлаганда, Резидәнең мие кызыша башлый. Йөгәнсез

малайны туры юлдан гына алып барып, каршысында бәхетле киләчәкнең капкасын киң итеп ача алмаячагын яхшы аңлый иде ул.

Нәкъ шул чорда бер табиб егет тол калган әтисенә пар булырлык ипле, инсафлы апа табу турында хыялланып йөри иде. Шундыйракны белмисеңме, дип, Резидәгә дә сүз кушты. Аның үзенә өмет баглап булмаганын, чөнки янында үсмер малай барлыгын яшь табиб белә иде. Тол хатыннар арасыннан берәрсе табылмасмы? Авылда җыйнак кына булса да төзек йортлары, бакчалары бар.

Гомерендә бер тапкыр да яучы-димче булып карамаган Резидә бу табибны бик тә ихтирам итә, үтенечен кире кага алмады. Димләү чарасына керешкәнче, башта егетне күрергә, кемлеген чамаларга кирәк бит. Табиб әтисен Казанга алып килеп күрсәтергә булды.

Кыскасы, Резидә башта кияү белән танышты, аннары авылга барып, аның өен карап кайтырга ризалашты…

Тол ирнең өенә кергәч, кантарланып каткан кәстрүл-табаларын ничек юып ялтыратмыйсың да бакчадагы гөлләрне басып киткән алабуталарны ничек йолкып атмыйсың. Җан түзми, кул кычытып тора бит.

Моны карап торган абзыйның авызы ерылды, күзләре очкынланды. Кадерне белә торган, сөйкемле, ипле-көйле кеше булып чыкты ул.

…Мәктәптә каникул, Динар Мәскәүгә барырга ашкынып тора иде. Саубуллашу җиңел булды, аерылышу вакытлыча дип исәпләнде.

Җәйне генә авылда үткәрим әле, аннары күз күрер, дип кенә киткән иде Резидә, көзен кире кайтмады. Абзыкайның сокланулы карашы, олы рәхмәтен белдергән елмаюы, җан җылысы җибәрмәде аны. Гөлләр араларында күңелгә якын кеше белән чөкердәшеп яшәүдән кем ваз кичәр икән!

Дуылдатып туйлар үткәрмәсәләр дә, никахланыштылар, язылыштылар.

...Изаилнең башына таш булып төшкән, Зәриягә күп борчулар китерәчәк үсмер малай исә Мәскәүдә бөтенләйгә калырга тиеш иде.

Тереклек иясе буларак, адәм баласын еш кына агачка тиңлиләр. Ышанычлыныкларын – имәнгә, зифаларын – талга, якты-нәфисләрен – каенга. Күпләр үзенең шәҗәрә агачы белән горурлана. Ә менә Динарның юк иде андый агачы. Тамырлары белән җиргә нык берекмәгән, тотрыксыз иде ул. Атасын белми, анасының: «Әйбәт кеше иде, армиядә парашют белән сикергәндә һәлак булды, кабере Байкал күле артында», – дигән сүзенә ышанып ук бетми иде.

Алдагы өчен ишәк кайгырган, диләр, бу яктан караганда, Динарда ишәк акылы да булмады бугай – киләчәген уйлап баш ватмады. Мәктәпне тәмамлагач, институтка акча түләп укырга кергән иде, ярты елдан куып чыгардылар. Андамонда сугылып, эш эзләп карады, тапмады.

Белгәннәр аның киләчәгенә якты өметләр багламыйлар, киресенчә, тагын нинди афәткә тарыр икән бу бала, дип, авыр сулап куялар иде…



*Равилә Шәйдуллина-Мурат 1949 елда Татарстанның Теләче районы Алан авылында туа. Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлый. «Ялантауга ай кунган» (2016), «Сихәтләнү» (2016), «Ялантау» (2017), балалар өчен «Батыр малай» (2010), «Алмагач дәресе» (2012) һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Равилә
Шәйдуллина-Мурат

# КӨЗЛӘРДӘН ЮАТУ ЭЗЛӘМӘ...

## Бичураның бәби туе

Әни бүген озатып кайтты
Яшьтәшенең иң соңгысын,
Тәгәрәшеп бергә үскән
Ахирәтен, соңгы дустын,
Еламады, намазлыкта
Тыныч кына кылды дога:
«Бу бәндәңә, бу колыңа
Җәннәтеңне бирче, Хода!»
...Ишек шакый фанилыкның
Туксанынчы көзе менә.
«Оныттыңмы әллә, Әҗәл,
Әллә гомрем булдымы җәл?
Башкаларга гыйбрәт өчен
Калдырдыңмы әллә мине
Тере тарих итеп кенә?»
...Җиргә килде яңа буын,
Ямьсез буын, гамьсез буын,
Аңлап булмый теләкләрен,
Ниятләрен, телен, уен...
Байлык өчен җанын сатып,
Һәр төн саен ясый алар
Бичураның бәби туен.

Туган нигез ясин көтә...
Булмый кереп:
Явыз эте, сары эте
Бәйләп куйган бүре кебек.

Туган, димәс, чәйнәп өзәр,
Килмә якын,
Алар күптән онытканнар
Туган хакын,
Алла хакын...
Капка-койма затлы үзе,
Ләкин биек.
Үтә алмас һичбер адәм,
Һичбер киек.
Кермәк булып җилләр улый,
Җилләр чаба.
Һәм карт шомырт
Бертуктаусыз,
Башын иеп, тәрәз кага:
– Кем бар анда?
– Әй, Бичура, тәрәзәң ач,
Төп нигезгә туксан яшьлек
кызың килгән,
Соңгы тапкыр ясин чыгу
ниятеннән.
Ишегеңнән керә алмый –
Этең усал.
...Бичура да картайган шул,
Чукракланган...
Ишетмиме?
– Ач, Бичура, эт бәйләгән ишегеңне...
Күзең ач та күр син, кара:
Туксан яшькә җиткән карчык,
Аксый-туксый,
Мәңгелеккә китеп бара.
Минут саен ерагая
Сезнең ара.
Ә карт шомырт,
Өметләнеп, әле һаман
Тәрәз кага.
Ишетмиләр...
Төп нигездә бит Бичура
Оныгының туе бара...

## Гомер көзе

Көз. Салкын. Яңгырлы.
Эзлим мин югалган җылыны.
Юатыйм күшеккән җанымны.

Көз. Салкын. Чәчәкләр
Иелгән чәчәкләр таҗына.
Кызыгып карыйм мин барына.

Көз. Салкын. Кырпак кар.
Гөлләрнең таҗына кунган кар.
Миндә дә чәчәкләр зары бар.

Көз. Салкын. Ак томан.
Кышларга кергәндә, кемдә дә
Куерган сагышлар бар сыман.

Чәчәкләр... Елыйлар!
Бу – көзләр яңгыры күзләрдә.
Көзләрдән юату эзләмә!..

## Сихәтләнү...

Егылдым мин каты чирдән,
Җир җимертеп йөргән җирдән.
Һава җитми суларыма,
Көннәр буе ятып торам,
Карап кеше кулларына.

Бәхет юк, дип йөргәннәрем
Кысыр хәсрәт булып калды.
Яшәү дәрте күңелемне,
Вөҗүдемне биләп алды.

Сихәтләнгәч чирләремнән,
Түзми җанның ярсуына,
Ак пәрдәле ак иртәдә
Чыгып киттем таң суына.

Көлә-көлә тамчылары
Кереп тулды чиләгемә.
Пар чиләкле көянтәмне
Элеп куйдым иңнәремә.

Чиләкләрем бизәкләде
Алсу таңның сурәтләре.
Түгелмәсен тамчы суы –
Таң суында ниятләрем.

## Китеп кенә торам

Гомер үтә, кеше үлә, имеш...
Ә мин никтер бер дә үлмәм кебек.
Посып калырмын күк, оныкларның
Күңеленә, җаннарына кереп.

Юк, үлмәм мин, коелырмын гына
Яфрак булып агач төпләренә.
Ак бураннар булып дулармын да
Әйләнермен ак кар көртләренә.

Юк, үлмәм мин, түгелермен генә
Гомер касәсенә мөлдерәмә тулып.
Ямансулап җиргә таралырмын,
Таң атканда ак томаннар булып.

Юк, үлмәм мин, җиргә әйләнермен,
Гөлләр тамырына һәм дә гөлгә.
Шытып чыгып, хәер-дога теләп
Зекер әйтер өчен һәрбер көнгә.

## Яшьлекне эзләү

Чәчкәләрем көзләр булып елый,
Юатырга янда ишем юк.
Кочаклашып уза ять-яшь парлар,
Аларның шул миндә эше юк.

Бәхетлеләр уза янәшәмнән,
Ел фасылы тими парлыларга...
«Бу бит безнең сукмак иде!» – диеп,
Эчтән генә дәшәм аларга.

Әй бу сукмак! Мәхәббәтне саклап
Басып торам монда ялгызым.
...Таныш шәүлә күрми китеп бара
Хыялында калган хур кызын...

Куеныма алдым, җылытырмын:
Ялгыз күшекмәсен хыялым.
Кара төнне икәү кичәрбез без,
Төн артында көтәр уяну.

Ә әлегә... Җанда кайтавазмы,
Китеп барган кошлар өнеме?!
Алар – көнгә, ә мин төнгә керәм –
Ялгызлыкның тәүге төненә...


## Күңел күбәләгем

Әйтмә миңа авыр сүзләр,
Рәнҗетим моны, димә.
Минем күңел күбәләгем
Бер кырын күздән үлә.

Мин – күбәләк, син чәчәк бул,
Шайтан таягы нигә?
Чәнечкеләрең кадалса,
Иреннәрем тиюгә,
Түзә-түзә түзәрмен дә
Очып китәрмен җилдә.

Ә хәзергә энәле син.
Белеп торам: инәлерсең.
Бәлки, гафу үтенерсең,
Үкенгәндәй итенерсең...

Тик ни файда үкенүдән,
Күбәләкне үтерүдән?..



Фарсель
Зыятдинов

# ӘГӘР ДӘ БУ КЕШЕ ВАФАТ БУЛСА...

НОВЕЛЛА

Ул кичтә аның кәефе юк иде. Әмма почта тартмасы хатларга ифрат та бай булып чыкты, шуларны барларга тотынды. Берьюлы җиде хат килгән. Алтысы – Лерон түләргә тиешле хисаплар. Әмма ул аларны якын көннәрдә генә түләргә әзер түгел иде. Шуңа күрә боларын да шкафта өелеп яткан, түләнмәгән счётлар өстенә ыргытты.

Җиденче хатта счёт та, «бурычыгызны вакытында түләмәсәгез, җавап бирергә туры килер» дигән шелтә сүзләре дә юк иде. Бары тик аның урта бер җиренә генә эре хәрефләр белән ниндидер фамилия язып куелган:

«Җәмил әфәнде Сабир».

Шушы ук биттә бер юл астарак болай дип тә өстәлгән:

«Әгәр дә бу кеше вафат булса... сез илле мең тәңкә акча алачаксыз».

Лерон башта шикләнеп калды. Коллектор хезмәткәрләренең шаяртуы түгел микән дип уйлады. Аннары, тынычлана төшкәч, хатны тагын бер кат әйләндерде дә конвертына текәлде: шикләнерлек нәрсә юк кебек. Тик кем җибәргәне генә күрсәтелмәгән. Бары аның фамилиясе, исеме һәм адресы гына куелган һәм шәһәр почтасының мөһере сугылган... Лерон, авыз эченнән генә нәрсәдер сөйләнде дә, конвертны ертып, чүп савытына ыргытты.

Икенче көнне Лерон бу хакта тагын бер исенә төшереп алды. Башка проблемалары да җитәрлек иде. Ул бит Җәмил әфәнде Сабирны бөтенләй белми, аның турында ишеткәне дә юк. Шуңа күрә илле мең сум алырмын дип уена да китермәде. Бу турыда беркемгә дә, хәтта хатынына да әйтмәде. Банктан, түләнмәгән кредитын түләүне таләп итеп шалтыраткан ханымга да сиздермәде. Югыйсә, «Җәмил әфәндедән алачагым бар, якын көннәрдә бурычымны түләячәкмен», дип әйтә ала иде бит.

Шуннан соң ул, гадәттәгечә, «акча уйнау» йортына ашыкты. Бәхетенә дигәндәй, башта 900 сум отты. Аннан 800не оттырды. Акча уены белән мавыгып, әлеге сәер хат турында онытып та җибәргән иде инде.

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ (1937) – *шагыйрь, икътисад фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе; «Онытылмас авазлар», «Яшәү мәгънәсе», «Безнең гомер» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

Өенә кайтса, яңа бер хатка тап булды. Ул монысын ертмады. Конвертны, балаларча аптырап, кулында әйләндерде-әйләндерде дә, аннан тышындагы имзаны абайлап, саклык белән генә ачты һәм шулчак дүрткә бөкләнгән бер бит кәгазь эченнән өстәлгә ун данә бишәр мең сумлык купюра коелып төште.

Бу минутларда ул үзен әлеге хат җибәрүче затка бурычлы итеп тойды, ниндидер җаваплылык кичерде, уйланды: әлеге яхшылыгы өчен нинди дә булса таләп куйса, дигән шик тә уянды... Озак уйланды. Аннары кулын селтәп, машинкада басылган биттәге язуга күз төшерде. Анда: «Бераз гына рәхмәтлемен Сезгә», дип язылган, әмма берninди таләп тә куелмаган. Бары тик битнең нәкъ урта бер җирендә бу юлы башка исем – «Гарифулла әфәнде Хәким» диелгән. Ә аз гына түбәндәрәк: «Әгәр дә бу кеше вафат булса... Сезгә 75 мең тәңкә акча киләчәк», – дип тә өстәлгән иде.

Шуннан соң Лерон, үз-үзен тынычландырып, Гарифулла әфәндегә бернинди дә зыян китерергә теләмәвен тәкрарларга кереште. Әмма бит 75 мең тәңкә аз акча түгел. Җибәрсәләр, аны файдаланыр урын табар иде. Юк, Гарифулланың үлемен тизләтүне уена да кертеп караганы юк. Шулай да аның белән ни дә булса килеп чыкса... нәрсә эшләргә?

Нәрсәдер килеп чыкса... Биш көн үткәч, газеталарны кулына алса, күзенә кайгы уртаклашкан хәбәрләр чалынды: Гарифулланың вафаты турында язылган иде аның берсендә. Ул инде яшь түгел, шактый ук өлкән кеше икән. Озак авырудан соң, картлар йортында үзенең караватында җан биргән. Газетада чыккан белдерүне укыгач, Леронның бөтен тәне буйлап ниндидер тетрәнү йөгереп үтте. Гарифулланың үлемендә ничектер бу юлы ул үзен гаепле кебек сизде. Шулай да аның ни катнашы бар соң? Ул бит аны үлемгә китерердәй бернинди гамәл дә кылмады. Картайган һәм авыру Гарифуллага, димәк, үз үлеме килгән. Шулай да бу карт, авыру затның үлеме уңаеннан Леронга ни өчен акча җибәрергә тиешләр? Ни өчен?

Күпме генә уйласа да, кемнәрнеңдер, кайчан да булса, аның кулы белән бик мөһим затны юлдан алырга әзерләнүләрен аңлый алмады.

Шулай да бу гамәлне кемдер эшли бит. Леронны болар, акча алырга өйрәтеп, хәлиткеч көнгә әзерлиләр иде. Ул көнне иртән иртүк Леронга өч хат кертеп бирделәр. Аның икесендә процент өчен бурычларын түләмәгәнгә кисәтү ясалган, аларны ул шунда ук кәрзингә ыргытты. Ә ак конвертны саклык белән генә ачты. Аннан соң ул, әлеге яшерен хатның хикмәтенә төшенергә теләгәндәй, селкенмичә, тып-тын уйланып утырды.

Сәер! Каян ява соң бу кадәр акча? Аның бит эшләп-эшләп тә мондый ук тәңкәләр алганы булмады. Фирмада эшләгәндә, атнасына 40-45 сәгать өчен нибары биш-алты мең түлиләр иде. Аена 20-25 мең сум чамасы чыга иде. Ә аноним хат авторы инде аңа айлык хезмәт хакыннан күбрәк түләде... Шулчак конверт эченнән өстәлгә тагын унбиш данә бишәр меңлек купюра коелып төште. Ә хатның эчтәлеге алдагыларыннан әллә ни аерылмый диярлек. Иң аста, әүвәлгечә: «Бераз гына рәхмәтлемен Сезгә!» диелгән иде. Бары тик чираттагы үлем көтүченең фамилиясе генә үзгә. Бу юлы «Мирфатыйх әфәнде Исхаков» дип куелган. Тагын да астарак: «Әгәр дә бу кеше вафат булса... 100 мең тәңкә алачаксыз», – диелгән. Леронның куллары калтырады. Бу аның өчен бик зур сумма иде. Ул җәһәт кенә телефон кенәгәсенә үрелде һәм ашыга-ашыга белешмәне актара башлады: «Әһә, исеме бар икән. Мирфатыйх әфәнде... Фучик урамында яши икән...»

Шуннан ул белешмәне шап итеп япты да әлеге хикмәтле хәлне башыннан

чыгарып ташларга теләде... Әмма ул моны эшли алмады. Моңа ул инде сәләтле түгел иде. Ул бирелде. Белешмәне кабат кулына алды да фаразлый башлады: «Бу кеше тагын нәрсәдән үләр икән? Бу бит котылгысыз, шулай түгелме?» Кемдер аңа вафат буласы затның исемен җиткерде. Димәк, ул кеше дә бакыйлыкка күчәчәк. Һәм шуның өчен Леронга акча түлиләр, чөнки Мирфатыйх инде үлемгә хөкем ителгән.

Ул белешмәдә күрсәтелгән телефон номерын җыйды. Трубканы бер ханым алды. Лерон аннан: «Мирфатыйх әфәнде белән сөйләшеп булмасмы?» – дип сорады.

– Мирфатыйх әфәнде хастаханәдә, – диде әлеге ханым. – Ә кем сорый аны?

– Рәхмәт сезгә, – диде Лерон, – рәхмәт. – «Аңлашылды», дип уйлап алгач, трубканы куйды. Болар кемнәр генә булмасын, якын арада вафат булырга тиешле затны ачыклыйлар. Ә инде үлеме котылгысызлыгын белгәч, Леронга хат һәм акча юллыйлар! Әмма ни өчен?! Аңлашылмый! Бу акчаны җибәрүче үз акылындамы? Леронга шунысы ачык түгел. Әмма ул үзе беркайчан да акчадан баш тартырга җыенмый, асылын ачыкларга да теләми. Әлегә үзен хәлиткеч көнгә әзерләүләрен дә төшенми. Җибәрәләр икән, җибәрсеннәр...

Төштән соң Лерон хастаханәгә шалтыратты. «Моннан ике көн элек Мирфатыйх катлаулы операция кичерде», – диде аңа медсестра, хәзер реанимациядә, хәле уңайлана.

«Димәк, рецидив булырга мөмкин, – дип уйлады Лерон, – югыйсә, бу зат бит үлемгә хөкем ителгән, аның үлемен хат авторы алдан билгеләгән бит». Мирфатыйх әфәндене Лерон үзенчә кызганды һәм шунда ук «акча уйнау» йортын исенә төшерде. Һәм янә шунда юнәлде. Биредә бу юлы да аның теләге акланмады. Башта биш йөз сум откан иде, соңыннан булган барлык акчасын оттырып бетерде. Уйнау өчен «сәмән» бик кирәк иде аңа.

Берничә көн үткәннән соң, ул кабат хастаханәгә шалтыратты. Шул ук шәфкать туташы аңа Мирфатыйх әфәнденең сәламәтләнеп килүен җиткерде. Шуннан соң да Лерон берничә көн рәттән авыруның хәлен белешеп торды. Беркөнне исә медсестра авыруның хәле начараеп китүен, аңын югалтуын әйтте. Әмма икенче көнне шул ук ханым, куанычлы тавыш белән, авыруның терелүен һәм хастаханәдән өенә чыгып китүен җиткерде. Лерон исә, моны ишеткәч, әллә нишләп калды, бүртенде, ачуы чыкты. Ниндидер көтелмәгән хәл булгандыр, югыйсә терелмәс иде, дип нәтиҗә ясады ул. Әгәр дә Мирфатыйх әфәнде вафат булса, бүген бит кулына өстәмә рәвештә 100 мең тәңкә кергән булыр иде. Әйе, Мирфатыйх әфәнде үлем алдында иде, әмма ул терелде, һәм Лерон керемнән мәхрүм калды.

Алдагы көннәрдә дә Лерон яңа хат көтте. Әмма нишләптер хат килмәде. Нәтиҗәдә, ул чираттагы взносын да түли алмады. Фатир өчен дә ике-өч ай түләнгәне юк. Бурычын бирмәгән өчен, аңа берничә кисәтү хаты килсә дә, көткән конверт күренмәде. Леронның кабат ачуы кабарды. Алдагы хатта бит: «Әгәр дә бу кеше вафат булса...» – диелгән иде. Башка бернинди шартлар да, түләү сроклары да күрсәтелмәгән. Үлемсез зат түгел бит инде бу Мирфатыйх әфәнде югыйсә! Барыбер ул соңгы сулышын алачак. Һәм Леронга үзенең 100 меңе киләчәк. Әйтик, Мирфатыйх әфәнде фани дөньядан китсә, яисә бу эш турыдан-туры Леронның катнашы белән эшләнсә (ул сискәнеп китте: «Аллам сакласын!»). Ул үтерүче түгел бит. Мондый нәрсәне башына китереп карарга да ярамый. Ул бит 100 мең тәңкәдән башка да яши алачак. Әлбәттә... Дөрес, ул бу акчаларга күңеле белән күнеккән иде. Дөресрәге, чираттагы керемне

дә инде үз кесәсендә дип хис итә башлаган иде. Нинди хөсетле кара уйлар!

Әмма икенче көнне Мирфатыйх әфәнденең исеме күпчелек газеталарның беренче битендә үк дөнья күрде. Үткән төндә аның Фучик урамындагы фатирына кемдер үтеп кергән дә Мирфатыйх әфәндене ятагында чәнчеп үтергән. Мотивлары да әлегә билгеле түгел, ди. Дөресрәге, ачыклый алмаганнар, иминлекне саклау вәкилләре шул тарафта әлегә эш алып баралар, ди...

Бу юлларны укыгач, аның уң як кашы тартышып куйды. Үзен өлешчә генә булса да гаепле тойды, чөнки ул да бит аның үлемен көтте. Шуңадыр, Мирфатыйхның йөрәгенә пычакны үзе кадагандай хис итте. Гүя, төн карасыннан файдаланып, аның фатирына үзе кереп, үтерүдә катнашкандай тоелды. Ә чынында исә бу җинаятькә бернинди дә катнашы юк иде. Әйе, ул бу турыда уйлавын-уйлады. Мондый хәлнең булуын да теләде. Хәзер исә: «Аллага шөкер, минем бер гаебем дә юк бу эштә», – диеп, җиңел сулап куйды.

Хатны бары тик икенче көнне генә китерделәр. Анда инде егерме данә бишәр меңлек купюра салынган иде. Һәм әлеге дә баягы таныш текст.

«Бераз гына рәхмәтлемен сезгә».

«Миңа рәхмәт?! Ни өчен?! Миңа рәхмәтегез кирәк түгел сезнең!» – дип сөйләнә-сөйләнә, ул акчаны янчыгына салды. «Миңа түгел, үтерүчегә әйтегез, кирәк булса, рәхмәтегезне...» Бу хатта яңа исем дә язылган иде:

«Мисбах әфәнде Арсланов», диелгән. «Гаҗәп! Ни хәл соң бу?!

Ә түбәндәрәк таныш сүзләр тезелеп киткән. «Әгәр дә бу кеше вафат булса... Сез 150 мең тәңкә алачаксыз».

Леронның конверт тоткан кулы бер мизгелдә һавада хәрәкәтсез асылынып калды. Ул авыр сулый иде. Йөрәге тәртипсез тибә башлады. Шулай да үзен кулга алып, хатка тагын бер кат күз йөртеп чыкты. Аннары элек килгән хатларны да алып, барысын бергә ертты да унитазга ташлады һәм су җибәрде.

Димәк, чиратта Мисбах әфәнде, дип уйлады Лерон. Һәм иртә белән тагын телефон кенәгәсен актара башлады. Мисбах Зорге урамындагы күпкатлы йортта яши икән. Лерон аңа шалтыратырга тырышып караса да, җавап бирүче булмады. Соңыннан ачыкланганча, Мисбах шәһәр советы депутаты икән. Белешмәдә аның офис телефоны бар иде. Ул телефон номерын җыйды.

– Мисбах әфәнде конференциягә китте, – диде секретаре, – аңа нәрсә дә булса җиткерергә кирәк түгелме?

«Әгәр дә бу кеше вафат булса...» дигән сүзләр бөтерелде аның башында. Ә бит Мисбах әфәнде – нык сәламәт, эше тыгыз булуына карамастан, конференциягә барырга да вакыт тапкан. Леронга хат җибәргән кеше бу турыда белмәде микәнни?! Үләрлек түгел икән бит ул! Әгәр дә үлмәсә, 150 мең тәңкә килмәскә мөмкин ләбаса бу юлы. Үземә тырышырга туры килер, ахры, монысында. Тик ничек? Леронның револьверы, пистолеты да юк, каян алырга икәнлеген дә белми. Аннан, Лерон бер гаепсез кешегә кул күтәрә алыр микән соң? Бәлкем, автомобиль белән генә бәрдерергәдер? Чынлап та шулай эшләсәң? Ишектән чыкканын карап торырга да өстеннән үтәргә. Бу артык четерекле эш түгел. Тик шунысы бар: полиция андый җинаятьләрне бик тиз ачыклый.

– Төкер һәм онып, – дип, ул үз-үзен тынычландырырга кереште.

Әмма барыбер бу турыда оныта алмады. Ике көн буе төрле ысуллар табарга тырышып карады. Тик башына юньле уй килмәде. Бары тик Мисбах һәм үзенә киләчәк 150 мең тәңкә генә баш миен бораулады. Аны ничек юк итәргә икән?!

Беркөнне ул гадәттәгедән иртәрәк торды да «Мисбах» компаниясе

урнашкан йорт ягына китте. Аныңча, хуҗа кеше шул тирәдә чуалырга тиеш иде. Машинасына утырган килеш, теге затның ишектән чыкканын күзәтә башлады. Ниһаять, депутат ишектән чыкты һәм турыдан гына юлның икенче ягына юнәлде. Лерон инде аягын газ педаленә куйган иде, стартерны кушасы да педальгә генә басасы калды.

Ул моны эшли алмады, йөрәге җитмәде, курыкты. Дөрес, аны хат җибәрүче белән әлегә ачыктан-ачык бернәрсә дә бәйләми. Шулай да Мисбах белән аны бәйләгән нәрсәсе юк, дисәң, дөрес булмас. Леронның әбисенә бурычлы ул. Әбисенең ике миллион сум акчасын үзләштергән иде аның компаниясе. Ә бу оешманың директоры – Мисбахның хәләл җефете. Күптән түгел халыктан җыелган миллионнар алар кулына күчте. Һичюгында теге хатта күрсәтелгән 150 меңне кайтарып калырга кирәк дип уйлады ул.

Чәршәмбе көнне иртә белән Лерон хатынына шалтыратты. Бүген өйгә кайтып тормыйм, турыдан-туры эшкә китәм, диде. Әмма эшкә китмәде. Теге кара исеме чыккан компания урнашкан бина ягына юнәлде. Машинасын читкәрәк куйды да күзәтә башлады. Чыгучы булмагач, офиска үзе керергә уйлады. Вахтёр читкәрәк китү белән, шыпырт кына офисның эченә үтте. Вахтёр дигәне, күрәсең, форма өчен генә куелган булгандыр. Биредә Леронга рәтле-башлы игътибар итүче дә булмады. Ул тиз арада Мисбах әфәнде утыра торган бүлмәне эзләп тапты. Каушаудан тирләп чыкты, йөзе-төсе үзгәрде, калтырана башлады. Кемнеңдер баскычтан менеп килгәне ишетелгән кебек тоелды.

Мисбах әфәнде Арсланов утыра торган бүлмәне барлагач, Леронга көч керде. Хәзер инде ул үз-үзенә ышана иде. Барысы да бит өстә хәл ителә. Тегеләрнең дә язмышы шунда – өстә хәл ителгән иде. Һәм ул аларны тагын бер кат күңеле аша үткәрде: Җәмил әфәнде Сабир да үлемгә хөкем ителгән иде, Мирфатыйх әфәнде Исхаков та, Гарифулла әфәнде Хәким дә хөкем ителгәннәр иде. Барысы да вафат булдылар. Мисбах Арсланов та нәкъ шулар кебек үк үлемгә хөкем ителгән зат. Димәк, ул да китәргә тиеш!

Лерон бу мизгелдә үзен тулы бер системаның кисәкчеге – гигант механизмның шөребе дип хис итте. Ул юк-барларга игътибар юнәлтмичә, үз эшен башкарып чыгачак. Барысы да ул уйлаганча булыр.

Ишек артында ир ике сәгать көтте. Тын да алмыйча, кыл да кыймылдатмыйча көтте. Ниһаять, ишек тишегендә ачкыч борган тавыш ишетелде, бераздан Мисбах үзе күренде. Шулчак ул Мисбах әфәнденең башына тимер белән орды, үзе ишек артына посты. Ышанычлырак булсын өчен, җан биреп ятучы әфәнденең башына тимер тукмак белән тагын ике менеп төште.

Лерон шуннан соң бармак эзе калырдай урыннарны яхшылап сөртте дә урамга юнәлде.

Ул төн буе йоклый алмый газапланып чыкты... Дер-дер калтырады... Менә-менә килеп керерләр күк тоелды...

Пәнҗешәмбе көнне аның исеменә күп хатлар килде. Әмма ак төстәге конверт күренмәде. Анысы җомга көнне генә пәйда булды. Бу конверт гадәттәгедән калынрак. Аның эчендә утыз данә бишәр меңлек купюралар салынган иде. Акчасыннан бигрәк, ахырдагы сүзләр гаҗәпләндерде: «Яңа һөнәрегез ошадымы соң инде? Ошаса, котлыйбыз Сезне», – диелгән иде.



Райнур
Әгъләметдинов

# ЧАТ

хикәя

Урамда яңгыр ява. Чиләкләп коя. Әйтерсең: «Яңгыр кирәк, яңгыр җитми», дип зарлана идегез. Менә сезгә яңгыр, рәхәтләнегез!» – диюе... Чулпан үзенең кызы белән хастаханәдән кайтып бара. Автобус тулы кеше. Яңгыр коеп яуганда, гел шулай шыплап тула ул.

«Нур» мәчете тукталышы. Киләсе тукталыш – Горький паркы».

– Әни, әнә, бабай! – Җиде яшьлек Сәйдә, парланган тәрәзәне кулы белән сөрткәләп, зур түгәрәк ясаган. Шул түгәрәккә нәни бармагын төртә.

– Кызым, тик кенә утыр.

– Галимҗан бабайга охшаган... – дип кабатлады кыз.

– Каян килеп Галимҗан бабаң булсын инде ул, кызым? Ниндидер сукбай. Кагылма тәрәзәгә. Кофтаңны пычратып бетергәнсең бит инде, җә. Ник тик кенә утыра белмисең икән син?!

Кыз бала күзен һаман тәрәзәдән алмады. Әнисе җилтерәтеп утыргычка утыртты, Сәйдә исә янә урамга үрелде. Сукбайга кул болгады. Аңа җавап итеп, сукбай да кулын күтәрде. Хәлсез кулын. Кыяфәте юк: тормыш таягы кыйнапмы-кыйнаган. Йөзендә мең дә бер җыерчык, яра эзе. Күптәнгеләре дә бар, яңалары да. Яңалары кызарып кутырлаган. Чәч-баш – җир-тузан. Шул пычрак, бит буйлап юылып, иягеннән тама. Күзләрендә – кара болыт, боз болыты. Шек... шек... Шул болыттан, туң күңел такталарына бәрелә-бәрелә, боз кисәкләре коела кебек. Йөрәкне өшетә...

Сәйдә сукбайга карап елмайды. Самими, беркатлы бала елмаюы иде ул. Бәхете чәчрәп торган.

Сез шунда сукбайны күрсәгез! Әле генә кара болыт каплаган карашы үзгәрде дә куйды. Кара болытны ертып кояш чыкты. Аннан ургылган яктылык урамда коеп яуган яңгырны, җиде нурга, җиде төскә җыеп, шәһәр күгенә элеп куйды. Салават күпере мәллә? Әйе, салават күпере! Ул күперне Сәйдә дә күрде. Күрде дә тагын да ныграк шатланып, көлеп җибәрде.

– Болгама теләсә кемгә кулыңны, кызым! – Кызганыч, әнисе генә берни күрмәде. – Нинди хәл ул?! Мин сиңа күпме әйттем! Бер колагыңа керми.

Юлларда көймә йөздерерлек су-күлләвекләр пәйда булды. Ярты сәгать эчендә җыелды алар. Шул су-күлләвекне як-якка чәчрәтеп, машиналар тыз-

Райнур ӘГЪЛӘМЕТДИНОВ (1988) – *яшь язучы; Мамадыш районының Урта Кирмән авылында туган. Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультетын тәмамлаган. «Иделем акчарлагы» конкурсында проза буенча Гран-при лауреаты (2007). Чаллыда яши.*

быз чапты. Вакыт – кичке биш, халыкның эштән кайтып барышы. Барысы да өйләренә ашыга.

Автобус кузгалды. Сәйдә барыбер тәрәзәдәге түгәрәктән күзен алмады. Теге сукбай автобус артыннан кулын күтәргән килеш карап калды. Кечкенә бер ноктага әйләнгәнче...

***

Моннан дүрт ел элек көз иртә килде. Сентябрьдә әле җылы була торган иде. Августның соңгы көннәрендә үк көз үз чыбыркысын шартлата башлады. Салкын, пычрак, яңгыр. Яратмый Чулпан көзне. Чөнки күңелне сагыш белән тутыра. Ә Чулпан бер сагышланса, каты сагышлана. Күңеле тула, елый башлый. Ә еларлык сәбәпләр шактый. Бик үк яхшы иргә эләкмәде ул. Эчәргә ярата торган булып чыкты. Танышкан гына чакта бер дә алай кебек түгел иде. Баһадир гәүдәле, типсә тимер өзәрлек ир, шул ук вакытта күзләре һәрвакыт елмаеп-көлеп тора, аралашырга ансат, рәхәт кеше. Чулпан аны бер күрүдә ошатты, бигрәк тә шул елмаеп торган күзләренә алданды.

Бүген шәһәрдән, ярминкәдән кайтып барышы. Җиләк-җимеш, яшелчә саттылар. Ике көнгә дип киттеләр, Чулпан икетуган апаларында куна калырга тиеш иде. Ходай рәхмәте, алып килгән тауарлары бик тиз сатылып бетте. Сәгать кичке бишләр тирәсендә бер әбигә соңгы кәбестәне төреп бирде.

– Тәмләп ашагыз.

– Рәхмәт яусын, кызым.

Болай булгач, кунып яталармы?! Җыенып юлга да кузгалдылар...

«Рәкыйпкә көтелмәгән бүләк ясыйм әле. Шатландырыйм. Кайтуына ашарына пешереп куйыйм», – дип уйлады Чулпан. Рәкыйп хәзер комбайнда төн уртасына кадәр эшли, урып-җыю вакыты бит.

...Өй капкасы бикле иде. Тик тыштан түгел, ә эчтән. Сәер... Ник алай соң әле бу? Шаяралармы?

Чулпан берни аңламады. Уңлы-суллы бөтерелеп, нәрсә эшләргә белмичә капка төбендә шактый басып торды. Дөбердәтергәме? Шакыргамы? Өйдә кеше булырга тиеш бит. Капка тик торганнан эчтән бикләнә алмый!

Кибетче Суфия апа кайтып бара иде. Авылда бар яңалык кибеттә була. Бөтен гайбәтне шунда кереп чәйниләр. Чулпан белә: Суфия апага кеше белмәгән бөтен серләр таныш.

– Нишләп басып торасың, кызым? Кертмиләрме әллә? – дип шаяртнандай итте ул.

– Исәнме, Суфия апа.

– Исәнме, исәнме... Бакча артлап кереп кара инде, моннан булмагач.

– Рәкыйп эштә түгелмени соң бүген?

– Бүген иртән яңгыр коеп яуды. Эшкә чыкмады алар.

– Казанда яумады...

– Казанга тиклем җитмеш чакрым бит ара. Урыны белән коя, урыны белән кояш.

– Эчтән ник бикләп куйган инде бу?

– Бакча артлатып кер син. Тавышланмыйчарак.

– Нишләп алай дисең?

– Моннан керә алмагач, дим...

Чулпан, аптыраса да, бакча артлатып керергә булды.

– Йә Аллам! Нәрсә бу?

Баскыч төбендә чит хатын-кызның аяк киемен күреп, Чулпанның күз аллары караңгыланып китте.

– Рәкыйп!

Ишекне ачкач та нәрсә күрәчәге күзалдына килеп баскан иде инде аның. Колагында Суфия апаның сүзләре: «Тавышланма, бакча артлатып кер».

Башындагы ямьсез уе хата гына булса иде... Теләсә нәрсә күрергә әзер иде Чулпан, тик хыянәтне генә түгел.

Ишекләр, ачылганда, ишетелер-ишетелмәс шыгырдап алды.

– Рәкыйп!

Тәрәзә буена аш бүлмәсендәге кечкенә өстәл кереп утырган. Өстәл тулы кабымлык, буш шешәләр һәм чит хатын-кыз исе...

Бер мизгел эчендә бөтен тормыш чәлпәрәмә килде. Монда басып торуның файдасы юк иде инде.

– Молодец, Рәкыйп... – дип, бугазындагы төерен көч-хәл белән йотты да... борылды да чыгып йөгерде. Кая барганын белмичә чапты. Алны да, артны да күрмәде. Ә күзләреннән бертуктаусыз яшь акты...

***

Һәр авылда эшкә нык кешеләр була. Җир җимертеп эшли торган ирләр. Алар тракторда, алар комбайнда яисә кырда, кулларына чалгы тотып, иртә-кич печән сызгырталар. Яз-җәй төнлә, ерактан-ерактан, бер сызыкка тоташып авылга таба аккан трактор гөрелтесенең ишетелер-ишетелмәс авазын тыңлаганыгыз бармы?

Террррр... Террррр... Төне буе терелди ул. Бер сәгатьлек тынлык, аннары иртәнге биштә тагын «терр» башлана...

Ул тракторларда авылның иң нык кешеләре эшли. Совет тәрбиясе алган ил уллары. Эшләүләре – мөмкинлекләренә карап, алган хаклары – хаҗәтләренчә.

Галимҗан абый да – шундыйлар рәтеннән. Ярты гомере трактор штурвалы артында узды. Була бит шундый кешеләр, аларга акча да, тәхет тә кирәкми. Алар – эш атлары. Рәхмәт өчен, кемгә дә булса файда китерүләрен тоюдан ләззәт, рәхәтлек алып яшәүче кешеләр. Яше буенча инде ул күптән лаеклы ялда. Барыбер, тракторына утыра да кырга чыгып китә, утыра да чыгып китә. Сүз әйтүче юк, киресенчә, элекке колхоз рәисе, бүген КФХ* җитәкчесе – җирбиләүчеләр шат кына. Ник дисәң, аның хәзер җирендә эшләргә кешесе дә калмады. Галимҗан абый кебек нык кешеләр исән булсын. Картайды инде, сүз дә юк, буыннары сызлап интектерә. Элек сынган кабыргалары да вакыт-вакыт чәнчеп, гәүдәсен яңгыратып ала.

Эшкә каты кешеләр, эчсә, ташланып, акыллары әйләнеп чыкканчы эчә. Галимҗан абый да кайчагында чамасын белмәде. Тар дөньяда вакыт-вакыт үзенә урын таба алмый иде. Андый чакта кул аракыга үрелә. Бердәнбер улы да мәгънәсез булып чыкты. Үзе аек чагында әтисенең исереклеген яратмый иде. Кыйнап чыгарган чаклары да исәпсез. Мәнсезлеге белән дә каезлап...

Берсендә шулай улы янына кергән иде. Аерым йортта яши алар. Ул йортны торгызырга Галимҗан абый үзе булышты. Бурасын салырга, түбәсен ябарга. Заманында шабашта да шактый йөреп алган кеше булгач, куллары андый эшнең рәтен белә. Әзрәк салмыш иде. Фуражкасын янтайтып кигән. Элек гел керләнгән, трактор маена каткан булыр иде ул фуражка. Ә бүгенгесе чиста, яңа

*КФХ – крестьян-фермер хуҗалыгы.

күренә. Кулында мүк өтергесе. Яңа өйнең бураларын мүкләргә кереп чыккалый ул шулай. Никтер, авызына әзрәк аракы кергәннән соң гына, дивар мүкләргә кирәклеге искә төшә. Улы Рәкыйп кызыл кар яуса да өтерге тота торган кеше түгел. Моны Галимҗан абый яхшы белә.

Рәкыйп көлә-көлә телевизор карап ята иде. Нindidер кызыклы кино бара, күрәсең.

– Менә бүрәнәләреңне мүкләргә кердем әле, улым. Алайса, түр почмак бигрәк ямьсез, мүкләре чыгып, асылынып беткән. Өч почмагын бер кат мүкләдем инде мин аның... Түр почмагын тагын бер кат йөреп чыгарга кирәк булыр...

Рәкыйп җавап бирмәде, телевизордан бүленмәде.

– Менә, улым, – дип, улына якынрак килде Галимҗан абый. Фуражкасын салды. Кулында шуны бөтерә. Күзләрендә балаларча беркатлы шатлык. Салмыш бабайлар кайчак бала-чагага әйләнеп ала бит. Галимҗан абыйның да шундый чагы булса кирәк. – Тегесе каешланып бетте. Карарлыгы калмаган. Кибетче Суфия алдыртты инде. «Менә, Галимҗан абый, яңа фуражкалар кайтты. Алып киеп җибәр әле», ди. «Монысын тотып ат, бигрәк ямьсез» – ди. Әй, мин әйтәм, чурту-матыр, чукынып китсен акчасы, алыйм әле, дидем... – Галимҗан абый әзрәк чайкалып китте. – Фуражка алдым әле, улым...

Тагын берничә тапкыр кабатлады әле ул соңгы сүзләрне. Нидер сөйли-сөйли дә ахырдан өстәп куя:

– Яңа фуражка алдым әле, улым, – ди...

Шунда өченчесендәме, Рәкыйп түзмәде, яткан җиреннән кубарылып торды да этисенең фуражкасын кулыннан сугып төшерде. Фуражка идәнгә очты, почмакка тәгәрәде...

– Ни пычагыма соң миңа синең фуражкаң, ә! – дип акырды Рәкыйп. – Ник кадалып китмисең шунда шул фуражкаң белән! Йөрмә монда кереп болганып!

Галимҗан бабай чайкалып куйды. Көтмәгән иде. Исе-акылы китеп, улына шактый карап торды... Аннары гына:

– И-их... – дип, бер сүгенеп куйды. – Улым, улым... – дип авыр сулап, тыныч кына фуражкасы артыннан тәпиләде. Иелеп алды, кире чыгып киткәндә, тагын туктап, улына караш ташлады. Рәкыйп ул мизгелдә яңадан телевизор эченә кереп йотылган иде инде.

– Ярый... Киттем алайса...

Рәкыйп берни җавап бирмәде. Галимҗан абый фуражкасын кырын салып киде. Кулына өтергесен тотты. Сүзсез генә чыгып китте. Аның чыкканын ишетүче дә, абайлаучы да булмады...

***

Галимҗан абый ул елны каты гына авырып китте. Бизгәкләп... Үпкә ялкынсынуы, диделәр. Берара туберкулёздан да дәваланып йөрде. Кешегә әйтмәделәр башта, аннары беленде. Каенатасының авыруына барыннан да бигрәк килене борчылды инде. Бабайны кызганып түгел, үзләренә дә чир йоктырыр дип курыкты. Хатын аеруча да яшь баласы өчен хафаланды. Галимҗан абыйны онығы янына якын да җибәрми башладылар. Сүз дә юк, киленне дә аңларга була. Кемнең баласын зәхмәтле авыруы булган кеше янында йөртәсе килсен. Галимҗан абый моны бик яхшы аңлый иде. Тик менә салмыш вакытларында гына... Авырыйм, дип, салуын туктатмады. Атна ахырында булса да бәйдән кубып ала иде.

Шундыйрак бер вакытында берчак онығы янына кергән. Баланы кулына ала да сөя, иркәли. Кечкенә кыз көлә, ул көлгәнгә карап карт сөенә. Агара башлаган

сакалы белән баланың әле кулыннан кытыклый, әле битеннән сыпыра. Ә бала һаман саен ныграк көлә.

Нәкъ менә шул мизгелдә эштән килене кайтып төште...

Керде дә, күрде дә... Каравыл акырып җибәрмәсенме! Күз яшьләренә буылып кычкырды.

– Галимҗан абый, нишлисең син?! Үз акылыңдамы син? Чиреңне йоктырасың бит!!! Галимҗан абый! – Дүрт ел бергә яшәп «әти» диярга өйрәнмәде килене. Бүген бөтенләй бәйдән купты. Каенатаның киленен мондый хәлдә беренче тапкыр күрүе. Күзләре акайган, йөзе бүртенгән, кабарынган. Кечкенә кызны бабайдан тартып алды да:

– Бар, чыгып кит, тиз бул! Бар, дим! Күземә күренмә! Югал! Рәкыйп! Син кайда йөрисең? – дип кычкырды. Өй диварларына кадәр селкенеп куйды...

Аһ, кызган да иде соң ул көнне килен кеше. Рәкыйп җаваплылыгында калган бала бабай кочагына кай арада кергән? Рәкыйп ун минутка гына калдырып чыгып киткән чакка ничек туры китергән?..

Шул кичне Рәкыйп Галимҗан абыйны ишегалдында яткызып каты гына кыйнаган иде. Кычкыртып, елатып кыйнады. Бөтен авыл ишетеп торды...

Ишеткәнегез бармы алтмыштан узган өлкән кешенең елаганын? Ә менә рәшәтлеләр ишетте. Шулкадәр авырттырып кыйнаганга елагандыр дип уйлады рәшәтлеләр. Юктыр. Үз улының шулай «үтерәм хәзер», дип кычкыра-кычкыра кыйнавына гарьләнеп елагандыр ул карт. Гарьлектән елагандыр...

Галимҗан бабайны ул көздә хастаханәгә салдылар да, ул аннан авылга бүтән кайтмады.

***

Тәрәзә төбенә гел су җыела. Ашык-пошык кына алыштырып киттеләр дә, шуннан соң, яңгыр яуса, бер почмакка су керә торган булып калды. Сибәләп кенә яуганда керми, бүгенге кебек чиләкләп койса, ага да төшә, ага да төшә инде шул каһәр.

– Теге малайларны кире чакыртмыйча булмас ахры... – дип уйлады эченнән Чулпан. – Кызым, тамагың ачтымы?

– Әйе...

– Хәзер, берәр нәрсә әтмәллибез...

Чулпан суыткычны ачып җибәрде. Ә анда ике йогырт, буш сөт шешәсе, ишегендә моңаеп утыручы сыңар йомыркадан башка бүтән берни юк.

– Ай тишек баш. Кибеткә керергә оныттым бит! Яңгырдан качам, дип... – Чулпан суыткыч ишеген шапылдатып япты да кулчатырга үрелде. Тәрәзә төбендә су эчендә иде тегесе. Ачып-ябып суын саркытты. – Кибеткә чыгып керәм, Сәйдә. Тик кенә утырып тор. Телевизор кабыз, мультик кара.

– Ярар, әни...

Кинәт телефон шалтырады.

– Чулпан, кызым, Суфия апаң әле бу. Рәшәт авылыннан. Кибетче. Таныдыңмы?

– Таныдым, Суфия апа... Ничек хәлләрегез?

– Хәлләр начаррак. Рәкыйп үлеп китте кичәгенәк... Иртәгә җирлиләр...

Чулпан берара сүзсез торды. Суфия апа дәвам итте.

– Беләм инде, бик үк матур аерылышмаганыгызны да беләм. Тик, ни... Белеп торсаң, яхшырак булыр дип уйладым. Кайту, кайтмау – анысы синең эш дигәндәй. Гаеп итмәячәк беркем дә. Шул гына иде...

– Рәхмәт... Суфия апа. Аңладым мин сине...

***

Җиде юл чаты, диләр... «Чат» дип Рәшәт авылында бер генә урынны атыйлар. Ике төп урам кисешкән төшне. «Җирнең уртасы кайда?» – дигән сорауга рәшәтлеләрнең җавабы һәрвакыт әзер: «Менә шушы чат инде аның уртасы!» Шулай шаярталар. Җирнең уртасыдырмы, юкмы – анысын берәү дә исбатлый алмас, ә менә ул чатның авылның үзәге булуы күпләргә билгеле. Ә бүген ул язмыш чаты да кебек әле.

Чулпан авылга яңадан кайтты. Бүген менә нәкъ шул чатта басып тора. Рәшәт чатында... Кайсы якка борылуына карап, кемнеңдер язмышы хәл ителер кебек. Ник кайттымы? Әлегә үзе дә белми. Әмма кайтуы очраклы түгел. Нидер тартып кайтарды.

Яраткан кешеләрне югалту бик авыр. Табигатьнең битарафлыгына кайчак ачу килә. Җирдә кеше үлгән, кемнеңдер якыны, газиз туганы вафат булган. Әле кичә генә ул шушы җиргә басып нидер эшләп йөргән. Су буйларына төшкән, бәлкем, шул табигатькә карап сокланып та утыргандыр. Сәпиттә урам тузанын туздырып үтеп киткән бала-чагага сәлам биреп калган. Һәр иртә зур адымнар белән җитез-җитез атлап эшенә чапкан. Ә бүген инде ул кеше юк... Юк. Бетте-китте. Бүтән су буена да төшмәячәк. Балаларга урамда сәлам дә биреп калмаячак. Җитез-җитез атлап урамнан да узмаячак. Күңел шулчак табигатьнең дулаганын, кешелекнең әлеге югалту белән килешмәвен күрергә тели. Җил кубуын тели ул! Тузан күтәрелсен! Коеп яңгыр яусын! Түбә калайлары дөбердәсен! Халык: «Кара, табигать ничек котыра!» – дип ах итеп сөйләсен! «Яхшы кешенең китүе белән килешә алмый torгандыр инде бу табигать. Яхшы кеше иде бит. Бигрәк яхшы иде...» – дисен! Ә юк... Беркем берни әйтми. Табигать тә тыныч. Әйтерсең, берни булмаган. Әйтерсең, кемнеңдер кадерле кызын яисә улын, кемнеңдер яраткан ирен яки хатынын соңгы юлга озатмыйлар бүген. Барысы да шулай тиеш кебек.

Ник алай соң?! Ник?! Кайчак табигатьнең шул битарафлыгына ачу килә. Ачу килә! Шул ачудан, сузылып ятып, җирне тырный-тырный кыйныйсың. «Ни өчен нәкъ менә ул? Ни өчен нәкъ менә минем әни, минем әти, минем ир? Ни өчен?!» Соңыннан гына аңлашыла. Гомерең – менә шушы юл чатындагы тузан. Җил истеме – оча да тарала. Кешенең җирдәге өлеше шулкадәр генә...

Моннан берничә ел элек Чулпан әнисен җирләгән чакта тормышның бу хакыйкатен аңлады сыман инде. Менә тагын бер дәлил. Тик ул бүген сузылып ятып җирне кыйнамаячак. Бүген ул, кызыл балчык катыш туфрак өеменә читтән карап, сүзсез генә басып торачак. Зиратта кеше юк. Чулпан үзе дә кызы. Башта кайтырга уйламаган да иде. Сәйдә өчен генә кайтты инде ул монда. Нинди генә булуына карамастан, кызга җан өргән әти кеше бит. Әлегә ул – бала, бөтенесен аңлап та бетерми, шуңа күрә әнисенә каршы берни әйтмәс, ә үскәч аңлар, «әти белән хушлашырга да алып кайтмадың», дип сүгәр. Ни өчен алып кайтмаганын, сәбәбен сорап тормас. «Алып кайтмадың», гына дияр.

– Әтиең белән хушлаш, – диде Чулпан.

– Хуш, әти, – диде Сәйдә. Әнисе кушканга гына әйтте...

Зиратта озак тормады алар. Чулпан тизрәк чыгу җаен карады.

Ә авыл үзгәргән... Соңгы тапкыр монда Чулпан дүрт ел элек булды. Әллә ни күп тә үтмәгән кебек. Тик бүгенге заман тизлеге белән – шактый. Әнә, күпме өйләр яңартылган, кемнәрнең түбәләре калайга алыштырылган, кемнәр коймаларын яңарткан, зур-зур сарайлар баш калкыткан. Ара-тирә яңа йортлар да күренә.

Авыл кешесе барыбер тырыша-тырмаша инде. Хәләл көче белән эшләп тапкан тиеннәренә йортын ямаштыра, кешедән калышмыйк, дип эшли, нидер төзи, яңарта.

Ә менә Рәкыйпнең хуҗалыгы яңармаган да, үзгәрмәгән дә. Тәрәзәләр һаман да йөзлекләрсез, өйалды яртылаш калай белән төрелгән, яртылаш ачык. Чулпан монда яшәгән вакытта ук ул өйалды, эшли башланып, ярты җирдә ташлап калдырылган иде. Авылда инде күптән бөтен кешенең коймалары тимер, калайдан. Ә Рәкыйпнеке – буяулары купкан, яңгыр явып, өске читләре кимерелгән, төсе уңып беткән тактадан. Бер-ике баганасы череп авышкан, аратасы-ниен бергә өстерәп бөтенләй җиргә сеңмәсен өчен, урам ягыннан каен агачы белән терәтеп куйганнар.

– Менә шундый хәлләр, Чулпан кызым...

Суфия апа Чулпанны өенә алып кайтып, чәй эчертте, кунак итте.

– Галимҗан абый тоткан коймалар инде бу, хәтерлисеңдер... Әтисе булмагач, йорт җирен карап-барлап торучы да юк. Көне-төне исерек. Бер аек көне булмады. Әле дә күпкә түзде инде, мин сиңа әйтим. Организм таза. Ул эчүгә, ул эчүгә инде, җанкисәгем! Әле дә озак чыдады. Синнән соң бик бетеренде Рәкыйп, сеңлем. Син киткәч, юлдан бөтенләй язды. Сиңа гына тотынып торган булган икән... Үлгән кеше турында начар сөйләргә ярамый инде, беләм. Бер тотып алырлык яхшы сүзе булмагач та кыен. Ни дип әйтергә дә белмәссең...

– Дәшмик, Суфия апа.

– Шулай итик, шулай итик. Дәшмик, сеңлем. Шул җанны телгә алып, гөнаһлы булганчы, әйеме? И Ходаем, тагын ни сөйлим инде. Үзеннән-үзе китә шул. Сизмичә дә каласың... Син, килгән-килгән, каенатаңның да хәлен белеп чык инде, ярыймы? Ул да чирле, аңа да күп калмагандыр. Гел-гел кайтып йөри алмассың.

Чулпан шунда кинәт туктап калды.

– Нинди каената, Суфия апа?

– Ник, мин сиңа әйтмәдеммени әле? Галимҗан абыйны әйтәм... Ул кайтты бит!

– Галимҗан абый?! – Чулпанның күзләре түгәрәкләнде.

– Әйе, нәкъ үзе! Синең каенатаң.

– Тукта, Суфия апа, ни сөйлисең син? Ул бишбылтыр үлде бит инде.

– Үлде, диделәр шул. Рәкыйп йөрмәде бит артыннан. Хастаханәдән чыгып качкан булган бит ул. Аннары югалды. Участковыйны гына җибәрделәр дә эзләргә... Ул да барып берни майтара алмады. Үз малаена кирәк булмаганны, чит кешегә нигә кирәк булсын адәм баласы?! Нindидер баракта бомжлар янып үлгән, ди. Шуларның берсен Галимҗан абый дип яздырып кайттылар. Менә шул инде аның бар булган үлгәнлеге.

– И-и Ходаем, миңа үлгән, диделәр. Үзең беләсең бит ничек булып беткәнен. Бик авыр көз иде. Начар чир белән дә чирләде... Ничек? Ничек исән ул?

– Белмим, сеңлем. Без үзебез дә шаккаттык! Күзебезгә күренәме, дип торабыз. Илдус абыең сөйли – минем хәләл җефет. Рәкыйпне җирләгәндә, ди... Алар җиде кеше, мулла да алты ир генә җирләделәр аны. Үзләре каберен казыдылар, үзләре бөтен эшен эшләделәр. Бүтән кеше кайтмады. Илдус әйтә: берәү басып тора читтә, ди. Кап-кара, шакшыга баткан, киемнәре ертылып беткән, бит-чыраен сакал-мыек баскан, ди. Басып тора, китми дә китми, ди. Хәле юк, җил әкрен генә иссә дә, егылып җиргә сузылып ятачак инде менә. Шул мәлне килде дә, кулына көрәк алды да, ди, кабергә балчык ишә башлады, ди. Аннан килә ис, ди. Авызыннан ник бер сүз чыксын! Теләсә дә чыгара алмый, ди. Ул авыз-иреннәре кибеп кутырланып ябышкан. Ачып әйтсә, шундук кан

саркып ага башлар сыман, ди. Илдус нидер ишеткән шунда. Пышылдаганы ишетелгән. «И, улым», – дигәнен ишеткән. Аңлыйсыңмы? «Улым», дигән. Менә шунда башларына китереп бәргән дә инде Илдусларның. «Галимҗан абый, син мәллә бу?» – дип, күзләрне шарландырып карап торабыз, ди. Бабай дәшми икән. «Галимҗан абый, синме?» – дип сорыйлар, ди. Дәшми икән. Берни аңламый, ди. Акылы томаланганмы?!

Чулпан ни әйтергә белми басып торды. Ә Суфия апа һаман дәвам итте.

– Бабай берни хәтерләми. Тиле кеше кебек карап тора, ди. Кайда булган, кайда йөргән ул шул вакыт? Ничек Рәкыйпнең үлгәнен белгән, ничек кайткан? Гаҗәп... Аңламыйлар берсе дә... Илдус әйтә...

– Кайда соң ул хәзер? – дип, Чулпан аны бүлдерергә ашыкты.

– Фатыймаларда булырга тиеш. Аның ире Хамис тә бар иде бит бүген зиратта. Ул өенә алып кайтып киткән. Аның әтисе белән классташлар иде алар. Фатыйма авылда бердәнбер шәфкать туташы да...

– Аңладым, Суфия апа. Аңладым. Рәхмәт... – Чулпан Сәйдәсен җитәкләде дә Рәшәт чатына таба йөгерде. Суфия апа иярмәде. Күз уңыннан югалганчы, артларыннан карап озатып калды...

***

Язмыш чаты. Гади бер авылда гына. Һәр юлы төрле. Авыл кечкенә. Ул чатта мең тапкыр басып торыла, мең тапкыр уңга да, сулга да барыла. Әмма шундый вакытлар була икән – синең кая борылуыңа карап, язмыш булып язмыш хәл ителә!

Менә Чулпан нәкъ шундый чатларның берсендә басып тора. Рәшәт чатында.

– Ник туктадык, әни? – Сәйдә әнисенә беркатлы самими күзләре белән карап тора.

– Әзрәк торыйк әле, кызым...

– Без кая барабыз соң хәзер?

– Аска төшәрбез. Фатыйма апаңнарга...

– Ә Фатыйма апалар кемнәр?

– Яхшы кешеләр.

– Ә без аларга ник барабыз?

– Белмим әле, кызым.

Тагын яңгыр сибәли башлады. Теге коеп яуганнан соң, әле ярты көн яумый тыелып кына торган иде.

– Керәбезме, әни?

Фатыйма апаларның капка төбенә җитүгә, тагын бер тапкыр туктап калды Чулпан. Атлап керергә йөрәге җитмәде. Нидер тыеп, туктатып тора сыман. Тик нәрсә? Нindидер яман эше, гаебе, гөнаһы бардыр кебек. Шул гөнаһы кара богавы белән Чулпанның кул-аягыннан эләктергән дә капканы ачып эчкә үтәргә ирек бирми, артка таба тартадыр шикелле.

Ә ул арада тиктормас кыз инде, капканы ачып, ишегалдына ук кереп китте. Капка, шапылдап кире ябылып та калды.

Чулпан әле аннан соң да ишегалдына керә алмый торды. Аякларына потлы гер асканнармы, ул аларны селкетә дә алмады.

Менә капка тагын ачылды. Кемдер ачты. Ишегалды бакча белән тоташ. Койма юк. Бакчада чәчәкләр. Яңгырда чыланган чәчәкләр арасында ике эскәмия кара-каршы утыртып куелган. Шуның берсендә кара яхшы күфәйкедән берәү утыра. Икенчесендә кем? Кызы утыра, Сәйдә...

– Бабай, син бит инде бу, әйеме? – ди.

Күфәйкеле кеше бер сүз дә дәшми...

– Галимҗан бабай бит инде син, әйеме? Мин бит сине теге чакта ук таныдым, – дип кабатлап сорый кыз бала.

Ә күфәйкеле кеше һаман бер сүз әйтми. Бары елмая. Кыяфәт юк: тормыш таягы кыйнапмы-кыйнаган. Йөзендә мең дә бер җыерчык, яра эзе. Куптәнгеләре дә бар, яңалары да. Алар кызарып кутырлаган. Иягеннән су тама. Ә күзләрендә – кояш. Моңарчы күренмәгән кояш. Бала шул кояшка үрелә. Кулына кагыла, сакалыннан тота.

– Ә мин сине таныдым... – ди кыз.

Әйе... Чулпан да таныды. Шул бабай иде ул. Автобус тукталышында Сәйдәгә кул болгап калган сукбайның нәкъ үзе иде...

Чулпанның тамагына төер тыгылды. Әче төер, каты, йотып булмый торган төер. Ул бугазны кыса, суларга ирек бирми, башка кан җибәрми. Әллә нәрсә булды шунда Чулпанга. Күңеле эчтән актарылып-актарылып килде. Мизгел эчендә үткәндәгеләр бер-бер артлы күз лдыннан үтте. Барысы да. Рәкыйпнең шул кичне әтисен елата-елата ишегалдында кыйнаганы... Туктатмады бит Чулпан аны шулчак. Өйдән чыкмыйча, кызын кочаклап тик утырды. Чыгып туктата ала иде. Чыгып туктатырга кирәк иде...

Менә хәзер бу хатирә Чулпанның бәгырен кисә, чәнчи, кадала.

Күфәйкеле кеше Чулпанны әле генә абайлады. Борылып карады. Чулпан карашын яшерде. Юк... карап булмый иде әлеге мизгелдә аның күзенә. Берничек тә туры карый алмады ул аңа.

Бик озак сүзсез тордылар. Тынлыкны өйдән чыгып җиткән Фатыйма апа бүлде.

– Чулпан, сеңлем, синме әллә бу?

Чулпан башын селкеде.

– Әйе, Фатыйма апа. Мин...

– Хамис абыең алып кайткан аны бүген... зираттан... – дип сөйли башламакчы иде. Чулпан бүлдерде.

– Беләм, Фатыйма апа. Мин барысын да беләм...

Берара тагын тынлык урнашты. Сәйдә әле әнисенә карый, әле бабасына карап елмая.

– Син, ничек, болай гынамы соң, кызым? Хәл белергә генәме? Чәй эчеп чыгасызмы? Әйдәгез, әзерлим. Галимҗан абыйга яңгыр астында торырга ярамый. Өйгә керик.

– Рәхмәт, Фатыйма апа... – диде шунда Чулпан. – Без аны үзебез белән алып китәрбез инде. Шәһәргә... аның монда бүтән беркеме дә юк...

Яңгыр сибәләвеннән туктамады... Җәй яңгыры булса да, озак басып торсаң, барыбер туңдыра.

– Әти, әйдә, кереп чәй эчеп, җылынып чыгыйк та... Аннары Казанга китәрбез...

Әти...

Моннан да ныграк җылытучы тагын нинди сүз бар?

Галимҗан бабай берни дәшмәде. Аның каравы, күзләрендә – рәхмәт, карашында – мәрхәмәт. Кипкән иреннәре кымшанмый, әмма аларда шат елмаю катып калган иде...

# РАЙНУР ӘГЪЛӘМЕТДИНОВ. «ЧАТ»

Татар әдәбияты өчен традицион хикәя: гадәти булмаган, күңелгә тиярлек сюжет, әхлакый нәтиҗә. Укыла, тәэсирле, публицистиклыктан алып китү өчен, автор берничә отышлы алым куллана. Беренчесе – хикәяләүнең вакыт-вакыт төп героиня Чулпан исеменә дә күчеп алып барылуы, ул психологизмны көчәйтә. Икенчесе – зур булмаган текстны график яктан өлешләргә бүлеп, аерым, чагыштырмача мөстәкыйль тарихларга әйләндерү. Әлеге тарихларны формалаштырып бетергәндә, һәрберсеннән мөстәкыйль нәтиҗә ясалырлык һәм гомуми текстның төрлечә укылышын тәэмин итәрлек әсәр килеп чыгар иде (монысына язучы алга таба үз әсәрләрендә игътибар итәр дип уйлыйм). Өченчесе – хикәянең башламы: бер яктан, ул үзәк каршылык чишелешендә Чулпан ясаячак адымга метафора булып килә, шул ук вакытта алда булачак вакыйгаларда катнаша, кайберләренең сәбәбенә әверелә. Әмма безгә тәнкыйтьләү өчен азык та бирә: кереш өлештә, хикәянең исемендә (көчле позиция!) ачык аңлашылган идеяне тагын ике тапкыр текстта кабатлау (беренчесе: «Җиде юл чаты, диләр... «Чат» дип Рәшәт авылында бер генә урынны атыйлар. (...) Ә бүген ул язмыш чаты да кебек әле»; икенчесе: «Язмыш чаты. Гади бер авылда гына. Һәр юлы төрле. Авыл кечкенә. Ул чатта мең тапкыр басып торыла, мең тапкыр уңга да, сулга да барыла. Әмма шундый вакытлар була икән – синең кая борылуыңа карап, язмыш булып язмыш хәл ителә!») артык булып тоела, укучының фикерен инде табылган төп идеягә кабат-кабат юнәлтеп, хикәянең әдәбилеген киметә. Мәгърифәтчелек, үгет-нәсихәтчелек чорына хас бу сыйфат бүгенге заман әдәбиятына куела торган төп таләпне үтәргә комачаулый – һәр укучының үз текстын табу, уку мөмкинлеген чикли.

Инде хикәягә якынрак килик. Ул кечкенә генә кереш белән башланып китә. Чулпан исемле яшь хатын үзенең кызы белән хастаханәдән кайтып бара, кыз, автобус тәрәзәсеннән күргән сукбайны Галимҗан бабасына охшатып, кул болгый. Кызчыкның елмаюы сукбайның карашын да үзгәртеп, җылытып җибәрә. Хикәя ахырында без шушы очрашуның «чаттагы» Галимҗанның авылга кайтуына, тормышын үзгәртергә карар кылуына сәбәпче булуын да аңлыйбыз.

Аннары хикәяләү Чулпанның уйларында моннан дүрт ел элек булган көз көненә әйләнеп кайта. Ире Рәкыйпнең хыянәтен белеп, яшь хатын тормышын үзгәртә: кызы белән шәһәргә чыгып китә.

Аерып куелган чираттагы тарих – авылның эшкә нык кешесе – Галимҗаннныкы. Рәкыйпнең әтисе Галимҗанның гомере эштә узган. Әмма улы белән якынлык, аңлашу юк. Авырып киткәч, аны гаиләдә бөтенләй читкә тибәрәләр. Улы кыйный. Көзен Галимҗан бабайны хастаханәгә салалар, ул аннан авылга бүтән кайтмый.

Хикәяләү кабат хәзерге вакытка күчерелә: Чулпанга Рәкыйпнең үлгәнен әйтеп шалтыраталар. Чулпан кызы Сәйдә белән ирен соңгы юлга озатырга авылга кайта. Зиратта була, Галимҗанның исән икәнлеген, аның да мондалыгын ишетә. Автобус тукталышында Сәйдәгә кул болгап калган сукбайның Галимҗан булганлыгы ачыклана.

Каенатасы белән очрашырга карар иткән Чулпан хәтерендә тагын бер күренеш калка: «Рәкыйпнең шул кичне әтисен елата-елата ишегалдында кыйнаганы... Туктатмады бит Чулпан аны шулчак. Өйдән чыкмыйча, кызын кочаклап тик утырды. Чыгып туктата ала иде. Туктатырга кирәк иде...» Бу күренеш һәр кешенең хата ясау мөмкинлеге турында искәртә. Әмма иң мөһиме: ул Чулпанны идеаллаштырудан коткара, чөнки хатын каенатасын үзе белән алып китәргә, аның өчен җаваплылыкны үз җилкәсенә алырга карар кылды! Героиняны идеаллаштырган очракта, язучы, бу игелекле адымның һәр кеше эшләргә тиешле, эшли ала торган гамәл икәнлеген ассызыклый алмас та иде.

Шулай итеп, хикәя гадәти булмаган, аянычлы вакыйгада зур фәлсәфи гомумиләштерүгә алып чыга. Ул тормышны – кешене адым саен сагалап торган сынау мәйданы, һәрвакыт ике капма-каршы якка аерылып китә торган чатлар белән чуарланган юл итеп күзаллауга

корылган. Чатта башкаларга мәрхәмәт күрсәтү сукмагын да, үзеңне генә ярату – эгоизм сукмагын да сайларга мөмкин. Әмма Чулпан-Сәйдә-Галимҗан мисалы һәр яхшылыкның, һәр елмаюның, һәр мәрхәмәтнең – башкаларга куаныч китерүе турында сөйли. Хикәянең авторы үзе әйтергә теләгән фикерне укучыга җиткерә, ишеттерә алды!

Инде хикәянең эшләнешенә кагылышлы кайбер күзәтүләр.

Хикәя артык гади, фикерләрне ачыктан-ачык әйтеп бара. Бу язучының публицистиклыктан котылып җитә алмаганлыгы турында сөйли. Гәрчә хикәянең үзендә укучы фикерен үстерергә юнәлеш күрсәтерлек оеткылар күренеп торса да, алар автор тарафыннан файдаланылмаган, уйнатылмаган. Әйтик, хикәядәге тарих – аяныч: яп-яшь ир гаиләсен таркатты, атасын ташлады, эчеп үлде; аның әтисе, гомере буе шушы җирдә эшләгән кеше, сукбайлыкка чыкты. Шушы күренешләрнең сәбәпләре (иҗтимагый, матди, сәяси, фәлсәфи???) хакында, әлеге кешеләр белән янәшәдә тормыш иткән күршеләре, туганнарының битарафлыгы (эчүләрен дә күргәннәр, кыйнауны да ишеткәннәр ләбаса!) турында уйланырга юл күрсәтү, ишарә ясау текстны баетыр, тирәнәйтер иде.

Матур гына итеп символ (чат) яки табигать күренешен куллана башлау өзелеп кала. Бу алымнарны баштан ахырга кадәр өзмичә, мәсәлән, хикәя башындагы яңгыр һәм салават күпере сурәтен, чат белән бәйле сукмак яки юлны символик образ дәрәҗәсенә куеп файдалану мөмкинлеге дә бар.

Татар хикәясе һәрвакыт тел-сөйләмнең матурлыгына, аһәң-яңгырашның көе-музыкасына, сүзләрнең урынлы сайлануына йөз тотты. Кече жанр булган хикәядә һәр сүз урынлы сайланып, һәр деталь тергезелгән ситуацияне мөмкин кадәр тулырак ачыкларга ярдәм итәргә тиеш. Без карый торган текстта сөйләмнең эчке көе, «музыкасы», эчтәлегенә тәңгәл интонация, тотрыклы булып, вакыйгаларны озата бармый. Хикәянең беренче җөмләсендә ачыкланган пафосның, хисси яңгырашның ахырга кадәр килүе шарт. Ул вакыйгалар алмашыну ноктасында бөтенләй үзгә, капма-каршы «ноталар» белән үрелсә дә, текстның тулысы белән йә үкенечле, йә сагышлы, йә раслаучы, йә романтик-күтәренке һ.б. яңгырашы – татар хикәясенең традициясе! Миңа калса, уңай традиция.

Сөйләмнең аһәңе мәсьәләсенә кагылмастан, сүз сайланышына игътибар итик. Менә бер өзек: «Шундыйрак бер вакытында берчак оныгы янына кергән», дип башланган абзац. Беренче җөмлә стиль хатасы (бер вакытында берчак) белән дә, төгәлләнмәгәнлеге белән дә сөйләмне боза. Алга таба «шул мизгелдә эштән килене кайтып төште», дигәндә, «кайтып төште» формасы ерактан, читтән кайтучыга карата гына кулланыла ала. Бу очракта «шул мизгелдә» ачыклавы да отышсыз булып чыга. «Каравыл акырып җибәрмәсенме» формасын экспрессиягә сылтасак та, киленгә карата «бүген бөтенләй бәйдән купты» фразеологизмы урынсыз икәне күзгә ташлана. Аны куллану башка ситуацияне, «бәйләп куелганлыкны» таләп итә. Алга таба «йөзе бүртенгән, кабарынган», дигәндә, «кабарынган» сүзе йөзгә карата кулланыла алмаганлыкны искәртергә кирәк. Мондый мисалларны күпләп күрсәтергә мөмкин.

Әмма бу очракта башкарак якка караш ташлау да таләп ителә: әлеге сүзләр Галимҗан исеменнән әйтелә, аларда килененә карата ачу сиземләнә. Хәлбуки, хикәянең гомуми пафосына туры китереп, аңлашып яшәмәүгә юнәлтелгән үкенеч соралып тора.

Кайбер мәгънәви каршылыклар да гомуми хикәяләү тәэсирен җимерә. Мәсәлән, зиратта Чулпан уйларында шундый монолог калка: «Гомерең – менә шушы юл чатындагы тузан. Җил истеме – оча да тарала. Кешенең җирдәге өлеше шулкадәр генә... Моннан берничә ел элек Чулпан әнисен җирләгән чакта тормышның бу хакыйкатен аңлады сыман инде». Ә хикәянең вакыйгалар бирелешендә кешенең ничек яшәве – якыннарына тәэсир итә, аларның бәхетле яки бәхетсез, гомерле яки гомерсез булуы һәр кешенең нинди юл сайлавына бәйле дигән фикер укыла! Димәк, кешенең гомере һәм эш-гамәлләре – тузан түгел, бәлки гомуми яшәешнең нindilegen хасил иткән бик мөһим кыйммәт булырга тиеш.

Гомумән алганда, әдәбиятның асылын барлыкка китерә торган алмаз таш табылган, әмма аның, кырланып-сырланып, бриллиантка әйләнгәнен күрәсе килә!

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

# ТОТКЫНЛЫКТАН КАЙТКАН ШИГЫРЬЛӘР

*Күренекле татар язучысы һәм шагыйре, Бөек Ватан сугышы каһарманы, җәлилче Абдулла Алишның (1908-1944) әсирлектә иҗат ителгән күп кенә шигырьләре сугыштан соң төрле елларда һәм төрле юллар белән туган илгә кайтып иреште. Аларның күп өлеше һәм иң беренче иҗат ителгәннәре гаиләсенә, туганнарына, якыннарына 1946 елда билгеле булды.*

*Болар – Абдулла Алишның Берлин төрмәсеннән Габбас Шәрипов тарафыннан чыгарылган дәфтәре һәм әсирлектә булган Нигъмәт Терегулов күчереп язган шигырьләр. Сугыштан соң 1946 елның язында Нигъмәт Терегулов, Уфадан махсус Казанга килеп, аларны (Муса Җәлилнең беренче блокноты белән бергә!) Абдулла Алишның тормыш иптәше Рокыя апага шагыйрь күрсәткән адрес буенча китереп бирә. Аннары бу әсәрләрне Татарстан Язучылар берлегенә тапшыралар.*

*А.Алишның бу дәфтәренә унбишләп шигыре һәм әсирлектә үз башыннан узган хәлләре тасвирланган «Тормыштан хроникалар» дигән язмасы теркәлгән. Монда ул үзе белән бергә кулга алынган кешеләрнең исемнәрен дә язган. Иң соңыннан, васыять кебек итеп, мондый сүзләр өстәгән: «Әгәр шушы дәфтәр исән-сау кайтып җитсә, мин бәхетле. Миңа башка берни кирәкми. Мескен анам, сөйгән иркәм бу язмаларны укысалар, дуслар аларның кайберләрен матбугатта чыгарсалар...*[*]

*24/XI – 42».*

*Шагыйрьнең 110 еллыгы уңаеннан тәкъдим ителгән бу шигырьләр җәлилчеләр каһарманлыгын, туган илгә-ватанга, ана телебезгә тугрылыкны кабат хәтерләрдә яңартып, яшәешебезне өметле итеп, тулыландырып җибәрсеннәр иде...*

*Шигырьләрендәге ялкынлы хисләре белән Абдулла Алиш бит бүген дә безнең күңелләрдә, халык хәтерендә яши!..*

А б д у л л а
А л и ш

## Туган илгә

Булгач давыл, ничек шауламасын,
Чайкалмасын камышы.
Ярсый йөрәк, дулкынлана,
Авыр-авыр сагышы!

Беренче кат күзем кояш күргән
Җирләр ерак калды.
Тирә-ягым көзге болыт кебек
Кайгы чорнап алды.

[*] Илсөяр Сөнкишевадан.

Туган илем, барлык рухым сиңа –
Барысы синең өчен!..

Якынлыгың синең белмәдем мин,
Ерак китми торып.
Ничек яшьлек тәмен без белмибез,
Картлык килми торып.

## Сагынам илемне

Сагынам илемне, нечкә билемне,
Яшь вакыт йөзгән зәңгәр күлемне.

Сагынам җәйләрен, матур айларын,
Майлы коймаклы Сабантуйларын.

Сагынам урманын, чишмә буйларын,
Таң аткан чакта кошлар җырлавын.

Сагынам кич-иртә, онытмыйм һич тә,
Чөнки мин сөям, әйтмимен тиккә.

Нигә бу кадәр сөям илемне? –
Җырына күмеп тирбәтте мине.

Үстерде илем батыр ир итеп,
Очырды яуга җитез җил итеп.

Барырмын таптап дошман тупларын,
Куркып чигенмәм зәһәр утларын...

## Үзем турында җыр

Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.

Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын, дип.
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем ирекле булсын, дип.

Ничек тели җаның, шулай яшә,
Кара кашлы кызлар үзеңә,
Дисәләр дә, әйтер идем: кирәк түгел,
Кайтам мин, дип, зәңгәр күземә.

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

## Кояш каршылау

Мин адаштым юлдан, төн караңгы,
Белмим, нидер көтәм.
Кайда икән минем якын дуслар?
Кайда минем иркәм?

Басып торам текә яр читендә,
Карыйм тирә-якка.
Шулчак янгын кебек алсуланып,
Батыр кояш калка.

Кулы белән нәфис пәрәнҗәсен
Акрын ачкан сыман,
Тирә-ягын һаман яктылата,
Күтәрелә томан.

Тормыш чишмәсенең горур агымын
Тәбриклиләр кошлар.
Чәчәкләрдән ява бертуктаусыз
Рәхмәтле алкышлар.

Кызганмый ул – минем өскә
Сибә көләч нурын,
Хәтерләтеп анам иркәләвен,
Аның йомшак кулын.

Уртаклашам йөрәк кайгыларын
Мин дә аның белән.
– Кояш бабай, барыр юлым кайда? –
Дигән сорау бирәм.

– Әнә минем нурлар, – ди ул миңа, –
Курыкмый һичбер нидән.
Шулар кебек син дә батыр бул,
Үрнәк алып миннән.

Төн артыннан көннең туарына
Ышанычың тирән.
Китәр кайгы, килер шатлык тиздән,
Тиздән, иркәм, тиздән.

Барыр юлың – үлем, – ди ул миңа, –
Мин калыккан чакта.
Ыргыт йөрәгеңнән кайгыларны,
Үлеп минем хакка.

Шунда синең дуслар, якын анаң,
Шунда синең иркәң.
Һәр көн саен кайнар сәламеңне
Мин аларга илтәм.

Саубуллаша, үрли югарыга,
Ә мин түбән калам.
Алып килгән төсле җылы нурлар
Туган илдән сәлам!

## Көтмә инде, көтмә...

*Әнигә багышлыйм*

Ана үрдәк бәбкәләре белән,
Ә син ялгыз үзең барасың.
Син көнләшеп аның бәхетеннән,
Моңсу гына озатып каласың.

Кая китте синең балаларың?
Арыслан күк батыр улларың?
Өмет белән һаман күзәтәсең,
Кайтырлар, дип, киткән юлларын.

Былтыр койган алма какларын син,
Чикләвекләр җыеп киптереп,
«Аларга!» дип, һаман саклыйсыңмы,
Сагыш белән көтеп тилмереп?

Төшләреңдә һаман алар белән,
Көндезләрен укып хатларын,
Теткәләнгән кәгазь битләренең
Һәрбер сүзен инде ятладың.

Язлар килер, чәчәк исен бөркеп,
Сыерчыклар кире кайтырлар.
Яңарырлар шунда йөрәгеңдә
Бертуктаусыз янган кайгылар.

Бал кортлары очар, күбәләкләр
Берсен берсе куышып уйнарлар.
Чәчәкләргә күмелеп торсалар да,
Куандырмас сине тугайлар.

Җир тетрәткән давыл уты, бәлки,
Карлар белән эреп югалыр.
Дөнья тынып калыр. Йөрәкләрдә
Кавышу хисе кабат кузгалыр.

Өчесенең берсе кайтмасмы, дип,
Син көтәрсең һаман аларны.
Ишек каккан саен кочакларга
Хәзерләнеп сөйгән балаңны.

Көтмә инде, көтмә, изге карчык,
Җир куенында ята улларың,
Чәчәкләргә биреп илгә булган
Мәхәббәтле керсез уйларын.

# ГАЛИ ЗАТ

## РҮЗӘЛ ЮСУПОВКА 80 ЯШЬ



*Татарстанда гына түгел, Россия һәм кайбер чит җөмһүриятләрдә дә киң танылган, күп дәрәҗәләргә һәм мактаулы исемнәргә ирешкән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең академигы, профессор Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның 80 яшьлеге уңаеннан мәкалә язарга алынгач, дөресен әйтим, беркадәр каушап калдым. Булдыра алырмынмы, киң даирәләрдә билгеле шәхескә кагылышлы тормыш-яшәештәге вакыйгаларны, язма героеның эчке һәм тышкы халәтен, һәм гомумән, аның җәмгыятебезне тәрәккый иттерер өчен кылган санап бетергесез игелекле гамәлләрен тиешле дәрәҗәдә калку итеп сурәтли алырмынмы дигән шик-шөбһә күңелдә баш калкытты. Шулай да олуг галим, шул ук вакытта гали дә, гади дә затка карата хөрмәтем көчлерәк булып чыкты – тәвәккәлләдем.*

### Башлангычы Кышкардан

«Октябрь революциясенә кадәр безнең авыл мәдрәсәсе белән данлыклы булган. Зур байлар салдырган Кышкар мәдрәсәсендә бик ераклардан, хәтта Оренбургтан, Казаннан, башка губерна шәһәр-авылларыннан килеп укыганнар. Монда Габдулла Тукайның атасы, Габделҗәббар Кандалый кебек шәхесләр белем алган», – дип яза Рүзәл Юсупов үзенең «Уйларымда кайтам үткәннәремә» дип исемләнгән китабында. 2018 елның 14 сентябрендә 80 яшен тутыручы филология фәннәре докторының әүвәл дөньяга аваз салган, шунда тәпи басып киткән, вакыты җиткәч, элекке мәчет бинасында урнашкан мәктәптә (хәзер, яңартылып, кабат мәчет) җиде сыйныф белем алган туган төбәгендәге тормышы бер дә җиңелләрдән булмаган. Сугышка кадәр туган үз ишләре кебек, кечкенәдән үк кул арасына керергә туры килә аңа. «Кышларын энем Әнәс белән салкын өйдә көннәр буе берүзебез ач килеш туңып утырабыз. Ике абый – Равил белән Наил – су буенда мичкә ягарга чи тал чыбыгы кисеп әзерлиләр, басуга барып, әрем җыялар, әвенгә менеп, качып, эскертләрдән салам йолкып алып, өйгә ташыйлар. Өйне җылытырга утын юк: салам ягабыз, пыскып утырган чи тал чыбыгын яки әремне. Алардан мич тә җылынып җитми», – дип искә төшерә авыр сугыш чорындагы үткәннәрне Рүзәл ага. Әниләре көнозын бетмәс-төкәнмәс колхоз эшеннән кайтып керми, ике абыйсы өйләрен чак кына булса да җылыту өчен ягулык юнәтү белән мәшгуль; үзеннән ике яшькә кечерәк Әнәсне аннан башка кем баксын инде, Рүзәл, әлбәттә. Күрәсең, киләчәктә кешеләрне кайгырту өчен кирәкле оеткы шул чагында ук салына башлагандыр. «Сугыш вакытында һәм аннан соң да күп еллар буе ашау ачтан үлмәслек кенә булды...» – дип, үткән гасырның 40-50 нче елларындагы авыл тормышының бихисап җәфалы мизгелләреннән кайберләрен санап китә. Үзләренең

җиде кешелек гаиләсендә (әти-әни, биш малай) ипине бәрәңге кушып пешерүләрен шәрехли: «Һәр атнаны ипи салу өчен, абый белән һәрберебез игәүләп тишеп ясалган угычта, берәр зур чиләк бәрәңге уа торган идек. Абый миннән дүрт яшькә олы булганлыктан, көче күбрәк, минем азрак. Көч җитмәгәч, басып уам: бармаклар угычка суелып, җәрәхәтләнеп бетә иде...»

Утыз ике яшендә – фәннәр кандидаты, ә кырык дүртен тутырганда, фәннәр докторы булу өчен бәрәңге ууларның да кирәге булгандыр, мөгаен. Үҗәтлеккә тиң тырышлык белән алдына куйган теләсә кайсы максатын чынга ашыру өчен кечкенәдән «чиләнүләр» (монда һәммәсе: тугыз-ун яшеннән җәйге каникулларда колхозның ат көтүен көтү; ындыр табагында эшләү; җиде яше тулыр-тулмас, беренче сыйныфка укырга кереп, җидееллык мәктәпне «отлично»га тәмамлау; йорт-кура арасындагы мең дә бер төрле эштә катнашу һ.б. керә), ахыр килеп, фән, мәгариф-мәгърифәт, иҗтимагый гамәлият Олимпына күтәрелүгә китерә дә инде.

## Юллар чатында: кайсын сайларга?

Ундүрт яшендә Казанга килеп, өч ел кооперация техникумында һөнәри белем алу, аннан соң Курган өлкәсенең ерак бер районында товаровед булып эшләү, гади авыл малаена тормышны танып белү, яхшылык белән янәшә әшәкелекнең яшәвенә, бериш явыз бәндәләрнең, җае чыкса, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, синдәй беркатлыларны салып таптарга мөмкин икәнлекләрен аңлау өчен (шөкер, ярый әле рәхимле затлар да бар – кыен чагында алар булыша), зур иҗтиһад мәйданына чыгар алдыннан сабак булалар. Боларга Совет армиясенең чик буе гаскәрләрендә өч ел хезмәт итү һәм физик, һәм рухи чыныгуны арттыру буларак өстәлә. Кечкенәдән татар рухы, Тукай рухы канына сеңгән туган төбәгеңнән читләргә китеп кара да сигез ел төрле сынауларга дучар ителеп кара! Егерме ике яшен тутырган егетнең эчке дөньясы инде формалашып җиткән, ул бер нәрсәне яхшы белә: ничек тә белем алырга, укып, Кеше булырга. Һәм Рүзәл Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген сайлый, зур конкурсны уңышлы узып, беренче курс студенты булып китә. «Бик яхшы» билгеләренә генә укыганлыктан, Ленин стипендиясе ала; активлыгына күрә, тарих-филология факультетының комсомол оешмасы секретаре итеп сайлыйлар үзен. Бишьеллык курсны дүрт елда тәмамлап, «филолог-тәрҗемәче» квалификациясе алган белгеч, әүвәл үзен радио-телевидение журналистикасында сынап карарга ниятли һәм башта тәрҗемәче, аннары мөхәррир вазифасында эшләп ала. Тик күңел дигәнең барыбер фәнгә тарта, өстәвенә профессор Мирфатыйх Зәкиев университетны тәмамлаган чагында ук аспирантурада калырга тәкъдим иткән була. Шуларны да искә төшереп, булачак галим, элекке остазы кул астына Казан педагогика институтына аспирантурага күчә. Радио-телевидениедә үткән өч ел кебек, аспирантурада уку һәм диссертация язу, шул ук вакытта тәрҗемә эше белән шөгыльләнеп, нәшриятта берничә китап бастыру белән мәш килә торгач (яшәргә кирәк бит), янә өч ел үтә. Кандидатлык диссертациясен якларга гына түгел, өйләнергә дә вакыт җиткән ич. Бу уңайдан да күңелгә хуш килә торган кандидат – Казан авиация институты студенткасы Диләрә, чыгышы белән Олы Мәңгәр авылыннан (сүз уңаеннан: бүгенге көндә дә Рүзәл ага белән Диләрә апа тату гаилә булып бергә гомер кичерәләр). Яшьләр гөрләтеп туй ясыйлар, вакыты җиткәч, әүвәл – уллары Фәнис, аннары кызлары Диләфрүз туа.

## Рүзәл Юсупов эшнең җаен, коллективның көен таба белә

Бер мәкалә кысаларында әллә никадәр иҗтимагый, оештыру һәм җитәкчелек, сәяси һәм фәнни эш алып барган шәхеснең барлык гамәлләрен тулысынча яктырту мөмкин түгел. Хәер, мин үз алдыма андый максат куймадым да. Хөрмәтле академигыбызга кагылышлы язмалар инде күп дистә еллар дәвамында вакытлы матбугат битләрендә дөнья күреп килә.

Рүзәл Абдуллаҗан улы 1983 елда профессор дәрәҗәсенә ирешә һәм КДПИның

тарих-филология факультеты деканы итеп билгеләнә. Ни-нәрсәгә сәләтле булуын яхшы күрсәткәндер, күрәсең, аны 1986 елда эшкә башка урынга күчкән элекке ректор Мирфатыйх Зәкиев урынына тәкъдим итәләр. Башта ул әдәп белән генә баш тарта бу тәкъдимнән. Шулай да партия өлкә комитеты секретаре Рәис Беляевнең үгетләүләренә колак салып, соңрак риза була. Кемнәргәдер табигатьтән җитәкче-оештыручы яисә башка төрле сәләт бөтенләй диярлек бирелмәгән була, ә кемнәргәдер Бөек Тудыручы бөтенесен өеп бирә. Миңа калса, Рүзәл аганы, һич икеләнмичә, соңгылары рәтенә кертергә буладыр. Ул ректор булып торган елларда Казан педагогика институты иң алдынгы уку йортлары рәтенә чыга. Уйлап карасаң, исләрең китәрлек: Казан педагогика институты сугыш вакытында, элекке яхшы биналарны Суворов училищесына калдырып, үзе иске-москы, ярым-йорты биналарда төпләнеп калырга мәҗбүр булган. Вуз шәһәрнең төрле җирләрендәге унлап иске бинага урнашкан. Шуның өстенә, берничә тулай торагы, «Яльчик» спорт-ял базасы, Победилово авылы янындагы агробиостанциясе бар. Шундый зур хуҗалыкны тәртиптә, төзек итеп тотуның катлаулылыгын ректор үзе генә белгәндер.

## КДПУ – белем һәм фән мәгарәсе

1986-2002 елларда (Рүзәл Юсупов ректорлык иткәндә) Казан педагогика институты (университеты) чын мәгънәсендә реформа кичерә. Вуз сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да күзгә күренеп алга китә. Ул, рейтингы буенча йөз педагогика вузының беренче унлыгына кереп, Татарстанда гына түгел, Россия буенча әйдәп баручы вузларның берсенә әверелә. Бу чорда факультетлар һәм кафедралар саны икеләтә арта: алты факультеттан – унике, утыз кафедрадан алтмышка җитә. Студентлар һәм укытучылар контингенты да күпкә киңәя, яңа белгечлекләр кертелә. Педагогика университетының Чаллы филиалы оештырыла, Казан педагогика югары уку йорты тарихында беренче мәртәбә вузның чит ил вузлары белән элемтәләре булдырыла һәм алар елдан-ел җәелдерелә, ныгый. Бу елларда вузның фәнни потенциалы нык киңәя: 1986 елда фән докторлары һәм профессорлар саны уналты булса, 2002 елда алар алтмышка җитә.

## Иң мөһиме – тәрбия

Педагогика уку йортының изге һәм төп максаты булачак укытучыларга белем бирү генә түгел, бәлки аларны югары әхлаклы, мәдәниятле итеп тәрбияләү дә Казан педагогика университеты коллективы үзенә йөкләнгән җаваплы бурычларын һәрвакыт игътибар үзәгендә тота. Ректорат, деканатлар һәм кафедралар, 90нчы еллардагы демократияләшү идеясе белән артык мавыгып китмичә, студентларны тәрбияләү эшенең заман тарафыннан сыналган ысулларыннан ваз кичмиләр. Киресенчә, университет җитәкчелеге тәрбия эшен тагын да ныграк яхшырту, камилләштерә бару, бу эштә таләпне укытучыларга да, студентларга да көчәйтә бару юлына баса.

КДПУ студентларын тәрбияләү эше максатчан, комплекслы һәм масштаблы итеп башкарыла. Һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, педагог-студентлар башка вуз студентларыннан әдәплерәк һәм культуралырак булулары белән аерылып торалар. Ректоратның тәрбияви эшендә җитди чаралар күрүе нәтиҗәсендә Казан педуниверситеты студентларының мораль-этик йөзе яхшы якка нык үзгәрә. Әйтүләренчә, Рүзәл Юсупов ректор булып эшләгән елларда университетта наркомания күренешләренең бер генә очрагы да теркәлмәгән, коллективта яшәү кагыйдәләрен тупас бозулар да булмый. Һәркайда тәртип, чисталык һәм пөхтәлек хөкем сөрә. Студентлар укытучыларга, хезмәткәр-эшчеләргә ягымлы һәм хөрмәт белән карыйлар.

Тәрбия эше – бик зур һәм киңкырлы өлкә. Аның бөтен үзенчәлекләрен тәфсилләп сөйләү мөмкин түгел. Шулай да педуниверситетта эстетик тәрбиягә зур игътибар бирелүенә киңрәк тукталырга кирәктер. Туксанынчы еллар азагын – ике меңенче

еллар башын Казан педагогика университеты тормышында үзенә күрә бер культура революциясе чоры дип атарга ярый. Эстетик тәрбиянең тагын бер чагылышы – ректор инициативасы белән татар филологиясе факультеты бинасында беренче мәртәбә студентлар театры оештырылуын искә алу урынлы булыр. Аның режиссёры итеп ТРның халык, РФның атказанган артисты Марсель Җаббаров җәлеп ителә. Театр зур популярлык казана, спектакльләр шәһәр сәхнәләрендә генә түгел, берничә мәртәбә телеэкраннардан да күрсәтелә.

## Киңкырлы, нәтиҗәле фәнни эш

Олуг галимебез Рүзәл Юсуповның тормыш юлының 60 елдан артыгын, үзен аямыйча иҗтиһад итүгә багышлап, шуның саллы өлешен фәнни эш тәшкил итеп торуына аерым тукталмасак, язмабыз тулы булмас иде. Уйласаң, хәйран калырлык: академикның 1968- 2018 еллар арасында язып нәшер иттергән китаплар саны гына да (бирегә монографик хезмәтләр, дәреслекләр һ.б. керә) 65кә җыела. Аларның шактые тәрҗемә теориясе һәм практикасына багышланган; сөйләм культурасы, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында белем алучылар өчен дәреслекләр һ.б.лар – һәммәсе конкрет максатны күздә тотып язылган. Аның 1961 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр дистәләгән исемдәге вакытлы матбугат басмаларында дөнья күргән мәкалә, очерклары һәм публицистик язмаларының саны 400дән артып китә. Тәрҗемә димәктән, фән өлкәсендә (урысчадан татарчага тәрҗемә итү күздә тотыла) иң беренчеләрдән булып тәрҗемә теориясен эшләгән кеше дә әле ул Рүзәл Юсупов. Аның әлеге махсус хезмәтен вузларда дәреслек буларак файдаланалар, студентлар, галимнәр, гомумән, гуманитар һәм техник юнәлештә эшчәнлек алып баручылар үзләренә методик әдәбият итеп кулланалар. Рүзәл Абдуллаҗан улы КДПУда ректорлык иткән елларында тел гыйлеме буенча диссертация яклау советында рәис булып кына калмый, үзе дә фән кандидатлары һәм фән докторларының диссертация эшләренә җитәкчелек итә, аларның саны 30га җитә.

## Иҗтимагый-сәяси мәйданда

Рүзәл Юсупов – табигате белән иҗтимагый актив кеше. Бу аңа мәктәп эскәмиясеннән үк хас сыйфат, һәм аның әлеге үзенчәлеге башта армиядә (хәрби хезмәттә комсомол секретаре һәм заставадагы стенгазетаның мөхәррире була), аннары Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында комсомол бюросы секретаре чагында тагын да ныграк чарлана. Казан дәүләт педагогика институтында эшләгәндә, аны берничә мәртәбә тарих-филология факультетының партоешмасы секретаре итеп сайлап куялар. Бу бит әле укыту эшләрен дә алып барган бер вакытта, җәмәгатьчелек башлангычында. Моның өчен күпме энергия таләп ителә, тик үзендә яшьтән ихтыяр көчен тәрбияләгән ир заты барысына да өлгерә.

Ул 1989 елда Казан шәһәр советына депутат булып сайлангач, андагы даими мәгариф комиссиясенең рәисе итеп билгеләнә, ә Татарстан Югары Советына депутатлык мандатына ия булгач, парламентның милли мәсьәләләр, мәдәният буенча комиссиясен җитәкли, президиум әгъзасы итеп сайлана.

Нәкъ менә парламентта эшләгән елларында Рүзәл Абдуллаҗан улының эшчәнлек потенциалы тулы куәтенә ачыла да инде. Ул чын мәгънәсендә үзен гражданлык позицияләрендә нык торучы, сәяси өлгергән эшлекле, принципиаль рәвештә халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы һәм яклаучы шәхес буларак таныта.

Үткән гасырның туксанынчы еллары Россиядә һәм милли республикаларда социаль вазгыятьнең кискен үзгәрүе нәтиҗәсендә, халыкларның милли үзаңы үсүгә китерде. Бу хәл, әлбәттә инде, Татарстанда да күзәтелде. Татарстанда яшәүче халыклар тигез хокуклык, мөмкин булган кадәр икътисади һәм сәяси мөстәкыйльлек, дин иреге һәм демократик җәмгыятькә хас башка атрибутларны даулап чыктылар. Әлеге күренеш тора-бара массакүләм төс алды һәм халык массаларының, мәйданнарга чыгып, республика суверенитетын таләп итүенә китерде.

Мондый шартларда Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов, парламент һәм аның президиумының әгъзасы, милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча комиссия рәисе буларак, берничек тә читтә кала алмый иде. Шунлыктан ул, Татарстан халыкларының киләчәк язмышына караган мәсьәләләрне хәл итәр өчен, җиң сызганып эшкә алынды. Академиклар М.Зәкиев һәм Ф.Ганиевлар белән Татарстан халыкларының телләр турында закон проектын эшләүдә, аннары әлеге проектны Югары Совет сессиясендә тикшерүдә актив катнашты.

Татарстан Югары Советының 1990 ел 30 августындагы дәүләт суверенитеты кабул итү турындагы тарихи Декларациясен яклап, ялкынлы чыгыш ясаучыларның иң беренчеләреннән – Рүзәл Юсупов. Ул һәрбер сессиядә һәрчак үзенең туры сүзен әйтә, катгый фикерен белдерә. Намусына тугрылык саклап, дөрес дип тапкан позициясеннән беркайчан да чигенми.

Рүзәл Юсуповның Татарстандагы Республика партиясен оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе булуын әйтеп китмичә мөмкин түгел. 1992 ел ахырында оешып (партияне оештыру эшенең үтә катлаулы икәнен аны оештыручылар үзләре генә беләдер – ким дигәндә, республика районнарының яртысында башлангыч оешмалары булырга, әлбәттә инде, программа һәм уставы кабул ителергә, юстиция министрлыгында теркәлү үтәргә һ.б. тиеш), өч-дүрт ел дәвамында республикада зур авырлык белән яуланган демократик казанышларны яклау һәм үстерү өчен, ифрат зур тырышлык куя әлеге партия. Зур вузның ректоры, парламенттагы даими комиссиясенең рәисе һәм янә әллә ничә юнәлештә (җәмәгать башлангычында) иҗтимагый эшләр башкаручы булуына карамастан, бертавыштан сайлап куйгач, Рүзәл Абдуллаҗан улының Республика партиясенең рәислегенә риза булудан башка чарасы калмый. Ул беркайчан да, бернәрсәне дә ярты-йорты гына башкармый. Аның яшәү принцибы – «эшлисең икән – үзеңне тулысы белән башкарган гамәлеңә багышлау тиеш». Ялганны, ялагайларны җене сөйми аның. Үзе алдашуны белмәгәч (калебе чиста булгач), башкаларны да шулай дип уйлый, һәм 2001 ел ахырында кайбер хөсетле бәндәләр югары оешмаларга шикаятьләр язып (койрык болгап, ярарга тырышып йөрүчеләр, җае чыгу белән, аннан котылырга ниятлиләр), аны ректорлыктан алдыргач, бу хәерсез гамәлне бик авыр кичерә. Дөреслек еш кына ерак яшерелгән була, тик тырышып эзләгәндә, кайчагында, аны табарга мөмкин. Хокук белгечләреннән бер рәхимле кеше Рүзәл аганың «эше» белән танышкач, Мәскәү судына мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә. Урынсызга эштән азат ителгән олуг галим кабат ректорлык эшенә кайта. Гаделлек тантана итә. Бер елдан соң Рүзәл ага үз теләге белән эштән китә. Хәер, алтынга пычрак ябышмый.

Язмабыз герое Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповны соңгы елларда үзем өчен гаҗәеп шәхес буларак ачтым (юкка гына аны 1997 елда Кембриджлагы Халыкара биографик үзәк «Ел кешесе» дип исемләнгән халыкара мактаулы титул белән бүләкләмәгән). Ул менә дистә елдан артык инде пенсия акчасына фәнни-популяр, әдәби-публицистик һ.б. тематикаларны эченә алган төрле исемдәге китапларын нәшриятларда бастырып чыгара. Ул аларны чын күңеленнән, халык укысын, аз булса да уйлансын, татарлар милләт буларак киләчәктә юкка чыкмасын өчен яза. Бәгыреннән алып, җан ачысын ак кәгазьгә салып, өзгәләнеп һәм шул ук вакытта якты киләчәккә өметләнеп... Өметләр генә өзелмәсен иде берүк.

**Фирдәвес ХУҖИН**



*Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары. Чүгәләп утырганнар (сулдан уңга): Илдар Юзеев (киләчәктә халык шагыйре), Суфиян Поварисов (киләчәктә Башкортстанның халык язучысы). Басканнар: язучылар Газиз Мөхәммәтшин (сулдан икенче) һәм Марат Әмирханов (уңнан беренче). Казан. 1953 ел.*



*Күренекле галимнәр (сулдан уңга) Әгъдәс Борһанов, Мархан Хәйдәров (үзбәк галиме). Икенче рәттә: Рәмзи Вәлиев, Марат Мөлеков (Татар иҗтимагый үзәгенең беренче рәисе), Борис Николаев (чуваш галиме). 1960 еллар азагы.*



*Татарстан Язучылар берлеге рәисе бүлмәсендә киңәшмә. Сулдан уңга: берлекнең яшьләр белән эшләүче консультантлары: шагыйрь Гәрәй Рәхим һәм рус язучысы Юрий Белостоцкий, берлек идарәсе рәисе Гариф Ахунов, берлекнең партия оешмасы секретаре Габдрахман Минский. Узган гасырның җитмешенче еллары.*



*Җәмит Рәхимов (1935-1996) – күренекле татар язучысы. «Батырша» исемле тарихи роман авторы.*



*Якташлар-замандашлар: язучы Рабит Батулла (сулда), артист Наил Дунаев. Зәй. 1997 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# ҖАННЫ КӨЙГӘ САЛУ

Кире кагылгысыз зарурлык таләбе: сәнгать югарылыгындагы һәрбер иҗат башкалардан аерылып торырга тиеш. Тик мондый максатка ничек ирешергә соң? Шушы юнәлештә даим эзләнүчеләр өчен катгый күрсәтмәләр әзерләү мөмкин түгел. Музага тартылган һәммә зат бу хасияткә үзенчә тиенә. Күрер күзгә сәләтле генә тоелган шәхеснең гадәтилек чигеннән чыга алмавы да ихтимал. Андыйлар да хәтсез. Әйе, сәмави илһам белән башкарылган эшчәнлектә кабатланмас урыныңны табу күп кенә рухи сыйфатларны яхшылап үзләштерү нәтиҗәсендә бирелә. Каләм әһеленең әлеге мөһим үзенчәлеге, әлбәттә, мавыктыргыч язу рәвешен булдырудан башлана. Чынлыкта әдәби әсәрнең сәнгатьчә кыйммәте барыбер камил өслүп нисбилегендә бәяләнә.

*Үз-үземне шигырьләремә*
*Ташлыймын да*
*Өр-яңадан*
*Яши башлыйм!*

Каләмдәшем Ләбиб Леронның «Мөмкин булса...» исемле шигырендә иҗадият белән җан-тән биргәлеге ачык чагыла шикелле. Чыннан да, шундый очракта гына шагыйрь, рухи гармония югарылыгына күтәрелеп, киләчәктә уңыш китерерлек үз почеркын гамәлгә куя аладыр. Күпләрне үзенә тартып торырлык стиль нәкъ менә күңел тирәнлекләрендә ярала. Ул кеше затының холык-фигыле билгеләренә дә, туган тел байлыгыннан файдалана белүенә дә, мәгълүмати әзерлегенә дә аерылгысыз рәвештә бәйле. Ә язучының тора-бара даими гадәтенә әверелгән үзенчәлекле тел-өслүбе яшәешнең асылын тирәнрәк аңлауда, чынбарлыкка әдипләрчә мөнәсәбәт белдерүдә яңадан-яңа офыклар ачарга сәләтле корал сыйфатында хезмәт итә. Бу җәһәттән Ләбиб Леронның лирик уйланулары хәтергә килә. «Синең хакта» дигән әсәрдәге мондый сүзләр шушы дулкында аеруча табигый яңгырый кебек: *«...Ыгы-зыгы. Башым гөжли. Нишлим? Зәңгәр киңлек сорый фикерләрем».*

Узган гасырның сиксәненче елларында зур әдәбиятка килгән Ләбиб Лерон үзенең эзләнүле иҗаты белән мине һәрвакыт төрлечә кызыксындырып тора. Каләм эшчәнлегенең башлангыч чорында аның максатчан омтылышларын, аерым алганда, фикерләү-язу рәвешен ныгыту юнәлешендәге тырышлыкларын да күзәттем. Инануымча, бу каршылыклы тормышны яктыртып күрсәтүдә шагыйрь төсләр муллыгына өстенлек бирә. «Нур-җеп белән гөлчәчәкләр чигеп...» Бай палитрага таянган хәлдә эш итәргә күнегүен автор «Нидер көтәм» шигырендә дә ишарәләп үтә. Монысы яхшы аңлашыла. Хәтта җирдәге меңнәрчә үсемлекне сурәтләгәндә дә күп төсләрдән маһирларча файдаланырга туры килә. Дөрес, яшәешнең игътибар үзәгенә алынган хәлләрен һәркем җаны теләгәнчә тасвирларга хокуклы. Үз әсәрләре тукымасында бары ак белән карага яки сүрән төсмерләргә генә авышучылар да бар. Ә менә Ләбиб Лерон дөньяны төрле яклап, аның бөтен чуарлыгын колачларга омтылуны хуп күрә.

*Сабак өйрәнәмен –*
*Заман бирә дәрес.*
(«Дәрес»)

*Иҗатның тормыш икәнен*
*Аңласаңчы, и йөрәк!..*
(«И йөрәк!»)

Шигъри иҗатны сынлы сәнгать белән чагыштырырга яраткан Ләбиб Лерон, күргәнебезчә, үзенә йөкләнгән олуг миссияне тирәнтен аңлавын язып та сиздертә. «Буяулар сөйләшә башлый, Кылкаләмгә ым бирсәң», дип гаҗәпләнә ул «Тылсымчы» исемле әсәрендә. Автор әлеге романтик күзәтүендә дә яшәешнең күпьяклы булуына, илһам чишмәсенең ирекле агарга тиешлегенә янәдән игътибар юнәлтә. «Ләйсән яңгыр яуганда» дигән шигырьдә дә бу искәртү башка сүзләр белән кабатлана: *«Күңел кылым чыңлап куйды... Күңел – моңлы саз икән»*. Белгәнебезчә, парлы яки өчәрле кыллардан торган әлеге уен коралы безнең әдәбиятта шигърият символларының берсен күз алдына китерә. Сазда санаулы гына кыллар, күңелдә исә алар бихисап. Артык җәелмичә аңлатканда, шагыйрь кальбе яратылышында, һичшиксез, моңлану мөмкинлекләре зуррак. Әлбәттә, бер кылы өзелгән скрипкада да катлаулы көйне гаҗәеп дәрәҗәдә оста уйный алучылар, ноталарның өчесен генә кулланып язылган җырлары белән зәвыгыбызны бозып ятучылар да бар. Төрле хәлләр күзәтелә. Әмма яшәеш симфониясен бөтен авазларда, табигый тулылыкта яңгыратуга ни җитә! Француз язучысы Гюстав Флобер хаклы рәвештә кистереп әйткәнчә, «Стиль – тормышның үзе ул»:

*Табигать – оркестр.*
*Аңлыйм да... аңламыйм:*
*Күктән дә,*
*Җирдән дә*
*Ява моң?!*

Иҗат өслүбенең яшәеш чынлыгын һәрьяклап ачуны тәэмин итәргә тиешлеген нечкәләп аңлаучы Ләбиб Лерон үзенең шушы карашын «Йомарлам» дип аталган поэмасындагы шигъри сурәтләүдә дә өлешчә чагылдырып уза. «Яшел тантана» исемле шигырьдә дә ул әлеге теманы үстерергә омтыла: *«Күңелләрдән ташып моң түгелә... Сәер хисләр белән җан яна»*. Аның башка әсәрләрендә дә «җан» төшенчәсе искә алына. Шул рәвешле, образ отыры киңәя бара. «Ван Гог «Автопортрет»ы янында уйлану» шигырендә автор хәтта илһамлану серләрен ачарга тели. «Гамьле төсләр җанымда эри», ди шагыйрь, ихласлык белән. Ошбу дүрт сүздә Ләбиб Лерон эшчәнлегенең төп кредосы да, озак эзләнүләр бәрабәренә табылган тел-өслүбенең йөкләнеше дә шәйләнә сыман. Гамьле төсләр эремәсе, эчке янулы җан, моңлы саз җыры... Аңлашылганча, үзен милләт улы итеп тойган каләм әһеленең язу стиле, әлбәттә, күпне колачларга сәләтле хасияте белән халыкның мәнфәгатьләрен кайгыртырга бурычлы. Моны Ләбиб Лерон да хакыйкать югарылыгында таный һәм җаваплы гамәлендә ошбу кагыйдәгә тугрылык саклый.

*Җиңеллек эзләмим –*
*Һәрвакыт иңдә йөк.*
*Пакьлим, дип, дөньяны,*
*Тырышам мин дә бит.*

*Халкым, дип, милләт, дип,*
*Туган тел, дип яшим.*
*Бик авыр мәлләрдә*
*Вөҗданым – иптәшем.*

(«Тукайча яшим, дип...»)

Янәдән кабатлап раслаганда, Ләбиб Леронның иҗат алымына җан-рухны җилкеткән колачлылык хас. Әлеге үзенчәлек шагыйрьне борчыган мәсьәләләр төрлелегендә дә, образлы фикерләү агышының тулылыгында да ачык күренә. «Фикерләрем оча кояшкача!..» Автор «Синең хакта» дигән шигырендә купшылык өчен генә шулай әйтмидер. Ул үзенең максатчанлыгын да, үҗәтлеген дә яшереп тормый. «Бу – тормыш бу!» дип аталган әсәрдә, әнә, яшь каләмдәшләренә үрнәк саналырдай ихтыярлылык

чагыла: *«Булыр, күзләреңә синең Яшь тыгылыр бик еш. Йөрәгеңә кан сауса да, Син язарга тиеш!»* Менә шундый ныклык белән Ләбиб Лерон авыр темаларга да алына, көндәлек тормышта гавамны туктаусыз кызыксындырган катлаулы сорауларга җавап та эзли. Аның тынгысыз җаны тар кысаларга сыймый. Әдәби эшчәнлектә һәммәсе мөһим. Остаз әдипләр искәрткәнчә, кайбер каләм ияләрендәге эч пошыргыч бертөслелек аларның нәкъ менә чикләнгән карашыннан киләдер. Безнең Ләбиб Леронга мондый куркыныч янамый.

*Мөмкин, әйе, тамак туйдырырга*
*Такмак язып һаман, такмак сатып...*
*Күтәрәмгә калган чакта илең,*
*Милләтеңнең булсын ак максаты!*

Дөрестән дә, күпне кичергән газиз кавемеңнең милли идеясеннән дә зуррак, аның олуг мәнфәгатьләреннән дә өстенрәк бурычлар бармы икән?! Шушы уңайдан Ләбиб Леронның «Ак максат» исемле ошбу шигырен кат-кат укыгач, Габдулла Тукайның «Юбилей мөнәсәбәте белән» дип аталган мәгълүм мәкаләсе искә төште. Хәтерлисездер, анда падишаһ хәзрәтләренә олы таләпләр кую урынына ваемсыз төстә вак-төяккә авышучылар тәнкыйть утына алына. «Бу хәл инде..., бөтен авыл янганда, белмәмешкә салынып, чабата киндерәсе үрү була иде». Шагыйрь әнә шундый мыскыллы нәтиҗә чыгара. Кызганыч ки, безнең каршылыклар тулып ашкан тарихыбызда уйланырга мәҗбүр итәрдәй гыйбрәтләр байтак. Замандашыбыз Ләбиб Лерон да әлеге әсәре аша милләттәшләрен иҗтимагый битарафлык чиренә бирелмәскә, татар халкының өзлексез сынаулардан гына торган язмышы үзәгендә фидаиларча көрәшеп яшәргә чакыра.

Шәхеснең эчке инанганлыгы нык-таза булган очракта гына аның иҗаты какшамас нигездә тармакланып китәргә мөмкин. Карашлар тотрыклылыгы исә алай җиңелдән бирелми. Моның өчен максатчанлык та, эзләнүчәнлек тә, сабырлык та, тынгысызлык та бердәй кирәк. *«Үз-үземне тинтерәткән мәлем, Аптыраткан чагым сезне дә...»* Шагыйрь Ләбиб Лерон «Җавапсыз сораулар» дигән шигырендә кадерле укучылары белән шулай аңлашуны фарыз саный. Ә чишелеш көткән мәсьәләләр чынлап та ифрат күп. Катлаулы сөальләргә җавапны бергәләп табу мәслихәт. Халыкны һавада эленеп торган идеяләр түгел, яшәештә зарур хаклыклар беренче чиратта кызыксындыра. Тормышта күзәтелгән аерым күренешләр дә аның төпченүле игътибарыннан читтә калмый. Каләм шуларга да төртеп күрсәтергә тиеш. XX гасырда аеруча көчәйгән мөһаҗирлек хәлләрен генә алыйк. Баксаң, гадәти тоелган ошбу мәсьәләдә дә кайбер милли үзенчәлекләр бар икән. Байтак илдәшләрнең язмышын зир-зәбәр китергән Октябрь инкыйлабыннан соң күпләр чит мәмләкәтләргә күченеп гомер сөрергә мәҗбүр булды. Башка милләт вәкилләре диңгез корабларына сыешмыйча, безнекеләр исә берәм-берәм диярлек китеп барды. Алар хәтта горбәттә дә төрле максатлар белән яшәде: берәүләр үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртты, икенчеләр сөекле халкының хакын даулады... Кыскасы, «Гаяз Исхакыйның кайтуы» исемле шигыре белән Ләбиб Лерон әнә шундый уйлануларга этәрә. Әлеге мөһаҗирләрнең тәкъдиренә, әйе, насыйп төрлелек хас.

*«Исән булсак, бер кайтырбыз әле!» –*
*Дип киткәннәр кайтты яңадан:*
*Урыс кайтты... Яһүд... Татар гына*
*Артка калды бераз алардан.*

Элгәрләребез әйтмешли, бу дөньяның көе бар, кырык төрле чөе бар. Безнең халыкта даим әйләнештә йөргән «кырык» саны күчмә мәгънәне дә аңлата, димәк, әлеге микъдар төшенчәсе кулланылганда, «бик күп» дигәнне күз алдында тотарга кирәк. Озын юл үткән кешелек җәмгыяте камиллектән әлегә шактый ерак тора. Әдәбият белгечләре өйрәткәнчә, шигърият әүвәл тормышның үзеннән үсеп чыккан, шуннан соң гына сәнгать төренә әйләнгән. Мондый раслама аһәңле сүзнең яшәештәге

олуг вазифалары, шагыйрьләрнең инсаният алдындагы зур җаваплылыгы турында сөйли. Әлбәттә, каләм әһеле географик бүленеш кысаларында кала алмый, аны уртак Җиребез язмышына бәйле һәрнәрсә тынычсызларга тиеш. Киң колачлы иҗат өслүбенә ияләшкән Ләбиб Лерон да үз миссиясенә чикләнгәнлек билгеләренең бөтенләй килешмәвен яхшы тоя. «Яралу» дип аталган шигырендә дә ул шуңа ишарә ясый шикелле. *«Мин уйдан яралганмындыр – Уй сыман оча күңлем...»* Дөнья гаме исә аны һәркайда эзәрлекли.

*Ялгыз булмә. Хуҗа миңа*
*Борчу уйлар өере.*
*Булдырылган кадәр мине*
*Бимазалый һәрбере.*

*Кайсы үрти, кайсы чәнчә,*
*Кайсы телсез күк ымлый...*
(«Ялгызлык»)

Күпләр стильне табигате буенча гаять четерекле иҗат рәвеше, ягъни гади әйберләрне аңлатуның катлаулы ысулы итеп күзаллый. Тәҗрибәле әдипләр, киресенчә, аны катлаулы хәлләрне чагылдыруның гади алымы дип саный. Мондый билгеләмәнең дөреслеккә туры килүе Ләбиб Лерон мисалында да раслана. Аның тел-өслүбе алай артык авыр түгел, әмма фикер сөреше күпчелек очракта җитди. Шагыйрь игътибар колачын отыры киңәйтә, күтәрелгән мәсьәләләргә глобальлек төсмерен бирә. Ә аек карашка ихтыяҗ бик зур. Җирдә ничәмә-ничә буын яшәп киткән, алар ирекле-ирексез күпме гөнаһ кылган. Дөнья сафлануга мохтаҗ. Бу җәһәттән Ләбиб Лерон да үз мөнәсәбәтен әледән-әле белдергәләп куя. *«Мин Җир шарын юар идем,* – ди ул, – *Яңгыр булып явалсам»*. Тынып тормаган эреле-ваклы сугышлар да аның генетик сызлануын көчәйтеп җибәрә. Әлеге афәтләр исемлегенә нокта куелмау «Йомарлам» поэмасында да искә алына.

*Кешелек авырый –*
*Бармы бер дәва?*
*Табасы иде бит,*
*Даруын табасы...*

Хәтерлим, Ләбиб Лерон 1991 елда яңа поэма иҗат итте. Аның гадәти тоелмаган исеме игътибарымны шундук үзенә тартты: «Танк биюе». Ошбу дәһшәтле сугыш техникасы миңа шактый яхшы таныш. Казан дәүләт университетын тәмамлагач, офицер буларак, армия хезмәтенә китеп бардым. Ерак Көнчыгышның мәһабәт сопкалары итәгенә сыенып урнашкан танк полкында рота командирының техника буенча урынбасары вазифаларын үтәргә туры килде. Үз халкы белән көрәшүдән туймаган совет илендә әлеге гыйфрит куркыту символына әверелгән заман иде. Мәйданнарда җыелган дәгъвачыл халыкны кичекмәстән авызлыклау өчен, нәкъ менә броняга төренгән хәрби машиналар файдаланылды. Төрле кайнар вакыйгалар җәһәтеннән, совет танклары Урта Азия, Кавказ, шулай ук Балтыйк буендагы союздаш республикаларны аркылыга-буйга иңләп чыкты. Татарстан Республикасының суверенлыгы турында тарихи референдум үткәрелгән чакта да (1992 ел, 21 март) РФ Куркынычсызлык советы утырышында «сепаратчы»ларга басым ясау мәсьәләләре карала. Безнең өчен гаять киеренке көннәрдә җөмһүриятебезнең көнбатыш чикләрендә меңнәрчә танкның «мотор җылытуы» хакында хәбәрләр дә йөрде. Шөкер, тавыш бирү уңышлы үтте... Әле дә истә, Чехословакияне «законлы төстә» социалистик лагерьга кайтару вакытында да шул ук совет танклары төп рольләрнең берсен башкарды. Күптән түгел Прагага баргач, илнең башкаласы үзәгендә көч-кодрәт һәйкәле кыяфәтендә туктап калган, дөресрәге, пьедесталга күтәрелгән куркынычлы машинаны шәхсән үзем дә күрдем.

*Үлчиләрдер кан басымын,*
*Белмим,*
*Нинди үлчәүдә, –*
*Җан басымы безнең илдә*
*ТАНК белән үлчәнә!*

Исеменнән үк сиземләнгәнчә, гайре табигый тоелган танк биюе поэманың төп метафорасын тәшкил итә. Күчмә мәгънәне аңлаткан әлеге сурәтләү чарасы образлы фикерләү агышына мантыйкый эзлеклелек бирә. Әсәрнең композицион бөтенлеге дә нәкъ менә шуннан киләдер. *«Шигыремне айкап, танк йөри – Сүз-тезгенем әзер өзелергә...»* Шагыйрь Ләбиб Леронның гаҗиз хәлдә әйтелгән ошбу сүзләре киеренке вакыйгаларны үзара бәйләүче үзенчәлекле рефрен рәвешендә яңгырый. Канлы тамаша Вильнюста бара. Халык белән тулы мәйданга, гайрәт орып, танклар колоннасы килеп керә. Барысын да сытып үтәргә әзер албасты, чикләнмәгән хокук алгандай, куркынган кешеләр арасында үзенчә бии башлый. Тәгәрмәч чылбырыннан очкыннар чәчри. Кара сөрем чыгарып, куәтле моторлар гүли...

Хәрби хезмәт барышында шәхсән үземнең дә, йөртүче сыйфатында, танк кадәр танкны... «Әпипә»гә биеткәнем бар. Вәләкин шау-шулы кызган мәйданда түгел, Биробиджан шәһәре читендәге аулак танкодромда. Минем катнаштагы арлы-бирле кискен йөреш вакытында хәтта кырмыска да зыян күрмәгәндер, Вильнюста исә литва татар кызы Лорета Асанавичюте фаҗигале төстә һәлак була. Күпләр җәфа чигә. Теге заманда совет танкларының биюе еш кына шулайрак төгәлләнә иде. Мондый сәяси уеннардан һәрвакыт уймак чыга. Ә милләттәшебезнең танк астында калуы турында уйланганда, төрлечә аңлашыла торган халык мәкале хәтергә төшә. Төгәлрәк әйткәндә, аның беркадәр үзгәртелгән үрнәге: хәтәр барда татар бар... Озын сүзнең кыскасы, Ләбиб Леронның «Танк биюе» поэмасы гамьле күңелдә хис-кичерешләр ташкыны кузгата. Үз халкыңны яратмау кайдан башлангыч ала? *«Патша килә, патша китә – Киткәннәрдә бар гаеп»*, дип, автор кайбер гомумиләштерүләр ясауны да кирәк таба. Сүз дә юк, Явыз Иван залимлекләре чорында танк әле уйлап чыгарылмаган. Әмма астарлы фикердән аңлашылганча, ил-көн белән үчләнеп уйнауда тәгаен тоталитар хакимият гаепле.

Әле яңа эрага кадәр үк яшәгән борынгы грек философлары безгә әйтеп калдырганча, һәрбер сәнгать төрендә табигатькә иярү чагыла; чынбарлыкка охшатырга тырышу иҗатның тормышчанлыгын билгели. Адәм баласын үзенә сыендырган табигать исә чын мәгънәсендә мөкәммәллек үрнәге булып тора. Аның үзара бәйләнешле бизәкләре исәпләп бетермәслек дәрәҗәдә күп. Хәтта салават күперендә дә төсләр җидедән артып китә. Яшәешне колачларга омтылу өчен дә каләм иясеннән киң карашлылык сорала. Алай гына түгел, ул һәммә алымнан нәтиҗәле файдаланырга тиеш. Шушы уңайдан Ләбиб Леронның төрле әдәби жанрларда уңышлы эшләве дә бу дөньяның бихисап катламнарын мөмкин кадәр тулырак ачарга теләүдән килә. Һәрбер шигъри формада да ул үзен иркен тота. Алар байтак: шигырь, поэма, робагый, җыр, эпиграмма, пародия... Шагыйрь юмор-сатира өлкәсендә дә зур мөмкинлекләрен күрсәтүгә ирешә. Гадәттә, юморны яшәүгә зарар китермәгән микъдардагы дөреслеккә тиңлиләр. Ә Ләбиб Леронның уен-көлкеле шигырьләре зарури хаклыкны укучы кальбенә сала. Әлбәттә, мондый әсәрләрнең күпчелеге тәрбияви максатларга юнәлдерелгән. Авторның чәнечкеле юллары да ачы дарудай кабул ителә. Милли мәсьәләләргә кагылышлы кайбер һөҗүи сүзләрне әйткәндә, каләмдәшебез күзендә яшь тә җемелдәп куя кебек. «Шайтан коткысы» дигән шигырьдә, мәсәлән, ирексездән, «нечкәрү» халәте тоемлана.

*Үземне мин үзем генә*
*Беләм инде, –*
*Җүләр төсле җылый-җылый*
*Көләм инде.*

Тәҗрибә аңлатканча, тезмә жанрның төрле мөмкинлекләреннән файдаланырга омтылу образлы фикерләүнең колачын сизелерлек киңәйтүгә китерә. Әйтик, Ләбиб

Леронның багышлаулар язуга зур игътибар күрсәтүе дә аның әдәби дөньясын тематик яктан баетырга этәргеч бирә. Ул, татар халкының мәгълүм затларына атап, инде берничә дистә шигырь иҗат итте. Бу үзенчәлекле галереяда кемнәр генә юк: Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Һади Такташ, Кәрим Тинчурин, Муса Җәлил, Бакый Урманче, Хәсән Туфан, Сара Садыйкова, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Миркасыйм Госманов, Ринат Таҗетдинов... Дөресен әйткәндә, безнең тирән тамырлы әдәбият һәм сәнгать үсешен әлеге шәхесләрдән башка берничек тә күзаллап булмый. Ахыр чиктә, халыкның бөеклеген дә нәкъ менә шундый мәшһүрләр билгели. Ошбу циклның барлыкка килүендә шагыйрьнең киң күңелле икәнлеге дә, аның үткәнебезне данлаучы элгәрләргә хөрмәт белән каравы да күренә. Аерым язмыш сәхифәләрен үзәккә алган мондый әсәрләр милли тарихыбызны тулырак аңлау өчен дә кирәк. Автор үзенең багышлауларында ил-көнне сынаган төрле заманнарны үзара чагыштыра, кайбер нәтиҗәләр ясый, өлгеләрнең кыйммәтен ачыклый, узганнарның тылсымлы көзгесендә үзен дә лаеклы рәвештә төсмерләргә тели.

*Бүгенгедән үткәнемә карыйм –*
*Үз-үземне килә күрәсем;*
*Гасыр аша һәр кешене барлыйм –*
*Мин түгелме шуның берәрсе?*
(«Җан күчеше»)

Рухи офыкларны киңәйтүнең, әйе, төрле-төрле юллары бар. Башка халыклар белән тәрҗемә алмашу да шушы игелекле максатка үзенчә хезмәт итә. Мондый юнәлештәге иҗтиһат теге яки бу әдәбиятны яңача баетып кына калмый, әлеге эшчәнлеккә алынган каләм ияләренең интеллектын тирәнәйтүгә дә уңай йогынты ясый. Бөтенесен берьюлы колачларга омтылган Ләбиб Лерон да, тәрҗемә кылуга әһәмият биреп, үз күңеленә ятымлы шагыйрьләрне татар укучысына якынайта. Шундый талантлар арасында Анна Ахматова, Леонид Мартынов, Андрей Вознесенский, Эдуардас Межелайтис, Кайсын Кулиев, Давыт Көгелтдинов, Юван Шесталов, Абдулла Арипов, Пабло Неруда, Поль Верлен, Артюр Рембо кебек затларны күрәбез. Ирекле төстә сайлап алынган әлеге авторларны санап үткәч, Ләбиб Леронның зәвык югарылыгы да шактый ачык төсмерләнә. Аларның әсәрләренә ул ни өчен тукталган? «Дала җыры» дигән шигырьдә моңа җавап табыла сыман.

*Сезнең җырлар өмет булып очкан,*
*Хәсрәтләрнең тараткан барын.*
*Сез ул – тугры сүзле горур башлар,*
*Ак хакыйкать тарафдарлары!*

Озак еллар дәвамында күзәтүемнән чыгып әйтәм, яшьтән үк уянган иҗади эзләнүләр дәрте Ләбиб Леронны бүгенгә кадәр озатып бара. Хәтта кайбер шигырьләрендә дә шул халәтнең билгеләре чагыла. *«Әйтелмәгән әле әйтер сүзем»*, дип белдерә шагыйрь ниндидер тынычсызлану дулкынында язылган «Бушану» исемле әсәрендә. «Йомарлам» поэмасында да бар шундыйрак юллар: *«Әллә нәрсә! Күңелемә уйлар килә өер-өер, – Башы булса, юк уртасы йә ахыры...»* Ошбу сүзләрдә Пегас-атның чыгымчылап алуын, эзләнү каршылыкларын күрми мөмкин түгел. Фараз кылуымча, мондый очракта Ләбиб Лерон вакытлыча бүтән жанрга күчәдер. Аның мөмкинлекләре зур. Ул прозада да үз югарылыгын тота. Тезмәдә яңгыраш тапмаган идеяләрнең драматургиядә ачылып китүе ихтимал. Шагыйрь балалар әдәбиятын да яңа табышлар белән баетты. Шигырьләр, хикәяләр, пьесалар, әкиятләр, мәзәкләр, җырлар, комикслар... Авторның шушы төрдәге әсәрләрен туплаган «Яңгырның ял көне» (1988), «Транзистор үч ала» (1989), «Тәгәрмәчле чана» (1993), «Таһир маҗаралары» (2000), «Кояшны кочкан малай» (2004) ише китапларында да киңлеккә ашкынучан тел-өслүп төсмерләнә. Тиктормас каләмнең хезмәтләре һәрбер юнәлештә күренә. Пьесалар республикабыз театрларында куела, телевидение аша тәкъдим ителә. Иҗатчы канәгатьләнергә ашыкмый. *«Хикәя йә*

*шигырь язып кына Үткәрмидер көнен һичбер әдип...»*, шулай фикер йөртә ул «Үтенеч көне» дигән шигырьдә. Аңа публицистика да бердәй дәрәҗәдә якын. Билгеле ки, Ләбиб Леронның язучылык эшчәнлегендә беркадәр чәчелү дә күзәтелә. Әмма монысы да безнең әдәбиятка хас. Бу күпкырлылыкка омтылудан килә. Иң мөһиме – әйтер сүзеңнең камил рәвешкә керүе, һәрбер гамәлдә үзеңнең биеклеккә ирешү. Ә Ләбиб Лерон барлык жанрда да без белгән шагыйрь булып кала күк. Дөресрәге, башка төрдәге әдәби әсәрләрдә дә ул үзенең шагыйрьлеген үзгәчә гәүдәләндерә. Элгәрләр мисалында расланганча, тотрыклы стилен калыплаштырган каләм әһеле сөйләм үзенчәлекләрен беркайчан да үзгәртми. Моның мотлак шулай икәнлеген Ләбиб Лерон да таный.

*Табынып, иманга инанып,*
*Яшәве һәркемгә кулайдыр.*
*Йөрәгем – иманым!*
*Шуңа да,*
*Бәлки, мин – үземдер.*
*Шулайдыр.*
(«Мин – үзем»)

*Без үзебез булып калдык –*
*Югалмадык!*
(«Шөкер»)

Шәт, ышангансыздыр, Ләбиб Леронның язу рәвешендә өстенлекле исәпләнгән үзенчәлекләр хәтсез. Шуларның тагын берсенә игътибар юнәлтәсе килә. Әһәмиятле саналган әлеге хасият каләмгә иркенлек бирүдән гыйбарәт. Чыннан да, шагыйрь кулындагы ошбу корал үзен шактый иркле сизәдер. Әйе, хыялый атның да тезгене булырга тиеш. Мондый хөрлекнең мантыйк кысаларыннан чыкмавы, һәрдаим аң-зиһен күзәтчелегендә торуы хәерле. Шулай да каләмнең кәгазь өстеннән мөмкин кадәр тоткарлыксыз йөгерүе, уй-фикер йомгагын көтелмәгән киңлекләргә алып чыгуы барыбер хуплауга лаек. «Сүз тыңлаучан авторучкам...» Укучы өчен күнегелмәгәнчә исемләнгән «? белән !» шигырендә дә автор үз өслүбендәге иреклелек сыйфатын ассызымлап күрсәтә. Гомумән, борынгы юнаннар әйтмешли, шәхеснең бәйсезлеге – зирәклек билгесе. Инде искәртеп үтелгәнчә, күңел тирәнлегеннән килгән әлеге үзгәлек Ләбиб Леронга да ят түгел. Иҗатта аның үз-үзенә артык чикләүләр куймавы «Йомарлам», «Танк биюе» поэмаларында, шулай ук «Мин – фасыл», «Өзеклек» кебек шигырьләрендә аеруча ачык чагыла. Монысы да холык-фигыльдән. Шагыйрь хәтта көнкүрештә дә үз иркенә яшәргә омтыла. «Вакытсыз вакыт» дип аталган әсәрдә нәкъ менә шундый халәт сиземләнә.

*Көн икән – көн. Төн икән – төн...*
*Барыбер үтәсе бер.*
*Сикереп чыгардай булам*
*Бу вакыт киртәсен бер!*

Каләмне, хәттин ашмыйча, ирекккә җибәреп язуның уңыш китерердәй өстенлекле яклары да җитәрлек. Мондый чакта фикер агышы ничектер табигый килеп чыга. Кәгазьгә хисләр дә бик ихластан түгелә. Уйлар да ачык. Аң-зиһен талчыгырга өлгермәгән. Шигъри юллар бер-бер артлы җайлы гына тезелеп барганда, көтелмәгән сурәтләү чаралары да чагыштырмача ансатрак табыла шикелле. Аерым чикләгечләр арасында интекмичә илһамланган очракта әсәр артык шомартуларга да дучар ителми. (Чамадан тыш көязлек сәнгатьлелек билгесе түгел.) Әгәр дә муза хөрлеге ашыгучанлыкка китерми икән, югарыда санап үтелгән сыйфатлар иҗатка гаять кирәк. Нәкъ менә шундый үзенчәлекләр җирлегендә тел-өслүп аныклыгы даими тотрыклылык ала.

Үзеннән-үзе аңлашылганча, мин үзара бәйләнгән әлеге хәлләр хакында Ләбиб Лерон иҗатына таянып фикер йөртәм. Стильдән аерылгысыз ошбу сыйфатлар

шагыйрьнең эчке бәйсезлеген ныгыта. Алар шулай ук аңа карашларын киңәйтергә дә, әдәби эшчәнлегендәге эзләнүләрен дәвам итәргә дә булыша. Туар әсәрләрнең калып-рәвешен табигый төстә төрләндерү дә хөр каләмне кулда ышанычлы уйната алуга баглы. Төрләндерү дигәннән, Ләбиб Лерон башка каләмдәшләрендә дә бу үзенчәлекләрнең чагылышын күрергә өметләнә.

*Аш та кирәк. Ә ашны бит*
*Төрләндерергә була;*
*Төрле тәмләткечләр белән*
*Тәмләндерергә була...*

*Минем кайчак һич югында*
*Бары тоз һәм борыч белән*
*Кайбер шагыйрь язганнарны*
*Төрләндерәсе килә,*
*Тәмләндерәсе килә!*
(«Сәер теләк»)

Ничек кенә гөман кылмыйк, һәр талантның иҗат өслүбе шәхеснең үзеннән башлангыч ала. Әлеге дә баягы төрлелек галәмәте Ләбиб Лерон табигатендә дә күзәтелә. Ул тормышта һәммә нәрсә белән кызыксына, яшәеш хәлләрен көндәлек битләрендә теркәп бара, дөньяга фотоаппарат объективы аша да карый, кадерсезләнгән тарихи документларны шәхси архивында туплый, мәрхүм язучыларның мирасын барлауда көч куя... Ләбиб Лерон җитәкчелегендә чыгып килгән «Безнең мирас» журналында да аның инде камилләшүгә ирешкән стиленә хас сыйфатларны анык тоемларга мөмкин: язмалар тематик яктан төрле, рубрикалар күпкырлы тарихыбызны колачлый, сәхифәләр яхшы мәгънәсендә чуар. Шәхсән үзем әлеге басманы эчке мавыгу белән укыйм. Шагыйрь сүзләрен файдаланып әйткәндә, *«Актарам иске китаплар – Күпме әсәр! Күпме шәхес!..»* Каләм әһеленең почеркын теләсә нинди гамәленнән танып алу бик табигый, чөнки көнкүрештә бер төрле, әдәби эшчәнлектә икенче төрле булырга ярамый.

*Шигырия! Йөрәк ярам да син,*
*Йөрәк парәм дә син күптәннән;*
*Киләчәккә бара алмыйм синсез,*
*Синсез кайта алмыйм үткәнгә!*

Колакка беркадәр ятрак тоелган сүз белән аталган «Шигырия» әсәрендә Ләбиб Лерон үзенең тәкъдири мәсләгенә тугры калуы турында белдерә. Шагыйрьлеге чәчрәп торган затның шулай рухланып эндәшүе урынлы. Әлеге бирелгәнлек гамәлдә раслана. Әгәр хисләр чын-хак икән, зиһен дә дөреслек яклы. Мондый кыйммәтләр турыдан-туры күңелдәге яралгыларга күчә. Әлбәттә, эзләнүчән табигатьле Ләбиб Лерон боларны әдәбиятка юл ярганда ук аңлагандыр. Эзлекле төстә баетылып килгән күпьяклы әзерлек аның каләменә хәзер дә ышаныч өсти. *«Шигырь итеп ятлыйм бу дөньяны – Көй отамын көн дә, сүз отам...»* Менә бит, «Бишмәтеннән чыктым Тукайның» дип исемләнгән шигырендә автор зур максатлар белән яшәвен сиздерә. Ул җиһанның көен кәгазьгә төшерергә тели. Гомумән, шагыйрь «көй» кәлимәсен чагыштырмача еш куллана. Хәтта серлелеге белән купләрне уйландырган шигърияткә дә шушы гап-гади кәлимә аша үзенчә билгеләмә бирә: *«Җанымны көйгә салдым...»* Карасана, ритмик оешкан тезмә назым җанны көйгә салу түгелме? Ә куктән иңдерелгән җанга барсы да сыя ич. Моны Ләбиб Лерон иҗаты да раслый.

**Зиннур МАНСУРОВ**

# ӘХМӘДҺАДИ МАКСУДИ МӘКАЛӘЛӘРЕ



*Әхмәдһади Максуди (1868-1941) – күренекле татар мөгаллиме, тел галиме, җәмәгать эшлеклесе, мөхәррир, нашир, китапханәче, мәктәп-мәдрәсәләр өчен дистәләгән китап авторы. Аның «Мөгаллиме әүвәл» дигән беренче дәреслеге 1892-1918 еллар арасында 32 мәртәбә басылып, миллионнарча тираж белән таралган. Бу дәреслекләрдән татарлар гына түгел, казакъ, үзбәк, уйгыр, кыргыз, башкорт кебек кардәш милләт балалары да белем алган, аваз ысулы ярдәмендә бик тиз укырга һәм язарга өйрәнгән. Ә.Максудиның «Ибтидаи мәктәпләрнең беренче сыйныф балаларына «Мөгаллиме әүвәл» исемле әлифбаи төркине укып чыгып, төркичә укырга һәм язарга өйрәнгәннән соңра кыйраәт гарәбиягә вә Коръән укырга төшендерү өчен тәгаллем кылынган» «Мөгаллим сани» китабы да үз заманында һәр ел саен басыла, һәм иң әһәмиятлесе: хәзергә кадәр мәдрәсә шәкертләре өчен алыштыргысыз уку кулланмасы булып тора. Мөгаллимнең язган китаплары арасында рус һәм француз теле дәреслекләре дә бар. Ә.Максуди – ишетелгәнчә язылырга тиеш, дип, татар әлифбасына 6 хәреф кертеп, уку-укыту системасын яңача тәртипкә салган һәм меңләгән шәкерт тәрбияләгән остаз да.*

*Әхмәдһади Максудиның мөхәррирлеге һәм наширлегендә дөньяга таралган «Йолдыз» исә Казан шәһәрендә иң озак вакыт (12 ел дәвамында) аралыгында өзлексез һәм иң күп тираж белән «шимбә вә дүшәмбедән башка һәр көн чыга торган сәяси, иҗтимагый вә әдәби газета» булган. Ә инде 1906 елның 2 гыйнварында ачылган «Китапханәи исламия» Казан шәһәр җәмәгать китапханәсенең мөселманнар өчен филиалы булып торган (анда хатын-кызлар өчен махсус зал да булган) һәм хәзерге ТР Милли китапханәсендә татар китапчылык эшенең башлангычын тәшкил иткән.*

*Әхмәдһади Максуди – сәясәт, тел-имля, милли тәрбия, уку-укыту, татар мәгарифе, мәктәп-мәдрәсәләре һәм дәүләт тарафыннан ачылган рус-татар мәктәпләре яки «ышкуллар» хакында дистәләрчә мәкалә авторы. Күпләр, урыслаштыру, чукындыру хәвефе күреп, «ышкуллар»га каршы булганда да, мәгърифәтченең бу мәсьәләдә фикере катгый: татар халкына, тел һәм динне саклау өчен, мәхәллә мәктәпләрендә дә, дөньяви гыйлем, рус телен үзләштерү өчен, «ышкуллар»да да укырга кирәк. Шул очракта гына халкыбыз, милли йөзен саклап калып, югары культуралы, көчле икътисадлы милләт булып калачак.*

*Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган мәкаләләр нәкъ менә шул, XX гасыр башында татар җәмгыятендә шактый бәхәс тудырган мәсьәлә – русча укыту, рус телле мәктәпләрдә татар теле һәм дин дәресләре турында. Мәкаләләрнең икесе полемика рәвешендә, ягъни Әхмәдһади Максуди фикерләренә «Вакыт» газетасында басылган кайтавазга җавап буларак язылган.*

## Ышкуллар ачу

Кырык елдыр мөселманнар өчен ышкуллар ачу хосусында бәхәс вә иҗтиһад ителмәктәдер. Башта бу эш өчен хөкүмәтебез бик иҗтиһад итте. Ул заманда без, мөселманнар, моның кирәклеген аңламый идек, шәһәрләрдә дә, авылларда да моңа каршы торган идек. Ул вакыт бу хосуста төрле шөбһә вә начар уйлар да бар иде. Күп тәҗрибәләр соңында шәһәр мөселманнары аңладылар ки: Русия эчендә сәүдә вә мөгамәлә, кәсеп белән мәшгуль булачак балалар өчен русча уку, һичшиксез, кирәктер. Шул сәбәптәндер ки, имди бу көндә мөселман балалары өчен ышкул ачылмаган шәһәр юктыр. Дәүләтле вә сәләтле мөселман балаларының русча укымый калганы да юктыр. Шәһәр мөселманнары балаларына русча ибтидаи *(башлангыч)* дәрәҗәне, һичшиксез, укыталар, моның белән генә калмыйча, тиздән игъдадия *(югары белемгә хәзерлек)* вә гали *(югары)* дәирәләргә кадәр укытачаклар. Әмма авылларыбыз күбесе һаман ышкулдан мәхрүмдер. Бу көндә авыл мөселманнары да аңладылар: укымый надан калуның зарарларын бик сизделәр. Шулай булса да, ышкул ачкан авыллар һаман бик сирәктер. Уфа идарәи руханиясе карамагында алты мең мәхәллә булганы хәлдә, ачылган ышкуллар алты йөзгә тулмыйдыр. Аеруча Казан вилаятендә ачылган ышкуллар алтмышка да җитмиләр. Казан өязендә исә алты ышкул да юктыр.

Казан әтрафында ысул җәдидә дә бик авырлык вә акрынлык белән таралды. Ышкул ачуның һаман таралганы юк. Моның сәбәбе: Казанда кадимияләрнең күплеге вә чат саен авыл байгураларына үзләренең иске вә файдасыз фикерләрен тукып торулары булса кирәк. Гафил булмаска кирәк: Казан әтрафында ышкуллар ачарга вакыт җитте инде. Дөньяның хәлен вә үземезнең наданлык белән яши алмаячагыбызны аңлаган мөселманнарга бу хосуста иҗтиһад итәргә кирәк. Бу елларда авыл халыклары да бик ачылдылар, балалары булган кешеләрнең һичберсе ышкул ачуга вә русча укуга каршы түгелдер. Мәгәр бала-чагасы булмаган кешеләр моны яратмыйлар. Балалы кешеләргә, балаларына хәерхаһлык кылып, боларның сүзләренә карамаска кирәк. Дөньябыз өчен тырышкан кеби, балаларыбызның дөньяларын да кайгыртырга кирәк.

Әүвәлдә халык ышкулның мәктәп вә мәдрәсәләргә керүеннән курка иде, чат русча гына укыла торган ышкулларга балаларын бирүдән хафаланалар иде. Бу хәвеф вә каршылыклар нәтиҗәсез калмадылар: хөкүмәт, мөселманнарның хәвефләрен бетерер өчен, 1907 елның 15 ноябрендә ышкуллар хакында яңа бер низам чыгарды. Бу яңа тип ышкуллар мәктәп вә мәдрәсәләргә кермиләр, үз алларына аерым ачылалар. Янә бу ышкулларда русча гына укытылмаячак. Һәркөн ике сәгать кадәр мөселманча дин вә тел дәресләре укытылачак. Димәк, хәзер ышкуллар безнең мәхәллә мәктәпләренә кермәячәкләр, киресенчә, безнең дин вә тел дәресләребез ышкулларга керәчәк. Эш болай булганда, мөселман өчен куркырга һич урын юктыр.

Һәр зур авылларга 15 ноябрь низамы буенча яңа төр ышкулларны ачтырырга кирәк. Һәр мөселманга Русиянең һәр җирендә сәүдә вә һөнәрләр илә кәсеп вә мөгамәлә кылып баерга юллар ачылсын. Мөселман бае – дин вә милләтебез өчен бер хәзинәдер. Динебезнең вә гадәт кадимиябезнең таләбе буенча, байларыбыз һәрвакыт дини эшләребезгә моңа кадәр ярдәм итә килделәр, моннан соң да һаман ярдәм итәчәкләре мәгълүмдер. Дин вә милләтебезнең мәңгелеге вә тәрәккыяте голамәбез илә юмарт байларыбыздан гына булачак. Ышкулның кирәклеген аңламый торган чабаталардан диянәт тә, дингә ярдәм дә юктыр. Ул бичараларда дөнья да юктыр. Моннан соңра һичбер мөселманга кара мужиклар кеби диянәттән дә, дөньядан да мәхрүм булып яшәү мәгъкуль түгелдер.

Авылларда ышкул ачуның кирәклеген аңлаган кешеләр бу елларда бик күбәйделәр. Бу әфәнделәр бу хосуста, киңәш сорап, идарәбезгә дә мөрәҗәгать кылалар. Казан әтрафы мөселманнарына бу хакта өяз земствосы гласныйларыннан вә ышкуллар комиссиясе әгъзаларыннан Габдулла Йосыф углы Апанаев җәнабларына мөрәҗәгать кылуны киңәш итәбез. Бу әфәнде үзенә мөрәҗәгать кылган авылларга, земство суммасыннан ышкуллар ачтыру хакында киңәшләр биреп, тиешле чараларын күрсәтәчәктер.

Бер авылга ышкул ачу өчен, ул авыл халкыннан приговор җыю кирәк түгелдер. Балачагасы булган ун кешенең ризалыгы җитәдер. Бу кешеләр ришвәтче куштаннардан курыкмасыннар, бу хакта бәйләнгән кешеләргә җәза бик катыдыр. Перепискә каршы торган кешеләр кеби, ватанымыз өчен файдалы икәне мәгълүм булган уку эшенә каршы торган кешеләр дә җәзасыз калмаячаклар.

Һәркем белә: барча шәһәрләрдә мелла балалары да, гавам баласы да русча укыйлар. Һәркем моның әһәмиятенә төшенгән, мәгәр авыл мужиклары гына моны аңламыйлар. Дөньяны аңсыз мужиклар идарә кылырга тиеш түгелдер ич?

*Йолдыз. – 1914. – №1132. – 25 февраль.*

## Мәктәп вә ышкуллар хакында

Наразый әфәнденең «Мәктәп тә, ышкул да кирәк» дигән фикеремә каршы «Вакыт»та язган мәкаләсенә килик. Наразый әфәнде: «Мин бу ышкулларны кырып-себереп ташларга гына тиеш», – ди. Дәлилләре шул: ышкулларда дин дәресләре – 20%, татар теле дәресләре – 20%, калган 60 проценты русчага гына кала. Дүрт елның әүвәлге икесендә мөгаллим рус теле дәресләрен һәм мәгълүматны татарча бәян кыла ала, соңгы икесендә русча гына бәян кылырга тиешле. Наразый әфәнде фикеренчә, менә бу ярамый, минемчә – ярый. Чөнки бу мәхәллә мәктәбе түгел, ышкула бит. Ышкуллардан балаларга русча белдерү максуд булгач, соңгы ике елында учительнең дөньяви мәгълүматтан русча сөйләвендә зарар юк. Бер дә курыкмаска кирәк, шулай була торып та, балалар русча белеп бетерә алмаслар әле. Моның өстенә бу ышкулларда һәркөн ике сәгать микъдары дин вә тел дәресләре, мөселманча уку булачак. Әүвәлге ышкулларда бу юк иде. Тел дәресенә игътибар ителми иде. Дин вә тел дәресләренең ышкулларга рәсми сурәттә керүенә кайгырмаска кирәк, киресенчә, сөенергә кирәк. Әүвәлдә халык дини мәктәпләребезгә ышкул керә, дип курка иде. Бу хосуста халык бер дәрәҗә хаклыдыр иде. Имди хәзер без ышкулларга дин вә тел дәресләре керүенә дә кайгырыйкмыни?

Наразый әйтә: «Ышкулларда дин вә тел дәресләрен мәхәллә мелласы укытачак, тел дәресләрен учитель дә укыта алачак», – ди. Ярый, бик яхшы. Монда ни зарар? Ул меллаларыбыз да, учительләр дә тел дәресләрен яхшылап укыта алмаслар, ди. Әлбәттә, башта яхшылап укыта алмаячаклар. Ләкин хәзерге мелла вә хәзерге учительләребезнең акылына карап хөкем кылмаска кирәк. Мөстәкыйль мелла белән мөстәкыйль учительләр исә, шөбһәсез, мәдрәсә вә дарелмөгаллиминнәрдә хәзерләнгән булачаклар. Минемчә, хәзерге мелла вә мөгаллимнәребезнең дә яшьрәкләре иҗтиһад кылсалар, татар теленең сарыф, нәхү вә әдәбиятын укыта алачаклар. Гарәп вә рус нәхүеннән дә хәбәрдар кешеләр үз телебезнекен ник укыта алмасыннар?

Наразый әфәнде ышкулларга өстән нәзарәт кылучылар мөселманнар түгел һәм мөселманнан булмаячаклар, ди. Бусы бик мәгълүм. Моннан 364 ел элек хәл кылынган мәсьәлә бу. Ләкин Русиядә һәр эшнең ислях кылынуын көткәнлегемнән, бу хосустагы низамнарның да үзгәрүен көтәргә кирәк. Бәлки, ышкуллар сәясәтендә игъдади вә гали мәктәпләрдә укыганнарыбыз күбәйсә, мондый нәзарәтләргә түрә булырлык мөселманнар да табылыр. Ул вакытта мөселманнарның мәптәпләр назире, мәктәпләр советының әгъзасы булуына низам да мөмкинлек бирер. Ул заман җиткәнче, без, ышкулларда укый-укый, үзебезнең гали мәктәпләргә керергә сәләтебезне арттыра торырга кирәк. Һаман надан көенчә тормаска кирәк.

Наразый әфәнде яза: «Дин дәресләренә һәм татар теленең яхшы куелуына һәм ул дәресләрнең ышкулларда тәртипле рәвештә баруына тиешле мәэмүрләр һич игътибар итмиләр. Моңа кадәр ни дин дәресләренә, ни ана теленә программа төзү хакында хөкүмәт тарафыннан эш булмады», – ди. Бу һәрберебезнең иске үпкәбез, ләкин 1907 сәнәнең 15 ноябрендә чыккан яңа программага дин вә тел дәресләре кергән. Инде шуны сөенеп кабул итәргә кирәк. Бу дәресләр бер мәртәбә рәсмият алгач, аларның дәрес җәдвәлләрен тәртип кылу үз кулыбызда. Тырышырбыз да, тәртипкә салырбыз.

Наразый әфәнде сүзе: «Дин вә тел дәресләрен укытачак кешеләр, ягъни мәхәллә меллалары бу дәресләрне укытырга хәзерлек күргән кешеләр түгел. Меллаларыбызның – педагогиядән, учительләребезнең татар теленнән хәбәрләре юк». Бу наданлыкларыбызга ышкуллар гаепleме, әллә ышкулларга ислам дине вә татар теле дәресләренең керүе гаепleме? Хәзерге меллаларыбызда да, учительләребездә дә кимчелек булса булыр, ләкин киләчәктә эш рәтләнер. Башта бездә ысул җәдидә белән укыта белүче дә һич юк иде. Күрә-күрә, тырыша-тырыша укыта белүче табылды. Хәзер көннән-көн күбәймәктә вә тәрәккый итмәктәләрдер.

Наразый җәнаблары учительләрнең училищный совет кулында булуында вә анда мөселманнан вәкилләр булмавына игътираз кыла. Бу игътиразга мин дә кушылам. Ләкин аңа карап ышкулларга каршы тормыйм. Безнең мәчет имамнарыбыз да губернски правление кулында. Анда да мөселманнан вәкилләр юк. Моңа карап мәчетләрне ябу вә меллаларны бетерү тиеш түгелдер ич!

Янә Наразый әйтә: «Ике елда балаларга русча белдереп бетереп булмый. Хәлбуки, ышкулларның яңа низамы буенча учительләр өченче вә дүртенче елларда дәрес арасында татарча һич сөйләмәскә, морадларын русча гына аңлатырга тиешле», – ди. Табигый метод белән укытканда, учитель беренче дәресендә үк морадын русча гына әйтергә, һичбер сүзне татарча әйтмәскә тиешле. Бу ысул белән укыта белүчеләр булганда, ышкулларда учительләр рус телен өйрәткән вакытта беренче елда ук татарча һичбер катыштырмаска мөмкин. Ләкин бу рус теле дәресендә генә. Татар теле дәресендә учитель әүвәлгенең киресен, русча һичбер сүз катыштырмаска тиешле.

Бусы – укыту ысул мәсьәләсе. Мин үзем табигый методтан тәрҗемә методын артык күрәм. Ничек булса да, русча белдерү өчен ачылган укуханәләрдә, русчаны күбрәк вә тизрәк белдерү өчен, төрле методларны сынап карауда истихалә юк. Ләкин мәгълүматны үз телемездә бирү мәсьәләсе бар. Мин үзем рус теле дәресендә сөйләүгә хилаф булмасам да, дөнья мәгълүматы дәресләренең татарча бирелүен телим. Бу теләгем кайчан кабул булыр, ул кабул булганчы, мин һаман укый тору, белә тору тарафында. Дөнья мәгълүматын укыту теле русча булса, балаларыбыз русчаны күбрәк белмәсләр иде микән, диючеләр булса, мин һич гаҗәпләнмим. Наразый әфәнде үзе дә ышкул балаларының русча белмәүләренә зарлана. Һичбер нәрсәне өшкереп кенә өйрәтер хәл юк. Аны тел белән әйтеп өйрәтергә кирәк була. Учитель балаларга русчаны никадәр күп сөйләсә, балалар да аны шулкадәр күп беләчәкләр.

Гыйлем өйрәнүдән курыкмаска да кирәк. Диянәт вә милләтебезне саклау өчен безгә мәхәллә мәктәпләренең калуы да кирәк, дөньяви тәрәккыятебез өчен ышкулларыбыз да лязим. Мәктәпләрне дә ышкулларны да ислях кылу кирәклегендә шөбһә юк. Ләкин боларны киләчәккә тапшырырга кирәк.

*Йолдыз. – 1916. – №1646. – 16 май.*

## Мәктәпләр хакында

Мин һәр мәхәлләдә әүвәлдәгечә мәхәллә мәктәпләре булып, аларда һәр баланың ике-өч ел укуын телим. Бу ике-өч ел эчендә җиде-сигез яшьлек балаларның татарча укый-яза беләчәгенә бик ышанам. Ышкулларга балалар шул мәктәпләрдән чыккач кына керсәләр иде, дим. Яңа низам буенча ышкулларда дин вә тел өчен һәркөн ике сәгать булачак. Ул сәгатьләрдә балалар дин вә тел дәресләренең мәхәллә мәктәпләрендә укылып бетмәгәннәрен генә укырлар. Бу тәкъдирдә ышкулларда дин вә тел мөгаллиме балаларга әлифба вә догалар гына укытмас, телнең сарыф, нәхү, инша вә бәләгатен һәм диннең тарих вә әхкямен дә укытыр. Эш бу рәвешчә булганда, дүртьеллык ышкулдан балалар динчә камил мөселман вә татарча камил сәүдәле булып чыгарлар. Әгәр дә мәхәллә мәктәпләре булмаса, балалар, сигез яшьтән туп-туры ышкулларга кереп, һәркөн берәр сәгать әлифба вә дога уку белән генә шөгыльләнсәләр, дүрт ел эчендә бик аз тәрәккый иткән булачаклар. Карача укырга-язарга белсәләр дә, татарча

грамоталары камил булмаячак. Дин мәгълүматлары да тәҗвидсез рәвештә Коръән укуларыннан гыйбарәт булып кына калачак.

Моңа каршы ышкулларда дүрт кенә еллык түгел, алтыеллык итәрбез диючеләр бар. Моңа мин шулай җавап бирәм: ибтидаи ышкуллар бөтен Русиядә дүртәр генә еллык булачак. Мөселманнарныкын гына алтышар еллык итү бик ерак бер ихтималдыр. Ышкуллар алтыеллык булганда, аның соңгы елларында дин вә тел дәресләренә һәркөн берәр сәгать урын бирелмәскә мөмкин. Ничек булса да, Русиядә ышкулларга дини вә милли мәктәп итеп каралмаячак, алар дәүләт вә дөнья мәктәпләреннән саналачаклар. Идарәи дәүләттә агым ни рәвештә булса, ышкулларның программалары да шул юлда үзгәрә барачак. Нинди хөрриятле мәмләкәтләрдә дә ышкулларга дин вә тел бишеге, дип каралмый, дөнья вә дәүләт бишеге, дип карала. Дәүләттә күпчелекнең максаты ни булса, ышкулларны шул максатка хезмәт иттерәләр. Шул сәбәпләрдән безгә, алтыеллык ышкул торнасына кызыгып, кулымыздагы милли чыпчыгыбызны очырырга һич ярамый. Яхшымы-яманмы, ул чыпчык безнең кулда калсын. Без мәхәллә мәктәпләрен мөмкин кадәр тәртипкә салырга тиешле, әмма бетерергә тиешле түгел. Дөрес, милләт өчен боларны асрау зур бер чыгым булачак. Ни кылмак кирәк: башка милләт эчендә калган һәр милләтнең хәле шулдыр.

Меллаларыбызның иҗтиһады вә байларыбызның һиммәте сәясендә моңа кадәр мәхәллә мәктәпләребез начар хәлдә булсалар да, дәвам итеп килделәр, моннан соң да дәвам итәрләр. Фикер вә мәгыйшәтебез тәрәккый итсә, бәлки, ул мәктәпләр тиешле дәрәҗәдә ислях ителерләр.

Уку мәҗбүри ителү һәр баланы сигез яшьтән мәктәпкә йөртү мәҗбүри ителер, дигән сүз түгел, бәлки һәр бала мәгълүм бер яшькә җиткәнче рәсми ибтидаи мәгълүматтан имтихан бирергә мәҗбүр ителер, дигән сүз. Бу чик рус балалары өчен дә унбиш яшь булачак. Теләгән кешегә баласын мәктәпкә җибәрмичә өйдә үзе укытырга да ирек булачак. Әгәр дә мәктәпкә йөрү мәҗбүри ителсә, моның өчен дә бер чик куелачак. Бу чик ун яшьтән башланыр. Чөнки Русиядә иртә укып, унике яшьтә имтихан биргән авыл балаларының күбесе, зурайгач, укуны тәмам оныталар икән. Шул сәбәптән, балаларны училищеларга яшьтән алмаска берничә ел элек Мәгариф нәзарәтеннән бер циркуляр да булган иде. Бу циркуляр хәзер янымда булмаганлыктан, андагы чикне атап үтмим.

Бу чик бөтен Русия өчен сигез яшьтән тәгаен кылына башлаганда, безнең Думадагы вәкилләребез мөселман балаларын бу хөкемнән истисна кылуны дәгъва кылырга тиешле. Бу дәгъва безнең дини вә милли зур бер эшебез булырга тиешле. Бу дәгъвага безнең дәлилләребез бар: мөселманлыгыбыз сәбәпле, без бер микъдар гарәпчә белергә мәҗбүр, татарлыгыбыз сәбәпле, үз телебезне дә укырга тиешле. Ошбу вәҗеһләргә нигезләнеп, мөселман балалары өчен ышкулларда укый башлаучының ике ел кичектерелүе һич гаҗәб эш түгел, мөмкин бер эш. Мөселманлыгыбызга вә татарлыгыбызга юл бирелгәндә, безнең балаларыбызга бу ике ел да багышланырга тиешле.

Алты яшь тулган балалар укуны үзләре дәгъва кыла башлыйлар. Җиденче яшендә балалык сыйдырган микъдарда татарча укый вә яза белгән балалар бик күп. Бу заманның җиңел әлифбалары белән күп бала мәктәпкә барганчы ук агаларыннан вә апаларыннан сораштырып укыштыра башлыйлар. Ике генә ел булса да мәхәллә мәктәбендә тәртип белән укыган бала ышкулга бик күп бәсыйрәт җыеп керәчәк. Ышкулның беренче елында ук андагы кыйраәт китапларын, хәтта татарча сарыфны аңларлык дәрәҗәдә булачак. Эш болай барганда, бер мәхәллә мәктәп белән ышкул ник бергә яши алмасыннар?!

Ләкин бу ихтимал бар: мәхәллә мелласы ышкулга дин мөгаллиме итеп тәгаен ителәчәк, имеш тә, мәхәллә мәктәбен ябачак, имеш. Андый меллаларга карабрак торырга кирәк: башка бер сылтау табып, алар мәчетне дә япмасыннар!

Икенче бер ихтимал: бер мужик, аны-моны карамый, җиде яшьлек баласын тота да ышкулга бирә. Анда да барыбер дин укыла ич, ди. Мондый мужиклар хакында бик сак булырга кирәк. Аларның арасында минем балам дин вә тел дәресләре укымаса да

ярар, грамотный булып дөнья эшенә керерлек булса, минем өчен шул җитә, диючеләре чыкмасын.

Мондый ихтималлар булмасын өчен, халыкны дини вә милли рухта тәрбия кылу кирәк, дибез. Иске, тәртипсез тәрбиябез дә безгә андый мелла вә шундый мужик бирмәгән иде. Безнең бик надан кешеләребездә дә дини вә милли рух таза була иде.

Моннан соңра бу рухның кимүен түгел, артуын күтәргә кирәк. Моңа кадәр безнең мәдрәсәләребезнең мәктәп яба торган мелла биргәннәре юк. Алар һаман юк мәктәпне бар итә торган меллалар биреп килделәр. Меллаларыбызның да моңа кадәр мәхәллә баласына дин вә тел укытмый торган итеп тәрбия кылынганнары юк. Моннан соң да, әлбәттә, андый тәрбия булмас.

Мөселманнарның теләвенә карамыйча, һәр мәхәлләдә балаларны сигез яшеннән үк ышкулларда укыту мәҗбүри ителгән тәкъдирдә, мәхәллә мәктәпләренең калуы безгә бигрәк тә кирәк, чөнки ул тәкъдирдә безгә 12 яшьлек балаларны, балигъ булып, эшкә керешкәнче, мәхәллә мәктәпләрендә укыту мөмкин булачак, ләкин шаид эш моңа калмас. Балаларны 10га кадәр мәхәллә мәктәбендә укыту мөмкин булыр.

Ышкул ачылган зур авылларның һәммәсендә бу хәл, ягъни, балаларның әүвәл мәктәптә, соңра ышкулда укулары булып тормактадыр. Уку яшьләрендә булган сиксән баланың яшьрәкләренең һәммәсе мәхәллә мәктәбендә, зурраклары ышкулда укыйлар. Учительләр үзләре балаларның ислерәкләрен сайлап алалар.

Янә шуны да искә алырга кирәк ки: илле генә йортлы авылларга ышкул салыну ихтималы юктыр. Салынса, ышкуллар зуррак авылларга салыначаклар. Кечкенәрәк авылларның балалары шул ышкулларга йөртеләчәк. Һәр кечкенә авылга ышкул салынганда да, ир балалар өчен – бер, кызлар өчен икенче салынмаячак. Булса, фәкать бер комплекты илле балалык бер ышкул булачак. Ничек булса да, һәр авылда егерме-утызга кадәр яшь бала ышкулга керә алмыйча читтә калачак. Шулар өчен дә безгә мәхәллә мәктәпләренең калуы кирәктер. Мәхәллә мәктәпләреннән морад ирләр мәктәбе генә дигән сүз түгел. Безнең кыз балаларыбыз да мәхәллә мәктәбендә мелла хатынынннан йә мөгаллимәдән укыйлар. Безнең кыз балаларыбыз өчен дә мәхәллә мәктәбе кирәк. Мәхәллә саен мәктәпләр берәр генә булырмы, әүвәлдәгечә ике көенчә тотылырмы – анысы икенче мәсьәлә.

Безгә дөньяви мәктәп тә, ягъни ышкул да кирәк. Ул ышкулларда да һәр фәннең үзебезгә тиешенчә укытылуына тырышырга кирәк. Динебез дә, телебез дә аларда укылырга тиешле. Һәр милләт үзе динен вә телен балаларына ни микъдарда укытса, без дә шул микъдарда укытырга тиешле. Һичбер милләт үз телен вә үзенең тарихын балаларына укытмый калмый, безгә дә болар кирәк. Әгәр дә безнең балалар, ике-өч ел мәхәллә мәктәпләрендә укымыйча, туп-туры рәсми-дөньяви мәктәпләргә керсәләр, аларның ул мәктәпләрдә әлифба укудан башлары чыкмаячак. Беренче елда төрки әлифба укысалар, икенче елда гарәби әлифба белән үткәрәчәкләр. Өченче елдан Коръән белән бер кыйраәт китабы укыячаклар. Дүртенче елда гыйльме хальдән бераз, соңрак ислам... Бу тәкъдирдә дүртьеллык ышкулларда дини вә милли тарих белән шәригатькә урын юктыр.

*Йолдыз. – 1916. – №1664. – 29 июнь.*

*Кереш мәкаләне һәм текстларны басмага* **Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН** *әзерләде.*
*Текстларның стиле чыганактагыча саклланды.*

## ВЕРА МИНКИНА
(1918-2011)



Татарстанның (1968) һәм Россиянең халык артисты (1977) Минкина Вера Егор кызы 1918 елның 9 сентябрендә Чистай районы Бахта авылында туа. Мәктәп елларыннан ук артист булырга хыялланган кыз Казанга килеп театр техникумына укырга керә һәм аны 1939 елда тәмамлый. Иҗат юлын Республика Күчмә театрында башлый (хәзер – Кәрим Тинчурин театры). 1952 елдан ул – Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы.

Вера Минкина – бөтен тормышын сәнгатькә багышлаган искиткеч талантлы шәхес, татар театрына 60 елдан артык хезмәт иткән сирәк артистларның берсе.

Кабатланмас һәм үзенчәлекле табигый таланты, киң сәхнә диапазоны, хатын-кыз табигатен нечкә сиземләве һәм шулай ук үзенең шәхси сыйфатлары артисткага гаҗәеп тормышчан, ихлас образлар иҗат итәргә мөмкинлек бирә. Аның барлык персонажлары – малайлардан алып төрле яшьтәге, холыктагы хатын-кызлары да тормышка гашыйк, зур ихтыяр көченә ия, кояшлы һәм бай эчке дөньялы була.

Вера Минкина башкаруында Миңлекамал образы түзем, кыю, фидакарь, нык ихтыяр көченә ия һәм, бөек җиңүгә зур ышаныч белән яшәп, тылда тырыш хезмәт куйган хатын-кызларга гимн булып яңгырый. Бу образ республика авылларына гастроль белән баргач, актрисага очрашып күрешергә туры килгән күп кенә реаль шәхесләрнең (прототипларның) сыйфат үзенчәлекләрен туплаган.

Милли характерлар иҗат итеп, аларга таныш төсмерләр биреп, актриса киң гомумиләштерүләргә һәм бер үк вакытта аларның символик яңгыраш алуына омтыла. Ул тудырган образлар асылы белән халыкчан һәм милли фольклорга якын.

Һәрвакыт яшь күңелле артистка үзенең 90 яшьлек юбилеенда сәхнәдә «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин) спектаклендә, Палый ролендә уйнап, талантына баш июче тамашачыларын тагын бер кат сокландырган иде.

Вера Минкинаның иҗаты театр сәнгате белән генә чикләнми, ул радио, телевидение тапшыруларында да даими чыгыш ясый, «Зифа оныгы – Ришат», «Хәзинә» нәфис фильмнарында төшеп, ил күләмендә тамашачы мәхәббәтен казана.

Төрле елларда башкарылган Уңганбикә («Кыз урлау», М.Кәрим), Полина («Дошманнар», М.Горький), Малай («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Кәләмзә («Зифа», Н.Исәнбәт), Гыйльмениса («Чаткылар», Т.Гыйззәт), Факиһә («Беренче театр», Г.Камал), Мелита («Кол», Г.Фигейредо), Мария Ильинична («Баһадирлар», Н.Погодин), Бибиәсма («Күк капусы ачылса», Х.Вахит), Хөлә («Әбиләргә ни җитми?», Ф.Бүләков), Ана («Моңлы бер җыр», Т.Миңнуллин), Степанида («Җимерелгән бәхет», А.Островский), Екатерина («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Хәмдебану («Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин) һ.б. рольләре аның иҗат биографиясендә генә түгел, татар театр сәнгате тарихы битләрендә дә күренекле урын алган гүзәл образлар булды.

## Солдатта булган, диләр...

Туйкыя, ирең эштән вакытында кайтамы? Юк, соңгы вакытта төрлесе булгалый, дисеңме? Анысы шулай, ул ирләргә эштән соңарып кайтырга сәбәп һәрчак табылып тора. Беркөнне ирем төнге берләр тирәсендә салмыш баштан кайтып керде. «Кайда йөрдең?» – дим. «Армиядә бергә хезмәт иткән малайлар белән кафеда солдат тормышын искә төшереп утырдык», – дигән булды. «Күз ачып йомганчы, армиядә булып кайттыгыз, шунда күрсәткән каһарманлыкларыгызны инде егерме ел буена искә төшерәсез», – дип әйтүгә, мужигымның үпкәләүдән күз яшьләре атылып чыкты. Үзе шул ук минутта, борынын чөеп: «Син нәрсә, ул каравылда торулар, нарядка йөрүләр гомергә онытылмый», – дип, күкрәк суга башлады.

Туйкыя, дөрестән дә, без, хатын-кызлар, солдатта булуның барлык нечкәлекләрен аңлап бетермибез, ахры. Ичмасам, андагы тормышны бераз аңлап булмасмы, дип, бер танышымнан: «Армиядәге вакытыңны сагынасыңмы?» – дип сорадым. Ул, күзен дә йоммыйча: «Нәрсәсен сагынасың аның, мин кырык градус салкында, ак аюлар арасында хезмәт иттем», – диде. Икенче бер таныш чик сакчысыннан: «Кызык булдымы анда, ничә шпион тоттың?» – дип кызыксындым. «Юләр сатма, нинди шпион, күргәнем дә булмады, – дип, бот чабып көлде. – Ул кинода гына шпионнарны этләр белән аулап тоталар. Хәзер алар турист булып самолётта гына очып керә».

Аптырагач, иремнән: «Армия тормышыннан ни дә булса исеңдә калдымы?» – дип сорадым. «Ничек кенә әле, мине анда бәрәңге әрчергә, идән юарга өйрәттеләр», – дип җавап бирде. «Начар өйрәткәннәр, армиядән кайтуга, миңа өйләндең», – дим. «Ә мин – тиле, егерме ел буена сиңа идән юып, бәрәңге әрчедем», – дип тә өстәдем.

Белмим, Туйкыя, солдат тормышыңны егерме ел буе кафеларда ничек итеп искә төшереп буладыр. Әйтергә генә җиңел, шул еллар эчендә өч бала таптым. Хәзер хатын-кызның өч бала табуы батырлык санала. Шулай булгач, мин роддом караватында бергәләп яткан хатыннар белән ел саен кафеда очрашырга тиешме?

Туйкыя, ни әйтсәң дә, безгә унсигез яшь тулгач, муен тамырыбызга сугып, дөрес итеп идән юарга, бәрәңге әрчергә өйрәтүче булмады. Без боларны күптән белә идек. Тормышның иң кызык якларын күрми үскәнбез икән.

Беркөнне иремнән: «Солдатта ничек идән юарга өйрәттеләр соң?» – дип сорадым. Кылтынланып юып күрсәтте бу. «Кара, миннән йөз мәртәбә чистарак юасың», – дип әйткәч, ирем, канатланып, фатир идәннәрен кабат өч мәртәбә юып чыгарды. Хәзер әйтеп торасы да юк, идән юу аның өстендә. Бервакыт: «Сез анда нәрсә ашадыгыз?» – дип сорагач, кичкә, һич булмаганны, борчак ашы пешереп ашатты. «Иң тәмле ашлар гына ашатканнар икән сезгә», – дип әйткәнемне сизми дә калдым. «Пүчтәк бу, өстәвенә, телеңне йотарлык карабодай, дөге, солы боткалары да пешерә алам», – дип мактанды. «Пешерә генә күр, плитә тулысынча синең карамакта, җаным», – дидем. Хәзер мине, эштән кайтканда, өстәлдә һәрчак җылы ризык көтә. Шунысын гына әйтә алмыйм: бу рәхәтлек озакка сузылырмы?!

Соң кайтканы өчен иремә бу юлы әллә ни каты бәрелмәдем. «Нәрсә, хатыннарыгыздан тагын гаеп эзләп утырдыгызмы кафеда?» – дип кенә сорадым. Ирем: «Юк, гаепләмәдек, бу юлы начар командирларны гына искә алдык», – диде. Ышандым инде, Туйкыя, ышанмый кая барасың, бәхәсләшеп тормадым. Бәхәсләшер идем, анда булмадык, каян белик без ул солдат тормышын?! Өйрәтергә безнең хакыбыз юк. Шту син, армия бит ул!

## Теш

– Сәвия, ирем: «Тешләрем коелып бетте, банктан кредит алып, яңаларын куйдыртмый булмас», – дип куркыта башлады. Нишләргә дә белгән юк. Бер яктан, иреңнең тешсез йөрүе күңелле хәл түгел. Ни әйтсәң дә, аңа гына акча табар идем әле. Тик менә... Әнә тешләре сирәкләнә башлагач, күрше хатыны: «Болай йөреп булмый, кеше арасында эшлисең», – дип, иренә, күп акча түләп, яңа теш казналыгы ясатты. Анысы дөрес, ире институтта укыта, соң, тешсез авызыннан кемнең лекция тыңлыйсы килсен ди. Күрше хатыны да шуны уйлап кылгандыр бу гамәлен. Әмма ире яңа теш куйдырткач, ике ай да эшләп өлгермәде, бер яшь студент кызга күзе төшеп, гаиләсеннән чыгып кыяклады.

– Кичә генә бер таныш хатынның зарланганын тыңлап кайттым. Ире тешсез кала башлагач, ул да, аны-моны уйламыйча, яңаларын куйдырткан. «Элек ирем бүлмәдә берүзе утырды, хәзер аның яныннан хатыннар бөтенләй чыкмый», – ди. Яңа теш куйдырткач кына, аның белән бергә эшләүче хатыннар иремнең нинди чибәр булуын күреп өлгерделәр. «Хәзер ул көнаралаш төн уртасында кайта, белмим, әллә эш урынын алыштырасы, әллә яңа тешләрен коеп төшерәсе», – дип, шыр елады теге хатын.

– Сәвия, ирем институтта да укытмый, бер көтү хатыннар арасында да эшләми, ә шулай да күңел бик борчыла. Үзең уйлап кара, буе – метр туксан, авызы тулы яңа теш булган иргә кайсы хатын карамасын ди. Көннәрдән бер көнне: «Үпкәләмә, башканы очраттым, бүген үк аның янына китәм», – дип кайтып керсә... Икенче яктан, шунысы да бар: ул төзелеш кранында эшли, анда менәргә генә ярты сәгать вакыт кирәк. Көне буе ялгызы гына утыра, өстән карап. Төзелештә хатын-кызлар күп, әмма кайсы җүләре, иренмичә, шул кранга менеп, иремнең авызына карап йөрсен ди.

Кичә алдына кайнар өчпочмак куйгач: «Ашыйсым килә, әмма чәйнәрлек тешем калмады», – дип зарланды. Сәвия, нишлим, син әллә ничә ир белән яшәп карадың. Әгәр иремә яңа теш куйдыртсам, көт тә тор, ялгыз калуым бар. Ирем бөтенләй тешсез калса да, минем янда калуы икеле. Ризыкны күп, тәмле итеп пешерәм, ә ул чәйни алмый интегә. Бу тормыштан туеп: «Җитте, болай яшәп булмый», – дип, китеп баруы да ихтимал. Ике ут арасында янам, белмим, иремне тешле итәргәме-юкмы?

– Шушы арада безнең подъездга бер хатын-кыз күченеп килде. Янында ир заты күренмәде, җитмәсә, аның стоматолог булуын да җиткерделәр. Бүген-иртәгә, көт тә тор, шырпы йә тоз сорап, безнең ишекне шакыячак. Мин югында, ирем авызын ерып, ишекне ачып җибәрсә, ул хатын аңа чиратсыз бушка теш куеп бирергә дә күп сорамас.

– Кайсыдыр җырчы: «Илледә дә әле соң түгел», – дип җырлый. Сәвия, соңарганымны хәзер генә аңлый башладым. Акыллы хатын-кыз тешсез иренә йә яңасын куйдырта, йә куып җибәрә. Мин һаман суздым, тегесен дә, монысын да эшләмәдем. Монда шунысы ачык: эшне озакка сузсаң, икенең берсе – йә ирсез каласың, йә урының түрдә булачак.

**Илдар ХӘЙРУЛЛИН**

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!

## Социаль челтәр

Дүшәмбе көннәрендә генә уза торган мәктәп линейкасына бүген көтмәгәндә җыеп алдылар. Мондый гадәттән тыш «линейкалар» йә берәр нәрсә майтарылса, йә үтә дә мөһим чаралар көтелсә генә җыела.

– Хөрмәтле дуслар! Бүгенге линейканы озын-озакка сузмыйбыз. Бер мөһим вакыйганы бөтенегезгә дә җиткерергә булдык, – дип сүз башлады мәктәп завучы Флёра Сәйфетдинова. – Яңа гына өстән фәрман килеп төште. Мәктәп турында район халкына, аннары республикага җиткерер өчен социаль челтәрләрдә эшне көчәйтергә боердылар. Сез социаль челтәр дигән әйберне бездән дә яхшырак беләсез. Һәрберегезнең өендә интернет бар хәзер. «Вконтакте» челтәрендә «Олы Әшнәк урта мәктәбе» дигән төркем ачтык. Хәзер шул төркемгә кешеләр җыярга, мәктәп вакыйгаларын язарга кирәк. Арагызда каләм чарлаучылар бар. Языгыз, кызыклы көннәрегез, дәресләр белән уртаклашыгыз, дус-туганнарыгызны өстәгез. Безнең авылдан каләм әһелләре шактый чыккан, сезнең арада да, бәлки, булачак язучы-журналистлар бардыр. Сез төркемгә күбрәк дуслар өстәгез, мәктәп тормышын яктырткан вакыйгаларны языгыз, мәктәп рейтингын интернет кырларында да үстерик. Конкурс эшләренә бер атна вакыт бирәбез, икенче атнага нәтиҗәләр чыгарылыр. Кем иң яхшы язма теркәп, иң күп лайклар җыя, төркемгә кешеләрне күпләп өсти, шул кешегә махсус бүләк – телефон бирәбез. Телефонны мәктәбебезне тәмамлаган артист Ирек Хафизов үзе тапшырачак. Ул әлеге бәйгенең иганәчесе булып тора. Димәк, киттек, – тырышыгыз, күрсәтегез, языгыз, мәктәп данын бөтен районга, республикага таратыйк, – дип, завуч сүзен тәмамлады.

Мәктәптә конкурслар еш үткәрелә, ләкин монысы укучыларны аеруча да тәэсирләндерде. Бүләккә телефон, диләр ич.

– Егетләр, телефоны нинди, дип сорарга онытканбыз. Андроид микән, гадәти төймәле булмасын тагы, ә бәлки айфон биргәндер әле теге иганәче дигәннәре, – дип класстагыларга сүз катты Айрат.

– Безнең урамга кайта ул Ирек абый, нинди айфон булсын ди анда, үзе дә төймәле телефон белән йөри, – дип көлде Алисә.

– Әйе шул, сорамадык яхшылап. Төймәле генә телефон булса, ул лайклар өчен эшләп тә утырасы юк. Өйдә өч-дүрт телефон бар андый, – дип сүзгә кушылды Ленар.

Телефонның нинди икәнлеген белмәсәләр дә, мондый җиңел конкурстан берсе дә читтә калырга ашыкмады. Әнә, шигырьләр язып, иләсләнеп йөрүче Марат шул ук көнне шигырь язып ташлады.

Тау башында горур басып
тора ул безнең мәктәп.
Сүз табалмыйм, остазларны
язарга монда мактап.

Телефонын гел кулында йөрткәч, шунда ук теге төркемгә элеп куйды. Иң беренче булып үз шигыренә лайкны да чәпәде.

– Бу шигырь болай гына, старт бирер өчен генә, соңрак яхшырагын язам әле, – дип, телефонын алып куйды.

Алисә мәктәптә үткән рәсем конкурсы турында мәкалә язарга булган, хәзер рәсемнәрен биргән һәр кешедән, нигә болай ясадың, нигә тегеләй ясадың, дип, интервью алып бимазалый.

Альбинаның узган атнада туган көне иде, әтиләре яңа фотоаппарат бүләк иткәннәр. Ул икенче көнне үк, фотоаппаратын тотып, мәктәпне төрледән-төрле ракурсларда фотога төшереп йөрде: тәрәзәләрне ачып та төшерде, дәрес вакытларында да шыртлатып алды, мәктәп баскычларына ятып та кыланды.

Алмаз исә мәктәпне тәмамлаган кешеләргә интернеттан хатлар язган һәм «Безнекеләр» дигән рубрика булдырып, тегеләрдән истәлекләрен яздырта башлаган.

Шул рәвешле, бөтен мәктәп мәш килде. Бер генә конкурста да болай катнашканнары юк иде. Бер атна булып килгәндә, «Олы Әшнәк урта мәктәбе» дигән төркем яңалыклар белән чуарланып бетте, кешеләр артык җыелмаса да, сәгать саен яңалык эленде. Ашханәдәге пешерүчеләрдән рецепт та яздырып куйдылар, завхоз Илдар абыйдан эшенең бик әһәмиятле булуын сөйләттеләр, укытучы Рәсимә апаның ни өчен бер класста ике ел утырып калуын да яздылар... Бу атнада күпләр дәрес әзерләүне дә онытты, телефон отасы килү теләге бөтен мәктәпнең һушын алды.

Шәмси генә берни эшләмәде. Беренчедән, аның өендә интернет юк, икенчедән, инде нәрсә язарга да белмәде, чөнки барысын да язып бетерделәр кебек тоелды аңа.

Бәйгегә йомгак ясарга бер көн калгач кына, аның башына идеаль фикер килде. Журналист кеше дөресен язарга, ялагайланмаска, дөреслекне фаш итәргә тиеш, диләр бит. Ул да мәктәптәге җитешсезлекләрне язарга булды. Күрше егете Айраттан ике сәгатькә кесә телефонын сорады да, төркемгә кереп, алдагы язмаларга үзенчә анализ ясады һәм үзе дә кулына каләм алды.

«Районыбызда әллә ничә Әшнәк бар, ләкин безнеке – Әшнәкләрнең дә Әшнәге. Авылыбыздан язучылар да, журналистлар да, артистлар да, хәтта тарихчылар да чыккан. Минем дә үткен каләмле журналист буласым килә. Ялагайлыкны җенем сөйми. Менә мәктәптә конкурс игълан иткәннән соң, бөтен укучы мәктәпне мактарга ашыкты. Ни өчен? Телефонлы буласылары килә. Ә болай дөрес түгел ул. Шуңа да мин фаш итәргә булдым мәктәпне.

Мәктәпкә акбурлар кайту белән, биология укытучысы Фәридә апа аларны өенә ташый, чөнки аның кызлары акбур ашарга ярата. Аннары без дәрес вакытында күрше класслардан акбур сорап интегәбез. Ел башында мәктәпнең бөтен укытучыларына да ноутбук бирделәр, ә информатика укытучысы алар белән бергә булган флешкаларны алып калган да хәзер шуларны «авито»да сатып ята (миңа моны ышанычлы чыганаклардан җиткерделәр). Авылыбыз мулласының алты баласы бар, аларның берсе дә ашханә өчен түләми, имеш, әтиләре мулла, сәдакага гына яшиләр. Өйләренә беркөнне кергән идем, аларның өй түрләрендә «ЖК» телевизор, күн диван, массаж ясый торган кресло, тагы әллә ниләр бар. Ә балалары мәктәптә бушка ашый. Ник мәктәп җитәкчелеге аларны барып тикшерми? Укучылар бөтенесе дә бертигез булырга тиеш. Узган язда мәктәпнең түбәсен яңа калай белән яптылар, завхоз Илдар абый тәки чәлдерде калайларның бер өлешен. Оялмыйча да үзләренең түбәләрен шул калай белән ябып куйды. Бөтен авыл күрә моны, мәктәп һәм Илдар абыйларның түбәләре генә шул зәңгәр төстә бит. Тик берсе дә дәшми.

Шундый хәлләрне саный китсәң, бик күп алар бездә. Бездә генә түгел, һәр мәктәптә дә бар алар. Күрә белергә, фаш итәргә генә кирәк намуссыз кешеләрне. Батыр йөрәкле егет булып, каләм белән көрәшүдән дә яхшырак эш юктыр».

Менә иртәгә конкурска нәтиҗә ясалыр, бүләкне дә лаеклы кешегә бирмәячәкләр. Әти-әниләре кибет тотучы Алисәгә эләгер инде, йә булмаса ай саен телефонын алмаштыручы Фидаильгә, дип уйлады Шәмси һәм, «бисмилласын» әйтеп, үзенең уникаль язмасын стенага беркетеп куйды.

Шәмсинең язмасы төнге унбердә генә беркетелгән булса да, иртәнге сигезгә

Әшнәк мәктәбе төркеменә 500дән артык кеше өстәлгән (авылда да аның кадәр хуҗалык юк бит хәтта), 80 лайк куелган, 15 репост ясалган иде. Хәбәр тиз арада директорга килеп җитте, директор, язманы күрү белән, үзенең сәркатибе Ләйсәнгә комментарийларны алып ташларга, язманы тизрәк юкка чыгарырга кушты.

Математика дәресе вакытында Шәмсине директорга чакыртып алдылар, ул инде төнлә нәрсә язганын үзе дә анык кына хәтерләми иде. Директорның кара йөзен күргәч, барысы да тиз исенә төште үзе.

– Энем, син үзеңне кем дип белдең шуның кадәр?! Башкалар арасыннан шулай аерылып торырга яратасың инде, ләкин бу эшең бернинди кысаларга да сыймый. Бүген төштән соң әти-әниеңне көтәбез.

– Фәрит Хәмитович, конкурска линейкада йомгак ясарга вәгъдә иткән идек. Ирек шалтыратып, кайта алмавы турында әйтеп гафу үтенде, телефонны үзегез генә тапшырыгыз инде, диде. Нишлибез? – дип, ишектән сәркатип Ләйсән килеп керде.

– Беренчедән, төркемне чистартыгыз, комментарийларны админ аша гына язып була торган итеп ясагыз! Ә бәйгегә йомгакны хәзер ясыйбыз. Менә шушында. Бәласеннән башаяк. Ни дисәң дә, бер төндә 500 кешене җыйган бит. Молодец, Шәмси! Менә сиңа телефон! Шуның белән, энем, сөйләшүем тәмам, калганын әтиең аша аңлатырмын, безнең телне аңламыйсың син барыбер, – дип, директор, ишеген ачып, Шәмсине чыгарып җибәрде.

Шәмси, кулына чыбыклы телефонын тотып (ә аларның өйләренә телефон да кермәгән бит), «эх, башта нинди телефон икәнен төпченәсе калган, юкка төн йокыларымны калдырып язып ятканмын» дип уйлап чыгып китте.

Мәктәпкә эшкә йөргән кебек еш барырга күнеккән әнисе урынына бүген кичкырын гына Шәмсинең әтисе китте.

## Җәйнең ямьле бер көне

Менә шулай инде, 1 сентябрь дигәннәре беренчегә баручыларга (чөнки алар әле алда niләр көткәнен чамаламый) һәм укытучыларның үзләренә генә (шуның кадәр чәчәк тагы кайчан бирерләр ди) бәйрәм ул. Калган укучылар өчен гадәти уку көне. Менә 7 нче сыйныф укучыларына бәйрәм көнне үк расписание төзеп куйганнар. Җитмәсә, ике дәрес рәттән – татар теле. Укытучылары Резедә Зөфәровна ике дәрес эчендә «Җәйнең ямьле бер көне» дигән сочинение язабыз, дигәч, ярты классның сөмсере коелды. Шундый матур көнне бозарга ул гына булдыра инде. Әнә алтынчы класслар, укытучылары белән табигать кочагында фотосессия ясап йөри, сигезенчеләр, өстәл табыннары ясап, классташлары Айратның туган көнен һәм берочтан белем көнен бәйрәм итәләр, бишенче сыйныфлар бәйрәм линейкасыннан соң өйләренә сызды, башлангычлар турында әйтеп тә торасы юк. Ә җиденчеләр сочинение яза. Адәм хурлыгы.

Шәмсинең аеруча да кәефе төште. Өйгә язарга бирсәләр, китап-мазардан күчергәләп, берәр нәрсә әвәләр иде дә – юк шул. Матур кәчтүм-чалбарлары белән мәктәпнең икенче катына да менеп җитәргә өлгермәде, озын булганга, бәйрәм линейкасында да арткы рәттә басып торды (кәчтүмнәрен күреп өлгермәгәннәрдер, шәт), шуның өстенә әле җәйдән соң шөрепләре дә нығытылмаган башка эш кушылды.

Укытучыга мин ручка-кәгазь апкилмәдем, дип тә караган иде, үч иткәндәй, күрше партадагы Ленар, мин берничәне апкилдем, дип, тизрәк яңа дәфтәр белән ручка сузды.

Беренче дәрес күз ачып йомганчы узды да китте. Бөтен кеше и язды, и язды. Шәмсинең генә башына матур уйлар килмәде, тик утырганны сизмәсеннәр, дип, кәгазьгә рәсемнәр ясап утырды. Ни турында язсын ди ул?! Җәй буе авылда ятты, ара-тирә күрше авылга әбиләренә төшкәләде. Шуннан. Тарих укытучысы Ильяс абый әйтмешли, иҗтимагый әһәмияткә ия булмаган вакыйгаларны «чебеннән фил дәрәҗәсенә күтәрү» катгый тыела.

Җиденчеләр тәнәфескә дә бүленмәде. Әйтерсең лә бөтенесенең әйтер сүзләре күбәйгән, башларын да күтәрми, әллә ничәшәр бит сыптыралар гына. Әллә барысы да кичә үк белгән инде сочинение турында, уй-фикерләрен чәчәк бәйләмнәре кебек төйнәп килгәннәр дә хәзер шуны язып утыралар, дип уйлады, кәефсезләнеп, Шәмси. Эх, ник берсе торып «бәйрәм көнне нинди сочинение инде, апа!» дип сүз башламый. Калганнары шунда ук кушылыр иде бит, укытучы да йомшарыр иде, бәлки. Юк шул, башларын игәннәр дә язалар... система коллары!

Шәмсинең башына никтер гел җәйнең ямьсез яклары гына килде. Ручкасы тик тормасын өчен, аны кәгазь өстендә арлы-бирле йөрткән булды. Яңа уку елына дип алган күлмәкләре бугазын буа башлады, тизрәк кәчтүмнәрен салып ташлап, иске футболка-шортигын киеп, мендәрен кочасы килеп китте (бу вакытта ул бит әле йокларга күнеккән иде). Түзмәде, сикереп торып басты да сүз башлады:

– Резедә Зөфәровна, ярыймы сүз әйтсәм?

Каләм кыштырдаткан тавыш кына ишетелгән класс бер мәлгә тын калды.

– Ярый, Шәмси, әллә бетердең дәме? – дип елмайды укытучы.

– Бөтен мәктәп ял итә, тфү... бәйрәм итә. Сез генә беренче көннән үк бимазалыйсыз. Ел да шул хәл. Беренче дәрестән үк йә диктант, йә инша, йә сочинение. Ничек мин башымны эшләтергә көйлим ди инде. Аннары ни турында яза алам соң. Авылдагы хәлләрне үзегез дә белеп торасыз. Шуларны язып, юләр кебек бер-беребезгә сөйләүдән ни мәгънә? Менә минем өчен җәйнең бер ямьле көне дә булмады. Көтүгә чыктым, түбән очтагы Фөлүзә апаларның сарыклары югалды – ике тәүлек эзләгәннән соң гына таптык, шуның аркасында әтидән шәп үк эләкте. Рәис абый буасына су коеныгра баргач, Алмазны коткарам дип кергән идем, үзем баттым, мине коткарырга – ярда ун егет торса да – берсе дә кермәде. Һәр иртә һәм кичен унбиш сутый бакчада колорадо коңгызы чүпләдем. Үзебезнең бакча гына җитмәгән, колхоз кырына чыгып чөгендер матикладык. Аннары мәктәптә практика башланды. Мәктәп бакчасын карадык. Июльдә ай буе печәнгә йөрдек, әле безнеке генә булса бер хәл иде. Күршедәге бөтен карчыкларга булышырга туры килде. Булышмас идем дә, әни «кешедән яхшы түгел», дип, ирексезләп кертеп җибәрә. Хәтта клубка шәһәр кызларының биегәннәрен карарга чыгарга да хәл калмый иде. Шулай, Резедә Зөфәровна! Саный китсәң, хәлләрне бездә берегез дә кызыгырлык түгел. Ә сез җәйнең ямьле бер көне, дисез. Гаиләдә бердәнбер бала булгач, бик авырга туры килә. Тормыш йөге минем сыртка төшә. Ярый ла Айратның апасы үзен Казанга алып китеп гүләйт итеп апкайта; Ленарның әби-бабасы, сиксәндә булса да, бөтен эшне үзләре җимереп эшли; Алисәләр кибет тотканга вапше да балда-майда гына яшиләр... Менә алар хәзер «ямьләндерер» инде сочинениеларын. Ә мин, бишле алыр өчен ялганлап, «матур булды җәйләр, эх», дип язарга җыенмыйм. Так што, Резедә Зөфәровна...

Шәмси сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, тәнәфескә чакырып, кыңгырау чылтырады. Бөтен класс, дәррәү килеп дәфтәрләрен җыеп, укытучы өстәленә өйде дә, тукталышка үзләренең автобуслары килгәнмени, ишеккә таба чаптылар. Класста укытучы белән Шәмси генә калды. Резедә апасы:

– Так что, Шәмси энем, котлыйм сине. Җәйләр үтеп китте, көзен бәрәңге аласың да башка артык эш булмас, ә бүген сиңа эш – өйдә сочинение язарга, – дип, күзенә төшкән чәчләрен рәтләп куйды да. – Онытма, иртәгә беренче дәрес – әдәбият. Җәйгә укырга биргән әсәрләргә анализ ясаячакбыз, – дип, класстан чыгып китте.

## Дегустатор булам!

Ел да бер балык башы дигәндәй, быел да мәктәптә «Үскәч мин кем булам?» дигән кичә оештырырга булганнар. Гадәттә, бу чараны зурлап үткәрәләр: үзеңнең булачак һөнәрең турында презентация ясарга, шул рәвешле киенергә, өстенлекләре турында сөйләп, мәктәп халкын ышандырырга тиешсең. Бу елда да чарада дистәдән

артык укучы катнашырга теләк белдергән. Җырчы булам дигәне матур көлмәкләр белән причёска ясап килгән, укытучы булам дигәне дәфтәр-китаплар тоткан, рәссам булачагы попугай кебек төрле төстәге шарф ураган. Ниләр генә кыланмыйлар инде.

Чарада катнашучылар, дәресләргә кереп тормыйча, репетиция ясаячакларын белүгә, Шәмси дә «мин дә катнашырга телим!» дип аваз салды. Катнаштырсалар яхшы булачак: барыбер дәресләрнең яртысы әзерләнмәгән, икеле алганчы, теленә булса да салынып чыгар.

Класс җитәкчесенең «син әзерләнмәдең бит?» диюенә каршы ул:

– Мин бик тә катнашырга телим, минем һөнәр өчен махсус киенү кирәкми, шул килеш тә бара, – дип әйтеп ташлады.

– Шәмси, син әзерлексез килеш бөтен бәйрәм чарасын боза аласың, кызлар-егетләр бер ай алдан әзерләнә башладылар бит, башка вакытта катнашырсың, – дигәч тә, җиңел генә күнмәде.

– Юк, Рушания Габдулловна, мин әзерләндем, чынлап!

– Йә, кем булырга җыенасың соң инде син?

– Ы-ы-ы... дегустатор! – дип, кичә генә телевизордан ишеткән яңа сүзне әйтеп ташлады.

– Анысы ни дигән һөнәр инде тагы, юк-юк, шаярып, монда кичәнең ямен алма әле. Әле ике ел элек кенә «мин ди-джей булам» дип утыра идең, узган ел депутат булам дидең, «д» хәрефенә башланган һөнәрләрне генә сайлыйсың ахры син... Икенче елга, бәлки, әле диктор, йә булмаса драматург булам, диярсең... Син уйлана тор, ләкин бу елгы чарага кермә, күреп торам, син әзерлексез килгәнсең. Чарага күрше мәктәп укытучылары һәм район газетасыннан яшь корреспондент да чакырылган, бөтен эшне бозып куярсың тагы.

– Рушания Габдулловна, дегустатор, дигәч, дегустатор булам. Дегустатор эшне бозмый, киресенчә, барысы да уңышлы булсын өчен, алдан иснәнә торган һөнәр ул. Ни кызыгы бар инде ул мин укытучы, мин җырчы, мин артист булам, диюләрнең. Ә монда – яңа һөнәр! Аннары безнең кушамат та дегустаторларныкы кебек бит – пәрәмәч. Бабайның ис-тәм тоюы көчле булганга, авылның икенче башындагы Галимә апасына иртәнге алтыда ук бара, яңа пешкән унбер пәрәмәчне бер утыруда ук бәрә, шуннан бу сүз тарала да, «пәрәмәч» дип кушамат тагалар безгә. Безнең геннарда бугай ул дегустаторлык сәләте: әти заварканы иснәп карый да кайсы көнне сәгать ничәдә ясалганын әйтеп бирә; бабай шулпаны бер кашык кына каба да ничә кашык тоз салганын чамалый; энекәш шоколадларның кайчан чыкканын әпридиләт итә ала. Ә мин... мин боларның барысын да үзем генә дә эшли алам. Әнидә генә андый сәләт юк, хәер, хатын-кызларга кирәкми лә ул, алар болай да артык иснәнеп йөриләр.

– Ярый, Шәмси. Тик кичәне бозсаң, кара аны, мәктәпнең кара тактасына фотографияңне ел буена элеп куячакбыз! Ояты үзеңә булыр! – дип ризалашты килешүдән гайре чарасы калмаган укытучы.

Кичә башланды. Мәктәпнең алдынгы укучысы Айдар, чыгып, үзенең галим булачагы турында сөйләде. Аңа бүген махсус киенеп торасы да юк – болай да көн саен күзлектән, ел буена кәчтүм-чалбардан, галстуктан, кулларына сәгать тагып йөри.

Җирән чәчле сипкелле Ләйсән, чыгып, җырчы булырга хыялланам, диде. Үзенең кәкре аякларын сизми микәнни, кем инде моны сәхнәгә чыгарсын дип уйлады Шәмси.

Гөлназ исә китапханәче булам, дип гәп сатты. Динара кибетче булачагын җиткерде.

Чират Шәмсигә дә җитте. Ул инде нәрсә сөйләргә җыенганын да оныта язган иде.

– Дегустатор булам мин. Кем икәнен беләсезме аның? Ис һәм тәмнәрне аеручы гына түгел, ә истә калдыручы да. Җиңел һөнәр дип уйлый күрмәгез. Әлеге сәләткә дөньядагы кешеләрнең нибары унбиш проценты гына ия икән. Менә күз алдыгызга китерегез: үсәм дә шикалат фабрикасына дегустатор булып урнашам, берсен ашыйм, икенчесен, өченчесен... әкәмәт булачак инде. Шикалаттан туйгач, сыра заводына (директорның акайган күзләрен күрүгә), о-ой, юк, сыраныкына түгел, сырныкына

китәм. Аларны ашап туйгач – башкасына. Әти әйтмешли, капчык күтәрми торган эш сайларга кирәк, әле, шуның өстенә, тамак та туеп кайта торган булса, бөтенләй дә яхшы.

Матур гына итеп сөйләгәндә, Шәмсине теге редакциядән килгән кеше туктатты:

– Чыгышың бик тәэсирләндерде. Шулай да әлеге һөнәрне син тамак ягын кайгыртып кына сайламакчымы? Әллә тагы үзенчәлекләре, башка файдалы яклары да бармы?

– Әлбәттә, ашау ягы белән генә түгел… Мин үземнең мондый сәләтемне кечкенәдән тоеп киләм. Мәктәптәге аш кичә үк әзерләнгән булса, шунда ук пешерүчеләрне шелтәлим. Алар миңа, күзләрен шарландырып, «каян беләсең?», диләр. Класста кинәт һава «бозылса», кемнән чыкканын да беләм… «Шанель» сибенеп йөрүче Рәшидә Исхаковнаның, өеннән чыгып, мәктәпкә килеренә ничә метр калганына кадәр чамалыйм… Классташ егетләрнең тәнәфестә тәмәке көйрәтеп керүләрен дә сизәм мин. Борын шәп минем, коеп куйган дегустатор инде! Аннары дегустатор булыр өчен ЕГЭ ише әйберләр белән дә азапланасы юк, математиканы ник шунда берлегә бирмисең! Шәп бит… Күп инде аның үзенчәлекләре… – дип тезде генә Шәмси. Алгы рәттә утыручы мәктәп җитәкчелегенең йөзләре бер каралды, бер агарды. Чара өчен җаваплы булган Рушания Габдулловнага директор каш астыннан карады да чыгып ук китте. Чара тәмамлану белән, укучылар таралышты. Укытучылар исә мәктәп кунакларын сыйларга дип табын әзерләнгән завуч бүлмәсенә чаптылар.

Ике көннән район газетасының беренче битендә үк «Әшнәк мәктәбеннән ТРның атказанган дегустаторы чыкмагае» дигән мәкалә басылды.

## Ураза

Рәхәт тә инде бу әбигә: өстәл түрендәге урын аңа, йомшак карават – аныкы, итнең тәмле калҗасы тагы аңа, әбиегез намаз укый тавышланмагыз, әбиегез ятып тора, урамда йөреп керегез, әбиегезгә моны китерегез, әбиегезгә бу булган… Әбиегез-әбиегез-әбиегез, дип ачуы чыга башлады беркөнне Шәмсинең. Бөтен әйбер һәм кешеләр әби тирәсендә әйләнә түгелме соң?! Җир кендеге диярсең. Әнисе еш кына Шәмсигә: «Әбиегез намаз укыганга, ураза тотканга – өйдә бәрәкәт-муллык», – ди. Күрше Диләрәләр дә муллыкта яши, әбиләре намазда булмаса да, Айратларның әбиләре бөтенләй юк, алар тагы та баерак әле… Так што, шыттырмасыннар миңа. Алайга китсә, тотам да үзем намаз укый башлыйм, уразасын да тотам, биесеннәр әле минем янда да дип уйлады ул.

– Әби, кайчан ураза көне? Әйдә бергә тотабыз! – дип, әбисенә эндәшкәч, карчыкның күзлеге үк төшеп китте.

– Ураза аена кадәр ерак әле, улым! Менә бу көннәрдә тотасым килеп йөри идем, пәйгамбәребез дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә тоту хәерле, дигән. Иртәгә бергә керик булмаса? – дип, оныгының дин белән кызыксынуына сөенде.

– Тотыйк әйдә, минем ураза тотасым килә. Мин дә дин юлына бассам, байлыгыбыз артыр, әйеме, – дип, әбисенең күзләренә тутырып карады.

– И-и, балам, булганы безгә җитәр, булганына шөкер итеп яшик, – дип, оныгын аркасыннан сөйде.

Мөнирә әбиләре, иртәнге өчтә үк торып, өстәлләр әзерләде, дүрт тулганда, Шәмси янына килеп:

– Вакыт, тор, улым, – дип, оныгының башыннан сыйпады.

Юк, ничек шушы вакытта җылы юрган астыннан торгандыр бу әбиләре. Хәер, аның янында биегән кебек минем тирәдә дә кайнашып торсалар, «улым, улым, улым», дип йөрсәләр, ник тормаска дип уйлады да җәлт итеп сикереп торды Шәмси. Ләкин тамагыннан ризык кына үтмәде, бер тәлинкә ашны көчкә ашады да чәйгә үрелде.

– Улым, яхшылап аша, карының ачар, – дип, әбисе өстәлдәге ит-бәрәңгеләрне, пешкән ризыкларны оныгына таба этте.

– Булды, әби, йоклыйм мин, – дип, өстәл артыннан китте.

Тик йокы гына кермәде. Әбисенең тәсбих тартуларына кадәр колак төбендә ишетелеп торды. Менә ул да ураза тотар, намазга да басар әле. Аннары «улыма тәмлерәген бирегез, йомшак түшәк Шәмсиебезгә булсын, тавышланмагыз, улыбыз ял итсен», дип, өйдәгеләр биеп кенә йөриячәкләр, дип, әзрәк уйланып ятарга да өлгермәде, будильник шалтырады.

Шәмси бүген үзен бөтенләй башкача хис итте. Зур батырлык эшләгән егет кебек. Әле көне башланып кына килсә дә, кичен авыз ачу вакыты турында уйлады. Менә әниләре тәмле әйберләр алып кайтырлар, пешерерләр, улларын мактарлар… шулай уйланып класс ишеген ачуы булды, анда бөтен парталарга мороженое тезеп куйганнар. Бүген Альбинаның туган көне икән. Классташларын шул уңайдан сыйларга булган.

Шәмсинең кәефе кырылды, ачуы чыкты, ләкин кешегә сиздермәде. Эченнән генә: «тапкансың туар көн», дип, Альбинаны битәрләде. Аннары «мороженое урынына шикалат апкилсәң ни булган, анысын өйдә дә ашап булыр иде», дип уйлады да үзенә тиешле туңдырманы тәмле ашарга яратучы Алсуга сузды. Алсу куанычыннан нишләргә белмәде, Шәмсигә тиешле туңдырманы да ике минутта юк итте. Дәрес башланганчы, Шәмсигә карап бер кызарынды, бер елмайды. Әйтерсең лә Шәмси аңа гади бер туңдырма түгел, бриллиант кашлы йөзек бүләк иткән?!.

Көне авыр үтте Шәмсинең. Эче улады, башы кинәт авырта башлады, моңарчы гел дәрестә бытылдап утырырга ияләшкән егет бүген су йоткандай булды. Укытучылар хәтта «бүген Шәмси юк мәллә?» дип тә сәерсенеп сорап куйгаладылар.

Әби йоклыйдыр анда, обедка әниләре кайтып, әбиләрен уятмас өчен, аяк очларына гына басып йөридер… Ул тагын әбисеннән көнләште.

Өченче дәрестән соң, бөтен мәктәп, күченнән кузгалган бал кортлары кебек, ашханәгә чапты. Шәмси, башын кулларына куеп, черем итеп алмакчы иде дә, өчпомак исе борынны ярып керде.

– Моны сиңа апчыктым, мә, – дип, теге Алсу, күзләрен тагы елкытып, Шәмсигә карап тора иде.

– Рәхмәт, үзең аша, мин бүген иртән бәлеш ашап килдем, – дип, өчпочмакны кызга кире бирде.

Классташлары ашханәдән өчпочмак, алма, вак бәлеш тотып чыктылар, тәнәфес буе ашадылар. Шәмси үзенең уразада икәнлеген белгертмәде. Белсәләр, шунда ук «мулла булырга әзерләнәсең мәллә?» дип үртәргә дә күп сорамаслар.

Туган көн дигәннәре дә моның белән генә бетмәде. Юбилей икән – 10 яшь тулган Альбинага. Дәрестән соң тәмле «Прага» тортын бүлгәләп, соклар таратып чыкты. Түзмәде Шәмси дә, әби барыбер белмәячәк, ник интегеп утырам соң, дип, «Прага»ның иң зур кисәгенә үрелде.

Каршысында елмаеп Алсу утыра иде. Бу юлы да, күзләрен майландырып, бер Шәмсигә, бер торт кисәгенә карады. Әллә тагы үз кисәген бирер дип көтте инде. Менә тотсын әле дип уйлады Шәмси һәм хапылдап «Прага»ны әмәлләде.

Эчтән кәефе бозылды бозылуын, уразаны тотып бетерә алмады бит, шулай да үзен юатты, беркем дә белми бит, тоткан кыяфәт ясармын, өйдәгеләргә сиздермәм дип уйлады.

Өйгә кайтуга ук, кояш баюын көтмәс өчен, йоклап алырга булды.

– Улым, синең янга классташың кергән, – дигән тавышка уянып китте.

Кухняга чыкса, авылның бөтенләй дә икенче башында яши торган теге Алсу «Прага» торты белән боларга килеп җиткән.

– И балакайлар, хәзер өстәлне әзерләп бетерәм, ашап алырбыз, – дип, әбисе өстәл тирәсендә кайнашты.

– Мин ашамыйм, әтинең туган көне иде бүген, әле генә ашадык. Әни «Прага» торты апкайткан. Шәмси бүген «Прага» тортын шундый мактап ашады мәктәптә, шуңа күрә дә аңа тагы апкилдем, – дип әйтеп ташламасынмы теге сер тотмас үрдәк.

Әбисе генә ишетмәмешкә салышты.

– Улым, аша менә монысын, бусын да авыз ит, – дип, өстәлдәге сыйларны Шәмсигә таба сузды. – Пәнҗешәмбе көнне тагы тотсак, яхшы булыр иде, – дип башлаган иде, Шәмси, стенадагы календарьга карап:

– Булмый, әби, пәнҗешәмбе Айратның туган көне, тучны булмый, – дип елмайды.

## Кәрим тавык

– Шәмси, үз-үзеңне тотышың бернинди кысаларга да сыймый, ни өчен тагы Гөлназны елаттың? – дип орышырга кереште Гөлсия Фатыйховна.

– Үзе елады, елатмадым, – дип башлаган иде, Гөлназ тагы үкереп елый башлады.

– Кичә ул миннән көндәлегемне сорап торды, өй эшләрен күчереп аласы бар дип, өенә апкиткән дә көндәлекнең һәр битенә «Мин – карга!» дип язып чыккан!

Тагы үксергә тотынды кыз.

– Шәмси, Гөлназ алдында гафу үтен, Гөлназ, син елама, яңа көндәлек алып бирер, ике атна эчендә алган билгеләреңне укытучылардан яңадан үзем куйдыртып чыгармын, – дип, укытучы Гөлназны тынычландырырга тырышты.

– Соң, гафу ит инде алайса, кәефеңне күтәрергә теләгән идем… – дип, Шәмси дә гаебен таныган кеше сыман кызга сүз катты.

– Миңа яңа көндәлек кирәкми, моны миңа Энҗе апам Мәскәүдән апкайтып бирде, тышын карагыз – Нюша төшкән, беренче битенә Нюша үзе автограф куйган бит анда, – дип, үксүен дәвам итте кыз.

– Соң, Гөлсия Фатыйховна, нәрсәгә үпкәләргә ди инде, бөтенебез дә кушамат белән әйтәбез бит бер-беребезгә…

– Шәмси, әниең әле кичә генә мәктәптә булды, аның өчен үзем кызарынып утырам инде, сиңа ун минут вакыт бирәм, шушы вакыт эчендә дуслашып өлгерәсез икән, молодцы, юк икән, әниеңне тагы көтеп калабыз, – дияргә дә өлгермәде укытучы, Шәмси инде аклану чарасын тапты да:

– О, минем башыма гениаль фикер килде, Гөлсия Фатыйховна! Иртәгә сишәмбе бит, димәк, иртә белән класс сәгате үтәчәк. Әйдәгез, үзем алып барам, «Кушаматлар дөньясы» дип атарбыз, бөтен классташлар үзләренең кушаматларының барлыкка килү тарихын сөйләр, кем әйтмешли, презентовать итәрләр. Менә яхшы булачак, Гөлназның гына кушаматы ямьсез түгел бит анда, әнә Рәмиснеке, мескенем, Чүптер, Илшатныкы – Махина, Илнарныкы – Баймак… Дөресен әйтергә кирәк, кеше үзе булмаганда, бөтенебез дә кушаматлап сөйлибез бит аның хакында, кушаматлар кичәсе үз кушаматыңны яратырга өйрәтәчәк. Кушамат – ул фамилиядән дә кадерлерәк бит, ни дисәң дә, бөтен нәселгә бирелә, кияүгә чыгып кына да аннан котылып булмый…

Гөлназның кәефе күтәрелсен дип кенә, укытучы да күнде:

– Классташларыңны ышандыра алсаң, әйдә соң, эшлә. Һәрберсенә өч-дүрт минут вакыт бирелер, бүген үк әзерләнә башласыннар.

Класс сәгатендә кушаматлар турында сөйләү идеясе күпләргә ошады, әллә нинди әхлак-тәрбия турында сөйләтмиләр бит. Мәш килеп әзерләнделәр. Беренче булып сүзне Шәмси үзе алды:

– Безнең кушамат – Тавык, Бикмулла бабам авылда иң беренчеләрдән булып торып ишегалларын себерә-җыештыра торган булган, шуңа күрә «тавык» дип кушамат такканнар. Бабайның дуслары мине урамда күрсә, «ти-ти-ти», дип котырта башлый, кем баласы дип кызыксынганда, үзем дә «Кәрим тавыкларныкы», дип горурланып әйтәм. Так што, сез дә, горурланып, кушаматларыгыздан оялмыйча йөрегез, – диде дә горур кыяфәт белән парта арасына кереп утырды.

Сүзне югары очтагы Күселәр нәселеннән Ләйсән алды. Төрле әйбер җыярга һәвәс булган бабасы Әхәткә кушылган икән кушаматы. Иске акчалар да җыйган ул, значоклар да, чигелгән кулъяулыклар һ.б. бик күп әйберләр. Бабалары үлгәннән соң,

Ләйсәннең әнисе верандада шул җыелган әйберләрдән музей ясап куйган икән. Киләсе класс сәгатендә укучылар, «Күселәр»нең өйләренә барып, музей белән танышырга сүз куешты.

Озын сыйраклы, бик хәрәкәтчән һәм тиктормас Рания үзләрен ни өчен Чикерткә дип атауларын сөйләп тормаса да була иде инде. Аларның өйләрендә барысы да чикерткәгә охшаган бит: чәрелдәп сөйләшәләр, озын буйлылар. Хәтта киленнәре Вәсилә апа да нәкъ үзләренә охшап килгән.

Америкaн Фирдүс абыйларның оныклары Раил үзләренең кушаматлары турында аеруча да горурланып сөйләде, бабалары Америкада Бушның ярдәмчесе булып эшләгән диярсең. Америка әләме төсендәге бер күлмәге булган аның, гомере буе шуны киеп йөргән. Шуңа да «Американ»га әйләнгән.

Дәрес һәркемнең дә күңеленә хуш килде. Класс сәгатенең яхшы гына баруына сөенеп, укытучылары да «тавышланмагыз, хәзер керәм, сөйли торыгыз», дип, класстан чыгып китте. Көлештеләр, кул чабыштылар, оялмыйча, бер-берсенә кушаматлар белән эндәштеләр. Отличник Айдарга сүз бирелде:

– Безнең кушамат юк, – дип сүз башлаган иде…

– Хәзер кушабыз үзебез, алай ярамый инде, – дип, бөтен класс дәррәү купты.

– Ләкин минем дә сүз аласым килеп китте. Башыма бер фикер килде…

– Сиңа гына килә инде ул фикерләр, – дип көлештеләр.

– Сезне тыңлау шундый ошады миңа, үземнең кушаматсыз нәселдән булуыма әзрәк үртәлеп тә утырдым әле. Сигезенче класслар уку елы азагына шигырь китабы әзерли дип ишеттем, әйдәгез, без «Кушаматлар китабы» әзерлибез. Ләкин китапны әзерли башлаганчы, миңа да берәр матур кушамат таксагыз иде, алайса мин керми калам бит, – дип, идеаль фикерен җиткерде.

– Кушабыз кәнишне, берне түгел, икене чәпибез әле, – диде Шәмси. – Ярый әле мин бар, мин булмасам, «Тәмәке тартуның зыяны» кебегрәк берәр темага әхлак дәресе тыңлап утырыр идегез. Әнә анда Диләрә үзенең телефонына барыгызны да яздырып бара, шуны компьютерга гына күчерәбез дә, китап та әзер була.

Соңгы сүзне Габбәзләр оныгы Динар алды.

– Безне «Габбәзләр» дип йөртәләр. Әтинең бабасы авылның зур кешесе булган, бөтен кеше аңа киңәшкә килгән, тапкырлыгы-уңганлыгы белән дан тоткан, – дип сөйли башларга да өлгермәде, классның төрле ягыннан тавыш купты:

– Шыттырма!

– Ялганчы!

– Ат карагы булган ул! Авылдагы атларны урлап, башка авылларда саткан, башка авыллардан урлап, безнең авылдагыларга сатып йөргән!

– Чын дөресен сөйләргә оятмы?!

Класста купкан шау-шуга укытучы йөгереп керде. Ыжгырып килгән машиналар кызыл утлы светофор каршында туктаганмыни – бөтенесе дә «тормозларына» басты. Кушаматлар турындагы китапны эшләү идеясен укытучыга әйтеп торуның да кирәге калмады.

Елак Гөлназның кәефен күрәм, дип, Габбәз Динары белән сүзгә килү яхшыга алып бармаячагын белгәнгә, әзрәк кәефсезләнде Шәмси. Укытучылары да бүгенге класс сәгате өчен башыннан сыйпамады. Эх, ничек матур башланган иде лә бит үзе, дип уйлады ул. Беренче дәрес математикага да соңлап кына керде һәм арткы партадагы үз урынына барып утыруы булды… чалбары юешләнгәнлеген тоеп алды, басып караса – урындыкта ватык йомыркалар. Күрше партадагы Динар, кыек тешләрен ыржайтып, «дәрестә килеш тә йомырка салып утырмасаң инде, тавык!» дип көлгәндә, Шәмси инде бәрәңге бакчасыннан гына өенә төшеп җиткән иде.

**Алинә БИКМУЛЛИНА**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Роберт МИҢНУЛЛИН**

## Күтәреп кенә йөрткәннәр

Язучылар сөйләшеп утыра. Шунда кайсыдыр, сүз иярә сүз чыгып, Мөдәррис Әгъләмовның башкорт телендә китабы чыгуы, аның үзенең шул уңайдан Уфага барып кайтуы турында хәбәр җиткерә.

Әлеге хәбәрне Галимҗан Гыйльман эләктереп ала:

– Әйе-әйе, хәбәре килеп җитте. Уфада Мөдәррисне күтәреп кенә йөрткәннәр.

Шунда Роберт Миңнуллин мыек астыннан гына елмаеп әйтеп куя:

– Булыр-булыр, башкортлар бик кунакчыл халык бит. Алар башта кунакны аяктан екканчы сыйлыйлар да аннары үзләре үк күтәреп йөрергә мәҗбүр булалар.

## Концерттан соң

Эстрада концертыннан соң бер төркем депутатлар фикер алышып утыра. Бер яшь җырчы турында да сүз чыга:

– Ну киенеп тә куйган, әй!

– Амазонкалар кебек!

– Кыйммәтле кием икәне әллә каян күренеп тора!

– Кайсыдыр спонсор киендерәдер инде аны?

Роберт Миңнуллин боларны тыңлап тора да бик белдекле кыяфәт белән:

– Кем чишендерә, шул киендерә инде аны, егетләр! – дип, сүзгә нокта куя.

## Ике кешелек бүлмә

Язучылар «Татарстан» поездында Мәскәүгә язучылар съездына китеп баралар. Купелар шау-шудан, мәзәкләрдән, уен-көлкедән гөр килеп тора. Мәскәүдә әйбәтләп каршы алачаклар. «Россия» кунакханәсендәге урыннар да билгеле, ике кешелек бүлмәләргә кем белән кем керәсе дә мәгълүм. Атаклы Мөхәммәт Мәһдиев белән яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев бер бүлмәгә туры килгәннәр. Студент кызларны яратучы Мәһдинең матур гадәтләрен яхшы белгәнгә күрә, барысы да Мансурдан көлә башлыйлар.

– Ну эләккәнсең, Мансур!

– Да, сиңа не повезло!

– Сиңа коридорда йокларга туры киләчәк инде!

Мәһди – канәгать, Мансур дәшми генә тыңлап бара...

Язучылар кунакханәгә килеп урнашалар, съезд эшендә катнашалар. Арып-талып кайткач, бәйрәм итәргә дә өлгерәләр.

Кич белән бик соңлап кына язучылар коридорда Мәһдине очраталар.

– Нигә кереп ятмыйсың, Мөхәммәт, соң бит инде?

– Бик ятар идем дә, бүлмәгә керә алмый йөрим. Мансур – сабакы малай – кем беләндер кереп бикләнгән бугай, ачмый да ачмый. Мондый гадәте барлыгын белсәм, мин аның белән бергә керми дә идем. Сез дә әйтмәдегез...

Икенче көнне дә шул ук хәл кабатлана.

– Нигә кереп ятмыйсың, Мөхәммәт абый, соң бит инде?

– Бик кереп ятар идем дә, бүлмәгә кереп булмый. Мансур – сабакы малай – бүген дә кем беләндер кереп бикләнгән бугай, ачмый да ачмый... Мондый гадәте барлыгын белсәм, мин аның белән бергә керми дә идем. Сез дә әйтмәдегез.

Шушы вакыйгадан соң Мансур Вәлиев белән Мөхәммәт Мәһдиев командировкалар вакытында бервакытта да бер бүлмәгә кермәгәннәр.

## Тәңгәлләштерү

Радиодан халык депутаты Разил Вәлиев сөйли. Сорауларга җаваплар бирә:

– Әйе, без Конституциябезне дә, законнарыбызны да Россиянеке белән тәңгәлләштереп бетердек. Суверенлыгыбыздан берни дә калмады...

Шуннан соң Р.Вәлиев сүзләренә язылган «Ватаным» исемле җыр яңгырый...

Ярый әле җырларны, шигырьләрне тәңгәлләштерергә кушмыйлар. Югыйсә бик күп шигырьләрне үзгәртеп язарга туры килер иде.

**К.ШӘЛЕ**

## Штрафниклар

«Казан утлары» журналында «планёрка» башланырга тора. Тынлыкны, гадәттәгечә, Камил Кәримов боза:

– Әгерҗегә – авыл бәйрәменә бардык. Кайтып, машинаны куярга өлгермәдем, ГАИдан хат килеп төште.

Көр күгәрчен гөрелдәвен хәтерләткән көлемсерәү белән, Фирүзә Җамалетдинова сүзгә кушыла:

– Һи, Камил абый, машина нәрсә ул, менә Газинур Морат җәяү йөреп тә бер көндә ике штраф түләде.

Баш мөхәррир Рөстәм Галиуллин, нәтиҗә ясарга теләгәндәй, өстәп куя:

– Штраф түләмәскә Ркаил Зәйдулладан өйрәнегез. Җәяүлеләр сукмагыннан чыкмаган өчен, патруль сержанты протокол тутыра башлый. «Исемең ничек?»кә: «Гомәр, – ди. – Фамилиям – Бәширов». Әтисенең исемен сорагач, Ркаил агай Гомәр Бәшировның отчествосын искә төшерә алмый да: «Атамны сатмыйм!» – ди.

Өч көннән Язучылар берлегенә – Гомәр Бәшировка мең сум штраф килеп төшә. Әллә кайчан арабыздан киткән Гомәр Бәшировка штраф түләтмәс өчен, идарәдә бәхәс туа.

**Рамил ХАННАНОВ**

## Нуриев песиләре

Юлында очраган һәр кызга көлтә-көлтә чәчәк бүләк итеп йөрүче Вакыйф Нуриевның көннәрдән бер көнне ике әнкә песие чирләп китә (күрәсең көнләшүдәндер инде, алар да хатын-кыз женесеннән бит!). Берсен ветеринарлар җиде меңгә дәвалый, ә икенчесенә, гомумән, операция ясатырга туры килә. Әлеге хикмәтле процедура унбер меңгә баса.

Шулай итеп, койрыкнисалар аркасында Казанның күпме кызы хушисле чәчәк бәйләменнән мәхрүм кала.

Вакыйф Нуриев Казан кызларына карата бу кадәр юмарт кыланмаса, песиләрнең әле чит ил клиникаларында дәваланырга да мөмкинлеге зур иде...

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### АВГУСТ КИҢӘШМӘСЕ

Кукмарада Татарстан мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең республикакүләм август киңәшмәсенең пленар утырышы булып узды. Анда Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов доклад белән чыкты. Киңәшмә эшендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул белем һәм тәрбия бирүдә республикабыз мәгариф хезмәткәрләре алдында яңа бурычлар куйды, милли дәүләт телләрен укытуга һәм аларны өйрәнүче укучыларга, аларның ата-аналарына аеруча игътибарлы булу зарурлыгын искәртте. «Тел – аралашу чарасы гына түгел, милләтнең тарихы, дөньяга карашы да», – диде Рөстәм Миңнеханов.

### МӘСКӘҮДӘ – ТАТАРСТАН МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Быел Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре сигезенче тапкыр үткәрелде. Көтеп алынган, Мәскәү һәм республикабыз җитәкчеләре катнаша торган бу бәйрәмгә чит илләрнең Россия башкаласындагы дипломатик вәкилләре дә чакырылган иде. Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәрен шәһәр үзәгендәге Халыкара музыка йортында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Мәскәү мэры Сергей Собянин ачып җибәрде. Алар Татарстан белән Мәскәү арасындагы икътисади, социаль, мәдәни хезмәттәшлекнең югары дәрәҗәдә булуын билгеләп үттеләр. Тантанада Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов та катнашты. Язучылар күренекле халыкара журналист Фәрит Сәйфел-Мөлековка һәйкәл (авторы – Рим Акчурин) ачу тантанасында да катнаштылар. Мәскәү татарларының милли үзәге – Асадуллаев йортында Казаннан килгән әдипләребез, шулай ук Мәскәүдә яшәп иҗат итүче язучы Ринат Мөхәммәдиев катнашында зур әдәби кичә үткәрелде.

### ФОРУМ

Казанда «Корстон» комплексында Милли һәм төбәк гаммәви мәгълүмат чараларының VII форумы узды. Анда Россиянең 19 төбәгеннән 200 кеше катнашты. Форумның пленар утырышын «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов ачып җибәрде. Әлеге чарада сүз милли һәм төбәк гаммәви мәгълүмат чараларының торышы, үсеш мөмкинлекләре турында барды. Пленар утырышта ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе урынбасары Михаил Ипатов, Россия Журналистлар берлеге рәисе Владимир Соловьёв, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова һ.б. рәсми затлар катнашты, чыгыш ясады. Форумда Минтимер Шәймиев туган телләр мәсьәләсенә карата да фикерен белдерде. Аның сүзләренә караганда, милләтара мөнәсәбәтләр проблемаларына, аеруча туган телләргә бәйле мәсьәләләргә бөтенләй кагылырга кирәк түгел иде. Шул көнне Россия һәм Татарстан Журналистлар берлекләре арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелде. Пленар утырыштан соң танылган журналист, Россия телевидениесенең тарихи-публицистик программалар дирекциясе директоры Леонид Млечин мастер-класс үткәрде.

### ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Казандагы 1 Май мәйданында моннан 74 ел элек фашист төрмәсендә җәзалап үтерелгән Муса Җәлил һәм җәлилчеләр Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш, Фоат Сәйфелмөлеков, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаровларны искә алу мәрәсиме булды. Анда ТР мәдәният министры урынбасары Светлана Персова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Муса Җәлилнең кызы Чулпан Җәлилова чыгыш ясады. Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, шагыйрьләр – Газинур Морат, Гөлүсә Батталова үзләренең шигырьләрен укыдылар. Искә алу мәрәсиме бер төркем иҗат яшьләре катнашында театральләштерелгән тамаша белән үрелеп барды.

### ЮБИЛЕЙ

Филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Мирфатыйх Зәкиевкә 90 яшь тулу уңаеннан, галимнең туган төбәге – Ютазы районында тантаналы чаралар булып узды. Юбилейга

галимнең рус телендә биш томлык хезмәте басылып чыкты. Төп вакыйга район үзәгендә әле яңа гына төзелгән гимназиянең Актлар залында үтте. Бәйрәмдарны район хакимияте башлыгы Рөстәм Нуриев, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты исеменнән профессор Фоат Галимуллин котлады. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты котлавын директорның фәнни эшләр буенча урынбасары Олег Хисамов, Чаллы педагогия университетының Рәхмәт хатын филология фәннәре докторы Әнвәр Шәрипов тапшырды.

### ШИГЫРЬ ҺӘМ ҖЫР САБАН ТУЕ

Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Миңнуллинга 70 яшь тулу уңаеннан, аның туган ягында – Башкортстан Республикасы Илеш районының Шәммәт авылында «Шигырь һәм җыр сабан туе» узды. Әүвәл авылның иске зиратына истәлек билгесе куелды, аннары каенлыкта әдәби-музыкаль чара уздырылды. Әлеге чараларда Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, Татарстанның халык язучысы Фоат Садриев, шагыйрь, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Ленар Шәех, шагыйрь, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире Фидаил Мәҗитов, прозаик, «Көмеш кыңгырау» газетасының баш мөхәррире Факил Сафин, прозаик, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, шагыйрьләр Газинур Морат, Мөхәммәт Мирза, Рафис Корбан, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, галим, шагыйрь Равил Рахмани, прозаик Галимҗан Гыйльманов, Башкортстан ягыннан мәдәният министры урынбасары Ранис Алтынбаев, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Зәки Алибаев, Башкортстанның халык шагыйрьләре Кадим Аралбай, Хәсән Назар һ.б.лар катнашты. Кунакларны Илеш районы хакимияте җитәкчелеге каршы алды һәм озатып йөрде.

### ФӘЙЗУЛЛИН ЙӨЗҮЛӘРЕ

Традицион «Фәйзуллин йөзүләре»нең кырыгынчысы булды. Монысы Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинга 75 яшь тулуга багышланды. Йөзүчеләр Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов туган Кече Өчиле авылы (ул бүген юк инде) каршындагы «Ахун чишмәсе»ннән туена торган киң буада ярыштылар.

Башта Казаннан һәм Мәскәүдән килгән кунакларны, ярышны оештыручыларны Арча районы хакимияте башлыгы Илшат Нуриев кабул итте. Әдәбият һәм спорт бәйрәменә җыелган халыкны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Арча районы башкарма комитеты рәисенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Рамил Гарифҗанов сәламләде. Быелгы ярышларда яшьләрнең дә күп булуы сөендерде. Җиңүчеләр – Арча педагогия көллияте укучылары һәм, әлбәттә, уллары Алмаз (ул бу бәйрәмгә Мәскәүдән махсус кайтты) һәм Газиз белән Р.Фәйзуллин үзе. «Татарстан – яңа гасыр» телевидениесенең баш мөхәррире Данил Гыйниятов, хатын-кызлардан шагыйрә Илсөяр Иксанова, Татарстан китап нәшрияты мөхәррире Наилә Зыятдиновалар да сынатмады.

### ГАЛИМ ДӘ, ЯЗУЧЫ ДА

Сүз филология фәннәре докторы, профессор, язучы-прозаик Тәлгат Галиуллин турында бара. Аңа 80 яшь тулу уңаеннан, ТР Фәннәр академиясенең зур залында узган юбилей тантанасында бәйрәмдарны республика вузлары җитәкчеләре, галимнәр белән бергә каләмдәшләре – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, юбилярның җәмәгате Фәүзия Галиуллина (шагыйрә Фәүзия Солтан) һ.б. котлады. Тантананы ТР Фәннәр академиясенең вице-президенты, шулай ук Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Дания Заһидуллина алып барды.

### ЯЗУЧЫНЫ ЯКТАШЛАРЫ КОТЛАДЫ

Язучы-прозаик Вакыйф Нуриевка 60 яшь тулуны туган ягы – Арчада билгеләп үттеләр. Башта бәйрәмдар 2 нче мәктәптә районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашты. 6 нчы мәктәпнең Актлар залында район үзәк китапханәсе хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән әдәби кичә булды. В.Нуриевның тормыш һәм иҗат юлы турында «Казан арты» тарих-этнография музее директоры урынбасары Шәфигулла Гарипов сөйләде. Район башкарма комитетының мәдәният идарәсе җитәкчесе Рамил Мөхетдинов Арча районы хакимияте башлыгы Илшат Нуриев котлавын ирештерде. Язучыны котларга туган авылы Сеҗедән авыл җирлеге башлыгы Гөлфия Гыйбадуллина җитәкчелегендәге делегация килгән иде. Район үзәгендәге әдәбият һәм сәнгать музеенда Вакыйф Нуриевның иҗатына багышланган күргәзмә ачылды.

### ӘБУНӘЧЕЛӘРГӘ – БҮЛӘКЛӘР

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятендә 2018 елның икенче яртысына газета-журналларга язылуда активлык күрсәткән әбунәчеләр арасында бүләкләр уйнатылды. Әлеге акциядә 120 кеше катнашты. Бүләкләрнең иң зурысы – «SAMSUNG» телевизорына Яшел Үзәннән Рамил Тимергалиев ия булды. Бүләкләнүчеләр арасында Чаллыдан галимә, шагыйрә Рәзинә Мөхияр да бар.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: исторический роман Ф.БАЙРАМОВОЙ «Гулейза», рассказ М.МАЛИКОВОЙ «Плод сладкой любви», новелла Ф.ЗИЯТДИНОВА «Если этот человек погибнет...»; стихи Г.РАХИМА, Р.ИДИЯТУЛЛИНА, Ф.СУЛТАН;*
*Н.ХИСАМОВ «В своих чувствах я свободен...» (обзор поэзии Ф.СУЛТАН).*
*Литературный конкурс «Достояние»: повесть А.ЗАРИПОВА «Мост».*
*«Новые имена»: стихи Р.ШАЙДУЛЛИНОЙ-МУРАТ.*
*Рассказ Р.АГЛЯМУТДИНОВА «Перекрёсток».*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Литературное наследие»: стихи А.АЛИША.*
*«Юбилеи»: Ф.ХУЗИН. «Великая личность» (80 лет Р.ЮСУПОВУ).*
*«Литературная критика»: З.МАНСУРОВ «Настроить музыку души».*
*«История»: статьи А.МАКСУДИ (со вступительным словом Л.ГУБАЙДУЛЛИНА).*
*«Наш календарь»: 100 лет со дня рождения В.МИНКИНОЙ.*
*«Юмор-сатира»: юморески И.ХАЙРУЛЛИНА.*
*«Белый парус»: рассказы А.БИКМУЛЛИНОЙ.*
*«Страницы юмора».*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Хлеба созрели». Картина Лутфуллы Фаттахова; режиссёр, член Союза писателей Татарстана Ахтам Зарипов.*
*Фото Ленара Губайдуллина.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: historical novel by F.BAYRAMOVA «Guleyza», story by M.MALIKOVA «The fruit of sweet love», novel by F.ZIYATDINOV, «If this man dies...»; poems by G.RAHIM, R.IDIYATULLIN, F.SULTAN;*
*N.KHISAMOV «In my feelings I'm free...» (review of the poetry by F.SULTAN).*
*Literary contest «Heritage»: story by A.ZARIPOV «The bridge».*
*New names: poems by R.SHAYDULLINA-MURAT.*
*Story by R.ISLAMUTDINOV «Crossroads».*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«Literary heritage»: poems by A.ALISH.*
*«Jubilees»: The Great personality (R.YUSUPOV is 80 years old).*
*«Literary criticism»: Z.MANSUROV, «Set to the music of the soul».*
*«History»: article by A.MAKSUDI (introductory remarks by L.GUBAYDULLINA).*
*«Our calendar»: 100th anniversary of V.MINKINA.*
*«Humor-satire»: humoresques by I.KHAYRULLIN.*
*«White sail»: stories by A.BIKMULLINA.*
*«Pages of humor».*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Bread is ripe». Picture by Lutfulla Fattakhov; director, member of the Union of writers of Tatarstan Akhtam Zaripov.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Игеннәр өлгерде».
*Лотфулла Фәттахов (бу айда аның тууына 100 ел) картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* режиссёр, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Әхтәм Зарипов. *Ленар Гобәйдуллин фотосы.*